# казан утлары

1

ЯНВАРЬ · 1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

1

ЯНВАРЬ
1970


## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ


К. ЭРЕНДЖЕНОВ. Ленинда кунакта. Шигырь . . . 3
Х. АЛИМҖАН. Онытылмас көн. Шигырь . . . 4
Г. ГАРАИ. Разливтагы исемсез кеше. Шигырь . 6
М. ЗОЩЕНКО. Ленин турында хикәяләр . . . 7
З. НУРИ. Ленинга — чәчәкләр. Репортаж . . . 14
А. МӨСЛИМОВ. Соңгы юлга. Очерк . . . . 29


РОМАН, ХИКӘЯ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР


С. ХӘКИМ. Васыятьләр. Поэма . . . . . . . 36
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Урамнар артында яшел болын. Роман . . . . . . . . . . . . . 45
Р. ГАТАУЛЛИН. Төрле дәфтәрләрдән. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 115
Г. РӘХИМ. Туган як имәннәренә. Тегермән. Шобагалар. Күзләреңне кара димәдем. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 122
Н. ХАЙТОВ. Хикмәтле хикәяләр . . . . . . 125


ДУСЛАР ҖЫРЫ


Е. ЩЕКАЧЕВ. Аучылар. Кара төндә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 138


М. МАКСУДКА 70 ЯШЬ


А. ШАМОВ. Зур тормыш . . . . . . . . 139


БЕЗ ҮТКӘН ЮЛЛАР


Ф. ИБРАҺИМОВА. Балалар әдәбияты, аның уңышлары . . . . . . . . . . . . 144


ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР


Э. СӘГЫЙДОВА. Тукайның ике җыентыгы . . 150
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Шагыйрьнең тагын бер рәсеме . . . . . . . . . . . . . 156



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ҖӘҮДӘТ ФӘЙЗИГӘ 60 ЯШЬ

З. ХӘЙРУЛЛИНА. Көрәш һәм җиңү җырлары. 157
Җ. ФӘЙЗИ. Халык җәүһәрләре . . . . . . . 159

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ. Башкортстан татарлары җырлый . . . . . . . . . . . . . 170

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Шкфалы яңгыр . . . . 174

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ф. ВӘЛИЕВ. Борынгы архитектурабыз . . . . 177

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Х. САРЬЯН. Финал. Хикәя . . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 5/XI-1969 ел. Басарга кул куелды 24/XII-1969 ел. ПФ 09059. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,3. Басма табак 12(16,8). Тираж 86246 экз. Заказ В-577. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1970 ел.




# *ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

**Константин Эренджэнов.**
Калмык шагыйре

## Ленинда кунакта

Калмык даласында адашып мин
Аера алмый уңым-сулымны,—
Гомер буе йөргән булыр идем
Табалмыйча барыр юлымны.
Кардәш санап, Ильич кулын сузды
Һәм мин суздым аңа кулымны.

...Бүлмәсендә аның басып торам,
Урын-җире минем каршымда:
Мамык белән сырган гади матрац —
Уңа төшкән юрган астында.

Күл суында йөзгән аккош төсле
Ак мендәре Аның килеренә
Ышангандай әле дә көн-төн көтә,
Тик ул һаман килми бирегә.

Кара савыты... Ильич каләменә
Беркайчан да хыянәт итмәгән.
Күпме еллар үткән, савыттагы
Зәңгәр кара барыбер кипмәгән.

Өстәлендә Аның җиделе лампа...
Янып тора гүя бүген дә.
Алҗыса да Ильич, йокысын онытып,
Тынмый эшли төннең-төнендә.

Лампа яна... Җыйнак бүлмә эче
Шуның нуры белән җылына.
Илем үзенең бөтен яктылыгын
Өсти бүген аның нурына.

Тумбочкада көзге... Крупскаяга аны
Бирәр солдат алып килгәндер.
Туган көне белән котлап, аңа
Истәлеге итеп биргәндер.

Шул көзгедә аның, әйтерсең лә,
Елмаюлы йөзе чагыла.
Шул көзгедән күрәм: Ильич үзе
Атлап килә минем яныма.

Кузгалырга кыймый басып торам,
Үзем шуны уйлыйм эчемнән:
Миңа кадәр күпләр булып киткән
Бу бүлмәдә гүя ата-бабам
Озак еллар гомер кичергән.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәсе

## Хәмид Алимҗан.

Үзбәк шагыйре

## Онытылмас көн

*Сәмәркандта 1924 елның 21 гыйнвары*

Ул көнне мин саклыйм гел күңелдә,
Истә әле ул чак бүген дә:
Ләкләк кебек бөтерелеп очты
Кар һәр җирдә һәм күк йөзендә.
Агачларга җепшек кар сыланды,
Куаклыклар күмелеп калдылар,
Карны ера-ера аксакаллар
Киң мәйданга сукмак салдылар.
Карлы бакча, көртле кыр-даладан,
Кышлаклардан килде балалар.
Карга бата-бата ашыктылар
Пәрәнҗәне ташлап аналар.

Нинди хәбәр икән, һәр йөрәккә
Уктай үтеп керде кинәттән?
Өлкән кеше мәйдан янында,
Сорау бирде халык алдында:
«Аңлат, улым,— диде чал карт ата,—
Халык шулай кемне озата?
Сәмаркандта вафат булмаган ул,
Үзе безнең якта тормаган,
Нигә яшьле кеше күзләре,
Ник кайгылы кеше йөзләре?»

Улкаен да авыр кайгы баскан:
«Җир тиңсез зур кеше югалткан,—
Ленин үлгән,— диде егет аңа,—
Чиксез кайгы килде дөньяга.
Моңа кадәр җирдә кем тумаган,
Нинди хәким, батыр тормаган?!.
Ленин кебек кыю, зур акыллы,
Даһи кеше ләкин булмаган.
Ленин күреп йөргән ул барын да:
Тормышның зур китапларын да,
Кансыз патша зинданнарында
Үзе газап чиккән чагында,
Җәберләнгән ярлы зарын да
Ул бик яхшы белгән, ишеткән.
Тиранлыкның кара терәген
Җимереп ташлап, биргән кирәген —
Истибдатны теткән, юк иткән.
Ленин эшчән кеше хакына
Багышлаган гомерен, йөрәген.
Ул юл салып бәхет дөньясына,
Бүләк итеп тормыш дәрманын,
Мәңге якты ирек кояшына
Җитәкләгән илләр кәрванын.
Исән булса, батыр Прометей да,
Богауларын өзеп, иректә,
Канлы таудан төшеп йөрер иде
Ленин йөргән чиксез киңлектә...»

Алар тагын алга үттеләр,
Мәйдан уртасына җиттеләр...
Йөрәк авыр кайгы кичерә,
Янып-көеп тибә, сикерә.
Кар туктаусыз ява, ишелә.
Күктә болыт һаман агыла...
Болытта да кайгы чагыла.
Ул көн һаман минем күңелдә,
Ул чак истә әле бүген дә.

МӨХӘММӘТ САДРИ тәрҗемәсе

## Габор Гараи.

Венгр шагыйре

# Разливтагы исемсез кеше

Иске рәсем:
Таныш түгел кемдер.
Ә мин, үзем белмим нилектән,—
Дәшсен генә!—
Шушы кемдер белән
Китеп барырмын күк кинәттән
Дустым итеп.
Йөзе — эшче йөзе.
Ихтыярлы, тыгыз ияге.
Ягымлы һәм кырыс иреннәрдә —
Көлемсерәү.
Кара гади күлмәк — кигәне.
Киң маңгаен буйсынмас чәч япкан..,
Күзләреннән аның ләкин мин,
Эчке яктылыктан кысыла төшкән
Күзләреннән таныйм:
Ул — ЛЕНИН.
Күнегелгән рәсеме дә түгел,
Ә париклы һәм ят киемле.
Ни әйтсәң дә, үзенә охшамаган.
Ләкин бу — ул. Әйе, ул инде.
Төс кенәме, аның асылы сыйнфый.
Сыйнфый хакыйкать бар аңарда.
Күңеле-уе белән бер бөтен ул
Миллионлаган массаларга да...
Инде беләм: бик еш әнә шундый,
Башкаларга күчкән Ленинны
Очратырмын авыр көннәремдә.
Бетмәс яктылыгы ул күзләрнең
Шиктән арындырыр күңелемне...
Берәр пролетарий,— белмим исемен,—
Аның белән алмашкандыр, ахры,
Иң-иң олуг хисен, җисемен.

Марс ШАБАЕВ тәрҗемәсе

*Михаил Зощенко*

# ЛЕНИН ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

## ЛЕНИНГА НИЧЕК БАЛЫК БҮЛӘК ИТКӘННӘР

Бервакыт Владимир Ильич Ленин үзенең Кремльдәге кабинетында эшләп утыра иде.

Өстәлдә стакан белән чәй. Бер савытта — сохари.

Ул елларда коточкыч ачлык иде. Халык нәрсә туры килсә шуны ашады. Бәрәңге кабыгы да, солы да ашадылар.

Ипи мәсьәләсенә килсәк — аны көненә берәр сынык кына бирәләр иде.

Билгеле, Ленин өчен иң әйбәт ризыклар да табып булыр иде. Ләкин ул үзе өчен мондый нәрсә эшләүне тыйды. Бөтен ил ачыкканда ул үзе өчен генә тук тормыш булдыра алмый иде. Ул хәтта чәйне дә шикәрсез эчте.

Менә шулай бервакытны Владимир Ильич Ленин эшләп утыра һәм тәнәфестә тамак ялгап ала: сохари белән чәй эчә.

Ишек ачыла да секретарь керә.

Ул Ленинга:

— Петроградтан балык эшләре буенча управляющий килде. Ул ничек кенә булса да сезне күрергә тели,—дип әйтә.

Ленин:

— Яхшы. Керә бирсен,— ди.

Һәм менә управляющий керә.

Ул — гади балыкчы. Балык промышленностеның эшен яхшырту максаты белән революция аны җаваплы урынга куйган иде. Һәм ул, үз эшен кайгыртып, балык тотуның ни өчен начар барганын аңлатырга Ленин янына килде. Көймәләрне рәтләргә һәм ятьмәләр сатып алырга акча кирәк. Югыйсә балык, совет ятьмәләрен көтеп тормастан, Англия суларына китә бара.

Менә управляющий Ленинга илдә балык юклыкның сәбәпләрен аңлата. Ул Ленинның язу өстәле янында басып тора. Һәм утырмый. Гәрчә Ленин, ике мәртәбә урындыкка күрсәтеп, утырырга тәкъдим итсә дә утырмый.

Ләкин ул утыра алмый иде. Аның артка куйган кулында зур гына төргәк. Төргәктә — ысланган балык. Бу — Владимир Ильичка бүләк.

Управляющий моны үзе ыслаган иде. Һәм Мәскәүгә ул аны Ленинга бүләк итәргә дип алып килде.

Билгеле, ул балыкны кабинетка керүгә бирермен дип хыялланган иде. Һәм ул көтелмәгән бүләк белән Ленинны гаҗәпкә калдырырга уйлап, төргәкне артына яшерде.

Ул хәтта бүләкне тапшырганда әйтәчәк сүзләрне дә алдан әзерләде: «Менә, кадерле Владимир Ильич, бу — сезгә. Рәхим итеп ашагыз һәм тазарыгыз»,— димәкче иде.

Ләкин кабинетка кергәндә балыкчы бераз гына курыкты һәм каушады, алдан әзерләнгән сүзләре хәтереннән чыкты һәм ул балыкны эш турында сөйләшеп бетергәч бирмәкче булды.

Һәм менә шуның аркасында төргәк аның артында калды.

Ул артында ысланган балыкны яшергән көе җайсыз гына басып тора һәм балык тоту ни өчен начар барганын Ленинга сөйли.

Ленин әйтә:

— Без сезгә акча бирербез. Һәм бөтен үтенечләрегезне канәгатьләндерербез. Ә сез инде, зинһар өчен, балыкны күбрәк тотыгыз, ач халыкның хәлен җиңеләйтерлек булсын.

Ленин балыкчы белән саубуллаша. Ә тегесе тәвәккәлләп кучтәначне өстәлгә куя да, әйтеп сала:

— Менә монда, Владимир Ильич... Бер балык тоткан идек... Менә дигән итеп ысладык...

Балыкчы кинәт кенә Владимир Ильичның кәефе кырылганын күрә. Ленинның хәтта йөзе җыерыла.

Балыкчы элеккедән дә бигрәк каушый һәм әйтә:

— Зинһар өчен, Владимир Ильич... Бүләкне кабул итә күрегез инде...

Ләкин Владимир Ильич балыкны алмый. Ул катгый рәвештә болай ди:

— Рәхмәт сезгә, иптәш, ләкин мин сезнең балыгыгызны ала алмыйм. Безнең илдә балалар ачыга. Сез аны ялгыш миңа китергәнсез.

Балыкчы бөтенләй аптырап кала. Тавышы чыгар-чыкмас:

— Кабып карагыз инде, Владимир Ильич. Менә дигән тәмле балык. Нәкъ суда йөзеп йөргәнен тоттык...— ди.

Балыкчы кинәт кенә Ленинның звонокка басканын күрә.

«Анакай гынам,— ди балыкчы эченнән генә,— нәрсә килеп чыга инде?»

Секретарь килеп керә.

Ленин аңа болай ди:

— Менә нәрсә: бу балыкны алыгыз да балалар йортына җибәрегез!

Балыкчының хәле чамадан тыш мөшкелләгән күреп, Владимир Ильич аңа кулын бирә һәм болай ди:

— Сезгә балалар исеменнән бу бүләк өчен зур рәхмәт белдерәм, иптәш.

Балыкчы Ленин белән саубуллаша һәм кабинеттан үз алдына сөйләнеп чыгып бара:

— Анакай гынам, хата ясадым бит...

# ЯЛГЫШУ





Ленин үзенең Кремльдәге кабинетында эшләп утыра иде. Шул вакытта аңа Наркомзем коллегиясе әгъзаларының исемлеге кирәк булып чыга.

Ул, исемлеккә тагын берничә хезмәткәрне өстәргә теләп, аны карап чыкмакчы була.

Чакыргач, Секретариатның дежурный хезмәткәре керә.

Ленин аңа:

— Миңа Наркомземның бөтен хезмәткәрләрен бирегезче,— ди.

Дежур хатын, бик гаҗәпләнгән кыяфәттә, ашыгып кабинеттан чыга. Кичә генә Наркомземның бөтен коллегиясе Ленин янында киңәшмәдә булган иде. Һәм менә бүген яңадан барысын да җыярга кирәк.

Дежур хатын коллегия исемлеген ала да, кичекмәстән Ленин янына килергә дип, барысына да телефон шалтырата башлый.

Ләкин коллегия әгъзалары бик күп һәм аларга хәбәр итеп чыгу өчен кимендә ярты сәгать кирәк иде.

Менә безнең бу дежур хатыныбыз ах-вах килеп телефон борып утыра.

Шулвакыт кинәт кенә Ленин кабинетыннан өч тапкыр звонок чылтырый. Бу — Ленин үз янына секретарьны чакыра дигән сүз.

Секретарь Фотеева шунда ук кабинетка йөгерә.

Ленин кырыс кына аңа болай ди:

— Безнең секретариатта нәрсә эшләгәннәрен мин аңлый алмыйм. Мин Наркомзем коллегиясе әгъзаларының исемлеген сораган идем. Менә унбиш минут үтте инде, исемлек әле һаман да юк.

Иптәш Фотеева секретариатта бик уңайсыз аңлашылмаучылык чыкканын белә: исемлек кертеп бирәсе урында, дежур хатын бөтен коллегияне Ленин янына чакырып ята.

Дежур хатын Ленинга хезмәткәрләр түгел, ә исемлек кенә кирәк икәнен белгәч елап җибәрә. Шундый аңлашылмаучылык чыкканга, ул бик гарьләнә. Бу хәл өчен ул үзенә эләгер дип уйлый.

Фотеева исә кирәкле кәгазьләрне алып кабинетка керә һәм нәрсә булганын көлә-көлә сөйли башлый.

Ул, андый комик хәлне ишетеп, Ленин да аның белән бергә көләр дип уйлый.

Ләкин Ленинга карап ул сизеп ала: Ленин кашларын җыерган һәм нидәндер риза түгел.

Ленин уйга калып үзенә-үзе болай ди:

— Мин шулай ук аңламаслык итеп әйттемме икәнни? Әйе, чыннан да мин шулай дидем: «Миңа бөтен коллегияне бирегез».

Иптәш Фотеева Ленинга:

— Владимир Ильич, сез, зинһар өчен, безнең хезмәткәрләрне гафу итегез. Ул әле тәҗрибәсез кеше. Бездә күптән түгел генә эшли башлады,— ди.

Ленин аңа:

— Һәм ул гаепле дә түгел. Бу — минем хата. Мин үз фикеремне төгәл әйтмәгәнмен. Гаеп — миндә,— ди.

Фотеева бу турыда чыгып сөйләгәч, яшь ханым шатлыгыннан нишләргә дә белми.

Ул күз яшьләрен сөртә. Аннан көлеп җибәрә. Һәм Фотеевага болай ди:

— Беләсезме нәрсә, мин узган ел бер канцеляриядә машинистка булып эшләгән идем. Канцелярия начальнигы бервакыт миңа ялгыш

җөмлә әйтеп яздырды. Үзенең хатасын таныды дип уйлыйсызмы? Юк шул, әле миңа җикеренде, ялгышны миңа сылтады һәм мине эштән куу белән янады. Мин шуннан соң атна буе еладым. Шул хәтле хурландым... Ә бүгенгесе үземнең ахмаклыгым аркасында булды. Ленинның шундый гадел кеше икәнен белми идем мин.

Иптәш Фотеева аңа болай ди:

— Юк, бу — гаделлек кенә түгел. Үз хатаңны тану, аны кешегә сылтамау — кеше характерының, ихтимал, иң сирәк очрый торган гүзәл сыйфатыдыр. Ләкин сезгә дә еламаска кирәк иде: тормышның барлык очракларында да түзем була белергә өйрәнергә кирәк.

Ул арада Наркомзем коллегиясенең чакырылган әгъзалары җыела башладылар. Ялгышлык аркасында чакырылганнарын белгәч, әлбәттә, кәефләре кырылды.

Ләкин хезмәткәрләрдән берсе:

— Юк, мин ялгышлык белән килүемә бер дә үкенмим. Ләкин менә бүген мин Ленин белән очраша алмадым — анысы кызганыч,— диде.

Башка хезмәткәрләр дә бу фикер белән килештеләр һәм таралыштылар.

## КАЙЧАК КАРА САВЫТЫН ДА АШАРГА МӨМКИН

Патша төрмәсендә Ленин нәкъ ундүрт ай утырды.

Ул — бер кешелек ярым караңгы камера иде. Анда булган бөтен җиһаз — тимер койка, өстәл һәм урындыктан гыйбарәт.

Ленин урынында башка кеше булса, бу камерада көннәр буе сыкранып ятыр иде. Ләкин Ленин мондый кеше түгел иде.

Ул монда да көннәр буе эшләде.

Иртән ул гимнастика ясый, аннан үзенең яза торган китабына керешә. Ул монда бик әһәмиятле революцион әсәрен— «Россиядә капитализмның үсеше»н язды. Дөресрәге, монда ул үзенең булачак әсәре өчен материал җыйды, күчермәләр ясады. Һәм, барысы өстенә, монда ул революционерларга хатлар язды, партиянең программасын эшләде.

Төрмәдә боларны эшләү бик үк ансат эш түгел иде.

Туган-тумачаның аңа китап җибәрү хокукы бар иде. Ленин әнә шул китапларга язды. Ләкин бу китапларга язганны төрмәдә берәү дә сизмәскә тиеш иде. Чөнки туганнарына кайтарып биргәндә бөтен китапларны тикшереп чыгаралар. Әгәр китапка бер генә революцион сүз язылган булса да, аны яндыралар.

Әмма революционерлар сөт белән язу ысулын беләләр иде.

Әгәр кәгазьгә сөт белән язсаң — берни дә күренми.

Язылганны уку өчен кәгазьне лампа яки шәм янында кыздыру җитә. Ул чагында кәгазьдәге сөткә төс керә, хәрефләр кызгылт-чия төсен алалар һәм язылганны укып була.

Ленин китап кырыена һәм юл араларына нәкъ менә шулай яза. Туганнары исә бу турыда беләләр. Алар төрмәдән чыккан китапны алуга аның һәр битен лампа янында кыздыралар, язганны укыйлар һәм күчереп алалар.

Ленин төрмәдә шулай эшли.

Ләкин моны эшләү дә бик зур саклык таләп итә. Әгәр моны надзиратель күрсә, эш бик начар булыр иде. Ул чагында авыру буларак Ленинга сөт бирүне дә туктатырлар иде. Әле җәза да бирерләр иде.

Ә надзиратель камерага бик еш керә. Яки тоткынның нәрсә эшләгәнен тишектән карап тора.

Ленин мондый нәрсә уйлап таба. Ул ипидән кара савыты ясый, аңа сөт сала һәм каләмен шуңа манып ала. Һәм шулай итеп яза.

Менә бервакыт надзиратель шыпырт кына тишектән карап тора һәм бик гаҗәп хәл күрә: Ленин китап кырыена язып утыра.

Надзиратель тиз генә ишекне ача, камерага керә һәм болай ди:

— Сез эләктегез. Минемчә, сез китап кырыена әле генә нәрсәдер язып утыра идегез.

Надзиратель китапка карый һәм күрә: китап чиста көе. Ул кара савытын алып карамакчы була, ләкин шул вакытта Ленин кара савытын тыныч кына авызына каба һәм чәйни башлый.

Надзиратель:

— Сез нишлисез? Сез бит кара савыты ашыйсыз! — ди.

Ленин аңа:

— Сез, ихтимал, сукырайгансыздыр. Бу — кара савыты түгел, ә ипи. Һәм менә мин аны ашыйм.— ди.

Надзиратель күрә: чыннан да ипи. Болай дип уйлый: «Мөгаен, минем күзләр начарлангандыр. Ул кара савытын ашаган кебек күренгән иде бит».

Шулай уйланып ул китеп бара. Ә Ленин шул ук моментта ипидән тагын бер кара савыты ясый һәм сөт салып тагын яза башлый.

Һәм надзиратель камерага кергән саен Ленин кара савытын бик тыныч кына ашап бетерә бара. Бу хәтта тәмле дә була. Чөнки ипи белән сөт бит.

Төрмәдән чыккач, Ленин үзенең туганнарына һәм танышларына көлә-көлә болай дип сөйләде:

— Беләсезме, бер көнне минем эшем гел кирегә барды: ике сәгать эчендә миңа алты кара савыты ашарга туры килде.

Барысы да көлештеләр. Ә эшнең нәрсәдә икәнен аңламаган кешеләр гаҗәпләнделәр: ничек итеп инде ул кара савытын ашамак кирәк?

Ләкин кайвакытта кара савытын да ашап була икән шул.

# ФЕДОСЬЯ ТҮТИНЕҢ ЛЕНИН БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮЕ ТУРЫНДА



Федосья түтигә бәла килде. Аның ире үпкә шешү авыруыннан дөнья куйды.

Ә ул кеше калай түбә ябучы иде. Менә дигән итеп түбә яба белә иде һәм ярыйсы гына хезмәт хакы алгалый иде. Федосья түти хәтта шикәр белән чәй эчә иде.

Ире үлгәч, әлбәттә, аңа кыен була башлады. Чәй эчәргә шикәр дә бетеп китте.

Менә ул пенсия артыннан йөри башлады. Ләкин берни дә барып чыкмый. Аңа әйтәләр:

— Син пенсия алмаячаксың. Синең ireң Совет власте урнашкач бик аз вакыт эшләп калган.

Лəкин Федосья бу сүзлəргə игътибар итми һəм кайда да булса пенсия бирергə тиешлəр дигəн өмет белəн бик күп учреждениелəргə йөреп тора.

Ə бер учреждениедə аннан котылу өчен:

— Синең эшеңне бер генə кеше карый ала,— дилəр.— Ул — Ленин. Телисең икəн Ленин янына барып чык.

Федосья түти Ленинның Смольныйда яшəгəнен сорашып белə. Һəм шунда китə.

Билгеле, часовой аны кертмəскə маташа. Лəкин бəхетсез карчыкның начар фикер белəн йөрмəгəнен сизə, аны кызгана. Тəвəккəллəп уздыра да җибəрə.

Түти икенче катка күтəрелə. Коридор буйлап бара.

Бер бүлмəгə башын тыгып карый — берəү дə юк. Икенчесенə борын төртеп караса — күрə, өстəл артында берəү язып утыра.

Бу кеше Ленин була.

Түти, билгеле, аның Ленин икəнлеген белми. Ул моны берəр хезмəткəрдер дип уйлый.

Шуңа күрə, каушап-нитеп тормастан, болай дип сорый:

— Əфəндем, сез язу эше буенчамы, əллə тикшерүчеме? Əллə, бəлкем, сез хисаплап утыручыдыр?

Ленин көлемсерəп җавап бирə:

— Кайчан ничек туры килə бит. Кайвакытта язасың, кайвакытта тикшерəсең, ə кайчакта санарга да туры килə. Ə сезгə нəрсə кирəк иде соң?

— Ничек дип əйтергə инде, мин пенсия алырга йөрим,— ди түти.— Менə шуның аркасында инде мин Ленинның үзе белəн сөйлəшергə дип килдем. Минем хəлемне аңлап, мине Ленин янына кертсəгезче.

Ленин тагын елмая.

— Ə сез миңа юньлəп сөйлəп бирегез əле! Ихтимал, Лениннан башка гына хəл итеп куярбыз.

Карчык риза булмый.

— Юк инде, əфəндем, Лениннан башка берни дə чыкмас. Минем үтенечем бик катлаулы. Аны Ленин гына ерып чыга алачак.

Ленин аңа:

— Шулай да нəрсə булганын сөйлəгез əле,— ди.

Түти сөйли башлый.

— Минем тормышымның «географиясе» бик гади. Күптəн түгел генə минем ирем үлде. Ул түбə ябучы иде. Менə мин үземə пенсия сорап йөрим. Лəкин миңа барысы да, сиңа пенсия булмас, чөнки картың совет чорында бик аз вакыт эшлəп калган, дилəр.

Ленин əйтə, алар, ди, ахмак сүз сөйлилəр. Сезнең ирегез Совет власте чорында озак вакыт эшли дə алмый иде, чөнки Совет власте əле күптəн түгел генə оешты бит.

Ленин трубканы ала да кем белəндер сөйлəшə.

— Сезгə хəзер бер гражданка килер. Аңа пенсия бирергə кирəк,— ди.

Ленин шуннан соң Федосья түтигə болай ди:

— Коридор буенча барып, моннан өченче ишеккə керегез. Һəм шунда сезнең эшегез хəл ителер.

Бернинди өмете булмаган хəлдə Федосья түти күрсəтелгəн бүлмəгə китə. Лəкин анда, артык сорашып та тормыйча, пенсия кнəгəсе алу өчен Федосья түтигə язу бирəлəр.

Шул көнне үк түти пенсия ала һəм, шатлыгыннан нишлəргə белмичə, базарга бара, шикəр һəм мануфактура сатып ала.

Аннан соң ул, кер чайкаганда кирәк булыр дип, синька алмакчы була һәм кибеткә китә.

Кинәт ул бүген генә үзе белән сөйләшкән кешенең портретын кибет стенасында күреп ала.

Портретны күргәч, ул аптырап кала һәм кибет мөдиреннән сорый.

— Әфәндем, бу рәсемдә кем икәнен әйтә алмассызмы? Мин бу кеше белән бүген генә сөйләшкән идем, шуңа күрә сорашам.

Кибет мөдире:

— Әбекәй, андый очрашуның булуы мөмкин түгел,— ди.— Бу — Ленин.

Федосья:

— Алайса, мин Ленин белән сөйләшкәнмен икән инде,— ди.

Өенә кайткач, ул үзенең күргәннәрен управдомга сөйли. Һәм аңардан болай дип сорый:

— Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен Ленин миңа үзен танытмады икән?

Управдом уйга кала һәм болай җавап бирә:

— Төрле кеше була, анакай. Бер төрлеләре шапырыналар, мактаналар. Янәсе, без тегеләй итәбез, болай итәбез, без ялгыша торганнардан түгел. Ә бер төрлеләре кычкырынмыйлар, мактанмыйлар, борын күтәрмиләр, ә гап-гади генә — үз эшләрен җиренә җиткереп эшләп утыралар. Менә кешенең иң җүнлесе шундый була да инде. Һәм, анакай, синен андый кеше белән сөйләшүеңне чын күңелдән тәбрик итәргә генә кала.

Федосья түти авыр сулый.

— Һай, аның үзенең кем икәнен әйтмәве никадәр кызганыч! Мин аңа башымны иеп рәхмәт әйткән булыр идем.

**М. Мөхәммәт тәрҗемәләре.**

**Зәки Нури**

# ЛЕНИНГА—ЧӘЧӘКЛӘР

*Польша җирләреннән репортаж*

## Краков базасы



Жәй урталары. Нурның, яшеллекнең һәм чәчәкнең иң мул чагы. Тагын шунысы яхшы: революция күгендәге күкрәүләр дә ишәйгән, торган саен көчәя барган көннәр!

Алар, икесе янәшә басып, вагон тәрәзәсенә иелгәннәр. Бәләкәй паровоз, ерак юлда мин дә әлсерәдем дигәндәй, пыш-пыш итеп сулый-сулый, йөрешне әкренәйтә бара. Польшаның борынгы башкаласындагы тәбәнәк таш йортларны, ук манаралы чиркәү биналарын, тротуарлар буйлап тезелешкән һәм вокзал янындагы плянт-паркта хуш ис сирпегән канәферләр белән ясминнәрне күрү ничектер күңелле дә, рәхәт тә, сәер дә.

Ниһаять, алар Краковта.

Илдән илгә күченеп (бу юлы Париждан) әле һаман эмиграциядә яшәүне дәвам итәргә тиешле бу пассажирларның берсе — Владимир Ильич, икенчесе Надежда Константиновна була.

Плянтта Ленинны, гәрчә моңарчы үзен күреп белмәсә дә, Сергей Багоцкий көтә. Ульяновлар киләсен белдереп, аларны каршыларга, урнаштырышырга кирәклеген әйтеп язылган хат Франциядәге дуслардан килгән. Сергейның үсмер чагы Плоцкида үткән. Полякчаны шәп белә. Киевта укыганда аны РСДРП членлыгына кабул итәләр һәм Варшава гарнизонында партия эше алып бару өчен 1904 елда Польшага җибәрәләр. Шул чакны ул Феликс Дзержинский белән дуслаша, Варшавада хәрби-революцион оешма члены була. Ә 1905 елда — кулга алыну, дүрт ел каторгадан соң — Себернең Балаган өязендә сөрген... Шуннан качып, ул 1910 елда Галициягә кайта. Краковка килеп урнаша, «Политик тоткын» исемле журнал чыгара, тоткындагы һәм сөргендәгеләргә ярдәм оештыру буенча Краков союзының секретаре булып эшли башлый. Университетның медицина факультетында укый.

Кара эшләпәле Ленин белән өсте-башына шулай ук бик гади киенгән Крупскаяны ул, шундый тынгысыз сәяхәтләрне үзе дә кичкән кеше буларак, эчке сизем белән бик тиз танып ала. Куанычтан көлешеп танышалар һәм гомер-гомергә дуслашалар.

Владимир Ильичның Польша турында шактый мәгълүматы бар, аның поляк дуслары моңарчы да күп була, әлбәттә. Инде 900 яшен тутырып килгән пястлар дәүләте ул чакта, сәяхәтче Ибраһим ибн Якуб язганча, славян илләренең иң зурларыннан берсе

санала. Аның нигез салучысы һәм беренче князе Мешко исемен белмәгән кеше юк. Европада беренчеләрдән булып, Краковта 1364 елда ук инде Казимир Великий оештырган Академия ачыла. Заманының беренче бөек астрономы, «кояшны туктатып, җирне урыныннан кузгатасы» Торун егете Николай Коперник шунда укыган... Поляк телендә иҗат итә башлаган беренче язучы Рей. Шведларга каршы сугышта тәүге тапкыр партизаннар тактикасын кулланган гетман Стефан Чарницкий. Беренче философлардан һәм җәмгать эшлеклеләреннән Станислав Сташиц... Ниһаять, Европада беренче булып үз конституциясен кабул иткән ил — халык күтәрелешен, халык армиясен оста оештыра белгән Костюшколар белән Домбровскийлар Польшасы... Азатлык җырчысы Мицкевичны, һәр авазы «чәчәкләр эченә яшерелгән туп сыман» булып яңгыраган Шопенны үстергән уңдырышлы җирләр...

Польшага килеп төшкән бу көнендә Ленин «Борынгы... Күптәнге... Данлыклы... Беренче...» дигән эпитетларны шулай алга куеп бик күп исемнәрне, вакыйгаларны һәм фактларны күңеленнән кичергәндер, әлбәттә.

Поляк эшче сыйныфының беренче революцион партиясе «Пролетариатны» оештырган Людовик Варынский Ленинга күптән һәм бик яхшы билгеле. Шушенскоедагы сөргендә ул революционер поляклар Феликс Кон, Ян Проминский белән күп мәртәбә күрешә. Алар анда ауга да бергә йөриләр. 1905 елдан соң Ленин Польша эшчеләр хәрәкәтенең күренекле оештыручылары һәм эшлеклеләреннән Роза Люксембург, Феликс Дзержинский белән якыннан таныша, алар да Ленин җитәкләгән көрәшкә катнашып киләләр. Әле узган елны гына Лонжюмодагы партия мәктәбендә укыганда очраткан революционер Эдвард Прухняк та искә төшә. РСДРПның IV һәм V съездлары делегаты булган Якуб Ганецкий белән очрашулар алда әле. Польша һәм Литва социал-демократлары Краковта «Пшеглонд» («Күзәтү») һәм «Червоны Штандар» («Кызыл байрак») исемле газеталар чыгаралар. Шунда эшләүче каләмдәшләр һәм көрәштәшләр дә, һичшиксез, табылачак һәм булачак.


Гомумән Польша, аерым алганда Краков, Ленинга беренче карауга ук бик ошый. Төзек, җыйнак, яшеллеге мул булган, күпчелек биналары гөмбәзләп-манаралап, сырлап-матурлап салынган бу кала аңа үзенең бөтен торышы һәм тормышы белән туган Россияне хәтерләтә. Анда да нәкъ шундый ук зиннәтле сарайлар, искиткеч купшы йортлар һәм чиркәүләр күп. Бөтенесен халык булдырган, ләкин берсе дә халыкныкы түгел. Барча муллык — капиталистка, алпавытка, байга. Эшчегә һәм крестьянга тигән өлеш — фәкыйрьлек.

Шәһәрнең чиксез оригиналь архитектуралы Кафедраль соборы, Мариацкий костелы, Вавель нигытмасы, Флориан капкасы, Барбакан крепосте, атаклы Сукенницесы әле хәзер дә бернинди үзгәрешсез сакланалар. Краковны, поляк дусларның үзләренчә әйтсәк, «германлылар» соңгы сугышта җимереп өлгерә алмаганнар, чөнки бу районда совет гаскәрләре камалышыннан алар үзләре көчкә качып котылган. Биредәге калын стеналар ташын бары тик күп еллар буе кына килгән вакыт сөреме генә каралткан.

Ләкин Ленинны, бу мәһабәт каланың тышкы күренешеннән бигрәк, аның Россия, буласы революция язмышын кайгырту, революционерлар белән элемтәне тагын да ныгыту һәм киңәйтү өчен җайлы урын булуы куандыра. Чөнки бит Прага конференциясеннән соң инде большевистик сайланган РСДРПның чит ил бюросы да бирегә күчәргә тиеш. Ә бу исә бик зур саклык белән һәм яшерен чаралар кулланып эш итәргә кирәк дигән сүз.

Россия чикләренә шулай бик якын килеп урнашуның патша охранкасы эшен җиңеләйтүе дә бар, әлбәттә, ләкин әнә бит Багоцкий бирегә хәтта чик аша чыгып йөрүләре дә бик мөмкин, ди. Басып алып өчкә бүленгән Польша җирендә Россия белән Австро-Венгрия чиге зонасын поляклар «пас» (русча «пояс», безнеңчә «чик буе») дип атаганнар икән. Ике ил арасындагы килешү нигезендә бу зонада яшәүчеләр чик сызыгы аша теләсә кайсы якка үтә алганнар: әйтик, бу якта — Польшада торучы кеше руслар ягына эшкә бара, тегеннән рус крестьяннары Краков базарына йөриләр. Моның өчен «Полупаска» («пас» сүзеннән) дигән таныклык алырга кирәк, ә ул фоторәсемсез була икән, димәк, чик аша чыкканда аны бүтән фамилияле кеше дә күрсәтә ала. Ниндидер фамилия кычкырганда: «Бу мин!» (полякча: «естем»!) дип әйтү бик җитә. Чик аша уздырырга теләгән нәрсәңне теге яки бу абзыйның яки апаның биштәренә ук салып җибәрергә дә мөмкин. Аннан соң бирегә Галиция җирләрен белүче

Австро-Венгр властьлары прогрессив интеллигенциягә һәм политик эмигрантларга карата алай ук каты куллы да түгелләр. Чөнки власть чиновникларының күпчелеге үзләре поляклар, ә азатлыкка сусаган ул халык исә рус патшасына нәфрәтле, шуңа күрә аларда патшага каршы көрәшүчеләргә усаллык эшләмәү нияте бар. Бер Краковта гына 12 мең политик эмигрант булуы шуңа күрә бер дә очраклы түгел. Краковка килеп урнашкан беренче көндә үк Лениннан ул чакта Каприда торган Максим Горькийга бик хаклы хат китә: «Сез минем ни өчен Австриядә булуымны сорыйсыз. Үзәк Комитет бирегә бюроны төпләде (монысы үзара): чик бик якында, шуны файдаланачакбыз, Питердан да ерак түгел, аннан матбугат безгә өченче көнне килеп җитә, газеталарга язышу бик җиңеләйде, хезмәттәшләшү җайлана»[1].



*В. И. Ленин Польшадагы елларда.*

Ара якынлыгы. Элемтә. Хезмәттәшләшү.

Бу өч нәрсә партиягә һәм Ленинга халык көрәше, партия таләпләре куйган өч моментны мөмкин кадәр күбрәк массаларга мөмкин кадәр тизрәк аңлату өчен, партияне һәм халыкны революцион эшнең яңа этаптагы яңа бурычларын хәл итәргә туплау өчен кирәк.

Момент дигәннәребез, билгеле булганча, шундый: тимер юлдан гаять еракта тайга эчендә Лена эшчеләрен атканнан соң политик протест стачкалары һәм забастовкалар дулкыны бик көчәя. 1912 елның 1 Май демонстрациясендә генә 400 меңнән артык кеше катнашуы билгеле. Ул чакта бик дөрес әйтелгәнчә, Ленада аткан мылтык тавышларыннан революцион хәрәкәт елгасы ярсып кузгала. Шул изге көрәшне бүтән илләрнең пролетарийлары да куәтлиләр. Әйтик, полякларның инде алда телгә алынган «Кызыл байрак» газетасы эшчеләргә мөрәҗәгать итеп менә нәрсә яза: «Себердә үтерелгәннәр эше — сезнең эшегез. Кичә Ленада булган хәлләрнең иртәгә Висладa булуы мөмкин». (1912 елның май ае, 186 сан.) Шуннан соң бер Ченстоховта гына 13,5 мең эшче забастовка ясый...

Кабынган көрәш утына май салырга, эшчеләр рухын күтәрергә, максатларны мөмкин кадәр ачыграк, күңелләргә үтемлерәк итеп аңлатырга кирәк. Моның өчен икенче момент — 1912 елның 5 маенда чыга башлаган «Правда» газетасын чын мәгънәдә пропаганда, агитация һәм оештыру үзәге итү төп бурычларның берсе итеп алгэ куела.

Шундый ук мөһим өченче момент — партия эшен гомумән көчле җанландыру, инде мөстәкыйль большевистик Үзәк Комитетны оператив эш башына кую чараларын конкрет билгеләү.

Ленинның күңеле күтәренке. Ул тизрәк эшкә утырырга ашкынып тора.

Фатирны Багоцкий белән бергә эзләп, Краковка килеп төшкәннең өченче көнендә үк, Ульяновлар шәһәрнең көнбатыш читендәге Звежинец бистәсендә Ян Флорчик исемле хуҗа йортының ике бүлмәсен алалар. (Элекке Звежинецкая урамы, 218 йорт, хәзер Королева Ядвига урамы, 4 йорт.) Аерым кухнясы бар. Тышкы яктан штукатура-

[1] Ленин. Әсәрләр. 35 том. 30 бит. Русча дүртенче басма.

ланмаган ике Катлы таш бина. Эшчеләр бистәсенең накъ үзәгендә. Шактый арзан бәяле. Бистә читендә генә Вольск урманы һәм Висла елгасы. Ял итәр өчен менә дигән урыннар!

Бала чакта әтисе белән Польшада торып, полякчаны белгәнгә [1] Надежда Константиновна кибеткә үзе генә барып җиһаз ала: ике тимер караватъ, ике гади өстәл һәм бер кухня өстәле, берничә урындык, кухня утыргычлары һәм этажерка.

Китап һәм газет-журнал төргәкләре бик тиз сүтеләләр. Төрле телләрдәге белешмәләр, статистика җыелмалары, яңа чыккан һәм чыгасы китап исемлекләре өстәл өсләренә, тәрәзә төпләренә, буш урындыкларга таратып куела. Бер карауга моның нинди дә оешмаганлык яки таркаулык билгесе булып та күренүе мөмкин. Ләкин күреп белүчеләр, үз истәлекләрендә, Ленинның һәр кәгазьне, һәр кулланманы билгеле бер система белән таратып куйганын, кирәкле кәгазьне тиешле урыннан бик тиз табып алуын раслыйлар.

Тизрәк эшкә, бер минутны да әрәм итмичә эшкә утырырга кирәк!

Ә эш муеннан!.. Уйда, планда йөргәннәре дә күп, инде кәгазьгә төшәргә әзерләре дә бар. Прописка вакытында, өй кенәгәсенә теркәр алдыннан, полиция комиссариатында сорау алганда Ленинның җавабы ап-ачык итеп әйтелә:

— Петербургта чыга торган рус демократик газетасы «Правда»ның һәм Парижда чыгарылган «Социал-демократ» исемле газетаның корреспонденты булып торам һәм шуннан эшләп алган акчага яшим.

Әйе, барыннан да элек «Правда». Ул инде хәзер 40 мең данә тираж белән чыга. Эшчеләргә йогынтысы бик зур. Газета эшен көннән-көн яхшыртырга, аңа киңәшләр, күрсәтмәләр әйтеп, бигрәк тә иң мөһим политик темаларга мәкаләләр, чыгышлар, хатлар һәм заметкалар язып булышырга кирәк. Краков дәвере саналган 2 ел эчендә Владимир Ильич «Правда»га 239 шундый хезмәт җибәрә. Алар Ленин әсәрләре дүртенче басмасының 18, 19, 20 һәм 35 томнарына кертелгәннәр. Аларда милли мәсьәләне теоретик яктан хәл итүгә аеруча күп урын бирелә. Чөнки, Крупская әйткәнчә, Ленин ул «яшьтән үк һәртөрле милли изүгә нәфрәт белән карарга өйрәнгән» кеше. Шуңа күрә дә аның хезмәтләрендә халыклар палачы самодержавиенең бөтен милләтләрне изү политикасы да, карагруһлы рус шовинизмы да, изелгән халыкларның буржуаз һәм вак буржуаз катлаулары арасында милләтчелек тенденцияләре дә берүк дәрәҗәдә рәхимсезлек белән фаш ителә. Ленин «Культуралы-милли автономия» лозунгысын иң нечкәртелгән һәм иң зыянлы милләтчелек дип саный, барча милләт эшчеләренең **тулы бердәмлеген** һәм милләтләрнең үзбилгеләмәгә хокукын яклап чыга. Шушы елларда ук аграр мәсьәләгә багышлап язылган кырыклап мәкаләдә исә юлбашчының бер төп тезисы ярылып ята: Россиянең җитмеш миллион дисәтинә җире алпавытлар кулыннан тартып алынып крестьяннарга бернинди түләүсез бирелергә тиеш! Троцкийны һәм ликвидаторларны дөмбәсләргә дә каты-каты сүзләр таба, хәтта «Правда» редакциясенең үз кимчелекләрен тәнкыйтьләүдән дә тартынмый Ильич. Газетаның оформлениесен күзәтү, аны таратуны оештыру, аның тирәсенә корреспондентлар туплашу эшенә аның шулай ук бик күп вакыты китә. Мәсәлән, ул Максим Горькийны газетага язышырга аеруча тырышып димли: «Правда»да сез әле һаман юк та юк. Бу бик кызганыч. Ә газетаны күтәрешергә кирәк иде» [2]. Һәм менә әдипнең Ленинга бик тиз килгән җавабы: «Мин газетада эшләячәкмен, тиздән аңа кульязмалар җибәрә башлыйм. Эшем чамасыз күп булу сәбәпле генә моңарчы җибәрә алмадым, чөнки көненә уникешәр сәгать язам, хәтта билләр сызлый». «Правда»ның бервакыт начарлана башлаган финанс хәлләрен кайгыртып та борчыла Ленин. Бу уңай белән ул



---

[1] Константин Крупский, югары юридик мәктәп тәмамлагач, Польшаның Гроец губернасына капитан чинындагы чиновник итеп җибәрелә. Бирелә ул Коллежский асессор титулын ала, полякчаны өйрәнә. Поляк крестьяннарының баш күтәрүенә теләктәшлек белдергәне өчен патша хөкүмәте аны эшеннән чыгара һәм судка бирә. 1874 елда 21 пунктлы гаеп белән хөкем итәләр. Шуларның берсе: «Кызы Надежда поляк балалары белән уйный, полякча бии». Крупскаяның әнисе исә балалар өчен полякча бер шигырь китабы язып бастырган. Бу турыда әле өр-яңа материалларны Польшада Варшава Ленин музееның фәнни сотруднигы Александра Ожог тапкан һәм шуны гыйльми хезмәт итеп әзерли.

[2] Ленин. Әсәрләр. 35 том. 33 бит. Русча дүртенче басма.

газета редакторы Сталинны Краковка чакырып хат җибәрә һәм ноябрьда РСДРП Үзәк Комитеты утырышын үткәрә.

«Моңарчы мин Ленинны атаклы теоретик буларак белә идем», дип яза Сергей Багоцкий бер истәлектә. Ә Краковта ул Ильичның оештыру эшләренә гениаль сәләтен күреп соклана. IV Дәүләт думасына сайлауларга хәзерлек барышында була бу. Думада социал-демократия фракциясе — массалар арасында эшләү өчен легаль мөмкинлекләрнең берсе. Большевиклар сайлауда өч лозунг белән катнашырга тиеш: демократик республика, сигез сәгатьлек эш көне, алпавыт җирләренең бөтенесен конфискацияләү.

Һәм менә бары тик шул уңай белән генә Краковта Ленин башкарган эшләр, ул оештырган конкрет чараларның кыскача гына китерелгән тезмәсе:

— Инесса Армандны Париждан Краков аша Петербургка Ленин юллый һәм алар сайлау чорына эш планын бергә тикшерәләр.

— Сайлауларга багышланган дистәләп мәкаләне Ленин яза.

— Эшче депутатлар чыгышы өчен тезисларны һәм социал-демократик фракция декларациясе проектын Ленин эшли.

— Думага уңышлы сайланган 6 большевик депутатның катнашы белән Краковта Үзәк Комитетның киңәйтелгән утырышын 1912 елның декабрендә Ленин үткәрә (яшеренлек өчен, аның «Февраль утырышы» дип аталганлыгы билгеле). Шунда ук Дума депутатлары белән Үзәк Комитет членнарының тагын бер утырышы уздырыла.

— Депутатларның Дума ачылганда сөйлисе декларация проектын, милли һәм аграр мәсьәләләр буенча алар чыгышын, дәүләт бюджеты һәм мәгариф министрлыгы политикасын тикшергәндәге чыгышлар проекты һәм башкаларны депутатларга шулай ук Ленин язып җибәрә...

Яңа революцион күтәрелеш чорының яңа бурычларын билгеләп, Дума фракциясе тактикасы буенча берничә карар кабул иткән гаять әһәмиятле Краков киңәшмәсе Ульяновларның инде тимер юл вокзалы янындагы квартирасында үткәрелә (элекке Любомирский урамы, 49 йорт, хәзер Фрич Моджевский урамы, 49 йорт).

Бирегә алар Звежинецтан көзге якта күченәләр, чөнки аннан Ленинга хатлар җибәрү өчен вокзалга йөрүләре ерак була, Россиядән һәм чит илләрдән килгән көрәштәшләрне каршылавы да җайсыз. Яңа квартира — шулай ук шәһәр читенең Весела бистәсендә, станциянең янәшәсендә үк, ә Россия чиге моннан унбишләп кенә чакрымда. Ул чакта әле яңа гына өлгертелгән ике катлы таш йорт. Элек бу бинаның бер ягын князь Любомирскийлар бакчасының коймасы каплап торган, диләр. Аның каравы Ульяновларның ике бүлмәсе һәм кухня тәрәзәләреннән «Пас» буе басулары да ап-ачык күренгән.

Киңәшмә кунаклары өчен аш-суны шул кухняда, әнисе Елизавета Васильевна һәм киңәшмәгә чакырылган ханымнар белән бергәләп, Надежда Константиновна әзерли. «Нәкъ шуның алдыннан гына,— дип яза ул үз истәлекләрендә,— өйдән төрле балык, семга һәм икра белән тулы посылка килгән иде. Бу уңай белән мин әнинең кухарка кенәгәсен алдым һәм коймак та пешердем».

Дөресен әйтергә кирәк, Ульяновлар Краковта да мул яшәмиләр. Цензура тыкшынулары сәбәпле, Россиядән гонорар алулары еш кына тоткарлана. Ә партия кассасыннан акча алырга Ленин бик сирәк очракта гына риза була. Ире өчен билгеләнгән пенсия акчасыннан ярдәм җибәрәм, дигәндә ул әнисенә дә катгый рәвештә каршылык белдерә.

Шундый шартларда эмиграциядә яшәп нихәтле титаник эш башкарылган!

Бирегә, Краковта, Ленин корректураларын Париждан китертеп укып «Социал-демократ» газетасын редакцияли, биредән ул 1911 елда үзе оештырышкан «Просвещение» («Мәгариф») журналына мәкаләләр җибәрә, хатын-кызлар өчен махсус журнал чыгарырга кирәк, дип Петердагы сеңелесе А. И. Ульяновага хат яза һәм аның беренче саны 1914 елның мартында чыга да. Мәскәүдә яңа легаль газета чыгару бурычы шулай ук биредән торып куела, «Наш путь» («Безнең юл») исемле ул газета 1913 елның августында чыга башлый. Краковның үзендәге поляк газеталарына да Ленин актив язышa.

Ә масса эшләре, телдән чыгышлар! Аларсыз һич мөмкин түгел. Менә Ленин Краковның Адам Мицкевич исемле Халык университетында «Россиядә эшчеләр хәрәкәте

һәм социал-демократия» дигән темага лекция укый, мөнә аны студентларның ирекле берләшмәсе «Спуйня» («Союз») яшьләре өчен чыгыш ясарга чакыралар. Балкан сугышы уңае белән уздырылган җыелышны да калдырырга ярамый, 1913 елның 1 Май демонстрациясендә дә булырга кирәк, Тарас Шевченконың 100 еллыгына багышланган тантанада да катнаша ул!.. Өстендә — спорт костюмычарак итеп тегелгән бик гади кием, ә башында җәен — салам эшләпә, кышын — кепка.

Ильичның эш режимы турында исә истәлекләрдә менә ничек сөйләнелә: иртәнге сигездән соңга калмыйча торып, көндезге икеләргә кадәр эшли. Төшке аштан соң тагын эшкә утыра. Кичке биштән җидегә кадәр — һавада йөрү, сәгать җидедә кичке почта килгән була — хәзер шуның белән утырасы бар. Төнге унберләрдә Ленин яңадан урамга чыга — бу юлы инде үзе язганнарны Краковтан киткән поездга илтеп салыр өчен. Шулай җибәргәндә алар тизрәк барып җитә, чит ил пичәте сугылмаган хатларны цензура да тикшереп тормый.

Ә ял сәгатьләре?

Алары да булган, әлбәттә. Ленин, һәрвакыттагыча, үзенең буш вакытларын сәламәтлеккә файдалы, матур һәм актив ял итеп оештырган.

Ул шәһәрдә күп йөри. Урамда ук сатылган әче катык порциясе белән бәрәңге алып аулаграк урынга утыра да, шәһәр халкын, алар тормышын күзәтә, кайберәүләр белән шунда ук гәпләшеп тә китә. Чөнки ул инде монда, сүзлек ярдәме белән, полякчаны да әзрәк белә башлый. Краков тирәсендә җәяү яки велосипедта йөрүләрне ул аеруча яраткан. Кесәсендә шәһәрнең һәм шәһәр тирәләренең планы бар — кая һәм ничек барырга-кайтырга икәне яхшы билгеле.

Ленинның бу турыда үзе сөйләгәннәрен Якуб Ганецкий хәтерләгән икән һәм ул истәлек итеп язылган Ленин сүзләре боларак менә ничек теркәлгән:

— Бик кызыклы халык биредәге крестьяннар. Менә дигән шәп материал. Берәрсенең өенә барып керәм, исәнләшәм, бераз сөт сатып бирүләрен үтенәм — һәм әңгәмә башлана... Полякча сүзләрем җитмәсә, немецчаны кушкалыйм. Анысын поляклар аңлый, чөнки солдатта булганнары күп. Ишарәләп тә алгаларга туры килә. Кыскасы, бер-беребезне ярыйсы ук яхшы аңлыйбыз. Биредәге социал-демократларга менә кемнәр арасында эшләргә кирәк. Ә бит безгә мужиктан башка эшләве кыен...

Крестьяннар хәерчелеген һәм изелгәнлеген Ленин, шулай итеп, бөтен вак-төякләренә хәтле үз күзләре белән күрә. Аннары шуны ук китаплардагы саннар телендә укый: Польшадагы барлык крестьяннарның 78 проценты биш гектардан кимрәк мәйданлы җир били. Шулардан яртысының җире бары тик ике гектар чамасы гына. Ә шул ук илнең 34 процент җире исә эре алпавытлар кулында. Потоцкий фамилияле граф бер үзенә 45 мең гектар җир биләгән... Мәкаләдә: «Польша крестьяны тавык итен бары тик ике очракта ашый — я үзе сырхауласа, я тавыгы чирләгәч», диелә. Нинди усал һәм тапкыр сүз! Менә ни өчен Польшада елына күпме кеше туса, шул хәтле үк үлә дә барган... Ә нәтиҗә шундый: җире азлыларның үче зур, үчле булганнарда зур көч бар...

Ул чакта Ленин үзе шулай күреп-белгән кешеләр эшчеләр арасында да күп булган. Аларның Ленин турында белгәннәрен һәм сөйләгәннәрен язып Краков музее работниклары кинопленкага төшереп алганнар. Менә шуларның берсе — Краковның Костовска бистәсендә торучы Хростек Юлиан истәлеген музейның фәнни сотрудницы Варвара Заджицка, пленка кәтүген әйләндерә-әйләндерә, полякча укый һәм русчага тәрҗемә итә бара, без шул ук сүзләрне аның артыннан күңелгә татарча теркибез:

«Минем Ленин белән беренче очрашуым 1912 елда булды. Ул кичке якта шәһәр үзәгеннән кайтып килә икән. Нәкъ минем йортым турысыннан узып бара. Алар торган йорт исә безнекенә каршы якта. Минем хатыным кулына бала тоткан һәм шуны юатып нидер кейли: — Тә-тә, ти-ти!.. Кыскасы, ул бакчада була. Ленин бакча турысына җитә дә туктый, чәчәкләргә сокланып карап тора һәм хатынымнан бакча турында нидер сораштыра. Шунда ул: «Яратам чәчәкләрне!» — ди. Хатыным аны болдырга менеп утырырга чакыра һәм бераз кәтәргә куша, ә үзе исә, баланы Ленин кулына тоттырып, чәчәкләр өзәргә китә. Нәкъ хатыным шикелле, Ленин да бала белән уйнап утыра: — Тә-тә, ти-ти! Хатыным бер букет чәчәк өзеп Ленинга биргәндә генә эшемнән мин кайтып җиттем. Аның күрше икәнен белә идем инде, ул минем белән дә үз генә сөйләшеп алды һәм соңыннан: «Синең белән очрашып, иркенрәк гәпләшеп булмас-

мы икән?» дип сорады. Хәл-әхвәл белешергә теләве сизелеп тора. Мин аңа: «Шимбә көнне бушый алам»,— дидем. Минем килүемне ул тәрәзәдән карап көтеп тора иде. Аннары урамга чыкты һәм без икебез янәшә атлап киттек. Кайда һәм ничек эшләвем турында белеште, миңа кемнәр килеп йөрүен сорашты...

Икенче көнне эштә үз дусларыма мин Ленинның аларны да күрергә теләге барын әйттем. Ул редактор кеше дип тә өстәдем. Шуннан соң аның белән тагын күп мәртәбәләр очраштым. Хәтта бер төнне бакчадагы шомырт куагы астына посып каршыдагы йортны күзәткән полицай белән дә очрашырга туры килде.

Берничә елдан соң мин Лениннан карточкалы хат алдым...»


Ленинның ничек ял итүе турында башланган сүзгә тагын шуны өстәп үтик: ул үзенең бала чактан ук яраткан спортын Краковта да онытмый — тимерәяктә шуа, Багоцкий белән бергәләп, алар Вольск урманында һәм Висла буйларында бик күп йөриләр. Ә августның бер көнендә алар Польша Карпатының — ягъни Татр тауларының чиксез матур һәм мәһабәт бер түбәсе булган Бабья Горага менгәннәр. Дөрес, башта караңгыга калып адашалар, ярты юлда туктап каравылчы өендә кунарга туры килә. Ләкин икенче тапкыр килеп, барыбер меңәләр.

— Күрәсезме, тырышуларыбыз бушка булмады ич! — дип күңелле елмая Ильич, Татр түбәләреннән күзен ала алмыйча.

Хәзер Бабья Гора тавына менгәндәге каравылчы өен дә музей филиалы итү турында сүз бара.

Краков базасы шулай оеша һәм эшли башлый. 1913 елның башында инде Максим Горькийга Лениннан отчетлы ук хәбәр килә: «Краков базасы файдалы булып чыкты: безнең Краковка күчүебез (эш ягыннан алганда) үзен тулысынча аклады»... һәм шунда ук: «Бирегә Россиядән тагын берничә яхшы работник килде. Киңәшмә оештырабыз. Эх, акча юк, югыйсә бу базада әллә ниләр эшләп булыр иде!..» [1]

Хәзер Краковта, инде 1950 елның апреленнән бирле, Ленин музее эшли. Югарыда әйтелгәннәрнең барысы турындагы материалларны безнең поляк дусларыбыз бик тулы итеп, җентекләп җыйганнар һәм аларны бөтен дөнья халкына горурланып күрсәтәләр.



*Краковта Ленин музее.*

[1] Ленин. Әсәрләр, 35 том, 42—43 битләр. Русча дүртенче басма.

# Тауларга, биеккәрәк...

Өзлексез дәвам иткән киеренке һәм мәшәкатьле хезмәт Ленинны шактый арыта. Бюроның бөтен язу-сызу эшләрен, җитмәсә тагын шифр белән, юл араларына химик ысул белән язып, алып баручы Надежда Константиновна кинәт сырхаулый ук башлый. Врачлар ял итәргә, кичекмәстән тауларга — биеккәрәк менеп дәваланырга кушалар. Ә таулар Краковтан бик үк ерак түгелләр — Подгалье дип аталган таулы җирләрнең үзәге саналган Закопане каласына 115 чакрым гына. Поезд йөри.

1913 елның апрель азагында Ульяновлар Закопанега киләләр. Бер ягы белән Татрның иң биек түбәсе Гевонт итәгенә үк килеп тәртелгән искиткеч матур, үзенчәлекле кала. Заманында биредә Синкевич белән Манюшко да ял иткән дип сөйлиләр. Шәһәрнең барча йортлары үзенчә матурлап, һәр дүрт ягына верандалар корып һәм антресольләр чыгарып катлы-катлы итеп салынган. Бөтенесе яшел куаклар арасында. Алар хәзер дә әле нык-тазалар. Тик яңа өлгерткәннәрә зурлыклары белән дә, заманча ипле булулары белән дә искеләрдән бик күп уздыра төшкәннәр. Ул елларның тере мирасы булып, Закопане урамнарында әле хәзер дә атлы фәйтуннар йөри. Ләкин хәзерге җитез такси белән ярышулары аларга бик үк җиңелдән түгелдер, ахры. Атларның башы шактый салынган...

Закопане безнең Сочилар һәм Ялталар шикелле чиксез шаулы, ыгы-зыгылы һәм кыйммәткә төшә торган урын булганга, Ленин шуның тирәсендәге берәр авылда торуны яхшырак күрә. Татр тезмәсе белән Лосювки калкулыгы арасындагы матур үзән буйлап алты-җиде чакрым үткәч — Поронин авылы, аннан тагын чакрым чамасында гына Белый Дунаец поселогы бар. Шаулап агып торган Поронец һәм Белый Дунаец сулары нәкъ шул тирәдә кушылалар. Ындыр артында ук Галицова Грата тавы, шуннан торып карасаң, уч төбендәгедәй булып, бөтен Татр күренә. Поронинда почта, тимер юл станциясе бар. Шуннан да аулаграк һәм җайлырак урынны эзләп тә торасы юк. Швейцария Альпларың бер якта торсын!

Шул Дунаецта Тереза Скупень исемле ханымның беренче каты тоташ балконлы, ике бүлмәле һәм кухнялы, өске катта бер балконлы бүлмәсе булган йортында тора башлыйлар.

Авылда тау халыклары — гуральләр яши. «Авыллары — рус авылы тибында,— дип яза Ленин моннан сеңелесе Мария Ильиничнага Подгалье турында.— Салам түбәле өйләр. Фәкыйрьлек. Бала-чага һәм хатын-кызлар ялан аяк йөриләр. Мужиклар өстендә гураль костюмы — өйдә суккан сукнодан тегелгән ыштан һәм шундый ук гади өсләма — ярым плащ, ярым куртка сыман бер нәрсә» [1]. Гуральләр агач эшкәртү һөнәренә бик осталар икән.


Белый Дунаецтагы бу йорт хәзер тулысынча Ленин музее ителгән. Аның һәр бүлмәсе ул вакыттан калган агач караватлар, агачтан гуральча сырлап эшләнгән урындыклар белән җиһазланган. Ленинның эш бүлмәсе икенче катта. Кунаклар килгәндә исә ул аскы катка, Крупская бүлмәсенә төшә торган булган. Аның бүлмәсендә, шулай килеп, Инесса Арманд, Багоцкий, Тихомировлар торганлыгы билгеле.

Үзенең яңа агымы белән Поронинdагы тормыш башлана. Ленин иртәнге җиләрдә



*Татр тауларында В. И. Ленин барып йөргән «Диңгез күзе» исемле күл.*

[1] Ленин. Әсәрләр. 37 том, 412 бит. Русча дүртенче басма.



*Белый Дунаецта Ульяновлар торган йорт.*

тора да Дунаецта коенып менә. Аштан соң — эш сәгатьләре. Тагын хатлар, чыгышлар, мәкаләләр язу һәм китаплар уку. Шул ук «Правда» һәм фракция эшләрен кайгырту дәвам итә. Троцкийның август блогына каршы көрәш мәсьәләләре яктыртыла. Лонжюмо курслары тибындагы махсус партkурслар ачуга хәзерлек эшен дә Ленин шунда алып бара — дачалар ялланыла, уку программалары төзелә, лекторлар табыла, теләсә нинди формада шунда эшләшергә чакырып Горькийга да хат җибәрелә. Ләкин, курсны оештыручыларның берсе Россиядә кулга алыну сәбәпле, ул ачылмыйча кала...

Көн якты чакта үргә яки тау башына ук менеп укып яки язып калырга кирәк. Чөнки авылда электр юк. Аның зур эше Поронинга почтага яки иптәшләре белән сөйләшүгә барган-кайткан арада гына, һәм, табигый, тауларга йөрергә чыкканда гына бүленеп тора.

Поронин почтасы шактый зур, ләкин ул чакта ук иске бер йортта булган. Ленинның көн саен шунда вокзалга килеп йөрүләре турында шул еллардагы почта начальнигы Радкевич музей кешеләренә менә ничек сөйләгән:


«Почтада һәр авылның үз киштәсе бар иде. Ә Ленин өчен аерым бер киштә эшләргә туры килде — чөнки аңа килгән хәтле корреспонденцияне алган бүтән бер кешене дә минем күргәнем-белгәнем булмады. Килеп почтасын ала да хатларның кайберләрен шунда ук бүрәнә өстенә утырып укый да башлый. Кайсы берләренә шунда ук җавап та язып калдыра. Килгән почтасын үзе генә күтәрә алмаса, калганын дуслары алып китәләр...»

Ә дуслары аның биредә дә күп була: әйтик, Польшадагылардан Багоцкий, Закопане санаторие директоры Длусский, Поронинда торучы поляк язучысы Каспрович, элекке революционер, хәзер Татрны өйрәнү җәмгыятендә фәнни эш белән шөгыльләнүче сырхау, ләкин рухы белән батыр кеше Борис Вигилев.

Шул ук Поронинда Гут Мостовой фамилияле хуҗаның туристлар һәм ял итүчеләргә бирел тору өчен махсус салдырган ун бүлмәле, кухняле мәһабәт пансионатында бер төркем Россия кешеләре — Дума депутатлары Самойлов, Бадаев, Петровский, Шагов, Россиядән һәм бүтән илләрдән качып яки эш белән килгән көрәштәшләр тора. Ленинның алар янына килеп сөйләшмәгән, партия эше алып бармаган көне юк.

Хәзер Гут Мостовой йортында Поронин Ленин музее. Аны, каршысына скульптор Шварц эшләгән Ленин һәйкәлен куеп, 1947 елда ачалар. Музейны карарга җир шары-

ның терле почмакларыннан кен саен күп кеше килә. Анда без булган көннәрнең берсендә, ягъни 1969 елның 17 июнендә, мәсәлән, музейны Мексикадан, Болгариядән, Венгриядән, Германия Демократик Республикасыннан, Советлар Союзының Мәскәү, Львов, Астрахань, Петрозаводск шәһәрләреннән килгән эшчеләр, галимнәр, нәшрият һәм газета хезмәткәрләре, очучылар карады. Көненә кимендә меңләп кеше! Чөнки Ленинның даһи эшчәнлеге белән бәйле документларны һәм әйберләрне күрү, кайчандыр ул сулаган



*Поронинда Ленин музее.*

җирләрдә һава сулау, аның истәлеге белән очрашу һәркем өчен кадерлә. Музейны караучыларның истәлек язмалары гына да инде бик күп дистә томлап җыелган. Шулар арасыннан грузин шагыйре Симон Чиковани язып калдырган поэтик сүз безнә әөруча кызыксындырды. Менә аның татарчага тәрҗемәсе:

Биредә ике ел Ленин яшәгән.
Җирнең һәр ягыннан бирегә
Чиксез күп хәбәрләр килгән.
Керәштәшләр әзлексез килгәннәр
Россия дигән дәвыллы илдән.
Ул тәрәз янында газетлар актара.
Каршыда — Татр, кул сузсаң җитәрлек ара.
Бу өйне революция сулышы җылыта,
Биредә төн буе киңәшмә бара.
Аның күзләре еракка караган
Әнә шул гап-гади пыяла аша.
Тавышы хәзер дә айкыйдыр тесле тауларны.
Уйлары-хисләре — чишмә булып таша.
Сүзләр белән китап битләре тулган кебек,
Аның фикере белән бу өй әче тулы.
Моннан әле тагын-тагын еракка
Алып китәр сине Ленин юлы!

Порониндагы хәзерге музей йорты 1913 елның сентябрендә РСДРП Үзәк Комитетының «Җәйге» яки «Август» киңәшмәсе (яшеренлеге өчен шулай әйтелгән) үткәрелгән урын буларак әөруча истәлекле һәм данлыклы. Анда «Правда», Дума фракциясе, «Просвещение», Петербург, Мәскәү, Харьков, Екатеринослав, Кострома, Киев һәм Львов партия оешмалары вәкилләреннән 22 кеше катнаша. Соңгарак калып, әле генә төрмәдән чыккан Инесса Арманд килә. Шулай ук поляк социал-демократларыннан да берничә иптәш чакырыла. Кунаклар пансионатта торалар, киңәшмә үзе исә Ульяновлар квартирында да, пансионатта да бара. Үзәк Комитет отчетын һәм урыннардан докладлар тыңлаган, поляк социал-демократларының эшенә әөруча игътибар биргән, Думадагы һәм легаль оешмалардагы эшне, партия съезды, стачка хәрәкәте, народниклар, партия матбугаты, Венада булачак халыкара социалистик конференция турында мәсьәләләр тикшергән бу киңәшмәнең партиябез тарихында роле гаять зур.

Чиксез калын бүрәнәләрне сумалалап таш нигезгә бик ныклап салган, махсус эшләнгән йомычка чүбе белән мәрҗән тәзмәседәй сырлап мукланган бу йортның хуҗасы Мостовойның улы Павел әле дә исән. Аңа инде 72 яшь. Ләкин таза-сау һәм бик кер күңелле әле. Музей ителгән йорты өчен Польша хөкүмәте салып биргән иркен, матур йортта тора. Ленинның алар йортына кен дә килеп йөрүләрен, киңәшмә вакытында атналап шунда ук торуын яхшы хәтерли ул. Музейда аның магнит лентасына



*В. И. Ленин Татр тауларында йөргәндә.*

язып алынган чыгышы да бар. Аны безгә музей директоры, тарихчы Евгений Халицкий үзе тәрҗемә итеп болай сөйли барды:

«Безнең өйне «Ванькоака» дип йөрттеләр,— дип башлый Павел ага Мостовой,— чөнки анда гел руслар, ягъни күбесе Иван исемлеләр тора иде. Ленин белән Крупскаяны Поронин ашханәсендә дә еш күргәләдем. Бервакыт аның белән мин Галица тавында очраштым. Татрга бергә карап тордык та, аннары, нәкъ безнеңчә итеп: «Матур! Матур!» — диде ул. Миннән төрле яктагы тау түбәләренең исемнәрен сорашты.. Йортыбызда киңәшмә барганда миңа, балконга чыгып, аларны тәрәзәдән карап торырга да рөхсәт иттеләр. Киңәшмәдә көндезләрен дә кичләрен дә утырдылар. Атнадан артык барды. Ял иткән араларда, күрәсең, аскы бүлмәләрдән русча һәм украинча җырлар ишетелә иде. Күңелгә кереп калганнары да бар: мәсәлән, «Ой на горе, на горе...», «Лучше было бы не любить...»

Павел агай җырларны хәтта көйләп күрсәтә.

Аннары ул Ленинны кулга алгач, аның әйберләрен һәм кульъязмаларын әтисе Гут ничек һәм кайда яшереп саклавын, шуларны эзләп 1920 елда Советлар иленнән Ганецкий килүен исенә төшерә. Ләкин, билгеле булганча, Советлар дошманы Пилсудский аларны инде бик еракка яшергән була. Биредә сүз, Порониндагы ике өйнә тентегән жандармнар әйткәнчә, бәйләм-бәйләм кульъязмалар, брошюралар, хатлар, китаплар турында барганын, аларның «ун центнерлап» булуын [1] Мостовой, әлбәттә, белми.

— Ул чактагы Поронинда йөзләп йорт, бер агач чиркәү һәм почта бар иде,— дип йомгаклый Мостовой.

Иске Поронинда кесәләренә һәрвакыт газета тутырып һәм балаларга бирер өчен конфет салып йөргән спорт костюмлы «Пан Ульяновны» хәтерләүче бүтән кешеләр дә бар әле. Аларның аеруча бер нәрсәгә исләре китә торган булган: бу сәер «җәйчене» [2] чәчүлекләрнең торышы, терлек үрчеме, балыкның булу-булмавы, гомумән, крестьян хәлләре ни өчен шулай кызыксындыра икән?

Ленинның Закопанега велосипедта барып йөрүләрен, гуральләр җырлап-биеп күңел ачкан төшкә килүләрен, Поронецта балык тотуын, кичләрен шахмат «сукканын», тауларга менгән чакларын я күреп, я ишетеп белмәгән кеше юк диярлек. Үзенең үр мену походларын Ленин «Тау акробатикасы» дип атаган һәм юлга һәрвакыт таяк тотып чыга торган булган. «Мин аңардан ун яшькә кечерәк идем, ләкин аңардан калышмыйча йөрүләре кайчакта миңа да бик кыенга туры килгәләде», дип яза Сергей

---

[1] Ленинның Поронин һәм Краков архивы материалларыннан хәзер, поляк дуслар ярдәме белән, бик күбе инде эзләп табылган һәм өйрәнелә.

[2] Полякча «Летник», ягъни җәй айларында фатир алып торучы.

Багоцкий. Ленин аның белән Татрдагы Черный Став (Кара күл), Морское око (Диңгез күзе) күлләрендә булган, иң биек саналган Свиница һәм Рысы түбәләренә менгән. Рысы — Польша белән Чехословакия чигендәге тау, биеклеге — диңгез тигезлегеннән 2449 метр. Аның түбәсендә «Бирегә Ленин менде» дигән мемориаль язу бар. Менүләре бик үк җиңелдән булмагандыр, әлбәттә, аның каравы нинди рәхәт ял, уйлану минутлары, күңел һәм күз карашына чикләнмәгән нинди киңлекләр ачыла. Ильичның ул чактагы атаклы альпинист Юзеф Оппенгайм белән танышулары тикмәгә булмаган күрәсең. Дусты һәм көрәштәше Горькийны да ул: «Бирегә искиткеч яхшы урыннар, килеп чыгарга уйламыйсызмы?» дип, әлбәттә, юкка гына кызыксындырмаган...

Ә Надежда Константиновна әле һаман да савыгып китә алмый. Аны Бернда (Швейцария) биз авырулары буенча иң яхшы белгеч Кохерга алып барырга туры килә. Июнь башында юлга чыгалар һәм операция уңышлы була. Крупская терелеп яткан арада Ленин Липск, Цюрих, Брно, Женева, Лозанна, Париж калаларында, Болгариядә һәм Англиядә лекцияләр укып һәм чыгышлар ясап кайта.

...Хәзерге Поронинда без асфальт җәйгән Ленин урамы буйлап йөрдек. Аның Белый Дунаецка күптән инде барып җиткән яңа таш йортлары сокланып туймаслык. «Болар барысы да Лениннан!» диләр биредә картлар да һәм яшьләр дә. Яшьләр дигәннән, алар биредә һәр елның җәендә Белый Дунаец — Поронин — Закопане маршруты белән «Ленин рейды» дип аталган җәяүле походлар оештыралар. Ленин турында белгәннәрен халыкка сөйләп, «Лениниана имтиханы» тоталар икән.

Закопанедагы кызына шигырь белән хат язып, күренекле поляк шагыйре Юлиан Тувим бу турыда менә нәрсә ди:

Закопане янындагы тау тезмәсен
Котла, кызым, баш иеп һәм кул изәп син,
Зурла, кызым, томаннарны һәм болытны,
Җиреңң яңа туган ямен күр-күзәт син.
Сәлам тапшыр иртә торган сайрар кошка,
Чәчәкләрне син үзеңә тиң итеп үп.
Эшче Польша, иркен-азат Польша кызы,
Хәзер алар бөтенесе синеке бит!..
Лодзадагы фабрикларның барчасына
Текә ярдан башың иеп карап тор син.
«Диңгез күзе» якларыннан бер карасаң,
Силезия тауларын син яратырсың.
«Без һәрвакыт әзер!» сүзен көчле яңгырат,
Таугa менсәң кулың күккә тияр булсын.
Сәлам тапшыр мин белмәгән дусларыңа,
Алар бар да илне янып сөяр булсын.
Сәлам тапшыр укытучыңа — иртә белән
Тиз-тиз атлап мәктәбеңә барган чакта.
Сәлам диген, кызым, курчак коючыга,
Кулларыңа яңа китап алган чакта.
Гевонт биек, ә түбәндә, тау астында
Сулар ага, җырлар оча, еллар ага...
һәр адымда уйла кеше хакында син,
Телә, кызым, җирдә якты юллар аңа,
Польшаны гиз, атла, кызым, Көнчыгышка,
Дуслар килсен аннан синең туган илгә.
Халыкларга бу бәхетне Ленин бирде,
Чәчәк куй син бөек Ленин булган җиргә!

Музей үзе дә яңа материаллар белән әледән-әле тулылана. Юлбашчының 100 еллык юбилеена әр-яңа экспозиция хәзерләргә керешелгән. Анда югалмас штрихлар, шиңмәс буяулар белән рәссамнар сызган сурәтләр дә урын алачак: Ленин Краков киңәшмәсе делегатлары белән, Ленин гураль көтүчесе Юхас белән сөйләшә, Ленин һәм Крупская тауда йөриләр... Шунда ук һәм шундый ук үлемсез фактлы бер схема: Краков базасында чакта Ленин Россиянең 100, чит илләрнең 50 шәһәре белән элемтәдә торган һәм язышкан... «Казан утлары» журналының Ленин темасына «Безнең бөек

якташыбыз» исемле цикл материалларының да музейга тулысынча җибәрелүен хәзер үк сорап калдылар...

Октябрь җиткәч, Ульяновлар Поронирнан тагын Краковка кайталар һәм шул ук Любомирский урамындагы 51 йортка (Цехановскийлар йорты) урнашалар. Элеккеге фатирдагы шикелле үк ике бүлмә һәм кухня. Инесса Арманд да Краковта торган чагы. Бик еш очрашып киңәшәләр, шәһәр читләренә прогулкалар була, өйдә Инесса Бетховенны уйный. Ленин инде икенче тапкыр ябылган «Правда» урынына чыга башлаган «Правда өчен» газетасына язышa. Биредә ул әле һаман дәвам иткән Балкан сугышына каршы митингта катнаша, Үзәк Комитет членнары киңәшмәсен үткәрә. Анары латыш социал-демократларының дүртенче съездын хәзерләү уңае белән Берлинга, Парижга бара, Брюссельдә үткәрелгән шул съездның үзендә катнаша. Булган һәр урында, Краковка кайтышлый исә Льеж белән Лейпцигта туктап, «Милли мәсьәлә» дигән темага докладлар сөйли.

1914 елның маенда — яңадан Поронин. Тагын яңадан-яңа эшләр. Арада иң кичектергесезләре: партиянең булачак съездына хәзерлек, РСДРП оешмаларының бердәмлеген тәэмин итү буенча Брюссель киңәшмәсе материалларын әзерләү. II нче Интернационалның Вена конгрессы мәсьәләсе... Яңа хезмәтләр языла, яңа очрашулар дәвам итә. һәм, һич көтмәгәндә...

## Яңадан төрмә

Көннәрнең берендә Ленинны жандармерия бүлеге коменданты вахмистр Матышчук өяз үзәге Яңа Таргка алып бара. Старостатта аны кулга алалар һәм шул ук минутта төрмәгә утырталар. Инде башланып киткән беренче бөтендөнья сугышы хәбәрләрен төрлечә юрап һәм сөйләп шаулаган шәһәрнең нәкъ үзәгендә, Ратушь белән базар мәйданы янындагы төрмә. Куплэрнең үзәгенә үткән һәм әле тагын үтәсе каргалган урын. Бишенче номерлы караңгы камера. Аркылысы да, буе да дүрт адымлык. Тимер карават. Кечкенә бер өстәл һәм урындык. Бер почмакта ләгәне, бер почмакта тимер миче бар. Төрмә күзәтчесе аны кенәгәгә терки: «26 июль, иртәнге 11 сәгать. Владимир Ульянов, Россиядә туган, 44 яшендә, христиан динен тота, рус эмигранты, 91 крон, 99 галлер, кара сәгать, пәке». Шул ук көнне Поронирнан килгән жандарм рапорты укыла. Имеш, ул: Белый Дунаецта күп санлы Россия кешеләре белән ниндидер яшерен киңәшмәләр үткәргән. Имеш, ул рус шпионы булырга тиеш, чөнки тирә-юньдәге калкулыкларга менеп карталар сыза... Имеш, руслар коеларга агу салалар...

Доносы ялган һәм нигезсез булса да гаепне ныклап тагулары бик мөмкин. Чөнки Германиянең Россия, Франция, Бельгия белән, Англиянең Германия белән, Австро-Венгриянең тагын Россия белән, ә Франция белән Англиянең исә тагын Австро-Венгрия белән сугышы бара. Шаукымлы, буталчык, ата улны, ана кызны беләсе түгел көннәр. Таякны бөгеп-сындырып ташлаулары да бар. Гражданский эшләрне дә инде хәрби суд карый. Их, билет алырга рөхсәт ителгән 23 июль көненә хәтле чыгып китеп кенә булмады бит!.. Әлеге дә баягы шул акча юклыгы инде.

Көтмәгәндә дисәк тә, Ленинның кулга алынуы бер дә көтелмәгән хәл булмый, әлбәттә. «Биредәге аграр шартлар белән танышу өчен Галициягә килдем, чөнки мин асылда шул мәсьәлә белән шөгыльләнәм. Шулай ук поляк телен дә өйрәнергә телим», ди Ленин Краковта беренче мәртәбә прописка кәгазе тутырганда. Шуңа полиция комиссары салган имза менә нинди: «Ульянов дигән шәхесне күзәтү астына алдым, нәтиҗәләрен вакыты белән хәбәр итәрмен». Поронинга беренче килгән елны ук вахмистр Матышчук Ленинның почта йортында типографи» оештырырга теләвен сизенә, кемнәндер ишетеп белә дә, аны кисәтеп кенә калмый, ә Яңа Таргка донесение дә яза.


Котылу өчен берләнбер чара бар — ул да булса йогынтылы, күренекле, Австрия властьлары каршында да танылган кешеләрнең Ленинны аклап һәм яклап чыгуы кирәк. Моны Ленинның иректәге дуслары һәм көрәштәшләре оештыра. «Ленин — патшалыкның иң усал дошманы, патша Россиясендә аны күптән инде атып үтергән булырлар иде. Ул үзенең шул патшаларга каршы көрәше белән бөтен Европага бик яхшы билгеле... Ленин шпион түгел!..»

Поляк телендә хат язып Вена парламенты социал-демократлары Адлерга һәм Диамандка Крупская мөрәҗәгать иткәч, бу сүзләр Министрлар Советы председателе Стюргка ук җиткерелә. Ленинны яклап шул ук сүзләрне Польшаның прогрессив язучысы Владислав Оркан, язучылар Ян Каспрович һәм Стефан Жеромскийлар, доктор Длусский, поляк социал-демократлары Варский, Валецкий, Кошутская һ. б. лар Яңа Тарг судына, полиция дирекциясенә һәм өяз комиссариатына язалар. Ленинның азат ителүен зур җәмәгатьчелек даулый. Ә Ленин исә бу көннәрдә төрмәдә утыручылар белән таныша, налог түләмәгән, властьларга буйсынмаган, кеше полупаскысы белән чик аша йөргән өчен кулга алынган крестьяннарга гаризалар язып, киңәшләр бирә. Ниһаять, Ленинны 6 августта азат итәргә тиеш булалар һәм алар, атна буена товар вагоннарында каңгырып, Швейцариягә барып җитәләр. Икенче көнне үк Бернда большевиклар киңәшмәсе була һәм Ленинның Европа сугышына мөнәсәбәте турындагы төп тезисы кабул ителә: сугышка каршы сугыш! Хәзерге империалистик сугышны гражданнар сугышына әйләндерергә!..

...Поронинннан Варшавага кайтышлый туктап, Яңа Тарг шәһәрендәге төрмә бинасын күрергә мөмкин. Анда хәзер (1951 елдан бирле) мәктәп балалары өчен Харцер исемендәге оешманың үрнәк йорты. Ленин утырган камера мемориаль бүлмә итеп саклана. Аның белән янәшәдә, тормыш юлы һәм революцион эшчәнлеге турында сөйли торган материаллар куеп, Ленин бүлмәсе ачканнар. Караңгы төрмәне якты көн чәчәкләре күмгән. Әйе...

## Ленинга—чәчәкләр

Биредә аларны бик күп җирдә күрергә мөмкин — Яңа Гутаның Ленин исемендәге металлургия комбинаты цехларында, Ленин исемендәге урамнарда һәм бакчаларда, Ленин һәйкәлләре һәм бюстлары янында, мәктәпләр, клублар һәм хәрби частьларның Ленин бүлмәләрендә.... Варшавадан Краковка хәтле без утырып барган тиз йөрешле



*Варшавада Ленин музее.*

поезда да, Краков — Закопане маршрутлы автобус-экспресста да, Закопанедан Поронинга килгәндә дә һәм Поронинннан Белый Дунаец ягына атлаганда да бар алар. Өлкәннәр кулында, яшьләр кулында, балалар кулында! Ленин булган бу якларда алар мәңге сулмаска калырлар, бәхетлеләрнең шатлыгын, тагын да матуррак киләчәккә омтылышын аңлатып балкырлар төсле.

Закопане — Варшава поезды пассажирлары исә шундый ук чәчәкләрне Ленинның Польшадагы Үзәк музеена алып баралар иде. Бу музей Ленин турындагы бөтендөнья материаллары белән эш итә. һәм, әйтергә кирәк, аларны ул я оста кулланылган яктылык ярдәмендә, я теге яки бу сурәтне экранда күрсәтеп яки тавыш тыңлатып күрсәтә белә. Әйтик, Октябрь революциясе көннәре залында чын кеше зурлыгында эшләнгән сурәт-солдатлар һәм сурәт-матрослар бастырып куелган. Син, тамашачы буларак, шулар арасына барып керәсең. Залда караңгы, экранда — «Аврора» залпы. Чыннан да, восстаниедә, революция барышында үзең катнашкан кебек истәлекле хатирә бит бу! Шунда ук Ленинның үзен экранда күрергә, аның үз тавышын тыңларга мөмкин. Эшлекле магистр Конар Юлиан җитәкләгән бу искиткеч үзенчәлекле һәм материалларга чиксез бай музей хәзер Советлар Союзында йөртер өчен «Ленин Польшада» дигән күчмә күргәзмә эшли. Ленин юбилеена чаклы «100 ел эчендә дөньяда революцион хәрәкәт» дигән темага фотокүргәзмә инде тиздән хәзерләнеп тә бетәргә тиеш.

Бирердә Ленин васыятьләрен үтәп, ленинизм юлыннан атлап азатлык һәм бәхет яулаган халыклар һәм илләр язмышын күрсәткән материаллар аеруча күп. Шул җөмләдән социалистик Польшаның үзе турында да.

...Польша белән очрашуны без Варшавадан башлаган идек. Юк, дөресе, ул Мәскәүдә үк башланды һәм юлда дәвам итте. Июньнең бишендә «Мәскәү» гостиницасында, «Трибуна Люду» газетасын алып, Краковта Ленинга яңа һәйкәл эшләү өчен конкурс игълан ителүен укыдык. Аннары без, Мәскәү — Варшава — Берлин поездының бер вагонына туры килеп, поляк егете Мячислав Михалак белән очраштык. Ул Польша Халык Республикасының Мәскәүдә оештырыласы промышленность күргәзмәсеннән кайтып бара икән. Ул, танышуга ук, «Сездә әллә нихәтле техник казаныш күрсәтәчәкбез, без хәзер бик күп илләргә чыгара торган яңа машиналар, приборлар һәм электрик аппаратлар куела анда!» дип, бер дә масаюсыз тон белән тезеп китте.

Әйе, социалистик Польшаның чын мәгънәдә мактанып һәм горурланып сөйләрлек уңышлары һәм ирешкән казанышлары күп хәзер. Польша — куәтле һәм күп санлы машиналар иле. Игенче поляклар үз илләрендә ризык муллыгы өчен күп көч куеп көрәшәләр. Инде күзгә күренеп торган нәтиҗәләре дә бар: Польшада үткән ел җан башына уртача 8 килограмм май сатылган (Германия Федератив Республикасында ул 5, ә Италиядә 4 килограмм), һәр кешегә уртача 35 килограмм шикәр (Франциядә 31) туры килә. Ә рухи азык исә аннан да мулрак. Польша җирләрендә 50 меңнән артык китапханә генә бар, авылда яшәүче һәр 100 кешегә 139 том китап туры килә, 3,5 миллион телевизор эшли, ел саен 32 мең егет һәм кыз югары мәктәп тәмамлый...

Боларның барысына без Ленинлы Россия белән бергә Ленин кушканча көрәшеп, социализмның төп көче булган Советлар Союзы белән бердәмләшү һәм дуслашу нәтиҗәсендә ирештек, диләр поляклар.

Әйе, Ленинның «Азат Россиядән башка азат Польша була алмый» дип раславы, Октябрь революциясе җиңгәч, патша Россиясенең Польшаны изә һәм җәберли торган барлык договорларын юкка чыгарырга дип Ленин имзасы куелган декрет сүзләре поляк дуслар йөрәгендә мәңге җуелмас хатирә булып саклана. Шуңа күрә бирердә, кем генә, кайчан гына килсә дә, Ленин эшчәнлегенә һәм аның истәлегенә бәйле һәр урында ирек шатлыгы һәм елмаюлы йөзләр яме булып балкыган чәчәкләрне күрер.

*Варшава — Краков — Закопане — Поронин — Белый Дунаец.*

## Альберт Мөслимов

# СОҢГЫ ЮЛГА

Ленин үлде, яши ленинизм,
Ленинизм — кояш тиңдәше.
Ленинның юк җирдә үлгән көне,
Бар Ленинның туган иртәсе.

(Нәби Дәүли. «Январь кичендә»)

Мәскәүдә Зур театр бинасында РСФСР Советларының XI съезды бара. 22 январь.

Иртәнге утырышка Михаил Иванович Калинин бөрникадәр соңгарып килә. Менә ул трибунага күтәрелә, үткен караш белән залны күзләп чыга һәм акрын тавыш белән:

— Иптәшләр! Мин сезгә авыр хәбәр белдерергә тиешмен,— дип сүзен башлый.— Владимир Ильичның сәламәтлеге соңгы көннәрдә яхшыра башлаган кебек иде. Ләкин кичә...— һәм ул врачлар имзасы куелган бюллетеньне укый:

«21 январьда Владимир Ильич Ленинның сәламәтлеге кинәт начараеп китте; көндезге сәгать 6 нчы яртыда сулышы өзелгәли башлады, аңын югалтты, гомуми көзән җыеру барлыкка килде. 6 сәгать 50 минутта Владимир Ильич, сулыш алу үзәге параличы нәтиҗәсендә, вафат булды. Гәүдәсен ачып карау баш миендәге кан юлларының кискен үзгәрешен, йомшак ми тышчасындагы кан юлларыннан дүрткел калкулык өлкәсенә яңа гына кан йөгерүен, һәм боларның үлемгә төп сәбәпче булуын күрсәтте».

Зал тын, тып-тын. Кешеләр селкенергә дә кыймыйлар. Һәркемнең колагында набат булып бер сүз яңгырый: «Үлгән, вафат булган...» Моңа беркемнең дә күңеле ышанырга теләми. Әле кичә генә: «Хәле яхшырып килә»,— дигәннәр иде бит. Делегатлар съездда чыгыш ясавын да көткәннәр иде...

Кинәт залның бер почмагыннан бер хатын-кызның үксеп елап җибәргәне ишетелә, аңа бүтәннәре кушыла. Съездга утыз өч хатын-кыз катнаша. Шуларның берсе — Чаллы кантонының Биклән авылыннан партиясез Нурдидә Мөхлис кызы Бохарметова. Ул съездның президиумында утыра. Аның белән рәттән — партия һәм хөкүмәтебезнең җитәкчеләре. Нурдидәнең аңына бу хәбәр һич кенә дә барып җитми: аның күз аллары караңгылана, үзен ниндидер бүтән бер дөньяда, тере кешегә хас булмаган бер халәттә итеп сизә — төш күреп саташу гына түгел микән бу? Бу халәттә күпме булгандыр ул — моны Нурдидә әби хәзер инде хәтерләми — бер ир кеше тавышына аңына килә:

— Сез Владимир Ильич табуты янында почетлы сакта торырга билгеләндегез. Хәзер үк Горкага барырга кирәк...

Татарстан республикасыннан съездга килгән делегация шундук киңәшмәгә җыела һәм делегатлар республиканың ике вәкилен Казанга кайтарып җибәрергә дигән карар кабул итәләр. Алар Татарстан хезмәт ияләренә бу авыр хәбәрне җиткерергә һәм юлбашчыны күмүгә катнашу өчен башкалага махсус делегация алып килергә тиешләр...

Горка. Озакламый таң атар. Ильичтан башка беренче таң. Ай яктысында йортның

ак фасады тирән кар өемнәре белән тоташкан сыман күренә. Авыл малайлары, әниләрен югалткан кош балалары кебек, бер урынга җыелганнар...

Менә Горкага съезд делегатлары килеп җитә. Аларны Надежда Константиновна, Анна Ильинична һәм Мария Ильинична каршы ала. Юлда туңып килгән делегатларга алар чәй тәкъдим итәләр. Тамак кайгысымыни хәзер — барысы да чәйдән баш тарта.

Делегатлар икенче катка күтәреләләр. Менә аның бүлмәсе. Ильич гәүдәсе — өстәл өстендә, ул чәчәкләргә күмелгән. Владимир Ильичның өстендә яшел костюм, кулларын күкрәгенә куйган. Йөзе ак, ләкин саф күренә, әйтерсең, ул йокыга гына киткән.

Костюм якасында — Кызыл Байрак ордены.

Бүлмәдә тын. Бохарметова Ильичның башы турысына сул яктан почетлы сакка баса. 15 минут бик тиз узып китә. Почетлы сак алышына. Бераз вакыттан аңа тагын чират җитә...

Йортта һәркем аяк өстендә. Надежда Константиновна, акрын гына атлап, Владимир Ильич янына килә. Кайгылы карашын аның кадерле, сөйкемле йөзенә төби. Озак алмый ул аңардан күзләрен. Бүлмәгә Анна Ильинична, Мария Ильинична, Дмитрий Ильич керәләр. Башларын түбән иеп тын гына торалар...

Алты сәгатьтә юлбашчыга соңгы сәламләрен тапшыру өчен Горка крестьяннары килеп җитә. Алар әле күптән түгел генә исән-сау хәлендә күргән юлбашчының үлеменә ышанасылары килмичә, күзләрен өстәл өстендә яткан Ильичка төбиләр. Әле кайчан гына соң Ильич ауга барган иде! Урман караучы Владимир Ильичның урманда йөрергә яратуы, үзенең аны озатып куюлары турында сөйли, ә күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага...

Сигез сәгать утыз минутта Ильич янында туганнары гына кала. Сәгать тугызда Партия Үзәк Комитеты членнары Ленинның гәүдәсен зур саклык белән табутка куялар. Серго Орджоникидзе Владимир Ильич күкрәгенә СССР Үзәк Башкарма Комитеты члены значогын беркетә.

Табутны урамга алып чыгалар. Барысы да сафка тезелә. Нурдидә Надежда Константиновна белән рәттән баса.

Нурдидә әби әле дә хәтерли: Надежда Константиновна шушы авыр минутларда да хезмәт кешесенең тормышы белән кызыксына — аңардан Татарстан крестьяннарының хәле, чәчүлекләр турында сораша...

Эшчеләр Ильич табутын җилкәләренә күтәрәләр.

Менә Герасимовская платформасы. Чуен рельслар траур поездын кайгылы Мәскәүгә — соңгы юлга илтәләр. Ә поезд махсус паровозга тагылган. Аның тендерена: «РКП(б) ячейкасының алты еллык юбилеена депоның партиясез эшчеләре тарафыннан ремонтланды. Мәскәү, Рязань — Урал тимер юлы, 12 май, 1923 ел»,— дип язылган.

Гомеренең соңгы язында Владимир Ильич Рязань — Урал тимер юлы депосы эшчеләре һәм хезмәткәрләреннән хат ала.

«Егерменче майда,— диелгән була ул хатта,— Мәскәү депосы эшчеләре һәм хезмәткәрләре, юбилейны бәйрәм итәргә җыелып, 127 номерлы паровозны ячейкага тапшырдылар һәм Сине, кадерле Владимир Ильич, бертавыштан почетлы машинист итеп сайладылар. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр бу паровозны Сиңа тапшырганда, Владимир Ильич, ышаналар, Син, тәҗрибәле машинист буларак, безне якты киләчәккә алып барасың».

Паровозның үзенең почетлы машинисты белән болай очрашасын кем белгән соң ул вакытта?!

Һәр станциядә эшчеләр, крестьяннар, балалар составны кара белән капланган Кызыл байраклар белән каршы алалар, озатып калалар.

Мәскәү. Павелецк вокзалы. Кайгылы марш астында чәчәкләргә күмелгән табутны вагоннан алып чыгалар. Митинг башланып китә. Фрунзе, Ворошилов сөйли...

Ә башкалага дөньяның барлык почмакларыннан телеграммалар ява:

Буэнос-Айрестан — «Ленинның үлеме турында хәбәр ишеттек. Дөресме икән? Бик тиз телеграмма белән җавап бирүегезне үтенәбез. Партия комитеты».

Лионнан — «Франция коммунистлар партиясе үтенә: Ленинны күмүне берничә көнгә кичектереп булмасмы икән? Франция пролетариаты делегациясе дә күмүгә катнашсын иде».

Германиядән — «Байрак йөртүче егылса да, байрак мәңге җилфердәр!»

Төркиядә бу вакытта мәҗлес утырышы бара. Ленинның үлемен ишеткәч, депутатлар утырышны туктаталар һәм, аяк өстенә басып, Ильичны искә алалар.

Коминтернның генераль секретаре иптәш Коларов Россия телеграф агентлыгына: «Беркайчан да беркемнең дә үлеме дөньяда бу кадәр кайгылы булганы юк иде»,— дип телеграмма җибәрә.

* * *

1924 елның 23 январенда Мәскәүдән Казанга РСФСР Советлары съездының ике делегаты кайта. Аларның берсе — Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты председателе, икенчесе — Татарстан профсоюзлары председателе Ендаков. Шәһәр Советының кайгы утырышында алар В. И. Ленинның авыру тарихы һәм үлеме турында сөйлиләр.

1922 елның мартында врачлар Владимир Ильичның сәламәтлеген тикшерәләр һәм аның нерв системасында бернинди дә үзгәрешләр тапмыйлар. Ләкин озакламый приступ була һәм шуның нәтиҗәсендә ул хәлсезләнә, сөйләү сәләтен югалта... Ләкин Ленинның көчле организмы бу хастаны җиңеп чыга, ул көзен эшенә кайта.

1923 елның мартына кадәр Владимир Ильич эшчәнлеген дәвам итә. 9 мартта уң як гәүдәсен паралич суга һәм сөйләү сәләтен югалта. Майда аны Горкага китерәләр. Җәен ул креслога утырып паркка чыга, үзен яхшы хис итә, йокысы, аппетиты әкренләп нормаль хәлгә кайта. Тиздән ул, бүтәннәр ярдәменнән башка, баскычтан күтәрелеп йөрер дәрәҗәгә җитә, көн саен сул кулы белән язу күнегүләре алып бара. Яңа елны каршылаганда, балаларның чыршы бәйрәменә катнаша. Инде барысы да сәламәтләнүгә таба бара. Ләкин 21 көннән соң...

ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты, шәһәр Советының кайгы утырышыннан соң ук, республиканың барлык хезмәт ияләренә мөрәҗәгать белән чыга:

«Татарстан эшче-крестьян хөкүмәте үзенең остазы В. И. Ленин васыятьләренә тугрылыклы булып калыр,— диелә анда,— һәм пролетариат диктатурасы, эшчеләр белән крестьяннар союзы идеяләрен тормышка ашыруда нык торыр... Безнең тупланып һәм дусларча эшләвебез Ильичка иң яхшы һәйкәл булыр!»

Шул ук көнне Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты кайгы демонстрациясе үткәрү буенча комиссия төзү һәм Мәскәүгә В. И. Ленинны күмәргә делегация җибәрү турында карар кабул итә.

Владимир Ильичны соңгы юлга озатучылар арасында эшчеләрдән: Сафин, Мөбаракшин, Дубровина һәм Карл Маркс исемендәге фабрика эшчесе Флиндре була. Бондюг химия заводы эшчеләре үз делегацияләрен җибәрәләр.

Типография эшчеләре, юлбашчының үлеме турында ишеткәч, ачык партия җыелышында башкалага үз вәкилен җибәрергә һәм Ильич каберенә республика полиграфистлары, матбугат һәм нәшрият эшчеләре исеменнән венок салырга карар кабул итәләр.

Венокка: «Пролетариат интересларын яклаучы алышусыз часовойга, даһи, курку белмәс юлбашчыга, коммунизм корабле капитанына, сөекле Владимир Ильичка»,— дип язылган көмеш пластинка беркетәләр һәм аны карт эшче Козловка тапшыралар да Мәскәүгә озаталар...

Салкын январь көннәре. Кайгылы көннәр. Ләкин кайгы никадәр генә зур булмасын, ыңгырашулар, сыкранулар ишетелми. Менә эшчеләр бара, алар станок янында гына чыкканнар да, Ленинны күргән кешеләр сөйләгәнен тагын бер кабат ишетер өчен, Партия Өлкә Комитетына, Халык Комиссарлары Советына, Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына ашыгалар.

Менә Татарстан Халык Комиссарлары Советы ишеге ачыла. Ишектә — тун якалары, сакал-мыеклары бәскә күмелгән крестьян агае.

— Мин Арча кантонындагы Мәтәскә авылыннан килдем,— ди ул.— Бу кайгылы хәбәр авылга килеп җиткәч, без җыен үткәрдек. Барысының да сүзе бер булды—Ленин безнең кеше иде! Менә мине эшчеләр белән бергә аны соңгы юлга озату өчен Мәскәүгә җибәрделәр.

— Соңга калдың, иптәш,— дип җавап бирәләр аңа.— Эшчеләр инде китеп барды. Хәзер күмәргә инде барып өлгермисез, Казанда калыгыз, демонстрациядә катнашырсыз.

— Алай икән, берни эшләп булмый инде, калырга туры килә. Ләкин авыл хатын-кызлары, юлбашчы табутына куярга дип, венок әзерләгәннәр иде.

— Бу да бик яхшы эш. Ләкин Ильичка иң яхшы венок — сезнең партиягә керүегез булыр...

— Әлбәттә,— дип җанланып китә агай,— партия бит ул Ленин партиясе...

Мөгаен, бу агай Татарстанда Ленин чакыруы буенча РКП(б) сафларына баскан беренче кеше булгандыр. Ленинның үлеме миллионнарны кузгата, 24 январьда Партия Өлкә Комитетына беренче коллектив гариза керә.

«Бу кайгылы атнада без, 4 нче янгын сакчылары части эшчеләре, бертавыштан барыбызны да Коммунистлар партиясенә член итеп алуыгызны үтенәбез»,—дип язылган була анда.

Икенче көнне Ленин исемендәге завод эшчеләреннән һәм башка коллективлардан гаризалар килә. Бер айдан азрак вакыт эчендә Татарстанда 1955 кеше, партиягә алуны сорап, гариза яза.

Газеталарга көн саен кайгы белдергән меңнәрчә хатлар килеп тора.

«Ленин васыятьләре безнең өчен мәңге изге,— дип язалар «Пролетарий» урман заводы эшчеләре. Барыгызны да Коммунистлар партиясе байрагы тирәсенә берләшергә чакырабыз».

Студентлар Владимир Ильичның туганнарына хат язалар. Егетләр һәм кызлар гомуми җыелышта чын ленинчылар булырга ант итәләр.

Крестьян Семенчев болай дип яза: «Без Кокушкино авылыннан бер генә чакрым арада яши идек. Кечкенә вакытта Володя белән еш кына бергә уйный, Кадылка елгасында балык тота идек. Ул бар нәрсәсен крестьян балалары белән бүлешә иде. Крестьяннар йөрәгендә Ленин исеме мәңге яшәр!»

26 январьда ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты түбәндәге карарны чыгара:

«Пролетариатның бөек юлбашчысы Владимир Ульянов-Ленинның һәр эшчегә һәм крестьянга бик кадерле исемен мәңгеләштерү максаты белән:

1. Казан дәүләт университетына Владимир Ильич Ульянов-Ленин исемен бирергә.

2. Татарстан республикасының башкаласы Казан шәһәрендә В. И. Ульянов-Ленинга һәйкәл салу өчен махсус фонд булдырырга.

3. Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршында һәйкәл салу фондының Үзәк комиссиясен оештырырга.

Ике көннән соң Казан биржа комитеты Ленин фондына алтын белән биш йөз сум акча кертә. Эшчеләр, кыен яшәү шартларына карамастан, үзләренең бер, ике атналык, хәтта бер айлык хезмәт хакларын Ленин фондына тапшыралар. Хатын-кызлар, әбиләр сандык төпләрен актарып, беләзек-алкаларын алалар да фонд файдасына җибәрәләр. Казан дәүләт банкысында 69 номерлы счет Ленин фонды счеты булып әверелә. Монда иртәдән алып кичкә кадәр бу көннәрдә һәрвакыт чират була: һәркем, хәленнән килгәнчә, Ильич истәлеген мәңгеләштерүгә өлеш кертергә тели...

Ел ярымнан соң, хезмәт ияләре җыйган акчага Казанда В. И. Ленинга һәйкәл салына. Бу һәйкәл әле дә В. И. Ленин бакчасында тора...

* * *

...Союзлар йортының Колонналы залы. Фасадка: «Юлбашчының үлеменә зур тупланганлык, ныклык һәм корыч дисциплина белән җавап бирик!» — дип язылган. Кешеләр агымының очы-кырые юк. Чират зур, Дмитриевка урамы белән килеп, боргалана-боргалана, Союзлар йортына кереп югала да озын коридорлар буйлап дәвам итә. Тынлык. Менә соңгы борылыш. Залда ярым караңгылык. Уртада табут.

— Ильич!

Һәр ике якта — почетлы сак. Сул якта — Бохарметова Нурдидә. Аны ТАССРның Сәүдә Халык комиссары Бажанов алыштыра.

Ишек төбендә кызылармеецлар винтовкаларын нык кысып сакта торалар. Кар ява. Ә халык агымының очы да кырые да күренми. Менә Татарстан пролетариаты вәкилләре Мөбарәкшин, Сафин, Флиндре, Дубровина, Козлов атлыйлар. Башлар иелгән. Алар белән меңнәр...

— Хуш, Владимир Ильич!

* * *

Зур театр.

26 январьда бирэдә Советларның икенче съезды кайгы утырышына җыйнала.

Трибунада Калинин:

— Без Владимир Ильичны кумәбез,— ди ул.— Аның васыятьләрен изге итеп саклыйк!..

Крупская күтәрелә:

— Бу көннәрдә,— ди ул, тын гына,— аның табуты янында торганда, мин Ильичның бөтен тормышын күз алдымнан кичердем. Менә мин сезгә шуны әйтергә тиешмен. Владимир Ильичның йөрәге барлык хезмәт ияләренә кайнар мәхәббәт белән типте. Менә шул хис аны дәртләнеп җавап эзләргә мәҗбүр итте: изелүдән котылуның нинди юллары бар? Бу җавапны ул Маркстан тапты. Ул эшчеләр янына барды. Ул алар янына укытучы булып түгел, иптәш булып килде. Ул аларга сөйләп кенә калмады, бик игътибар белән алар сөйләгәнне дә тыңлый иде...

Коммунист иптәшләр! Ленин байрагын — Коммунизм байрагын югары күтәрегез!

Шул ук көнне Советлар съезды Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы карарын раслый:

«Союз Үзәк Башкарма Комитетына килгән бик күп мөрәҗәгатьләргә, күп санлы делегацияләрнең теләкләренә җавап итеп, күмү көнендә Мәскәүгә килеп җитәргә өлгермәгән барлык теләүчеләр өчен... СССР Үзәк Башкарма Комитеты карар бирә: Владимир Ильич гәүдәсе салынган табутны төрбәдә (склепта) барлык кешеләр керерлек итеп ясарга.

Төрбәне Кызыл мәйданда, Кремль стенасы буенда Октябрь революциясе көрәшчеләренең туганнар каберлеге янында корырга...»

Мәскәү урамнарында учаклар яна. Тирә-якта төтен. Кремль стенасы буенда архитектор Шусев җитәкчелегендә вакытлы мавзолей төзелә. Гаҗәеп кыен эш була бу: юк, ломнар да вата алмаслык каты җирне казудан түгел, бозлы балчыкларның биткә сибелүеннән дә түгел,— чөнки алар рус җиренең бөек улы өчен кабер казыйлар...

* * *

27 январь. Колонналы зал. Нәкъ сигез тулганда разводящий табут янына сак куя: Калинин, Сталин, Томский, Дзержинский. Һәрберсе янында эшчеләр. Дипломатлар ложасы чит ил дәүләтләре вәкилләре белән тулы. Зур театр оркестры Вагнер, Моцартның матәм маршларын уйный. Менә музыка тына.

Барысы да җырлый:

«Сез корбан булдыгыз авыр көрәштә...»

Команда яңгырый: «смирно! Алты эшче табутны җилкәләренә күтәрәләр. Табут өстенә Коминтерн, РКП(б) Үзәк Комитеты, электәге политкаторжаннар байраклары иелә.

Ильичны күмгәндәге кебек авыр кайгылы вакыйганы күз алдына китерү дә кыен. Халкыбызның ул вакыттагы тормышка, киләчәккә омтылыш белән тулы гаҗәп дулкынландыргыч анты кешеләр күңелендә, тарихта мәңге сакланыр. Бу кайгылы атнада миллионлаган хезмәт кешеләренең революцион омтылышлары, бөек Октябрь эшенә бирелгәнлекләре, аның идеалларын һәм казанышларын сакларга соңгы чиккә кадәр әзер булулары бөтен Җир шары буйлап кайтаваз булып яңгырады. Бу көннәрдә РСФСР Советларының XI съезды делегаты татар кызы Бохарметова болай ди:

— Без Совет властена кул ягарга һич тә мөмкинлек бирмәбез!

Кешеләр бу кайгылы көннәрдә нинди генә көчле, нинди генә хак сүзләрне кабатламыйлар!

Менә алар:

— Коллектив аңында Ленин үлемсез!

— Юлбашчыларның үлүе мөмкин, ләкин революция яшәячәк!

— Ленин үлде, ленинизм яши!

— Беркем дә безне ярты юлда калдыра алмас!

Эшчеләр һәм крестьяннар алдан ук Кремль стенасын веноклар белән күмәләр.



*В. И. Ленин табутта.*

Казан типография эшчесе Козлов һәм Бондюг делегатлары үз венокларын мавзолей ишек төбенә куялар. Менә күмү процессиясе мавзолейга якынлаша. Оркестр «Интернационал» уйный. Барысы да баш киемнәрен салалар. Кызыл мәйдан ун меңнәрчә кешеләр белән тулы. Алар баш өстендә меңнәрчә байраклар җилферди.

Спасс манарасындагы сәгать уклары дүрт тулырга биш минут күрсәтә. Тынлык...

27 январьда, 15 сәгать 59 минутта Советлар Союзының телеграфы әле тарихта беренче тапкыр эшен туктата. Нәкъ 16 сәгатьтә илнең барлык телеграф аппаратларында шундый сигнал ишетелә:

— Аяк өстенә басыгыз, иптәшләр, Ильич кабергә куела.

Дүрт минуттан икенче сигнал яңгырый:


— Ильич үлде, ленинизм яши!

Бу вакытларда Казан кешеләре барысы да диярлек урамда була. Паровозлар, фабрика-завод гудоклары кайгылы симфония булып бөтен шәһәр өстенә яңгырый.

Әгерҗедән килгән берәү болай ди:

— Гудоклар да хәтта елыйлар...

Траур колонналары Ирек мәйданына, Вахитов мәйданына, Беренче Май мәйданына агыла. Митингларда партия хезмәткәрләре, гади эшчеләр сөйли. Вахитов мәйданына җыелган халык алдында Кокушкино авылы крестьяны Матвеев болай ди:



*Халык юлбашчы белән саубуллаша.*

«Кадерле Ильич — безнең якташыбыз. Ул безгә җир бирде, канечкеч алпавытларны куды»...

Митинг тәмамлана. Резолюция кабул ителә:

«Без, Болак арты, Плэтән районы эшчеләре һәм эшче хатын-кызлары, Ильич васыятьләрен үтәргә ныклы ант бирәбез. Партиябез тирәсенә ныграк тупланырга чакырабыз».

Ирек мәйданы. Халыкның кайнар сулышыннан һавага пар күтәрелә. Салкын, ләкин беркем дә аңа игътибар итми. Ораторны оратор алыштыра. Трибунада яшь эшче.

«Без ячейкада теге яки бу карарны кабул итәбез икән,— ди ул,— һәрвакыт үз-үзебездән сорыйбыз: бу очракта Ленин нишләр икән? Хәзер ул юк, ләкин Ленин партиясе бар. Ул безгә якты киләчәгебезгә юл күрсәтер»...

Халык Ильичны күргән, аның белән сөйләшкән, аның чыгышларын тыңлаган кешеләрне аеруча зур игътибар белән тыңлый. Менә трибунага ак сакаллы карт менә. Ул — Феклин. Ульяновлар семьясы Кокушкинода торганда Феклин Володяны атына утыртып йөрткән. Үзенең чыгышын ул болай дип тәмамлый:

«Ленин биргән барлык нәрсәне безгә нык сакларга кирәк...»

Бөтен Татарстан үзенең Ленинга турылыклы булуын демонстрацияли. Буа кантоны авылларында кешеләр «Интернационал» җырлап демонстрацияләргә чыгалар. Лаешта демонстрациягә ике меңнән артык кеше катнаша. Спасс эшчеләре затонны Ленин исеме белән атыйлар. Түбән Ослан елгачылары Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына үз затоннарына «Ленин истәлеге» исеме бирүне сорап мөрәҗәгать итәләр. Кукмарада почта бинасы янына митинг җыйнала. Аңа волостьтагы барлык аучыларны чакыралар. Нәкъ сәгать 16 да алар 86 мылтыктан 25 залп бирәләр...

Бу бөек кайгы көннәрендә хезмәт ияләре үз көчләренә тагын бер кабат ышаналар: әйе, алар җиңәргә сәләтле! Әйе, алар гасырлар буе зур акыл ияләре хыялланган дөнья — хезмәт хакимлек иткән дөнья төзә алалар һәм төзиячәкләр!

30 январьда Ленинны күмүгә катнашкан Татарстан вәкилләре Казанга кайта. Полиграфия эшчесе Козлов иптәшләренә болай сөйли:

— Табутны әкрен генә Кремль стенасы янына китергәндә, елашу башланды. Мәйдан халык белән тулы иде... Алтынчы ячейка һәм эшчеләр әманәтен үтәдем. Венокны куйдым.

46 ел элек Татарстан хезмәт ияләре, барлык совет халкы белән, Ленин эшен тулы җиңүгә кадәр дәвам итәргә ант бирделәр. Ант үтәлде. Бу — Ильичка иң яхшы, мәңге шиңмәс венок. Һәр елда, һәр сәгатьтә без бу венокка яңа чәчәкләр үрәбез: бу — миллионнарча тонна нефть, яңа йортлар, заводлар.

* * *

Ильичны соңгы юлга озаткан, аңа ант биргән кешеләрнең күбесе безнең арабызда инде юк. Владимир Ильичны күмүгә катнашкан Татарстан делегациясе членнарыннан Нурдидә әби Бохарметова исән әле. Ул хәзер дә Чаллы районы Биклән авылында яши. Мәскәүдән кайткач, ул Коммунистлар партиясе сафына кергән.

Күптән түгел мин аның белән очраштым. Моннан 46 ел элек узган көннәрне исенә төшергәч, аның күзләренә яшь килде.

Тынычлангач, Нурдидә әби РСФСР Советларының XI съезды делегаты мандатын, съезд эше бюллетенен, андагы чыгышларның стенограммасын, Союзлар йортына, Кызыл мәйданга керү өчен Дзержинский кул куйган пропускны күрсәтте. Аннары нәрсәдер хәтерләп, беравык уйланып торды даниндидер бер төргәкне чишәргә кереште. Аннан дүрт почмаклы бер значок алды. Значокка Владимир Ильич рәсеме һәм бер-берсенә аркылы ике флаг рәсеме төшерелгән. Мондый значокларны В. И. Ленин табуты янында Почетлы сакта торган кешеләргә биргәннәр икән. Ә Нурдидә Бохарметова Ильичны Горкадан Колонналы залга, Союзлар йортыннан Кремль стенасына кадәр озата барган.

Әңгәмәне тәмамлап, ул болай диде:

— Яшьләр дә, безнең буын кебек үк, сөекле юлбашчыбызның васыятьләренә тугрылыклы булсыннар!

## Сибгат Хәким

# Васыятьләр

ПОЭМА

I

Декабрь... Яратмыйм шул айны,
Яратмыйм, рәхимсез эш итте.
Ул мине гомергә үксетте,
Ул мине гомергә өшетте.
Борчулар кайтарды. Кайгылар
Йөриләр басып гел ник эзгә?
Нигезем... Гомеремдә мин күпме
Еладым ятып шул нигезгә.
Декабрь... Кырларның төсе юк,
Бар нәрсә охшый күк кәфенгә.
Карадым әнкәйгә: юлларым —
Әнкәйнең агарган чәчендә...
Аңладым: әнкәйдән бөтен моң,
Шигырьне мин кемгә укырмын?
Эчеңдә үз җылың булмаса,
Файдасы юк икән уколның.
Сабый чак... Ачлыктан еладым,
Яңаны кыштан ук көтәләр.
Кайда сез, чабагач тигәч тә
Шыбырдап нур чәчкән көлтәләр?
Ни генә язса да гел шушы
Нигездә, беркая чыкмаган.
Кышкы төн, атыла йолдызлар,
Ә җирдә ул суккан чыпталар...
Суыктан еладым... Буранда
Сыеныр куак тап, чокыр тап.
Кайда син, адашып тилмерткән
Бер күзе — уң күзе — сукыр ат...
Утырдым мин әнкәй катында,
Коткарыр нәрсә бар я, синдә?
Малае янында, ул һаман
Саташты калды дип әсирдә.
Саташты. Тәрәзә төбендә
Улады декабрь, шомлы кыш.
Җәфалый кайчандыр күңеленә
Бер кереп утырган шомлы төш.
Шомлы төш: яна ат абзары,
Ут капкан атның да ялына.
Ә әнкәй: ачыгыз абзарны...
Кычкыра, ул елый, ялына...

Бәрелде, сугылды җирән ат,
Сикерде арата өстеннән...
Әнкәй киң сулады: котылды,
Төште дип кара тап өстеннән.

Утырдым мин әнкәй катында,
Әнкәйгә — нигезгә таяндым.
Күршедә солдатка озаталар,
Тавышы тынмады тальянның.
Юлына ашыкты яшь солдат
Кысты да әнкәйнең кулларын...
Тукталмый бу тормыш, иртәгә
Әйтерләр кем югын, кем барын...
Сугышны еракта калды дип
Сөйлиләр... Кич сызлый буыннар...
Өлгерде яшь буын, борчулы
Хатлары Уссури буеннан.
Сугышны еракта калды дип
Сөйлиләр тыкрыкта кич белән.
Тәсбихы кулында әнкәйнең,
Җитмиләр төймәләр-дисбиләр...
Утырды тын гына, тәсбихта
Төймәләр беткәннәр шомарып.
Минем бар уемны үземә
Сөйләде, карадым шомланып.
Мин аның каршында үземне
Шагыйрь дип атарга оялдым.
Мин түгел, ул — шагыйрь, утырды
Нур белән тутырып өй алдын.

Кашыклап су салам: үлмәсен...
Кузгатып урыннан авыруны,
Уйнады урамда, буранда
Шул иске, шул татар гармуны.
Кашыклап су салам... Минутлар,
Кешене ник җирдән аерасыз!
Басуда тирләрне сыпырып
Эшләгән вакытлар, кайда сез?
Кашыклап су салам... Ул яна,
Йолырмын шикелле мин уттан.
Кайда сез, үлемне бар дип тә
Белмәгән, кадерле минутлар?
Шул нигез, ил белән, җир белән
Бәйләгән җепләрне син өзмә.
Декабрь... Нигездә елый җил,
Икәүләп елыйбыз нигездә.
Декабрь... Кермәсен бураннар,
Ишекне куйганнар киезләп.
Нигезем... Шул туган нигезне
Моңнарың буенча кил эзләп.

2

Декабрь... Шыгырдый капкалар,
Алар да зарлана, күрәсең.
Башыма гел сугып тора күк
Капканың күгәргән келәсе.

Керәләр туктаусыз. Ут тонык.
Тынлыкта сәер бер хасыять бар.
Күңелләр сафлана, онытылып,
Ашыкмый сөйләнә васыятьләр.
Әнкәйнең васыяте: кайткала,
Ташлама, таратма бу йортны.
Бабаңнар рухы бу нигездә...
Ул тагын бер тамчы су йотты.
«Бәхиллим» бәхилләп бетермәү
Шикелле ишетелде, я, хода!
Кем нинди васыять калдырган,
Кем кемгә укыган бәддога,
Яңарды барысы да, яшь белән
Яңарды мәңгегә ризалык...
Тугач та шул изге сүзләрне
Күңелемә куйганмын мин салып.

Өстәлдә самовар, нияте:
Өй эчен тутырып шауласы.
Кем телгә алынса, ак карда
Сузыла мәһабәт шәүләсе.
Тәрәзә каршында шәүләсе...
Кем йөрер шушындый төндә соң?
Атаклы әкиятче Әхмәтҗан...
Әхмәтҗан, кер өйгә, туңасың.
Әхмәтҗан... Ул вафат, күптән юк.
Чабата, ак тула оектан.
Бер ымсыз, бер сүзсез, бер өнсез
Баскан да тик тора, боеккан.
Тәрәзә каршында шәүләсе.
Көртләрдә безнең ут яктысы.
Ник болай боектың, кер, әйдә,
Әйтерсең, без сиңа ят кеше.
Түргә уз, ягымлы сүз белән
Юат бер, әнкәй дә тыңласын.
Онытыйк үлемне, Әхмәтҗан,
Чуалт бер әкиятләр дөньясын.
Әхмәтҗан тутырган әкиятләр
Саклана эчендә тартмамның,
Әйтерсең, тартмамны ул йөргән
Сукмактан, тузаннан тапканмын.

Ул күрше авылдан, ә бездә
Зур базар — бер тапкыр атнага.
Атлады сукмактан таң белән
Тузанны актара-актара.
Акчасы вак-төяк, акчасы
Бик эчкә нык җыйнап куелган.
Борынгы ташларга күз са́лып,
Атлады ул зират буеннан.
Алмады, сатмады. Уртага,
Калку бер урынга басар да,
Кузгалмас, күзәтер ул шуннан,
Әйтерсең, дирижер базарга.
Әхмәтҗан җаена җайланган
Бу базар, иртә я соң була.

Алмады, сатмады. Бары тик
Белеште, сорашты — шул гына.
Чайкала бар дөнья... Дирижер...
Я салам, я камыш кулында.
Хәлен ул аңлатыр йөрим дип,
Я — сабан, я — арыш кырында...
Сабанда йөрим ди, янәсе
Ашыйм ди ул бодай икмәге,
Күзендә хәйләкәр елмаю:
Өлгереп җитмәгән тик әле...
Алмады, сатмады, карады,
Юанды... Моңа бик күп еллар.
Кайдадыр чыгарга җыена
Кырларга беренче фордзоннар.
Базарда татарлар, марилар,
Күлмәкләр ал, кызыл нәкышлы.
Тәңкәләр, чулпылар чыңыннан
Кешеләр бер-берсен табышты.
Татарлар, марилар... Төрле тел...
Аер син Иләттән Ашытны.
Алмады, сатмады, кешеләр
Әхмәтҗан янына ашыкты.
Ул узып баручы марига
Кычкырыр: зур рәхмәт — тау сиңа! —
Ике дус халыкның мәҗелестә
Чәкешкән чаклары тавышында.
Туган як җиләндә җылыткан,
Эреткән сүзләрнең җилемен,
Базарга куш учлап сипте ул
Мәкален, мәзәген җиренең.
Туган тел — аның бар байлыгы,
Аякта чабата — сүс баулы.
Базардан әллә ни кермәде,
Күңелдә уелып сүз калды.

Әхмәтҗан миңа гел ак булып
Күренде — ак сакал, ак ыштан.
Каршыма нәкъ Хозыр Ильястай
Чыкты ул һәрвакыт арыштан.
Чыкты ул арыштан, текәлдек
Илаһи зат итеп без аңа.
Йөргәндер көн буе сөйләшеп
Арышта, кунгандыр ызанда.

Халыкның бәйрәме... Бәйрәмдә
Яшьтән үк буталып үсelгән.
Әхмәтҗан... Эзләдем мин аны,
Эзләдем гел халык эченнән.
Барысы да халыкта, фәкать шул
Халыкта! Мин кабат аңладым,
Шул Казан артының күңелдә
Бастырдым мин кала-тауларын.
Җыены, бәйрәме... Басуда
Рәхәт бер җылысы ашлыкның.
Ат, арба, канатлы тарантас
Буеннан буена Ашытның.

Картлар һәм карчыклар болында,
Түшендә шуышып йөргәне,
Болында — егерме авылның
Яшьлеге, гармуны, йөрәге.
Тау, анда куаклык, каберләр...
Изгеләр чишмәсе ургыла.
Тарихтан ташланган ташларга
Кылалар берьюлы ун дога.
Кузгатты Оренбург, Казанны,
Уйласам бу кала-тауларын,
Онытылам — рух яши мең еллык! —
Кайчакта ут ала тәннәрем.
Барысы да буталган: җыр, дога,
Моң тулган тирән бер зәңгәрлек...
Ашытта тегермән — биш ташлы,
Ашытта таллар нык, ярлар нык.
Әхмәтҗан үзенә яртысын
Караткан болында халыкның.
Әкияте җаена көйләнгән
Тегермән, тавышы чарыкның.
Сөйләде бүленеп — сүзләрен,
Әйтерсең, таллар да җөгләде.
Әхмәтҗан кулында бәйрәмнең,
Тарихның күренмәс җепләре.
Кайчакта күренде күземә
Әхмәтҗан сихерле тау булып,
Күченде, мин бардым артыннан,
Мин бардым сүзләргә табынып.
Язмышым шикелле бормалы
Шул Ашыт — тугайлы, тын сулы.
Сөйләде, ул салган сүзләрнең
Күңелдә мәңгелек тылсымы.
Рәхмәтем әйтергә язмады
Ичмасам бер шулар өчен дә.
Әхмәтҗан... Ник әле керде ул
Көтмәгән борчулар эченә?
Ник килгән вакытсыз? Өстендә
Ак кием, кайчаннан алышма.
— Нихәл? дим.
— Ярый, — ди, — искечә,
Туганкай, һаман шул арышта...
Васыяте — чакырган үлгәндә
Онытын: байлыгым тапшырам —
Саклана байлыгым халыкта,
Тирәндә, еракта, тап шуннан...

Әйтмәгез: Әхмәтҗан үлде дә
Бу халык барын да онытты.
Базарга күптәнге сукмактан
Икенче карт килә, оныклы.
Икенче карт килә, костюмнан,
Итектән, иркенләп тын алып.
Саный ул, йөзләгән трактор
Ял итә зиратка теләлеп.
Килә ул онытын җитәкләп,
Сөйләшеп, беркайда утырмас.

Исәпли: колхозда йөзләгән
Трактор, ат саны: утыз баш...
Килә ул оныгын җитәкләп.
Үзгәрде әкиятләр, күп җырлар...
Ил буйлап эзлиләр музейлар,
Кайда сез, беренче фордзоннар?
Килә ул оныгын җитәкләп,
Җор сүзне кем тели, шул тыңлар.
Шул базар: татарлар, марилар,
Тик инде чыңламый чулпылар.
Шауламый һәм кала-тавының
Бәйрәме... Сүтелде тегермән...
Бер чуен алтынын чыгарды
Бульдозер гасырлар төбеннән.
Берсенең мирасы булгандыр
Ул алтын... Үлемнән ул саклар,
Нигезне ул тотар дигәндер...
Өй тып-тын, сөйләнә васыятьләр,
Декабрь... Бураннар җиһанда,
Җиһанда күмелә күп эзләр...
Нигезем... Шул иске нигезне
Давыллар эченнән кил эзләп.

3

Декабрь... Кич, эңгер, күңелсез.
Күршебез пешергән өчпочмак...
Әнкәй тик капшады, капмады,
Карадык өй белән без кыстап.
Тыкрыкта — машина тавышы,
Ул тавыш бәрелде капкага.
Керде дә аптырап күреште.
Егетнең күзләре кап-кара.
Бу йортның буй җиткән кызына
Текәлгән карашы сөрлеккән.
Өстәлдә пыяла савытта
Ничә көн йокламый сөлекләр.

Ул гафу үтенде, аңлатты
Оялып, кызарып булса да...
Тукталмый бу тормыш, юана
Кыз биреп, кыз алып булса да...
Берәүләр йомгаклый, берәүләр
Каршылый санаусыз көннәрен...
Тукталмый бу тормыш, иртәгә
Әйтерләр кем югын, кем барын.

Декабрь... Сөйләнә васыятьләр...
Өй эчен бар читтән шәйләүче.
Кем телгә алынса, ак карда
Сузыла мәхәббәт шәүләсе.
Шәйдулла... Сугышта ул вафат...
Йөзенә өйдән нур сибелгән.
Ак карда шәүләсе... Шәйдулла
Колакчын бүректән, шинельдән,

Ул корды колхозны, колхозның
Байлыгы амбарда аз ята.
Үтте ул тыкрыктан таң белән:
— Ипиләр пешәме, Газзапа?
Тыкрыкның буеннан буена
Әнкәйнең тавышы: — Шәйдулла!
Кайтканда онытма керергә,
Ипием мичемдә, чәй була.
Колхозга ипи сал төн буе,
Ипигә юк җирдә ял көне.
Әнкәйнең йөзендә уйнады
Зур мичнең — колхозның ялкыны.
Утырды әнкәй мич каршында.
Тезгән дә йөзләгән кибәнен,
Елмая шатлыктан! Көтте ул
Ипинең йөзләре килгәнен.
Ипинең битенә су сипте,
Кызартты, суккалап карады, —
Ул гүя кулына яткырып,
Тирбәтте, уйнатты баланы.

Авышкан күпме ел. Күңелем
Юксына, сагышта, газапта,
Яңгырый һаман тар тыкрыкта:
— Ипиләр пешәме, Газзапа?
Шәйдулла... Ул корды колхозны.
Коммунист, эш күрсәт, үл, акла.
Ул корды, ул каты, ул коры:
— Басуга-станга, уракка.
Килсә бер фикергә, бүкәнгә
Нык итеп балтасын батырыр.
Бураның өстендә — ул үзе,
Хезмәттә ярышсын батырың.
Ул корды, күчтеләр урамнан
Ындырга келәтләр, амбарлар.
Күченде, кузгалды нигезләр,
Үзенә түгел бит, аңларлар.
Күчтеләр амбарлар. Тапшырдык
Атларны ялыннан тоттык та,
Атлар һәм хатын-кыз авазы
Яңгырап калды тар тыкрыкта.
Кечкенә, тар гына тыкрыкта
Орынмый, бәрелми җай гына,
Күрәштән, гаугадан бер читтә
Яшәсәң ни була, Шәйдулла.
Кузгалмас иде бу шау-шулар,
Урынына әкренләп куйганда...
Күчтеләр келәтләр — мәҗелесләр,
Кайчандыр гөр килгән туйлар да...
Ул корды... Әйттеләр: Шәйдулла
Хөкемнең үзеннән үткен дип,
Ярый ла ул янып бетмәсә
Урта бер төшендә утның дип.
Дошманнар батырды... Калыкты...
Иртәдән кичкәчә ындырда.
Әйтерсең, сугышка туп-туры
Атлады ындырдан — Одерга.

Ак карда шәүләсе... Бүректән,
Шинельдән, беркем дә кәтмәгән...
Әйтә күк: мин һаман чыгалмыйм,
Газзапа, давылдан, көртләрдән...
Без Сабан туенда аунаган
Күлмәкләр теләнгән паласка...
Шәйдулла үстергән имәннәр
Басуда полоса-полоса.
Һәр авыл читеннән кузгалып
Китә бер колонна — Шәйдуллар...
Кайларга, нинди чит җирләргә
Сиптегез аларны, әй, юллар?!
Шәйдуллар күп алар, миллионнар...
Күп киткән, борылып аз кайткан.
Буранлы декабрь төнендә
Йөриләр тынгысыз васыятьләр.
Күптәнге бик таныш авазлар
Мәңгегә артыңнан калмаслар,
Йөриләр тыкрыкта васыятьләр,
Йортлары — кешесез, кар баскан.
Утырдым мин әнкәй катында,
Авылның гади бер карчыгы...
Тамчылап су салам. Янымда
Зур Идел, кулда бал кашыгы.

4

Утырдым янында, уйландым:
Әнкәйнең ник үзен язмыйм соң?
Әнкәйдән аеру мөмкинме
Илемнең, халкымның язмышын.
Мин шулай башладым, ишеттем:
Юлларны урынында кисә бел...
Тутырдым тыгызлап шигырьгә
Ашыкмый җирнең һәр кисәген.
Җор сүзле Әхмәтҗан, Шәйдулла
Көн саен нигезгә җыелалар.
Кисәкләр... Мин ничек аларны
Ыргытыйм? Бер бөтен җир алар.
Кисәкләр... Мин ничек, мин кая
Ыргытыйм тормыштан үлемне?
Васыятьләр, яңарды васыятьләр,
Барысы да бер җепкә үрелде.
Утырдым янында, уйландым,
Күземә гел кабер күренә...
Калыкты икенче бер васыять
Буранлы декабрь төнендә.
Күпере, вокзалы, уты юк
Йөгемне илтүче юлларның,
Калыкты түреннән ул васыять
Егерме икенче елларның.
Җир әле тын ята, җир ярлы,
Җилләрдән җир әле теләнгән,
Калыкты ул васыять халыкның
Үзеннән, йөрәге түреннән.
Васыятьтә ил, дәүләт, киләчәк...
Васыятькә барлыгы — ун минут.

Уйлыйм да кабынам, шигыремә
Менә бит кайлардан үрли ут.
Көненә ун минут... Ун минут
Деньяны ул ничек киңәйткән,
Калыкты алыплар шикелле
Түбәннән хөр, азат милләтләр.
Васыятьтә язмышым... һәркемнең
Үз теле, үз йөзе, үз төсе...
Бер җыр аз, бер моң аз, бер тел аз,
Йөз телдә сөйләшеп үс, кеше.
Әйткән дә яздырган уйларын
Халыклар, булмасын бер яклы,
Төшкән ул васыятькә сузылып
һәр халык күңеленнән бер якты.
Шул изге васыять хакына
Гомереңне кызганма, кыл барын,
Укыйм да кабынам, яңара
Тарихым, хисләрем, моңнарым.
Декабрь... Еракта ул васыять,
Еракта, буранда ул төннәр...
Юлымны яктырткан ул төннәр
Сагышлы хис белән өртелгән.
Ил олы нигезгә әйләнде,
Сал яңа күперләр, төз, ныгыт.
Барсы да йоклаган тыкрыкта,
Буранда җемелди безнең ут.
Тамчылап су салам: үлмәсен...
Кәфенлек сандыкта, кисмәгән.
Кайда сез, урактан кайтышлый
Юлларда очраган чишмәләр?
Утырдым мин әнкәй катында
Булышып, мендәрен тигезләп,
Нигезем... Шул изге нигезне
Син, шагыйрь, үлгәч тә кил эзләп.

1969.

Аяз Гыйләҗев

# УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН

Роман [1]

30



Ниса бухгалтериягә кеше юграк чакны чамалап керде. Ишекне ике куллап сак кына япты, бүлдыра алган хәтле ягымлы итеп сәлам бирде. Үзенә гонорар тиешле өстәл янындагы урындыкка килеп утырды.

— Аз-маз акча бар иде шикелле, Ниночка.

Шунда ук Нина алдында ята торган «Социалистик Татарстан» газетасында шәмәхә кара белән кыеклап язылган таныш фамилияне күрде. Башта үз күзләренә ышанмады, бухгалтер Нина аның карточкасын эзләп картотекага иелгән арада терсәге белән газетаны үзенә табарак тартты. «Идрис Бакиров... Яшьләр редакциясе... 18 сум...»

Үз акчасын әллә алды Ниса, әллә алмады, рәхмәтен әйтергә дә онытып, бүлмәсенә кайтты, учындагы кыштырдавык кәгазьләрне өстәл астына тыкты, кире алды, ахыр чиктә, түзмәде, беренче катка төште. Саклык кассасы тәрәзәчеге төбендә тәбәнәк карчыктан башка берәү дә юк иде, ул песи сыман шыпырт кына аның артына чиратка басты. Нафталин исе аңкыткан бу карчык аз-маз сукыр да, азрак саңгырау да икән, ул квитанциясен борын очына тидереп карый-карый, тешсез үртләрын шапылдата-шапылдата шулай озак мыштырдады, Нисаның хәтта табан аслары чымырдап кычытты:

— Тизрәк маташыгызсана, әбекәй,— диде ул күзләрен ишек-баскыч тирәләренә йөгертеп.— Тизрәк дим...

Ниһаять, Ниса бәләкәй тәрәзәчеккә борынын тыкты...

Кулындагы Маркс томына саклык кенәгәсен кадерләп кенә яшергәннең соңында (тагын егерме җиде тәңкәгә кыйбатланды кенәгә!), ул олы эш майтарган кыяфәт белән ашыгып-ашыгып өченче катка менде, туп-туры редактор ишеген ачты.

— Керим әле мин, Рәкыйп туган,— диде ул, тәкъва гына.

— Керегез, кер, Ниса апа.

— Сез бернәрсә дә белмисездер, Рәкыйп туган...

— Дөнья йөзендә сез барында ни-нәрсәне белми калуым ихтимал икән? — дип шаяртты Рәкыйп.

---

[1] Ахыры. Башы узган елгы 10, 11, 12 саннарда.

Шаяртса да сабан туе көрәшчесе кебек жыелып, сагаеп калды, тагын кайсы яктан китереп каптырыр икән бу дигәндәй, Нисаны башыннан-аягына кадәр күздән кичерде.

— Бухгалтериядән чыгып килешем,— дип башлады Ниса кыяфәтенә серлелек, вәкарь чыгарып.

— Шуннан...

— Һич истә-оста югында коточарлык хыянәт ачтым!

— Ниса апа, бухгалтериядәге җинаятьләр турында халык контроленә шалтыратыгыз. Телефоннарын биримме?.. Я булмаса ОБХССка...

Үзенең мөһим, олы эшкә ябышуына шикләнмәгән Ниса алай ялан кул белән тотканга гына бирешмәде, көлеп куйды:

— Сез, Рәкыйп туган, гел шулай,— диде.— Юньләп сөйләргә керешкәндә телне бәйлисез дә куясыз!

Рәкыйп үзен тыя алды, тынычланды, тәмәке кабызырга маташкан Нисага:

— Үтенечем шул, зинһар, бүлмәдә тартмагыз. Иртәдән бирле башым чатный,— диде.

Ниса авызына капкан папиросын утсыз килеш әүкәли иде.

— Рәкыйп туган,— дип башлады ул редакторны үз күреп.— Күп кисәтә килдем, колак салмадыгыз. Сагайттым, ышанмадыгыз. Сотрудниклар сезнең йомшаклыкны күреп, әйе, хәтта ки, либераллыкны тоеп дияр идем, тәмам азындылар. Бөтенләй чыгырдан чыктылар.

Редактор аны бүлдерергә теләде, тыелып кала алды, учы белән өстәлне сыпыра-сыпыра:

— Тагын кайсыбызның җанын ашарга җыенасыз, Ниса апа? — дип сорады.

Ниса сискәнде, әмма сер бирмәде.

— Ни дигән сүзегез монысы, Рәкыйп туган? Һәрнәрсәгә күзе җитә торган кристаллдай саф Ниса апагыз барлыгына куаныр чакта, җәмҗал чакырып ямьсезләнеп утырасыз, килешмәгәнне.

— Куанам, Ниса апа, бик куанам!

— Идрис Бакировның нәрсә эшләвен беләсезме?

— Тизрәк ишеттерегез инде...

— Сезнең җилкәгә пычак кадый...

— Шулай укмыни?

Ярсуына күмелгән Ниса редакторның ачыктан-ачык ирониясен, мыскыллавын да абайларлык түгел иде, бичара, ул кинәнеп, җәелеп сөйләргә әзерләнде.

— Хезмәттәшләрнең байтагысы ялда... Калганнарыбыз газетага материал җиткерә алмый тинтерибез. Һәркем хәл кадәренчә эш, хезмәт дип көяләнеп йөргәндә ул малай нишли?.. Менә кайчан килеп чыга ул Әхәт Нуруллинның кәсафәте!.. Үзе булмаса да эшәке вирусларын редакция бүлмәләрендә үрчетеп ята!

— Нәрсә эшләгән Идрис? — диде тәкате корыган Рәкыйп.

— Эш белән җитәкчелек иткән кеше барыннан да элек каты куллы булырга тиеш иде дә бит, кайбер тармакларда җинеллеккә җибәрдек,— дип тезде Ниса редакторның ачуы чыгуын абайламыйча.

— Ни эшләгән ул?!

— Материалын башка газетага биргән. Эзен яшерер өчен псевдоним белән чыгарган.

— Миннән рөхсәт сорады,— диде Рәкыйп, гәрчә бу турыда берни белмәсә дә.

— Ничек? Сез... күрә торып ирек бирдегезме?

— Идрис — журналистлар союзы члены. Аны башка газета-журналларда язышудан беркем дә тыя алмый!

— Вакыты бит, вакыты,— дип ыңгырашты чын күңеленнән Ниса.

— Күпме акча язганнар үзенә.
— Унсигез сум.
— Бездә ул материал өчен сигез сум алыр иде.
— Журналист акча турында уйлый алмый...
— Бакиров жилдән җиң тегеп йөрүче зат түгел, аның гаиләсендә һәр яктан кыен, авыр вакыт. Без монысы белән исәпләшмичә булдыра алмыйбыз.
— Үзегезнең җитәкчелек авторитеты какшаганын сизмисезмени? — дип инәлде Ниса.
— Ниса апа,— диде Рәкыйп, куллары белән өстәлгә ябышып.— Сез әллә минем корыч бугаз белән генә алдыра торган, һәр инициативаны буып торучы редакторга әйләнүемне телисезме?
Ниса авызында әүкәләп кыйшап бетергән папиросын тәрәзәдән ыргытты да икенчесен алып шырпы кабызды.
Рәкыйп барып тәрәзәне кинрәк ачты, күлмәк якасын кайтарып җилләнде:
— Эссе!
— Идрисне бер җәзасыз калдырыйк дисез алайса?
— Әйдәгез, җыелышыйк та аны куып чыгарыйк.
— Куарга димим...
— Шулай дип әйтеп карагыз.
— Өйрәтергә кирәк, Рәкыйп туган!.. Ул безнең изге бурычыбыз!
— Минем өйрәтәсем килми, Ниса апакаем... Сез, без пәйгамбәрләрме? Тормыш барыбызны да үзе өйрәтә... Дөресен әйтим, Идрисне өйрәтергә көчегез җитәме?.. Дөрес, аның характерында сугышчанлык җитенкерәми, вакыты белән анысы да табылыр! Әмма егет төпле. Никадәрле материал тикшерә, эшли, газетага күпме яза, өстеннән бер жалоба килгәне бармы?.. Нигезле тикшерә, чебен борын тыгарлык урын калдырмый... Газетадан башка тормышы юк аның, бөтен көчен бирә, җанын кызганмый... Миңа калса, әнә шундый яшьләрдән сезгә өйрәнергә кирәк, Ниса апа!
— Миңа?!.
Чәймилова күзен акайтып, хәтта ялгыш ишетмәдемме дигән шикелле, алгарак иелеп катып калды.
— Әйе, сезгә... Клуб ишегендә йозак, фәлән инешнең басма култыксасы кыйгайган дип комнан бау ишеп, сәнәк белән су сөзеп утырудан ни файда? Яшьләр андый вак-төякне, каурый белән теш арасында казынуларны укып та тормыйлар.
— Алай... Нигә басасыз ул чагында андый мәкаләләрне?
— Чөнки сез башкача эшли белмисез, ә ныклап таләп итәргә бездә либераллык көчле.
— Сез... Мин... редакциядә яраксыз элемент булып чыгаммы?
— Андый раслауга барып җитмәдем, тик үтенәм: заманча, кирәгенчә эшләүче яшьләргә кагылмагыз. Болгатмагыз саф суны!.. Менә Идрискә ГДРдан килгән архитекторны ышанып тапшырдык. Әйтегез әле, сез аның белән йөри алыр идегезме?
— Нигә йөрмөскә?.. Германиядән килгән дигәч тә, әллә кем түгелдер, берәр фашист калдыгыдыр...
— Менә, сез шулай гына әйтә аласыз... Ә мин бүген тып-тыныч, Идрис сынатачак түгел. Әхәт кебек, Идрис кебек егетләр барында эшләү рәхәт, яшәү күңелле. Кая барсаң да йөзең ак.
— Әхәт кебек?
Нисаның чырае чытыкланганнан чытыклана бара иде.
— Әйе, Әхәт кебек. Җае чыкканда әйтим, Нуруллин редакциягә кайтырга җыена. Гариза бирде. Мин аның теләгенә каршы килмәдем.
— Бу мөмкин түгел! — дип чәрелдәде саклыгын онытып Ниса.— Акылга сыймаслык хәл! Һич! Әгәр алайга китсә, я ул, я мин!

— Үзегез чамалагыз, Ниса апа,— диде Рәкыйп тыныч кына.— Сайлау хокукын үзегез бирдегез... Мин Әхәтне сайлыйм.

Чамасы Нисага беренче тапкыр хыянәт итте, ул үзенең җитәкчесенә яман сүзләр әйтеп бакыра башлады. Төкерек чәчте. Чөнки Рәкыйпнең тәкъдиме Ниса күңеленә гомергә дә килә алырлык түгел иде. Рәкыйп аның бушануын тын гына күзәтеп торды, аннары салкын гына:

— Ниса апа,— дип башлап китте.— Сез теләсәгез кем янына, теләсәгез нинди дәгъва белән бара аласыз. Мин бүгенге көндә раслап куелган редактор...

— Алай булганда, мин монда кала алмыйм.

— Үзегезне лаеклы төстә озатырбыз.

Песи күк кенә кергән Ниса яралы киек кебек үкереп чыгып китте. Ишек ябылуга, Рәкыйп бер секунд тормыйча Әхәткә шалтыратты.

— Синме бу?.. Телевидениедә эшләрең кай тирәдә?

— Норма!

— Бер-ике көннән монда күчә аласыңмы?

— Күрәм: хезмәттәшләр дипломатик арадашлыкны нығытуга күчәләр. Редактор куркынычлы цейтнотта... Барометр көне-төне давыл буласын күрсәтә... Шулаймы?

— Чыга аласыңмы, юкмы?

— Башлаган эшне өч көндә тәмамлыйбыз. Шуңарчы түзәр мәлең бармы?

— Хәзер монда кил... Телефоннан аңлашып булмый...

Әхәт озакламый килеп тә житте. Ул ябыгып, йөзе сураеп киткән, һәрчак ялбыр йөрткән чәчен бераз кыскарткан, әмма күзләрендә шул ук дәрт, нур сирпелеп тора. Сүзсез генә кул бирештеләр.

— Инҗилдәге адашкан азгын малай атасы йортына кайтты... Җылашабызмы? — диде ул, көлемсерәп.

— Куйчы, картлач.

Әхәт шундук тонын үзгәртте:

— Син борчылгансың, шеф, күрәм.

— Бераз бар.

Чак кына тын утырдылар.

— Тәвәккәлләп сугыш ачарга җыенасыңмы?

— Әйе.

— Алайса союзникларны туплыйсың инде? Әллә детонатор гына кирәкме?

— Сугышырга туры килер микән? Ниса редакциядән китәргә булды.

Әхәт галстугын чишеп ыргытты, туктаусыз шаркылдап, тып-тып биергә тотынды:

— Ходаем, Хуҗа Баһаветдин, Кәҗә Гыйльметдин, Саескан Камалетдин һәм «Чаян»нан хаксызга сөрелгән Сәйфетдин белән Котбетдин рухына багышлап тост тотар идем! Яхшылыгың җәлләмә! Ичмасам, сирәк-мирәк булса да, кодрәтеңне күрсәт: коткар безне шул афәттән!

Ул туктап Рәкыйпне кочаклады, инде тынычланып урыннарга утырышабыз дигәндә ишек ачылды, анда иреннәрен тегәрҗеп калынлыгы гына калдырып кыскан, күм-күмгәк яңаклары эчкә баткан Ниса күренде. Ул Әхәткә күзенең агы белән генә карап алды да Рәкыйп өстәле янына атлады, ике учы белән таянды, көрсенде, тонык, җансыз тавыш белән:

— Рәкыйп Шәкүрович, мин бая аз-маз кызып киткәнмен,— диде.— Кичерегез... Редакцияне ташлап чыгарга көчем житми. Моңарчы кулга-кул тотынышып, бергә-бергә ярдәмләшеп эшләдек. Моннан соң да шулай яшик... Хәзерге хәлендә коллективны ташлап чыгарга намусым кушм

Ул жавап көтеп идәнгә текәлде.
— Үзегез әйбәтләп уйлагыз,— диде Рәкыйп, хәле китеп.
Ниса сүзсез генә ым какты һәм кулөгә шикелле шыпырт чыгып китте.
— Ну, артист! — дип шаркылдады Әхәт.— Ну, кылана!.. Мондый чагын күргән юк иде, нык кыскансың, ахры үзең! — Редактор жавап урынына ияген биетте.— Кулга-кул тотынышып пенсиягә кадәр, шеф мөхәррир!
— Нишлисең,— дип көрсенде Рәкыйп.
Икесе дә аптырашта калдылар, сискәндереп телефон шалтырады. Рәкыйп Әхәткә китмәскә кушып ишарәләде дә трубкага үрелде.
— Бу мин, Рәкыйп абый.
— Идрис?.. Әхәт тә монда. Өч көннән сезнең бүлектә иске «яңа мөдир!»
— Менә бусы кәттәсе! Шә-әп, Рәкыйп абый. Яшибез икән бер! Трубканы шул сәфәрчегә бирегез булмаса! Әхәт, сәлам, чуклы-чачаклысы! Бирешмә, әй!..

## 31

Күз будымыни, Виталий Петровичның үзе янына артка кереп утырганын Идрис сизми дә калды.
— Кузгал да акрын гына бар, Вася,— диде Жаденко шоферга.
Гостиницаны артта калдырып, стадион яныннан бара башладылар. Виталий Петрович эсселектән гажиз булып пиджагын салып тезенә куйды, сүзне жиңел генә итеп каянрак чәлмәргә, ничегрәк тәмамларга икән дип баш ватып утырды. Әгәренки алар Идрис белән электән танышып, хәтта кайбер мөнәсәбәтләрдә дошманлашырга да өлгермәгән булсалар, хәзерге минуттагы аңлашу бик ансат кына узар иде!..
— Безнең театрлар гастрольләрдәме? — дип сорады ул «безнең» сүзенә аерым басым ясап.
— Җәен шулай инде...
— Быел кайларда алар?
— Камал исемендәге театр Ленинградта. Зур театр Пензада. Операчылар нефть районнарында йөриләр.
— Ленинградта нинди телдә чыгыш ясыйлар инде алар?
— Әлбәттә, татарча. Мәскәү, Ленинград, Свердловск кебек зур шәһәрләрдә безнең агай-эне байтак яши...
Сүз Виталий Петрович өчен уңай башланды болай үзе...
— Без кунакка буш сәхнәләрне генә күрсәтеп чыгабыз була инде?
Идрис тезенә учы белән суккалап көлде:
— Театр — бер чакта да буш булмый, анда бөек рух саклана, Виталий Петрович. Мин шулай уйлыйм... Әйтик, безнең рус драма театры илебездәге иң мөгтәбәр храмнарның берсе. Качалов уйнаган, Савина чыгыш ясаган сәхнә алдында баш иеп тору үзе-үк тетрәтерлек вакыйга түгелмени?.. Академия театры фойесында оештырылган күргәзмәдә һушыгыз китеп торганыгыз бардыр сезнең... Үзем калса, барган саен, кайчандыр яшәгән, моңарчы күрелмәгән эшкә тотынган дәртле кешеләрнең узган юлына сокланып, таң калып кайтам... Бер яктан царизм кыса, чамасыз изә. Рус булмаган милләтләрне йотар өчен аларның телләрен, сәнгать-әдәбиятларын буарга кирәк була. Икенче якта архиреакцион мөселман динчеләре, фанатиклар, бакыр башлы күсәкләр... Татар динчеләренең, рус карагруһчыларының бергә тоташкан зынҗырларын өзеп, ниһаять, егерменче гасыр башында татар милли театры төзелә. Атаклы Галиәсгар Камал, бөек Кариев, җир йөзендә яшәү барында мәңге онытылмас Сәйдәшләргә бәйле театрда булып чыгу Курт Карл өчен ифрат гыйбрәтле булачак...

Машина Ленин урамы буйлап тавышсыз гына барды. Университет янына житкәч, Жаденко, ым белән, Васяга борылырга боерды. Элек «Бегемот» исеме белән данлыклы биш катлы мәһабәт йорт янына житкәч, ул туктарга кушты.

— Көт шушында чак кына, Вася!

Идрис аңа сораулы күз белән карады.

— Монда кагылыйк әле, иптәш Бакиров.

ЗАГСның чак кыймылдый торган дәү ишеген көч-хәл белән кузгатып, салкынча бүлмәгә керделәр.

— Яшь кияүләрнең егәрен сынар өчен шулай ясаганнармы әллә бу ишекне? — дип көлде Идрис.

Ундагы озынча бүлмәдә өч кыз алтын балдак сайлыйлар, әллә никадәтле аппаратлар аскан, галстугы бер якка кыйшайган фотограф диванда йокымсырый, башка кеше күренмәде.

Жаденко сулдагы буфет ягына борылды, ишеккә эленгән калын яшькелт шторны каерып Идрискә юл бирде. Кеше азлыктан файдаланып, буфетчы ханым җәелеп кенә чәй эчә иде, аларны күреп кыл да кыймылдатмады, башта иплəп кенә чәен эчеп бетерде, халат итәгендәге сохари бөртекләрен шыбырдатып идәнгә коеп торып басты. Дәшми генә аның бушавын көттеләр. Виталий Петрович киштәдәге шешәләрне күздән кичереп:

— Берәр шешә сухой алабызмы? — дип сорады.

— Сухули-мухули,— дип көлде Идрис нәкъ Әхәт төсле итеп.— Эчне тишмәс дип өметләнәм.

Ханым сораганны да көтмичә нәзакәтле генә кыланып суыткычтан бер шешә «Псоу» алып бирде.

— Ярыйсы мал,— диде Жаденко, шешәне чөеп-чөеп.

Аягүрә басып кына сап-салкын, чак кына шикәрләнгән коры ак шәраптан авыз иттеләр.

— Идрис,— диде Жаденко, шешәдә калганны көмеш каймалы юантык бокалларга тагын бушата-бушата.— Минем академия театрында бер дә булганым юк. Рус театрына да бик үк ешлап булмый.

— Ә нигә йөрмисез?

— Гадәткә кермәгән, шуңа күрә йөрелми.

— Партерда махсус тәрҗемә оештырылган. Колагыңа наушник ал да тыңла... Юкка йөрмисез театрларга, Виталий Петрович... Безнең академия театры илебездәге иң атаклы театрлар белән рәттән тора алырлык. Аның гаҗәп кызыклы актерлары, режиссерлары бар! Әйе, шулай! — диде Идрис үз фикерен дәлилләргә ясканып.— Миңа сезгә актер квартира сорап керде ди... Кем ул сезнең өчен?.. Беркем түгел... Ә үзебез кая да булса читкә чыксак, әйтик Африкага юлыксак, башаягыбызны онытып тык-мык кабиләсенең чүлмәк ватыкларын карарга булса да чабабыз! Ах-ух киләбез, ватык чүлмәк янында карточкага төшәбез, шытыр-шатыр блокнотларны тырмыйбыз, кайткач фотоларны күрсәтеп кардәш-ыруларыбыз алдында мактанабыз... Мин ул кабиләне кимсетергә, чүлмәк кыйпылчыгына табынырга томылган дәртчелләрне җәберләргә җыенмыйм... Мине кайберәүләрнең үз шәһәрендә, үз өлкәсендә яшәгән, үз күршендә генә торган халыкның үзенчәлекле сәнгатьләренә, театр-концертларына, көнкүрешенә, этнографиясенә бармак аша карауларына гаҗәпләнәм. Әйтик, Идел буенда бик үзенчәлекле халыклар — марилар, чувашлар, мордвалар борынгыдан яшәп яталар. Татарлар турында әйткән дә юк. Без бит сезнең күк җаваплы иптәшкә, нәкъ сезгә: «Әйдәгез, Идел буе халыкларының этнографик музеена нигез салабыз!» дип барырга тиешбез.

Жаденко, бокалын бөтерә-бөтерә, һаман аска карап уйлана иде.

— Мәсәлән, без үз яшәешебезне рус сәнгатеннән, рус һәм дөнья әдәбиятыннан башка күз алдына китерә дә алмыйбыз. Ничек инде, йөз еллар уртак Ватанда бергә яшәп, уртак дошманга каршы яуга йөреп, бергә үлеп, бер туганнар каберлегенә күмелеп яшәгән халык белән якынаймыйсың? Рус әдәбиятын белмәгән, аны укымаган кеше бездә надан булып санала... Ә менә сез, татар башкармасында эшләүче җаваплы иптәш, татар театрында булмадым дип белдерәсез... Беръяклылык булып чыга түгелме сон бу, Виталий Петрович?

— Идрис... Сез мина исемегез белән дәшкәнгә ачуланмыйсызмы?

— Театрга бармавыгызны кичергәнне, монысына гына түзәрбез!

— Сез хаклы! Мина калса бу безнең зур ялгышыбыз.

— Хәер, бу сезнең шәхсиян үз эшегез,— диде күңелсезләнеп Идрис. «Псоу»ны эчеп бетерделәр.

— Шушы хәлләрне анлап, мин Курт белән театрларга бармаска булдым,— диде кинәт Жаденко.

— Нигә, Виталий Петрович?

— Шулай.

— Икәүләп ничек тә ермачлап чыгарбыз. Сез шәһәрнең бүгенгесен, киләчәген менә дигән беләсез... Сез барында мин тыныч, сабыр...

— Юк, Идрис... Үгетләмәгез... Машинаны сезгә калдырам.

— Ярый инде алайса.

— Кирәксәм, я квартирага, я эшкә шалтыратыгыз. Телефонны язып алыгыз әле: 4-77-80.

— Булды. Сез райбашкармага кайтмыйсызмыни?

— Кагыласы урын бар...

Гостиницага барырга иртәрәк иде, Идрис Жаденкога, без сезне озатып куйыйк, дисә дә, тегесе ризалашмады. Аның тизрәк аерылып калырга теләве сизелеп тора иде.

— Вася, безнең бераз буш ара бар, нишлибез? — диде Идрис.

— Коенып алганда шәп булыр!.. Машинада оета, әнә, газетаны ике кат укып чыктым. Клименковны сөендерегез!

— Әйтермен. Кунакны да су керергә алып барасы калган, уйламаганбыз.

— Кичке яраулда тагын да шәбрәк коенырбыз!

Бишбалта дамбасына чыгып машинаны стадион коймасы янына куйдылар.

— Чиратлап коеныйк... Машина яңа, малай-шалай «Фантомас» дип кадак очы белән язып тутырмагае,— диде шигәеп Вася.

Әүвәл Идрис коенып килде. Васяны коенырга озаткач, ул шактый таушалган газетаны машина күләгәсенә җәеп җиргә сузылды. Бераздан аның янына нәфис коену костюмнары кигән, каралган тәнле, мул күкрәкле ике кыз якынлашты. Алар бер читтәрәк басып, әллә машинаны, әллә Идрисне күрсәтеп, көлешә-көлешә нидер сөйләштеләр. Егетнең мондый җимгә генә алданмавын күреп, якынрак килделәр.

— Сәлам! — диде аларның берсе.

— Хәерле көн,— диде Идрис сузылып яткан җиреннән.

— Хатын-кыз белән яткан җирдән сөйләшәләрме? — диде икенчесе.

— Алар шәрә булсалар да тәкәллефне онытмыйлармыни? — диде Идрис уенга борып, үзе шулай да торып утырды.

— Хәлләр ничек? — диде чытлыкланып беренчесе.

— Әйбәт.

— Кунак белән безне таныштырыгызчы.

— Нинди кунак? — диде Идрис төртмә генә.

— Кунак нинди була? ГДРдан килгән турист... Сез аның тәрҗемәчесеме?

— Кызлар, ике яктан басып, аны уртага алдылар.

«Провокация булмасын!» дип уйланды Идрис. Кызлар, аның кызаруына игътибар итмичә, тәтелди бирделәр:

— Ай-һай оялчан кунак икән!

— Нигә су керенергә төшмәде? Казан кызларыннан оялып йөриме әллә бичара?

— Эше бар,— дип мыгырдады Идрис.

Кызлар тагын ниләрдер сайрарга гына керешкәннәр иде, Идрис капланып сузылып ятты, аның болай гына тел язарга җыенмавын төшенгән сизгер кызлар турыдан-туры һөҗүм башладылар.

— Безне ресторанга чакырыгыз әле. Сез дә икәү, без дә...

Ул эндәшмәде.

— Ялындырган булмасана! — диде беренче кыз.

Идрис кыймшанмады, кызларның кәефе китте.

— Телсез пижон! — диде берсе.

— Бәхетсез турсык! — диде икенчесе.

Күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, елга ягыннан Вася килә иде, кызлар аны күреп җәһәт-җәһәт тая башладылар.

Сөйләшенгән минутта Курт бүлмәсенә вестибюльдән шалтыратып ятканда ул үзе килеп төште.

— Виталий Петровичны күрмим,— диде ул бер-ике сүз алышкач.

— Иптәш Жаденко гафу үтенергә кушты, аның ашыгыч эше килеп чыккан.

— Кызганыч,— диде хафаланып Курт.— Бүген бик кирәк буласы иде.

— Ул үзе безне эзләп табарга тиеш,— диде Куртның хафасын аңламаганга бераз җәберсенгән Идрис.

Иң элек опера театрына бардылар. Аның бинасында Мәскәүнең Станиславский исемендәге (аты хәтәр зурдан булса да, уеннары бик урта кул. Идрис бер-ике спектакльләрен карады инде!) драма театрының гастрольләре барганга, кая карама, шул театр кешеләре күренә иде. Цехларда да эш тукталмаган, сәхнә култыкларында балта, чүкеч тукылдаганы ишетелеп калды.

Тамаша залындагы стена бизәкләрен, фойедагы милли орнаментларны Курт зур кызыксыну белән карап йөрде:

— Иптәш Астахов тыйнаклык күрсәткән икән! Менә ич милли рәсем үрнәкләре! — диде ул куанып.

Академия театрында сәгатькә якын булдылар. Идрис театрның тарихын сөйләде. Беренче артистларның рәсемнәрен, беренче афишаларын күрсәтте. Аннан Зур драма театрына сәфәр ясадылар. Иң соныннан мәчет булды. Анда намаз вакыты туры килмәде, озынча зур зал буш диярлек иде, почмак-куышлардагы карт-корылар гына күзгә чалынды...

Аннары, табигать белән хозурланырга дип, Кабан күле буена киттеләр. Аның тип-тигез көзгесе өстендә, шатыр-потыр килеп, скутерларга утырган егетләр куыша иде. Кызыксынып кына аларны тамаша иттеләр, әңгәмә ялганып торды, сөйләшер сүзләр күп булып чыкты.

— Виталий Петрович безне эзлидер, мөгаен,— диде Курт кузгала башлагач.

— Хәзер шалтыратабыз.

— Миңа Казанда бер иптәшне табарга кирәк,— диде Курт, кыенсынып кына.

— Аны Виталий Петровичтан башка табалмабызмы?

— Белмим.

— Архитектормы ул?

— Түгел... Ул минем әтинең дусты. Алар Бухенвальдта бергә булганнар... Шунда очрашканнар. Минем әтине Эттерсберг тавына утыз

жиденче елның җәендә үк китергәннәр. Иң беренчеләрдән... Кырык икенче елны алар шунда очрашканнар.
— Исем-фамилиясе ничек аның?
— Ка-сим Усанов.
— Усманов түгелме?
— Юк, Усанов,— диде Курт ышаныч белән.— Алар бер блокта яшәгәннәр, бер яшерен оешмада торганнар.
— Алайса Усанов ни өчен әтиегезгә адресын бирмәде икән?
— Әйтә алмыйм. Алар кырык бишенче елда аерылышканнар. Истәлек өчен лагерь билгеләрен алмашканнар. Кызыл түгәрәк эчендә кызыл шар... Бу — лагерьдан качарга омтылган тоткын дигәнне аңлаткан... Әти кырык бишенче елдан соң Усановка берничә тапкыр хат язып караган, нигәдер җавап ала алмаган. Үзе лагерьда алган чирләреннән котыла алмыйча алтмышынчы елда вафат булды... Ул миңа еш кына: «Улым, син, әлбәттә, Россиядә булырсың... Безнең илебезнең киләчәге шул ил белән тыгыз бәйле... Казан шәһәренә барып чыгарга тырыш, анда минем язмышымның каты сынауларын бүлешкән дусларымнан берсе, татар коммунисты Касим Усанов яши», дигән иде.
— Сезнең әтиегезне дә фашизм үтергән икән.
— Әйе.
— Минем әтием дә фронтта үлгән. Мин утыз жиденче елда туганмын.
— Мин дә утыз жиденең көзендә. Әтиемне мин кырык бишенче елга кадәр күрә алмадым...
— Усановны, әгәр ул исән-аман икән, табабыз аны!.. Эх, килгәч тә әйтсәгез, газета аша халыкка мөрәҗәгать итәр идек.
— Ул кадәрле үк шау-шу кирәкме икән? — диде тыйнак Курт.
— Хәзер үк адреслар бюросына барабыз... Тәгаен шәһәр кешесе булдымы икән Усанов?..
Куйбышев мәйданындагы белешмәләр бюросында Идрис «Касим Усанов»ны да, «Усманов»ны да эзләп карауларын үтенде. Аларга берничә минут көтәргә куштылар. Курт та, Идрис үзе дә соң дәрәҗәдә дулкынлаңганнар иде, Җаденкога шалтыратырга да оныттылар. Һичбер урында тынычлык тапмаганга, кеше күзеннән читкәрәк китеп, Кабан күле буендагы Тукай һәйкәле куелган бакчага барып утырдылар. Һәйкәлне карадылар. Сүз әдәбият турында китте. Татарстаннан Германиягә күчтеләр, әтиләренә, билгесез Усановка әйләнеп кайттылар.
— Әгәр бюрода «юк» дисәләр?
— Үзәк бюрога барабыз. Хәзер Казанда булмаса, бәлки, кайчан да булса яшәгәндер. Табарбыз.
— Әгәр «бар» дисәләр?
Белешмәләр бюросына дулкынланып, каушап бардылар.
— Усанов гомумән юк... Усманов Касыйм Ваһап улы бар... 1907 елда туган... Хәзер Тельман урамы, унберенче йортта, бишенче квартирада яши...
Кәгазьне үрелеп алганда Идриснең куллары калтырады.
— Исән! — диде ул немецча.— Исән Усманов!.. Усанов түгелдер дидем бит...
— Алайса ул башка кеше,— диде көенсезләнеп Курт.
— Бездә татарларда андый фамилия юк та!.. Башкамы, түгелме, безнең кулда адрес, кадерле Курт!.. Очтык, Вася! — диде Идрис машинага утыргач.
— Еракмы? — дип сорады Курт.
— Монда гына!
Казанның үзәктәге аулак урамнарының берсенә, Тельманга выжла-

тып барып керделәр. Усмановның Тельман урамында яшәвендә дә Идрис әчке бер мәгънә күрде...

Ишек алдын тиз эзләп таптылар. Сәрби куаклары чуарлаган киң генә чиста почмактагы куләгәдә өч-дүрт кеше домино сугалар, коляскаларда бәбәйләр йоклый, карчык-корчык гайбәт сатып утыра. Аргы башта ике карт көймә төзәтәләр. Бәлки шуларның берәрсе Усмановтыр?..

Ундагы агач йортның икенче катына күтәрелделәр, кайдадыр балык кыздыралар иде, борынга тәмле ис килеп бәрелде. Идрис бишенче квартира ишеге янындагы ак төймәгә басты. Эчтә аяк тавышлары ишетелде...

## 32

Виталий Петрович туп-туры шәһәр советына керде һәм дежурный яныннан унбишенче больницага шалтыратты. Икенче кат, нейрохирургия бүлеге, зең-ң!..

Телефонга озак килми тордылар, ул хәтта шомлана башлады.

— Сезне тыңлыйм,— диде, ниһаять, зарыктырган мөлаем тавыш.

— Бу Ленин районы башкармасыннан, председатель урынбасары Жаденко. Безнең санэпидстанциянең баш врачы сездә... Нина Михайловнаны телефонга дәшсәгез икән?

— Булавинамы? Ул нәкъ шушы минутта чыгарга җыенып йөри.

— Хәзер үкме?

— Әйе, документларын көтеп тора.

Җибәрмәскә тырышыгыз, яки көтеп торсын дип әйтү уңайсыз иде, Виталий Петрович гадәттә булмаганча җитез кыланып урамга чыкты. Чатта гына таксилар туктый иде, бәхетсезлеккә каршы, бүген берсе дә күренмәде. Ул кабаланып, икенче катка, оештыру бүлеге мөдире бүлмәсенә менде.

— Коткар, Серафим Иванович!

— Ни булды, кадерлем?

— Бер сәгатькә генә машина биреп тор. Югыйсә яна!

Соңгы сүзне ул матурлык өчен генә әйтте. Каршы алырга өлгергән тәкъдирдә дә анын януы бик ихтимал иде. Әмма ул аны-моны исәпләп тормады, машина килгән арада музей каршысындагы киосктан зур бер бәйләм ап-ак пионнар сатып алды.

Юллары уңмады, унбишенче больницага гадәттәгедән озаграк бардылар, чат саен диярлек янап светофорлар туктатты, җитмәсә тимер юлда шлагбаум төшкән иде, сабырсызланып Арча ягына карый-карый, поезд күренгәнне көттеләр. Виталий Петрович минутына әллә ничә кат сәгатенә карады, туктаганмы әллә дип колагына китерде, соңга калдылар, ахры...

Чәчәкләрен дә алмыйча атлыгып икенче этаж баскычына аяк басканда Булавина белән йөзгә-йөз килделәр. Нина Михайловна ялгыз түгел, аның артыннан ук титаклап, бәләкәй төен тоткан кайнатасы Һашим да төшеп килә. Алар сөенешеп чөкердәшәләр иде, тәкатьсезләнеп менеп барган Жаденкога баш кагып кына уздылар. Виталий Петрович аны каршыларга килгәндер дип, Нина Михайловнаның уена да кереп карамады. Узып бераз төшкәч кенә әсәренеп туктады, Жаденко яшь гашыйк кебек тиргә батып аңа текәлеп каткан иде.

— Саумысыз,— диде ул юаш итеп.

— Әйбәт,— диде Булавина, исе китмичә генә.

— Нигә хәбәр иттермәдегез? — диде Жаденко, аларга ияреп төшә-төшә.— Очраклы гына белеп килдем!

— Сезнең мине каршылавыгызмыни? — диде Булавина, көлеп.

— Кемне булсын тагын? — диде Жаденко, картка күз кырые белән караштырып.
— Рәхмәт, Виталий Петрович, чын күңелемнән рәхмәт... Сез, әткәй, таныш шикелле.
— Таныш, таныш,— диде шатланып Жаденко.— Һашим Сәлимгәрәевич, сез такси-мазарда килдегезме?
— Гарип-гораба түгел, троллейбуста да бик әйбәт кайтырбыз,— диде карт, коры гына.
— Алайса, озатырга рөхсәт итегез. Машина сезнең карамакта.
Каршы килеп маташу әдәпсезлек иде, машинага кереп утырыштылар.
— Сез кунаклар янында мәшгуль түгелмени? — дип сорады Булавина Жаденкодан.
— Үзегез барын да белеп яшисез тагын...
Идрис шалтыратты...
Жаденконың йөзе сөенеч белән балкый иде:
— Кунакны бүген аңа тапшырдым! Сезне каршыларга кирәк иде бит!
— Кылган гөнаһларыгызны ярлыкату өченме бу кадәр хөрмәт? — диде карт чәнчеп кенә.
Булавинаның бу сүзләрне телдән әйттерәсе килмәгән иде, хәтта ул Жаденконың каршылавына шат та иде, ялт кына әткәсенә карап аны шелтәләде.
— Шулай, шулай, Һашим Сәлимгәрәевич,— диде Жаденко күтәренке күңел белән.— Дөньяныкы дөньялыкта бетсен!
Аның соңгы сүзләре картка ошамады, гомумән, Жаденконың каршылавы аңа әдәпсезлек булып тоелды, аның туйдан кайтып килүче яшь кияүдәй машинада балкып баруы бу өнәмәүне тирәнәйтте. Ул, тротуарда кайнашкан халыкны күзәтеп, үзалдына фәлсәфә сатып барды.
— Анысына без оста... Берәүне рәнҗетәбез дә, аһ, ялгыш булган, кичерегез, дип гафу үтенергә, лаф орырга, күкрәк төяргә тотынабыз.
— Житәрегез сезгә! — диде Нина Михайловна, әрләмичә генә.
Элек очрашканнарда да Жаденко картны өнәмәгән иде, хәзерге кискенлегенә ачуы отыры куерып барса да, Нина Михайловнаның хәтерен саклап, сүзне уен-көлкегә борды, әңгәмә акрынлап тыныч җай алды: хәл-әхвәл алыштылар, эш, җәйге яллар, таныш-белешләр турында сөйләшергә керештеләр. Жаденкога элеккеге олысымаклыгы кайтты.
— Әйтергә онытканмын, Лоскутов егетлеген күрсәтеп өлгерде анда.
Нина Михайловна кул астында эшләүче Лоскутов фамилияле санврачны ул югында баш итеп билгеләгәннәр иде.
— Складта озак яткан консерваларны кибеттән кире кайтарганнар... Капкачлары күгәрә башлаган, башка шикләре дә булган. Бу нишли дигез сез: төзелгән актны расламый, консерваларны ашханә аша халыкка саттыра...
Булавина кинәт ап-ачык итеп райбашкарманың һәрвакыт чак кына тузан исе беленеп торган озынча, караңгы коридорын, председатель ишеге янындагы кешеләрне, Гагарин урамында үзенең бәләкәй кабинетын, зәһәр чылтырый торган телефонны, үзе көн саен дип әйтерлек очратып торган хезмәттәшләрен, калын, юеш иренле, маңгай чәче коела төшкән төче, кыланчык Лоскутовны күз алдына китерде...
Эссе, ямьле җәй көннәрендә больницада сары саргаеп яту никадәрле ялыктыргыч, ничаклы ямансу булмасын, анда бәлачел Лоскутовлардан колагы тынып тора иде, менә хәзер исемен ишетүгә үк күңеле җилкенеп, бөтен тамырлары чемер-чемер итеп алды... Шуларны күрмичә, үз дигәннәрен белән, галәшмыйча, җанга рәхәт итеп эшлисе

иде... Яшәешеннең нигезен тәшкил иткән эшенне дә җәфалы башкарып, нигә интегергә?
Кайтып җиттеләр: әнә аларның йортлары... арык ат сырты кебек дугайланып-дугайланып киткән тротуар... әнә аларның тәрәзәләре...
Виталий Петрович машинадан төшәр дип уйламаган иде ул, әмма Жаденко төште, арт тәрәзә янышнан кәгазьгә төргән зур букетны алгач, шоферга эндәште:
— Булдырдың, егет, сау бул.
Машина киткәч, ул пионнарны Булавинага сонды:
— Исән-сау кайтуыгыз белән тәбрикләп, Нина Михайловна.
— Рәхмәт инде... Нигә артыгын мәшәкатьләнергә?..
Һашим, килененең уңайсызлануын сизмәмешкә салышып, кунакны өйгә чакырды. Жаденко кыстатмыйча нярде, аның бөтен кыланышы, сөйләшүе тиз генә китәргә җыенмавын әйтеп тора иде.
Сагынылган үз куышын... Тәрәзәләрне ачып китеп этисе бик дөрес иткән, алар салкынча саф һавалы бүлмәгә керделәр... Сырпаланып, мыраулап каршылаучы Мурзик... Шук малайлар көйдергән сул мыегы үсә төшкәнме?..
— Пес, пес, иркәҗан... Исәнме?..
Һашим белән Жаденконы зал якка озаткач, Нина Михайловна туалетка керде, көзгегә күз төшерде. Үзен озын, ямьсез халатта түгел, килешле күлмәк кигән хәлдә күрү сәер кебек тоелды аңа...
Аннары тирә-якка хуҗаларча күз ташлады, краннарны борды, бачоктан су төшерде. Бит-күзләрен юды да кухня ягына узды. Адымнары җиңел, сулышы тигез, күңеле тыныч иде. Киң төпле зәңгәр чәйнеккә чырылдатып су агызып, газ өстенә утыртты. Газ куандырып, гөлт итеп кабынды. Суыткычны ачып карады. Әткәсе аның кайтуына нык әзерләнгән иде: табак белән кып-кызыл каен җиләге утыра (соңгыларыдыр инде, бигрәк эрене, мәмрәп пешкәнне сатып алган!), кайнаган сөт тә, каймак та бар. Ул аларны алып кухня өстәленә куйды. Виталий Петровичны чәй белән сыйлап җибәрергә кирәк... Суыткыч ишегенә куелган портвейнны кузгатып тормады, ире үлгәннән бирле алар өендә исерткеч нәрсә бик сирәк кунак, мөгаен, әткәсе чит кешеләр өчен алмагандыр... Нина Михайловнаны зарыгып, сагынып, ямансулап көткән берәр минутында алынган нәмәрсәдер, утырсын әлегә...
Чәчәк вазасын кулына алгач әллә ничек ямансу, күңелсез булып китте... Моннан ике ел элек, сигезенче мартка ире Вәкил алып кайткан иде бу вазаны... Су агызып пионнарны шуңа утыртты. Әтисеннән сорашасы сүзләре, үзенең сөйләселәре хәттән ашкан булса да, чәй арасында уралып вакытын кыскартты, зал ягына бөтенләй чыкмады. Ул яктан тавыш ишетелмәсен дип, шәһәр челтәренә тоташтырылган репродукторны кабызды, бер җайга гына аккан талгын музыка тулышкан күңелне өстәмә тетрәтте, әллә каян гына хыянәтчел күз яшьләре сытылып чыктылар...
Чәй сала торган көмеш калак... Кара чәчәкләр төшкән ак фарфор чынаяклар... Үз өе... Аның тәмле-тәтлы исе... Акрын гына җан тирбәткән музыка... Зәп-зәңгәр, үтә күренмәле ялкын телләре... Болар барысы да юлда кайтканда, аннары әле генә өйдә туган икеле-микеле моңзарларны алып киттеләр, ул залдагылар янына чыкканда баш әйләндергеч киеренкелектән арынган, ял иткән иде.
Күңелле генә итеп чәй эчтеләр.
Чәй урыны да җыелды, соңгы хәбәрләр дә сөйләшенеп бетте. Ләкин Виталий Петровичның китәргә җыенуы күренмәде. Һашим аны балконга чакырды. Җиләс күләгәдә алар шахмат уйнарга утырдылар.
Нина Михайловна туалетка керде, ваннага су җибәрде, бадузан агызды. Кайнарлатып биш-алты кастрюль су салды. Бадузаннан күпереп чыккан болыт-болыт күбек ванна бүлмәсен тәмле яшь чыршы исе

белән тутырды. Ул ишекне бикләде, акрын гына чишенде, ялангач калгач, көзге каршысына басты, чәчләрен тузгытып башын артка ташлады... Чир җәфасыннан шактый ябыкса да, күз тимәсен, дөнья мәшәкатьләреннән бөгелеп төшәрлек түгел әле Нина Михайловна!.. Тик менә чәчләр... Чигә тирәләреннән агарып бөтерелеп торалар...

Һашим бирелеп һәм яратып уйный иде, Жаденконы ике тапкыр отты. Виталий Петрович оттырышын авыр кичермәде, ул биллиард, шахмат уеннарына гади бер мәзәк, вакыт уздыргыч дип кенә карый иде. Үзе уйнады, үзе һаман Нина Михайловнаны көтте. Өченче партиядә Һашимның үзәк пешкасы, ачык юлга чыгып, акларның араларына кыю гына барып кергәндә, балкон ишегендә Булавина күренде. Ишеккә арты белән утырса да, Жаденко моны шундук сизде, елмаеп борылды.

— Менә мин әзер булдым,— диде Булавина, рәхәтлектән күзләрен кысып.

Тәбәнәк урындыкта утырып аяклары оеган Жаденко аягүрә басты, нелеп чираттагы йөрешен ясады.

— Без дә бетерәбез.

Нина Михайловна өстендә ару күлмәк, аягында алтынсу йөзле Һиндстан туфлялары, юеш чәчләрен бигуди белән ураштырып, сизелмәслек итеп калын яулык белән төрештереп куйган.

Аның монарчы Нина Михайловнаны гади хатын, йорт хуҗасы итеп күргәне юк та иде. Ирексездән сокланды, карт тәкъдим иткәч, ничьяга берсүзсез ризалашты.

Балконнан өй эченә керделәр, кузгалган чакта Һашимның протезы шыгырдап куйды.

— Бик оста уйныйсыз,— диде Жаденко, аны мактап.

— Шахмат — пенсионерлар шөгыле,— диде карт, бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлап.

Ары-бире карангач, ул пианино өстеннән китабын алып икенче бүлмәгә керде, ишекне тыгызлап япты. Жаденко белән Булавина зал якта торып калдылар. Виталий Петрович, үз бәхетеннән үзе исереп исәрләрчә елмая-елмая, кыюсыз гына атлап аңа якынлашты. Тегесе кыймшанмады, селкенмәде, җентекләп карап торган күзләрен каймалаган керфекләре генә дереллдәп киттеләр. Жаденко борылды, нәни малай фотосын алып, Нина Михайловна чалымнары белән чагыштырып карады: охшаган!

— Йөреп кермибезме? — диде ул, фотоны ашыгып куеп.— Кич булып килә.

— Рәхмәт,— диде Булавина таркау гына.

Ул, Жаденконың шактый комарланып карап торуыннан уңайсызланып, этисе кереп киткән ишеккә табарак тартылды. Эчкәрге яктан өзек-өзек кенә йөткергән тавыш ишетелде.

— Без зиратка барып кайтабыз...

Виталий Петрович үзенең шуны алданрак искәрмәвенә үртәлде. Ул аңа ияреп бүген теләсә кая барырга да әзер иде, әмма Нина Михайловна әйткән җөмлә аның өмет-теләкләрен кисте дә куйды...

— Эшкә кайчан чыгарга диделәр?

Бу сүз әлегә артык, бөтенләй кирәксез иде, Виталий Петрович эш турында ничарадан бичара гына сүз кузгатты.

— Әле ашыкмыйм, Виталий Петрович.

— Бәлки кичкә таба очрашырбыз? — диде ул, һаман өметләнеп.— Минем апаларга кереп чыгарбыз...

— Кеше мәшәкатьләп йөрмик инде...

— Нинди мәшәкать ди?.. Ул күптән түгел Һиндстанга барып кайтты. Бик кызыклы диапозитивлары, пластинкалары бар...

— Очраштык ич инде, Виталий Петрович... Каршы алуыгыз өчен тагын бер тапкыр рәхмәт.
— Сезнең авыр чагыгыз...
— Әллә жәлләргә дә ниятлисез инде?
— Сезнең хәлне авырлаштыруда минем катнашым да булды...
— Менә яңа яралган Нехлюдов! — дип, Нина Михайловна көтмәгәндә көлеп җибәрде.— Толстойчылар мәзһәбенә язылмадыгызмы?.. Бәреп егам да тартып торгызам!.. Ансат фәлсәфә... Ахыр килеп, кулымны һәм йөрәгемне тәкъдим итеп тез чүгәм!
— Чын сөйләшүне клоунадага әйләндердегез.
— Сезнең өчен иң ансат котылу юлын сайладым,— диде Нина Михайловна мәрхәмәтле генә.
Алар, кара-каршы басып торсалар да, бер-берсенә карарга кыймадылар.
— Эткәй! — дип эндәште дә, Нина Михайловна ишекне ачты.
Жаденко, «Суд килә!» дигәнне ишеткәч сикереп торган тоткын кебек, ап-ак агарынды. Кулына китап тотып күзлекле Һашим чыкты.
Нина Михайловна, иңенә кофта салып, аңа эндәште:
— Кузгалабызмы, эткәй?.. Виталий Петрович безгә үпкәләмәс...
— Кузгалырбыз,— диде Һашим, таягына үрелеп.
— Виталий Петрович,— диде Булавина, мөлаем гына.— Чәчәк эзләп йөрергә соң инде, сезнең пионнарны зиратка бүләк итсәк, рәнҗемәссезме?
— Юк, юк, зинһар...
Карт титаклап арттарак калды. Баскычтан төшкәндә Жаденко ике куллап Нина Михайловнаның беләгеннән кысты.
— Яратам ич мин сезне, Нина!
— Тагын бер тапкыр шушы сүзне сезнең авыздан ишетсәм, без сөйләшүдән бөтенләй туктыйбыз. Ике тапкыр әйтсәгез, башка урынга күчәм.
— Миңа өметләнергә дә хокук калдырмыйсызмы?
— Аннан ни файда?
— Белеп яшәргә телим...
— Ә мин белеп яшәргә теләмим... Белеп яшәү күңелсез бертөрлелек түгелмени?.. Сез канәгатьме?
Жаденко аның күзләренә карады, баскычта эчне пошырып, җанны кыйнап протез шыгырдады.

33

Тар гына ачылган ишекнең теге ягында яулыгын җилкәсенә төшереп татарча бәйләгән, бераз бөкрерәк, кечкенә буйлы карчык күренде. Ул ят кешеләрне абайлап кыбырсый башлады, аны бөтенләй аптыраштә калдырмас өчен, Идрис ашыгып-ашыгып сәлам бирде:
— Исән-сау гына яшисезме, әбекәй?
Карчык ишекне киңрәк ачты, танырга җыенгандай, аяк очларына басып, муенын суза-суза карады, танымагач, авыз читен яулык почмагы белән томалап:
— Исәнмесез, балалар. Әйдәгез, өйгә рәхим итегез,— диде.
— Керәбез, әби, шатланып керәбез.
Карчыкның сәер бәйләнгән яулыгын, җыерчыклы, сөйкемле йөзен Курт кызыксынып карады: Ка-сим Усановның хатынымы бу? Шулмы? Шулармы?
— Таныган сымак та итәм, күзнең мае беткән, каһәр суккыры. Мәүлиха кодачаның улы түгелсеңдер бит? Кираммы әле?
— Юк, әби, исемем минем Идрис, үзем газеталар чыгара торган җирдә эшлим. Редакциядә... Бер мөһим йомыш сезнең бусагага китерде.

Ул үзе утырмады, урындык алып, Куртка утырырга немецчалап тәкъдим итте. Ят тел сүзләрен ишетеп болай да коты бот тирәсендәрәк йөргән карчык бермә-бер шөбһәләнде. Идрис Курт белән таныштырды:

— Бу безнең Казан кунагы, әбекәй. Германиядән килгән.

— Германнан диденме?.. Шуннан укмыни? И аллам!.. Ни йомышыгыз бар иде соң сезнең бу йортта?

— Без Касыйм абый Усмановны эзләп килдек. Бу аның квартирасы булгач, сез, мөгаен, аның карчыгыдыр инде?

— Касыйм кирәк немени? — диде карчык, ачылып.— Әллә кайчан әйтми торасыз... Юк, мин аның җәмәгате түгел, аның хатыны Минниса исемле, ә минем атым Хәдичә. Минем картым, гәжиттә утыргач, мужет ишеткәнең дә булгандыр, Бәкер исемле иде, меховойда эшләде... Фәрхетдинов фамилияле ие, Герман сугышыннан кайтмады.

Идрис әбинең үз ире дә Германиядә үлүен Куртка әйтеп бирде.

— Усанов исәнме, сорагыз, зинһар,— диде кычкырып Курт.

— Хәзер беләбез... Карчык бераз куркып калды.— Идрис әбигә мөмкин кадәр йомшак эндәшергә тырышты.— Касыйм агай кайда соң?

— Аның кайдалыгын сорап торасы бармы? Шунда инде, дачада, дачада! Кара яздан карчыгы белән киткәннәр иде... Январында бер кызлары — Рәисә генә бар. Сез, егет-җиләм, шуны эзләп йөрмисездер бит? Миннән яшермисезме?

— Исән! — дип кычкырды Идрис, немецча.

— Исән-сау!? — дип кабатлады Курт.

— Әстәгъфирулла тәүбә,— дип укынды карчык, куркынып.

— Их, әбекәй, Хәдичә әбекәй!.. Хәбәрнең иң-иң шатлыклысын әйттегез безгә, мең яшәгез!

— Мин аларның күршеләре,— диде аптырап карчык.— Гөлләргә су-мазар сибим, аз-маз тузан арчыйм дип керүем. Ялгыш туры килдегез.

— Эх, әби! Германиядән килеп туры китергәч ялгыш буламы соң ул? Бу кунак егетнең әтисе белән Касыйм абый бергә немецта пленда булганнар, әсирлектә.

— Үзе нимес дисең, үзенең әтисе ниместә әсирлектә дисең... Ничегрәк була инде анысы?

— Концлагерьда, әбекәй, үлем базында. Аның әтисе коммунист булган.

Карчык, баш кага-кага, аның сүзен җуплап торды:

— Ныгытып ук әйтә алмыйм, балам, илла-мәгәр Касыймның нимесләргә каршы сугышып йөрүләрен сөйләгәнен ишеткәнем бар. Бәйрәмсәйрәмнәрдә йөрешәбез. Тол башымны да аштан-чәйдән калдырмыйлар дигәндәй... Рас дип бетерә алмыйм, әмма йөргәндер Касыйм! Бик тә уңган, кәттә кеше үзе менәтерәк. Күрүгә исегез китәр.

— Курт, кадерлем,— диде Идрис, дулкынланып.— Без эзләгән кеше шушы йортның хуҗасы булырга тиеш.

— Болай ансат табылыр дип һич уйламаган идем. Белгән булсам, беренче көнне үк, килгәч тә... Үзәктә яшәп яткан бит!

— Хәдичә әби, инде дачаларының кайдалыгын да әйтеп җибәрсәгез, сезгә миллион рәхмәт тә кызганыч түгел.

— Кайда дисенме?.. Һә, аты коргыры, бик һәйбәт урында, исеме урысча, ничек иде соң?.. Пруховой ягында инде, Юдиннарны узып барасы... Бик матур урыны! Иделе дә якында гына дигәндәй, урманы да өстенә аварга тора... Һавасы да коры. Касыйм абзагыз өч ел дигәндә йортын салды, бакчасын тергезеп җибәрде. Карлыганы, чиясе житәрлек, барган саен сыйланмый кайтмыйм. Кызлары Рәисә китап баса торган җирдә эшли.

— Бакчалары Займищеда алайса?

— Шул инде шул, аты коргыры! Үзең дә беләсең икән.

— Журналистлар дачасындамы?
— Әйе, әйе, Касыйм Усманов дип сорасаң, аны белмәгән кеше юктыр. Хәзер дә бик закунный кеше, каравылына-ниенә тылкышып нәчәльник булып йөри.
— Рәхмәт, әби.
Идрис карчыкка ике кулын сузды, Курт та шуны ук кабатлады.
— Шулкадәр җирдән Касыймны эзләп килгән диген... Бар да соң инде изге җанлы кешеләр! Нимесендә дә бар икән!..
Баскыч араларын бер генә сикерделәр, Идрис әби белән сөйләшкәнне Куртка түкми-чәчми аңлатып бирде, сүзе бераз корырак чыкты, чөнки әби телендәге тәмне тәрҗемә итеп торырга вакыт та, мөмкинлек тә юк иде. Тизрәк-тизрәк Касыйм Усмановны эзләп табарга кирәк! Моңарчы беленми яткан Бухенвальд герое бер Курт өчен генә түгел, Идриснең үзе өчен дә, газета өчен дә, Татарстан өчен дә гаять кызыклы булачак.
Куртның этисе, Касыйм Усманов, Курт үзе...
Мәсьәләне ике сүз белән Васяга да аңлаттылар.
— Нинди поездларга утырып йөрү? — диде ул, Идрисне ачуланып.— Туп-туры Займищега сыпыртабыз. Юл такыр, тирә-ягы картинкә, кирәк кешене тапмый кайтмыйбыз.
Ирек мәйданында телефон автоматтан Жаденконың өенә дә, эшенә дә шалтыратып карадылар. Квартир телефонын алучы булмады, эшеннән: «Виталий Петрович бүген-иртәгә эш белән йөри, монда килми»,— диде секретарь.
Курт белән Вася, машинадан чыгып, җилләнеп торалар. Киң Ирек мәйданын кояш яктырта. Ак алъяпкычлар буып җибәргән бакчачылар, боргаланган шлангларын үз артларыннан ияртеп, чәчәк түтәлләренә су сиптерәләр. Анда да, монда да — аллы-кызыллы түтәлләр өстендә күкле-зәңгәрле салават күперләре җемелди.
Эсседә көнозын шәһәр урамнары буйлап йөреп, ашханә яки ресторанннарда ризык җыеп утырганчы Иделнең киң кочагына чыгу ни тора?!. Шушы матурлыкны, байлыкны, кабатланмас табигать гүзәллеген, житешеп, Куртка күрсәтеп булырмы дип йөргәндә, акылэле имән үзе өскә ауды!..
Телевышка янында бензинга шактый чират иде, әмма Вася иң алга ерып үтә алды һәм ә дигәнче бензин тутырып кузгалдылар.
— Юлның турысына чыктык: Казан — Горький, Мәскәү — Берлин! Теләсәгез илтергә була! — дип көлдерде шофер.
Моңарчы мыштыбый гына йөргән Вася, Жаденко аерылып калганнан бирле, әллә ничек ачылып китте. Ул Германияне бик әйбәт белә икән, сугыштан соң өч ел шунда хезмәт иткән, немецчаны да аз-маз сукалый, хәтта берничә җыр җырлап күрсәтте. Андагы бер хуторда яраткан кызым калды, чак өйләнешмәдек, Татарстаннан, Казаннан дигәч, эти-әниләре риза булмады,— диде ул.— «Анда кысык күзле, киң яңаклы татарлар яши, алар һаман чи ит ашыйлар, кызыбызны кыргыйлар арасына җибәрә алмыйбыз»,— дип терәлеп каттылар».
Боларын Вася ярым мактанып, ярым шаяртып сөйләде.
Идрис башта иптәшләренә ияреп көлде, аннан кинәт моңайды, уйчанланды. Европада татарларны шулай дип уйлыйлар микәнни?
Ул Куртка үзләре узып бара торган Киров районы тарихын, татар пролетариатының үзәге булуын, аның революцион традицияләрен, Пороховой заводын, Елан тавындагы монастырьне сөйләп бара иде, шып булды...
Урман юлына төшкәч, Вася хәтсез кызу барган машинасын җайга куйды, бая үзләре артта калдырган дәү-дәү үзбушаткычлар гәрс-мәрс килеп аларны узарга тотындылар.
— «Тын күл»не хәтерлисезме? — диде Вася хәйләкәр генә.

— Шунда барганда таныштык ич,— диде Идрис, ачылып.
— Кунакны алып кереп күрсәтеп чыгабызмы әллә дим... Виталий Петрович үзе булса, читләтеп узалмас иде!
— Әшебез ашыгыч ич, Вася.
— Белми дә кала ул,— диде шофер, хәйләкәр елмаеп.— Әйләнечтән юл туры дибез дә тәвәккәллибез!
— Алай алдарга ярамый,— диде Идрис, уңайсызланып.— Дөресен әйтик! Бер дус малай да бар анда минем!
— Шулай булгач, сыпырдыкмы?.. Кайтышлый керергә соң булыр, алар иртә кунаклыйлар...
Балалар шәһәрчегенә кагылып чыгарга Курт шатланып риза булды. Пиджак кесәсеннән фото алып күрсәтте, аның үзенең дә ике улы бар икән. Балалар турында сүз купкач, фото кулдан-кулга йөргәндә Идрис әчке бер җайсызлык тойды, үзен суык аяклы ханҗа дип уйламасыннар өчен, хатынының сырхаулап торуын, хәзергесе көндә санаторийда дәваланып ятуын аңлатты.
— Минем башкисәр малай да «Тын күл»дә,— диде Вася, исе китмичә генә.
— Аңлашылды,— диде көлеп Идрис.
Гөжелдәп, таныш дачага барып җиттеләр. Иң элек аларны Фаина Наумовна белән Галия апа күреп алды. Ак марлялар өретелгән тәрәзәле кухня янындагы күләгәдә, чебен-кигәвеннәргә койрык селкеп, юаш кына бахбай тора, ишек алдында башкача җан иясе барлыгы сизелмәде.
Фаина Наумовнаның урман-далада яшәгәнлеге йөзенә чыккан, анда-санда эре сипкелле йөзен җил кискән, ялангач беләкләре дә көрәнләнеп, юкарып калганнар, ул Идрисне ерактан ук танып ягымлы эндәшеп килде:
— Кунак бар икән, рәхим итегез, хуш килдегез!..
— Ялгышмадыгыз, Фаина Наумовна, кунакның да иң кадерлесен алып килдем. Иптәш Курт Карл, Германия Демократик Республикасыннан... Без сезнең белән бер дәрәҗәдә — хуҗалар бүген.
Гринберг, күптәнге танышын очраткан сыман, Курт белән немецча сөйләшә дә башлады, Вася белән Идрис бер-берсенә күз кысышып алдылар. Галия апа да Идрисне онытмаган икән, күрүгә әрләргә тотынды: «Ял көннәрендә шушында килсәң — кай төше ярамаган,— диде. Коеныйм дисәң — күле, кызыныйм дисәң — эссе комы бар. Килмисең генә бит!..»
Фаина Наумовна Васяны да бик яхшы белән икән, аңа:
— Бүген ата-аналар белән очрашырга ярамый яравын, Василий Павлович,— диде.— Шуның өчен сез үзегез барып күренеп йөрмәгез. Федяны Галия апа гына дәшеп китерер.
— Берочтан Айдарны да чакырырсыз инде, Галия апа.
— Мин теге мәкаләне язып бетергән идем, Идрис Булатович... Тик Айдар турында чынын ук язарга кулым бармады... Малайны бөтенләй ташладылар, җәйгә чыгып бер аяк басканнары юк! Әтиләрен күреп бер сөйләшмәссезме?
— Бәлки алар шәһәрдә түгелләрдер?.. Нигәдер очрашмыйбыз.
— Белештек. Икесе дә каядыр китәргә әзерләнәләр, әмма хәзергә шәһәрдә.
— Мәкаләне алып китә аламдыр ич?
— Әлбәттә... Сез Айдар белән сөйләшә торыгыз, мин кунакны дача белән таныштырырмын.
— Миңа рәхмәт, Фаина Наумовна.
Идрис, Куртка карап:
— Менә монда безгә Виталий Петрович җитми,— диде.— Сайрар кошларың бер якта торсын иде!

— Фаина Наумовна да бик ягымлы ханым...

— Жаденко шушы балалар шәһәрчеге өчен орден алган кавалер!

— Искәртүегезгә рәхмәт, котларга кирәк үзен. Шәһәрчек чыннан да күңелгә ятышлы күренә.

— Виталий Петрович шәһәрдә йөргәндә гадәттән тыш тыйнак телле булса да, мондый урында антик заман архитекторларыннан башлап Оскар Нимайер, Карбюзьеларга хәтле килеп җитә ала.

Курт, Идриснең шаяруын аңлап, үзе дә бер-ике көлке әйтеп алды. Гринберг аны корпусларга таба алып китте, Идрис күл ягына атлады. Агачлыкта аксыл чәчле малаен житәкләгән Вася күренде, бераз арттарак калып Галия апа кыска чалбар, кыска җиңле ак күлмәк кигән ялан баш малайны болай таба йолыккалый иде. Малай бармый, карыша, аякларын җиргә терәп тартыша. Айдар ич бу!

Идрис алар янына йөгерде.

— Айдар!

— Менә күр: әйдә дим, янына абыең килгән, дим... Юк, ди, ышанмый... Минем янга берәү дә килми, ди... Тагын ябып куярга алып барасыз, ди.

— Сез аны ябып та куйгалыйсызмыни? — дип сорады Идрис.

— Юк ла... Беркөн, инде канны бик кыздыргач, мөдир бүлмәсендә чак-чак кына, ябага тай аунар ара гына утырып торды бугай...

Малай, аларның татарча сөйләшүләрен бөтенләй тыңламаган да сыман, әллә кая бер читкә карап тора иде.

Идрис малайга кулын сузды:

— Сәлам, Айдар!

Малай сәламне алмады, кулларын артка куеп басты да, каш астыннан гына аңа бер-ике рәт карап алды.

— Танымыйсыңмы әллә?

Малай ләм-мим сүз әйтмәде, Идриснең кулын җилкәсеннән кагып төшерде.

— Сөйләш абыең белән, затсыз,— дип кычкырды Галия апа.— Беркөн коеныргa алып баргач, кызларның күлмәкләрен балчык тутырып суга ыргыткан... Аннары, аннары... ин биек чыршы башына менеп шуннан тәрәт иткәннәр, нәләтләр... Әй, булды инде хәлләр, булды...

Галия апа тәтелдәпме тәтелди иде. Малай, апаның әләкләвен сизенде, ахры, борчыла башлады.

— Син шулай төрле әкәмәтләр дә күрсәтәсеңмени? — дип сорады Идрис кырыс кына.

— Нинди әкәмәт? — диде аңламамышка салышып малай.

— Күл буенда, су коенганда...

— Әләкләшмәсеннәр,— диде малай, җиргә карап.

— Син мине гафу ит,— диде Идрис, борчылып.— Моңарчы янына килеп булмады. Һич эштән бушатмыйлар.

— Катырак сөйләш үзе белән,— диде китә башлаган җиреннән борылып Галия апа.— Болай кәнфитләнеп торма... Бер урамда торабыз дисеңме?.. Агайнелек тә ташка үлчим генә икән шул... Әйдә, ичмасам ир-ат сүзе үтмәсме? Беләүләнгән малай, затсыз... Үзе шундый тере, белмәгәне юк, эшкә дисәң дә үтә чыккан гаярь, әмма усал! Малайларны куркытып бетерде.

Идрис, Айдарны нык итеп җитәкләде дә бер кырыйгарак китте, алар дәү күләгәле каен төбенә барып утырдылар.

— Сөйлә хәзер, ни хәлләрең бар.

— Әйбәт.

— Чикерткәләр тотасыңмы?

Малайның күзе бераз янды да тагын сүнде.

— Тотмыйм.

— Тоттырмыйлармы?

— Мин скрипкәчеләрне тота башлаган идем... Эти коробкалар алып киләм дигән иде... Аптекаларда дарулардан бушаган картон каплар була икән. Аларны бушлай да бирәләр, диде Фаина Наумовна... Әти шуларны алып килергә вәгъдә итте... Мин скрипкәчеләрне буш шырпы кабына тутырдым... Алар, сугышып, бер-берсенең тәпиләрен өзеп бетергәннәр... Шырпы капларын күлгә ыргыттым.

— Кызларның күлмәкләре белән бергә йөзсеннәр дипме?

— Әләкләшмәсеннәр,— дип кабатлады малай.

— Каян шулай үчегәләр алар сиңа?

— Витяга әтисе компас бүләк итеп бирде... Без шуны сынап Аккош күле кырыннан урман аша чыгып шәһәргә кайтмакчы булдык.

— Икәү генәме?

— Әйе... Наилька да иярмәкче иде, курыкты.

— Шәһәргә нигә кайтмакчы инде сез?

— Мин малайларга Рексны сөйләгән идем, алар ышанмыйлар.

— Нәрсәгә?

— Бәләкәчләрнең бар икәнлегенә ышанмыйлар... Мин ант иттем, барыбер ышанмадылар... Аннары бәләкәчләрнең берсен мин Витяга бирмәкче идем, ул миңа компасын...

Идрис малайның чәчен озак кына сыйпап утырды.

— Шуннан ни булды?

— Без барабыз шулай, барабыз, асфальтны да уздык... Шуннан Фаина Наумовна белән тетя Галия арттан куып тоттылар... Кызлар күреп калганнар да әләкләгәннәр.

— Алай...

— Наильканы тукмадык.

— Анысы нигә тагын?

— Кызларның әләкләргә йөргәнен белгән ич ул!

— Кирәкми кешегә тияргә...

Якында гына күке кычкырды. Малайны иркәләп, юатып әллә ниләр әйтердәй булды Идрис, дәшә алмады, туктаусыз сөйде, иелеп аның җилкә чокырыннан үпте. Малайның тәненнән татлы кояш исе килде.

— О, син ике түбәле икән,— диде, малайның башын сыйпап.

— Шулай диләр...

— Бәхетле буласың алайса...

— Ә синең Рексны күргәнең бармы? Бәләкәчләр олымы?

— Юк бәләкәчләр,— диде ул, читкә борылып.— Рекс та юк.

— Алдыйсың,— диде малай, кинәт аның куеныннан ычкынып.— Син дә, мин качмасын дип, алдаларга килгәнсең!

Ул бер кырыйга йөгерде һәм бүген беренче күрешкәндәге кебек үк кыргыйланып, усалланып, каш җыерып карап тора башлады.

— Айдар, Айдар! Алдамыйм, ышан... Мин синең янга тагын киләм. Аптекадан картон каплар, компас алып киләм... Тик Рекс та, бәләкәчләр дә юк.

— Кайда соң алар?

— Алачык та юк... Теге әшәке малайлар ут төртеп яндырганнар.

— Яндырганнар.

— Тик син борчылма... Киров районында хезмәт этләрен тәрбияләү клубы бар. Бик кирәксә, шуннан бәләкәчләрне алырга була.

Тик малай Идрискә ышанмады.

— Синең янга керергә җай булмады. Безгә Германиядән кунаклар килде, мин шуларны озатышып йөрим.

— Германиядән? — диде малай саңгырау гына.

Ыштанын күтәрә-күтәрә Вася малае узып китте.

— Айдарка, әйдә! — дип кычкырды ул шоколадлы бармагын ялап.

Идрискә дә ашыгырга кирәк иде, әнә, Фаина Наумовна белән Курт, сөйләшә-сөйләшә, аның ягына караштырып алалар.

— Син мине шушы араларда көт.
— Ярар.
— Килермен.
— Ярар.
— Ә кызларга тимә...
— Ярар.
— Алар бит син адашмасын дип курыкканнар.
— Безнең компас бар иде...
— Шулай да... Адашуың бик тиз!

Малай каерысы кубарылып беткән нарат төбендә боегып кына басып калды....

Фаина Наумовна мәкаләне Идрискә тапшырды, хуҗалар чәй эчәргә калырга кыстасалар да, кунаклар рәхмәт әйтеп баш тарттылар. Бераздан Васяның машинасы, агачларның юлга иелгән йомшак ботакларын ике якка айкый-айкый, урман юлыннан йөгерә иде.

Юл коры, һава шәп, Куртка балалар шәһәрчеге бик ошаган. Ул дулкынланган, сөйләп сүзләре бетми. Вася немецча җыр куплетлары башлап куя, өчәүләшеп аны күтәреп алалар, күңелләр көр, кәефләр шәп, сәфәр гаҗәп уңышлы дәвам итә. Сүз арасына тагын Касыйм Усманов килеп керә, машина көпчәкләре тагын да ятьрәк тәгәри башлыйлар...

«Урман арты» совхозында Казан — Горький шоссесын калдырып, Юдинога борылдылар. Вася мондагы юлларны яхшы белә икән, ул, Юдиноның комлы урамнарын читләтеп, турыдан-туры Биләй авылына барып төште.

Займищеда тимер юл аркылы чыкканда Идриснең эчендә ниндидер кайнарлык йөгерде... Тиздән, тиздән, әнә теге борылышны үтүгә, алар Бухенвальд җәһәннәмендә булган, мең газапларны кичергән татар коммунисты Касыйм Усмановны күрәчәкләр.

Дачаларның легендар каравылчысы — тоз күзле, аяксыз Хәким — машинага капка ачты, сорашты һәм Усмановлар дачасын күрсәтте:

— Әнә теге яшел түбәне күрәсезме?.. Шуның янында әберәкәй кадәрле генә зәңгәр йорт. Юк, анысында түгел... Шул йорт артында чуар кәрнизле, курчак өе кук бизәкле өй булыр. Шул инде Усмановның дачасы... Үткән атнада бергәләп балыкка барган идек, тоттык, әздән сигез кило булыр!..

Машинаны каравылчы өе янында калдырып, бакча түтәлләре арасына кереп киттеләр. Вася да, үтә кызыксынып, алар артыннан иярде. Хәкимнең эте Пальма кунаклар артыннан яман өреп калды...

## 34

Зәйтүнә: «Әткәйнең мылтыгы чормада ауный бугай», дип Мөзәкиргә дөресен әйтмәгән иде.

Әткәсе Фәтри язга таба ак халатын киеп, урман буйларында кыска койрык, кылый күз куяннарның чәлмәштергән чуар эзләре буйлап арка тире чыкканчы бер-ике тапкыр әйләнеп керде дә, рәт чыкмагач, мылтыгын майлап, шунда күз алдына гына, келәтнең түшәмен терәткән шома баганага элде.

Хәзер әтисе я кырда, я башка эштә, абыйсы Шәүкәт механика мастерскоеннан чыкмый ята, әнкәсе көнозын җәйләүдә, йорт арасындагы эшләр, кош-корт карау тулаем Зәйтүнәгә йөкләнде.

Әле ярый, бәбкәләр исәйделәр, тилгән мәлгуньгә бирешерлек түгелләр...

Тавыкларга җим алырга келәткә кергән саен кызның ике күзе тик кушкөбәкле мылтыкка төшә... Учы белән иске кыл иләккә бодай тутыра, күзе һаман мылтыкта...

Куркыныч, хәвефле нәрсә ул мылтык...

Бүген дә, кулын ларга тыгуга, кыз шома баганага карады, әсселесуыклы булып китте: мылтык урынында юк иде!

Зәйтүнә иләген атып бәрде, кубарылып ишек алдына чыкты. Дәү ак тавыклар келәт астыннан да, капка ярыгынннан да аңа таба зыр-пыр чабышалар иде.

Әтисе берәр башка урынга алып куйган булса?..

Мөгаен, шулайдыр, күз алдында тормасын дигәндер...

Ул, келәткә кире кереп, ашык-пошык актарынырга кереште. Абыйсының пыяла китеге белән шомартып ясаган җәясе килеп чыкты. Яшен ташы дип ата-бабадан сакланып килгән шома чуерташ күзгә чалынды... Каз мамыгы тутырылган мендәрнең авызы юньләп бәйләнмәгән икән, киштәдән идәнгә төшеп йон чәчелде... Мылтык бер җирдә дә күренмәде. Тавыклар, кызны үртәгәндәй, аның саен әрсезләнеп келәткә һөҗүмне көчәйттеләр, өерелеп эчкә үк керделәр, ишекне ябар иде, караңгыда кала, Зәйтүнә аларны куркытып тибеп иләкне тәгәрәтте, кулларын яман чәбәкләп:

— Кө-өш! — дип ишек янына йөгергәләп килде.

Аннары чалгыга ябышты. Тамак асларын дер-дер селкетеп, ко-ко-ко дип тавыкбикәләренә көч биреп торучы әтәч, кызның ярсулы тавышын ишетеп, иң әүвәл читкә шылды...

Әйе, әйе, кичә соң гына аларга Мөзәкир кереп чыкты...

«Шәүкәт абыйның техникумда укыган китаплары калмаганмы?» дип кергән... Нәрсәгә кирәк булган аңа китаплар?.. Нигә ул абыйсы өйдә чакта кермәгән?

Әйе, әйе, ул кергәндә Зәйтүнә ындырдан беренче тапкыр яшь бәрәңге казып алып, болдыр баскычында шуны кыра иде... Мөзәкир керде, әтисе белән сөйләшкән булып торды, китапларны да шуннан сорады... Әтисе: «Малай үзе кайткач керерсең инде, парин», диде...

Әтисе көн саен, эштән кайткач, ишек алдында җиз таста кояшта җылынган суны күтәреп, ягылмаган мунчага юынырга китә... Мөзәкир белән сөйләште дә, тасын күтәреп тагын шул мунчага юнәлде... Зәйтүнә бәрәңгене казанга салырга дип өйгә керде... Ишек алдында Мөзәкир берүзе калды түгелме? Калды!.. Капка ачык, келәт ишегенең бигендә агач чөй генә, суыр да чыгар, атла да кер... Ә мылтык, юри әзерләп куйгандай, күз алдында гына тора. Ал да шыл...

Кыз өйдәге эшләрен бетереп чыкканда, малай ишек алдында юк иде!

Зәйтүнә, келәт бусагасына утырып, яңагына таянып, боларны берәмберәм күз алдыннан кичерде... Аннан ул мылтыкны кочаклап чыгып баручы Мөзәкирне ап-ачык итеп күргәндәй булды... Менә ул шыпан-шыпан гына чыгып сыза... Теге явыз дошманнарын эзәрлекләп, түше белән шуышып бара... Менә юл кырыенда, агач артында аларны сагалап тора... Менә... Моннан арысын күз алдына китерергә курыкты кыз... Кинәт колак янында гына коточарлык шартлау яңгырады, ул чәрелдәп идәнгә авып төште, колакларын томалады...

Бераздан самолет гөрелдесе ишетелә башлады, уф, реактив самолет авыл өстеннән очып үткәндә, шуның шартлавы гына булган икән.

Ул идәнгә тезләнде, лардан ике кушуч бодай алып итәгенә салды, келәт ишеге төбенә чәчеп җибәрде, ындыр капкасына аркылы бастырык салды: эт-кош кереп тавык-чебиләрне куркытып бетермәсен. Ишекне бикләп-нитеп тормады, урамга чыкты һәм Мөзәкирләргә таба тыр-тыр чабарга тотынды.

Мөгаен, шул алгандыр, шулдыр, шулдыр...

Теге куркынычлы очрашудан бирле кыз аның артыннан күзәткәләп йөрде... Нәгыйм урынына җәйләүгә киткәч, Мөзәкир аннан дүрт көн кайтмады (бит-күзләре төзәлгәнне көтеп ятты). Зәйтүнә ул чагында көн саен әнкәсе янына барып йөрде. Моның белән әнисен дә, зоотехник

Тәслимәне дә шаккатырды. «Моңарчы, ферма дигәнне ишеткәч, чиләдә койрык чәнчеп чапкан яшь бозау күк йөргән кыз ипкә кереп барамы әллә?» дип, җәйләүдәгеләр үзара сөйләшеп тә алдылар.

Беркөнне, каз бәбкәләрен барлаганда, кыз Мөзәкирне теге тракторлар ишкән ярда күрде. Кулында кармак саплары, ә үзе суга караган да нидер уйлана...

Кемнәр кыйнаганын нигә берәүгә дә әйтмәде икән?..

«Исерек башлар Бизрә ярын ишеп бетергәннәр», дип авыл халкы сукрангалап йөрде, юл төзүче бульдозерчыларны милициягә чакырып штраф та түләттеләр, ә малайның кыйналуы турында бер кем авыз ачып бер сүз әйтмәде...

Урам капкалары шар ачык...

Җилдә шыгыр-шагыр килә, майламаганнар...

Ишек аллары буп-буш...

Өй тәрәзәләре дә ачык.

Зәйтүнә, әллә кемне генә эзләгән төсле урамның теге башына карап, алар турына килеп басты. Җыр шыңшыгандай итте... Үрелеп карар иде, тәрәзә биектә, сылап акка буялган таш нигезле, эре-эре таза бүрәнәләрдән ишле семьяга исәпләп салынган биек йорт. Әле нигез киртләченә бассаң да буең җитәрме, наличниккә ябышып аяк очына бассаң гына...

Кинәт өй эчендә кемдер чәрелдәп җылап җибәрде:

— Әлә-лә-лә!

Зәйтүнәнең куркудан чәчләре үрә торды: нигә шулкадәр акыра икән Рузилә?

Ул сыңар аягы белән таш нигез киртләченә басты, үрелеп, наличниккә тотынды, түше белән бүрәнәләргә ышкыла-ышкыла сузылып, өй эченә карады. Берни күренмәде, гөлләр комачаулый иде.

Рузилә тагын такмакларга ябышты.

— Әтә-тә-тә, абый, абый!

Кыз куркуыннан чак очып төшмәде. Нәкъ аның борын төбендә генә Рузиләне көн яктысына алып килеп, Мөзәкир сеңелесенең күзеннән чүп алып маташа иде. Башта ул аның ни эшләгәнен аңышмый торды.

— Йомма, йомма дим күзеңне!.. Тигәнәк чаты кергән синең күзенә, кызый. Аны алу ансат түгел, бел... Акырсаң — сукыр да калырсың, түз...

Малайның кулында дүрткә бөкләгән чиста кульяулыгы.

— Авырта-а! — дип, авызын вак бәлеш хәтле ачып елады Рузилә.

— Ума дим... Каткан сарык койрыгы төсле кулың белән күзеңә тотынасың, кагылма!

Ул Рузиләнең күзендә бик җентекләп чокчынды, Зәйтүнә, чытырдап ябышып дөньясын оныткан бер рәвештә, аның хәрәкәтләрен күзәтеп торды. Мөзәкир бераздан турайды, бармак очларында нидер әвәләп, ышкып карады.

— Беттеме?

— Ю-юк... Әлә-лә-лә!.. Сызлый.

— Чүбен алдым, акырма. Урыны кырса кырадыр... Моннан болай акыл, тигәнәк арасына кергәненне күрсәм, теш казналарынны буш ясармын. Чәчләрең киезләнеп беткән, юньсез. Ал тарак, тара әйбәтләп.

— Теш казнамны? — диде кыз, күзен кара йодрыгы белән уып.

— Әйе. Врачка алып барам да теге дырылдавык машина белән барын чүпләтәм. Йөр әби авыз булып.

Зәйтүнә житез генә ычкынып җиргә сикермәкче иде, кулы тамчы гөл чүлмәгенә кагылды, чүлмәк әчке якка идәнгә тәкмәрләде, шапылдап төшүе булды, көлгә дә әйләнде. Кыз куркудан җайсыз сикерде, үкчәсе зыңгылдады, йөз чытып өскә караса, тәрәзәдә — Мөзәкирнең ачулы күзләре. Менә ул кинәт елмайды:

— Жен бар дип торам...
— Чүлмәгегез батылдымы?
Хәзер генә бер хәйлә табасы иде дә бит, тик Зәйтүнәнең анысына башы җитмәде. Малай күздән югалып торды, янадан күтәрелгәндә аның кулында балчыклы тамырлары таралып торган тамчылы гөл иде.
— Ватылуы әйбәт булды, чүлмәге бәләкәйләнгән икән. Кара инде, тамырлары кырыйга шыпланып ничек бөялгәннәр!.. Күчереп утыртасы булган...
Авызына бармагын капкан куян күзле Рузилә абыйсының култыгы астыннан күренде. Мөзәкир, култыгын җәеп, аның башы кысты:
— Бар диләр сиңа, уйна.
— Әле чәч тара дигән иде...
— Житешерсең, уйна.
— Өченче көн кая бардың, Мөзәкир?
Малай көлеп үк җибәрде:
— Син шуны сорарга тәрәзәгә мендеңме?
— Ха,— дип борынын җыерды кыз.— Шуңа мендем ди... Рузиләне ник чырылдатасың икән дип җәлләп мендем.
Малай өстән торып сөйләшүне яхшысынмады, капка төбенә йөгереп чыкты һәм кызны ишек алдына чакырды, алар бер-берсеннән шактый ерак торып сөйләшергә тотындылар.
— Торна сазына барып печән карадым.
— Аннан чаптырмыйлар бит.
— Чалгы кермәслек түмгәк аралары калыр әле!
— Былтыр да әнә безнең Тажи абыйны штраф түләтеп җәфаладылар... Кеше кермәслек урыннардан гына җыештырган идем дип зарланып йөрде.
— Тажи абыйны тотканнар бит аны, мине тотып карасыннар!
— Алай да,— диде кыз, көрсенеп.— Әнкәй җибәрсә, мин дә сезнең белән барам.
— Йөрмә.
— Нишләп?
Мөзәкир, Зәйтүнәнең теге серне бераүгә дә ачмавына эченнән генә рәхмәт укыса да, кызның чытлыкланып, сагаеп эзәрлекләвен сизенгәли иде. Йомышсыз-эшсез тәрәзәгә менеп йөрүенә ачуы чыгып торганда, тагын печәнлеккә тагылып барырга җыенуын да ишеткәч, тупасланырга керешге.
— Ерак ул, я еларсың...
— Синең арбаңа утырмам, курыкма. Барсам, камыр җимеше ашарга барам.
— Камыр җимеше пешмәгән.
— Каян беләсең?
— Карадым,— диде малай, беләген сызганып.— Күрәсеңме, камырлыкта сыдырттым.
Терсәктән чак кына түбәнрәк ике-өч урында песи тырнаган сыман кутырлаган эзләр бар иде.
— Камыр җимеше пешмәсә, торна бәбкәләрен карыйм.
— Батып үләсең килсә, керерсең, Мукшы күленең суы арткан. Аннары, торна бәбкәләрен карарга ярамый. Кеше күрсә, аны ата-аналары ташлап китә.
— Торна үз бәбкәсен ташлыймы? Белдең...
Әллә кай арада гына аяк астына килеп кергән Рузилә тагын борынын казырга тотынды.
— Кызлар янына барасыңмы син, юкмы, тигәнәк чыпчыгы?
Рузилә кап-кара үкчәләрен күрсәтеп урамга йөгерде.
— Миңа да шул ук әмерме? — диде Зәйтүнә, шукланып.
— Нинди әмер?

— Кызлар янына куасындыр инде.
— Куды ди...
Малай, гаеп өстендә тотылган төсле, кызарынды.
— Торналарны күрдеңме?
— Тавышлары ишетелде.
— Шунда күршедәге борчак җиренә төшәләр алар.
Кызның китәсе килми, аның мылтык турында берәр сүз чыгартасы килә, шуңа күрә ул тагын торналар турында сүз куертты.
— Түбән очның Гаптери былтыр торна аткан дип сөйләделәр.
— Аннан булыр...
— Ничек йөрәге җитеп атты икән? Ятим калган сыңары каргый ди бит аның...
— Сыңары каңгырып үлгәнче йөри инде, ә аткан кешесенә берни дә булмый.
Ул арада нәкъ алар телгә алган Түбән очтан чабышып менүче ике малай күренде. Болар, Мөзәкирдән бәләкәйрәк булсалар да, бер очның хокукында бергә аралаша торган кандалалар. Алар нидер бәхәсләшеп чапкан җирләреннән мышкылдап тукталдылар. Мөзәкир капка янына килде.
— Ни гөрлисез?
— Мөслах җизни төлке атып алган,— диде малайларның берсе.
— Кайда?
— Төнәген төлке фермада ун тавыкны буган... Өченче көн дә күргәннәр.
Тавык фермасына төлке ияләшкәнне Мөзәкир дә ишеткән иде.
— Мөслах җизни бүген таңнан саклап торган да аткан,— диде мактанып малай.
— Белдең,— диде малайларның икенчесе.— Бер аткач та тимәгән. Төлке үлгән булып хәйләләп ята икән, Мөслах абый бара башлагач, торган да чапкан. Икенче көпшәсеннән аткач кына үтергән.
— Булыр,— дип раслады Мөзәкир.— Мөслах абыйның сездән мылтык алып чыкканын күргән идем, Зәйтүнә.
— Чынмы? — диде кыз, шатланып.
— Әйе инде, әйе. Йөгердекме?
— Кая?
— Түбән очка.
— Әйдә!
— Рузилә, Рузилә! — дип эзләнде Мөзәкир.
Итәгеннән туфрак коя-коя, болдыр астыннан Рузилә килеп чыкты.
— Кай арада кереп өлгердең, бичара? Әйдә, төлке карарга!
Алар өчәүләшеп Түбән очка йөгерделәр.
Капка ачык...
Шыгырдый...
Өй алды ябылмаган...
Өй ишеге дә шар ачык...
Тавыклар кырлый-кырлый өй алдына кереп тулдылар, өйгә өерелеп уздылар, идәндә яткан тамчы гөлен чукып, тырмап, тамырларын чәрдәкләп, чәчәкләрен өзгәләп, туфрагын чәчеп бетерделәр.
Капка шыгырдаган саен башларын күтәреп карыйлар үзләре тагын...

## 35

Тожымнарын бөдеркәли-бөдеркәли әрсезләнеп түтәл араларына сузылган кыяр сабаклары, купшы кишер мыеклары чәтерт-чәтерт итеп аяк астында калалар, алар, егылып китмәс өчен кулларын киң айкый-айкый, кабаланалар, иң алдан Идрис теркелди, аның артыннан кабаланып Курт килә, иң арттан Вася йөгерә.

Кура җиләге куаклары куелыгыннан сипкелле борыннар, елтыр күзләр карап кала, сукмак чирәмендә чуар песи балалары шаяра. Каяндыр татлы төтен исе, татлы ризык исе килеп борынга керә. Төзелеп бетмәгән йортның как идәненә шәп-шәрә егет чалкан яткан да иренеп кенә гитара чиртә.

— Тополя... тополя... тополя...— дип бер җайга гына суза ул. Идрис ялт кына Куртка борылып карады.

— Йөрәк урынындамы?

— Әйтү кыен... Тизрәк күрәсем, сөйләшәсем килә. Минем әтием сүзгә саран кеше иде. Бәлки үзем яшьрәк, акылсызрак булганга чынчынлап сөйләшеп бетереп кала алмаганмын, күп нәрсәләр билгесез миңа!.. Ә алар озак кына бергә яшәгәннәр, сер бүлешкәннәр, дошман белән көрәшкәннәр. Касыйм Усманов күп нәрсәләр белергә тиеш.

Хәким каравылчы күрсәткән маршрут бетеп килә.

Әнә зәңгәр йорт...

Әнә курчак өенеке төсле бизәкле тәрәзәләр...

Төртке-төртке кара төшкән ак күлмәгенең изүен мул ычкындырып, кара кәләпүшле татар карты йорттан чыгып килә. Кулында чүкечме, өтергеме... Сөннәтләп кырылган ярым чал сакал... Калын кара кашлар... Карт булса да, күкрәк киң, гәүдә базык. Маңгаена эре-эре сырлар таралышып яткан. Маңгайга сыймаганнар, ваграклары, тере, шат күзләр тирәсенә каймаланып тәгәрәшкәннәр. Шулмы? Шул үземе?

Карт үзенә чекерәеп аптырашкан өч ирне күреп туктады, елмайды.

Үземе, үземе?

Алар өчәүләшеп, бер-берсен этә-этә, карт алдына килеп бөялделәр һәм бер мәлгә бөтенләй исләрен-акылларын җыя алмыйча таралып, аптырап басып калдылар. Инде карт та уңайсызланды, гаеп-кыегым бармы әллә дигән сыман, өс-башына күз төшерде, кулындагы нәрсәләрен сулдагы верстакка куйды.

— Касыйм абый сез буласызмы? — диде Идрис, ниһаять.

— Үзе идем,— диде карт, йомшак кына.

— Ул! — диде Идрис, немецча.

Өчесе дә аһылдап куйдылар.

* * *

Алар эзләп килгән кеше чыннан да Касыйм Усманов булып чыкты.

Мең дә тугыз йөздә җиденче елда туган...

Кырык бернең июнендә үк сугышка чыгып киткән...

Көнчыгыш Пруссиядә бароннар өнен туздырганда дүртенче кат яраланган һәм сугышны шунда тәмамлаган. Өч орден һәм җиде медаль кавалеры. Коммунист.

Бухенвальд?

Сугыштан соң ишеткән... Бухенвальдны да, Маутхаузенны да, Освенцимны да... Юк, үзе әсирлектә булмаган, кызганычка каршы, Куртның әтисен дә очрата алмаган...

Касыйм Усманов... Үзе дә, түгел дә...

Курт үзенең кәефе кырылуын сиздермәскә тырышты.

Кунак немецның әтисе гозерен үтәү йөзеннән шулкадәрле җирләр үтеп, үзенең адашы Касыйм Усмановны эзләп килүен ишеткәч, картның исе китте, ул аны олылап түренә чакырды.

— Безнең халыкта бусагадан борылып китеш юк, тормыш-көнкүрешебез белән дә танышырсыз,— диде ул кат-кат.

Килгән-килгән, ташлап китү ару түгел иде, аякларын салып, өй эченә оекчан уздылар.

Биләмгә киткән җиреннән Минниса карчык та кайтып керде, алар карт белән күзгә-күз генә караштылар, карчык шунда ук чебеш әнкәсе күк кыр-кыр җилләнеп йөрергә тотынды. Кухня идәне астында кар

базлары бар икән, карчык, бисмилла дип, иң әүвәл шуннан катык алып менде.

— Сөтне кибеттән алмыйбыз, кибетнеке сыек була, ләззәтсез. Ике көнгә бер тапкыр Биләй авылына белеш апайга йөрибез. Кыйбатрак булса да, сөте бик куе, хуҗасы да бик пөхтә — чиста, кинәнегез,— диде ул, коштабак тирәсенә тәти агач кашыклар тезеп. Күз ачып йомганчы кара карлыган, кызыл карлыган, кура җиләге ише нәрсәләр өстәлгә тәлинкә-тәлинкә менеп тезелештеләр.

— Акча җимеше түгел, бакчаныкы, үзебезнең хәзинә,— диде канәгатьлек белән Касыйм.

Картның әндый-мондыйга алып куйган бер кызылы белән бер агы да бар иде, муеннарыннан гына тотып аларны да чоланнан алып керде. Минниса карчык газ өстендә тиз-тиз генә күкәй тәбәсе куырды, шпрот ачты, күмәч-мүмәчләрне телде, табын түгәрәкләнде. Чәй чокырларына иң элек шәрап койдылар.

— Ягез, туганнар, житешегез,— диде Касыйм, иple мыекларын сыпырып.— Дөнья булгач, менә очраштык та... Тазалык-саулык өчен җайлап кына берне күтәреп куйыйкчы.

Өстәл тирәсендә әңгәмә бик тиз җанланды.

Бераз кызып, үзләшеп алгач, Касыйм абзыйның теле тагын да чишелде:

— Кайда тукталдым дисең, Курт туган? Гостиницада?.. Һәй, ямьле җәйдә интегеп шунда яталармы?.. Бүгеннән миндә торасың. Көймә дә бар минем, кармак-кормагы да житәрлек, рәхәтләнеп балык тотып тик ят!.. Усманов татарда күп таралган фамилия ул... Усманов исемен йөрткән легендар героебыз да, дөньясына даны киткән галимнәребез дә, бик кызыклы яшь белгечләр дә бар... Син ары-бире ял иткән арада бергәләп теге Усмановны да табып куярбыз.

— Бәлки ул Усановтыр?

— Белеп булмый, туган... Дөнья бик чуар, безнең татар халкы Рәчәйнең дүрт ягына таралып утырган. Русы, чувашы белән аралашкан дигәндәй, Усмановың бер җай белән Усановка әйләнсә дә — бер дә гаҗәп түгел. Төрле хәлләр булып узды ич!.. Ул Себер якларында, примергә әйтик, нинди генә исемнәр юк... Чәләкә дип йөртәләр, бактың исә, ул үзебезнең Сәләхетдин булып чыга.

— Безгә кирәкле Усанов Казанда яшәргә тиеш. Яки кайчан исә бер шушында торган кеше. Анысын әти яхшы хәтерли иде,— диде Курт, уйланып.

— Монда икән, бигрәк мач килә! Табабыз аны, шикләнмә, бергәләп тотынсак тапмыйбызмы соң? Кеше кадәр кеше ник табылмасын, юләр!

Дипломатия кагыйдәләренә ярагандырмы, юктырмы, бер дә сырланмыйча, бик әйбәтләп сыйланып чыктылар. Карт белән карчыкның «кунакларыбыз!» дип өзгәләнеп, кеткелдәп кенә торулары Куртка да өметсезләнергә вакыт бирмәде.

Бик якынаеп, адреслар алмашып, туганнарча саубуллашып кына торганда тоз күзен майландырып, титаклап, каравылчы Хәким дә килеп житте. Касыйм карт аның өлешен шешә төбендә калдырган икән, аны да сыйладылар...

Хуҗалар белән саубуллашып капкага таба юнәлгәннәр иде, әле буялмаган да ап-ак йортның ишек төбендә Ренат Кәрамов күзгә чалынды. Зуп-зур, буаз сыер корсагы хәтле яшел рюкзаклар, кармаклар, якорьлар арасында нидер бәйләп маташкан Ренат аларны күрмәде, эндәшми генә үтеп китеп тә була иде, әмма Идрис Айдарның этисе яныннан сүзсез-өнсез генә үтеп китә алмады. Тукталды, азрак карап торды, аннан гадәттәгедән кычкырыбрак сәлам бирде:

— Кәрамовка салют.

Ренат калкынды, кара күзлеген салып башын иде, сәламне алды. Веранда тәрәзәсе тавышсыз гына ачылды, аннан түбәсенә күбәләк канаты хәтле генә ак яулык чөйгән Луизаның башы күренде.

— Кунаклармы, Ренат?

— Әлегә белгән юк...

— Кунаклар, кунаклар,— дип чикылдады Луиза.

— Каршыларга чык.

Ренат, рюкзакларны, кармак сапларын бер кырыйгарак күчереп, баскычтан үтәрлек ара ясады, йөгереп диярлек Луиза чыкты.

— Өйгә рәхим итегез.

— Ашыгабыз, Луиза ханым.

— Кая шулкадәр ашыгасыз инде сез?

Яшь хатынның күзләре шуклык белән яналар иде.

— Шәһәргә... Бу... Курт иптәш. ГДРдан. Безнең кунак. Архитектор. Безнеңчә әйткәндә, мигъмар була.

— Германиядән? — Луизаның ясалма кунакчыллыгы, кыланчык кызыксынуы шул секундта ук чынга әйләнде.— Ренат! Күктән йолдыз чүпләргә кушмыйм, әмма кунакны коры гына кайтарып җибәрсәң, рәхим-шәфкать өметләнмә.

— Монда күңелле генә сәфәр оешырга тора,— диде Ренат.— Хәзер иптәшләр килеп житә, төнгегә балыкка барырга дибез.

Алар чакыруында күңелгә йогышсыз бәйләнчеклек, төчелек сизелсә дә, Идрис тәкъдимне Куртка әйтми булдыра алмады. Үзе күңеленнән, компаниядә кемнәр булыр икән, дип борчылды. Ренат санап күрсәтте. Редакция егетләренең берсен — атаклы балыкчы, яр буенда язынкөзен (җәйне-кышны әйткән дә юк!) җилдә кибеп үзе дә корышкан воблага әйләнгән җирән Сибайны ул яхшы белә... Аның азрак шәрап йоткач кызып-кыдрачланып китә торган гадәте дә бар бугай... Башкаларны ул белми дә диярлек... Шулар арасына бер әзерлексез Куртны алып барып кереп соныннан оят булмасмы?

Эш Куртның үзендә калды.

— Балык тотып булырмы анда? — диде ул.

— Күз туярлык ук димим, әмма күңел почмакланырлык тотарбыз.

Курт Ренатның тыйнаклыгын ошатты. Ул арада сүзгә Василий катышты:

— Җәмәгать, Виталий Петрович безне асып куяр бит!

Курт үзенең бик теләп барырга ризалыгын, Казанга килеп төшкәннән бирле Иделдә балык тотарга, яки һич булмаса карап торырга кыҗрап йөрүен әйткәч, икеләнеп торырга урын калмады.

Идрис Васяны бер читкәрәк чакырып алды:

— Сиңа шәһәргә кайтырга туры килә, дус,— диде.— Югыйсә эшләр харап. Виталий Петрович та, Куртның юлдашлары да аның кайдалыгын белергә тиешләр... Мин чит ил кунакларының хокуклары статусын белмим, сүзе миңа булыр, әйдә, беткән баш беткән! Иртәгә үз вакытың белән алырга килерсең.

Вася бик борчылып, икеләнеп торды, кунакны ташлап китәргә авырлык белән генә ризалашты.

— Алайса, Виталий Петровичка Усманов турында да сөйләргә кирәктер инде?

— Әлбәттә! Сүзне шуннан башларсың!..

— Хушыгыз алайса!

Васяны озатып килделәр, Ренатның иптәшләре һаман күренмиләр иде. Көн никадәрле озын булмасын, кояш әнә ашыгып-ашыгып офыкка тәгәри. Идрис Ренатка пошынып карады.

Луиза янына урта яшьләрдәге, ләкин шаккатырырга теләп киенгән икенче бер ханым килеп, алар нидер киңәшә башладылар.

— Балыкка ханымнар да барамы?

— Алар безне утраура озатып куялар.
Балыкчы егетләр кайтып төште. Алар сазлык тирәләрендә казынып суалчан эзләгәннәр, бер очтан Займище кибетенә кагылып чыкканнар иде. Сибай, Курт белән Идриснең балыкка барырга теләүләрен белгәч, авызын ерды:
— Төнгелеккә малай чактагы кебек тупланып барырга яратам! Әкәмәт тә кызык була анда!
— Сиңа свита җитми инде, король,— диде Ренат.— Юлыгыз уңдымы?
— Без дә булыйк, юл да уңмасын ди!..
— Ягез, кем нәрсә күтәрә ала?
Ренатка мотор тоттырдылар, Идрис бензин багын алды, башкалар, кем нәрсә күтәренеп, шау-гөр килеп Иделгә таба киттеләр. Ике хатын-кыз, биш ир-ат утырган җиде метрлы тирән генә көймәне сигез ат көчле «Җилкәй» моторы дөпелдәп кенә кузгатты, журналистлар дачасын каймалаган тыныч аулак култыктан Иделгә, утраулар арасына алып чыкты.
Моторда Сибай үзе, аннан алдагы шома тактада Идрис белән Курт урнаштылар, ишкәк янындагы киң эскәмиядә дүртәү: ханымнар, тезләрен яшерергә тырышып, Идрисләргә карап утыралар, ирләр, борынга менеп сузылган Ренат белән сөйләшкәләп, алга карап баралар.
Мачта кебек озын, чалбары да тормаслык шома, ябык Сибайның җирән бөдрә чәчләрен, өй түбәсендәге бер почкак саламны селкеткән кебек, өзлексез җил җилбердәтә. Балык җене кагылган бу кешенең Идел суы төсле саргылт-зәңгәр күзләрендә ниндидер бәхет, онытылу томаны өретелеп тора иде.
Сибай торымнан-торымга Ренатка нидер кычкыра, Ренат иренеп кенә калкына, моторга һәм колакларына ишарәләп күрсәтә. Хатын-кызлар да су иркенлегендә рәхәтләнеп чыркылдыйлар, борт аша үрелеп су алалар һәм борылып Ренатка сибәләр.
Курт Идел киңлеген бүлгәләгән тезмә-тезмә бәләкәй, күңелгә ятышлы утрауларны тынсыз-өнсез гашыйк кебек тамаша итә иде. Алар аратирә Идрис белән сүз алышалар да тагын онытылалар.
Шушы ич инде Идел!
Волга, Волга!.. Матушка река!
Фашизм шушы матурлыкның хуҗаларын кол итәргә, шушы ярларның әфәндесе булырга омтылган икән!..
Шушы бөек елгадан күтәрелгән баһадирлар Берлинга барып кергәннәр... Дошманны алдан да, арттан да тукмаганнар... Петр Гавриловлар, Мусалар... Әнә Касыйм Усмановлар...
Курт Идел белән мавыгып барганда, Идрис хатын-кызларның сөйләшүенә ирексездән колак салды. Луиза белән бу ханым (Идрис аның исемен дә, кайсы ирнең хатыны булуын да белергә өлгермәде) бергә укыганнар, ахры, уртак танышлары да, уртак хатирәләре дә бик күп иде...
— Роза нишләгән, ишеттеңме?
— Хи-хи-хи...
— Ул хәтле үк ярамый инде.
— Болганышканнар... Сөяркәсе моны озата килә икән, капка төпләрендә ире басып тора ди... Әхтәмхан... Роза авызын ерып иренә: «Таныш, менә бу егет минем сөяркәм», ди икән...
— Маһирәне күргәлисеңме?
— Менә кем яши белә ул!.. Өйдә берни эшләми: ашарга әзерләми, идән юмый, кергә кул тидерми, барын да ире башкара. Каенанасын куып чыгарды, картларны өенә эз бастырмый. Дөрес инде, дөньяны бутаучылар шулар!.. Ә Маһирә ни тели шуны ашый, рестораннан чыкмый, һәр кич иң соңгы сеанска кинога керә. Ире балаларын ашатып-

әчертеп, юындырып йоклаткач, өйдәге эшләрне тәмамлагач кына кайтып кирә.

— Анын икәүме?

— Берсен картларга илтеп ташлаганнар, икенчесе атналыкта.

Идриснең яңак мускуллары тартышып алды, Маһирә дигәннәре бу ханымнарның идеологлары иде, ахрысы, икесе дә аның исемен тирән хөрмәт, данлау белән телгә алалар.

— Көйләгән алайса тормышын...

— Кем уйлаган диген, я ходай! Группада иң йолкыш, иң сабыр, үтә тыйнак кыз иде ләбаса... Баксаң, хәзер аю кебек ирен биетә.— Ханымның тавышы шыпыртланды.— Ә киногә нинди егетләр белән йөргән белсәң!.. Алар йортында гел спортсменнар... Мине дә берәү белән таныштырды... Ишү буенча Европа чемпионы, тик саран каһәр...

Көймәдән сикереп төшеп калып булмый, чыдаса да чыдады Идрис, ниһаять, котылу юлын уйлап тапты:

— Әйдәгез, җырлыйбыз,— дип кычкырды.

Сибай, көймә койрыгына басып, таслаган такта кебек сипкелле беләкләрен болгап дирижировать итәргә тотынган иде, көймә кылдыйбылдый бара башлады...

Татарча җырларга керешкәннәр иде, ул оешмады, егетләр тырышып та карадылар, ханымнар катышмагач, ул җыр сүнде. Аннары «Мәскәү янындагы кичләр»не суздылар. Курт та бу җырны белә икән, немецча-татарча-русча күмәк җыр мотор такылдавын күмеп яңгырады. Аларга каршы очраган көймәләрдән хатын-кыз, бала-чага кычкырып, яулык болгап узды. Көймәнең бнек, үткен борыны чожт иттереп вак камышлар арасына ерып кергәнче җырдан туктамадылар.

Утраулар тезмәсенең соңгысы икән инде бу, моннан ары Олы Идел, фарватер башлана. Элек кайчандыр эре агачлык булган бу утрауларда хәзер тәбәшәк гарип иманнәр, таллар һәм әрсез гөлҗимеш агачлары үсә. Нәкъ уртада һәр яктан вак тал куаклары белән ышыкланган түгәрәк алан бар икән, нәрсә-караларны көймәдән тиз-тиз шунда күчерделәр.

Күз бәйләнә башлаганчы палатка куярга, учак тергезеп, коры-сары утын запасы әзерләргә, балык тотып кичке ашка уха өлгертергә кирәк иде.

Монда инде Сибай биләмәләре. Эшне ул бүлеп бирде:

— Ренат-ялкау, барыбер сиңа балык эләкми, палатка куярсың... Мин егетләр белән бәхетне сынап карарга барам! Кунакларга да кармак бар, көн яктысында тирә-юнь белән аз-маз танышып алганнан соң алар да көч сыный алалар... Ханымнар утын җыештыра!

— О,— диде иренен бөрештереп Луиза.— Безнең кунаклар белән йөрисе килә.

— Ул чагында утынны бергәләп җыябыз,— диде Идрис.

— Бусы башка мәсьәлә,— диде Луиза, шатланып.— Мин утынлыкны күрсәтермен.

Луиза чытлыкланып Курттан бер адым да калмый башлады, икенче ханымның исеме Нәзирә икән, анысы күзләрен очкынландырып Идрискә карый. Куртның гаиләсе, эше, кайсы илләрдә булуы турында Луиза бик тәфсилләп, тәмләп сорашып бетерде. Ике-өч кочак ботак-сатак җыйган арада Курт көлемсерәп тулы биографиясен сөйләп бирде.

— Ирекле баштан сезне коллыкка саттык, ахры, без? — диде борчылып Идрис.

— Зарар юк,— дип көлде Курт.

Утрауның читләрен карап әйләнделәр. Иделнең югары агымы уңаенда түгәрәк-түгәрәк кенә тын күлләр бар икән, шыпырт кына барып кыр үрдәгенең балаларын карадылар.

— Миллионга якын кешесе булган шундый зур шәһәр янында гына мондый табигать гүзәллеге саклану зур бәхет инде, халкыгызның әйбәтлеген күрсәтә бу,— диде Курт.

Луиза Иделнең шушы Моркваш каршысындагы утраулары, кайда нинди балык эләгүен дәртләнеп кенә сөйләп бирде.

— Сез монда еш буласыз, ахры? — дип сорады Идрис.

Аның соравында астыртын мыскыллау ятса да, Луизаның читенсенергә исәбе юк иде:

— Икебез дә матурлык яратабыз,— дип мактанды ул.

Ул арада резин итекләрен чожтырдатып Сибай килеп житте.

— Кунак иптәш,— диде ул Куртка мөрәҗәгать итеп,— алабуга матур гына чиртә башлады, барырга исәп юкмы?

Курт Сибай белән китте, Идрис белән Ренат палатканың эшен бетерделәр, өчаякны торгызып, казан астылар.

— Сүз балыкчыларга бирелә,— диде Идрис.

— Хәзер мин ханымнарны озатып киләм,— диде Ренат.

— Ә без кайтмыйбыз,— диде Луиза.

— Феодал булма, Ренат,— дип Нәзирә ханым да аны куәтләде.

— Кайда йокларсыз? Черкиләрдән кайда качасыз?

— Безнең Курт белән буласы килә.

Идриска Луизаның бәйләнчеклеге бер дә ошамады. Төне буе шуның ахмак, төче сорауларын тәрҗемә итеп йөрергә генә калган ди!

— Куртка бераз ял бирергә кирәк,— диде ул.— Рөхсәт итсәгез, бераз ялгыз да йөрсен инде!

Ренат Идрисне яклап сүз әйтүгә, Луиза аның үзенә каныкты, алар елмаешып чәкәләшергә үк керештеләр:

— Чит илләргә алып чыгарга кулыңнан килмиме?

— Анысы башка мәсьәлә...

— Килми!.. Нигә без йомылып яшәргә тиеш?

— Хәзер чит илгә чыгу берни түгел, акчаң гына булсын.

Ханымнар Ренатны ике яклап йолыккаласалар да, ул, егетлеге житеп, сүзендә торды:

— Бер палаткага җидәү сыя алмыйбыз. Аннары, Сибайның талканы коры, белегез.

— Кайтмыйбыз!..

Идрис, балык тотам дигән булып, Сибайлар янына китте, Ренат белән Луизаның бәхәсен тыңлап торырга аның түземе калмаган иде. Аңа да кармак табылды, әмма егет балыкчы буларак әллә кем түгел иде. Сибайның әче теленнән куркып-куркып кына тотынды. Бәхет елмайды тагын үзенә, кашык буе биш-алты алабуганы чәптереп тә алды. Курт арада иң бәхетле булып чыкты, җиде йөз граммлы, каты тәнле, буынтык-буынтык бизәкле көчле алабуганы ул тартып чыгарды. Аны берәү дә уздыра алмады.

Ничек юллагандыр, Ренат ханымнарны озатып килде. Учак утын зурайттылар. Җәен-кышын сәяхәттән кайтмый торган Сибай ашкасуга да бик оста икән. Табынны да күркәм итеп әзерләде. Комлырак жирне сайлап шунда иске плащлар җәйде, аларны чиста ашъяулык белән каплады. Ашъяулыкның дүрт почмагына дүрт стакан бастырып куйды.

— Архитектура бизәкләре белән артык мавыкмыйсыңмы, Сибай?.. Курт — белгеч кеше, дилетантлыгыңны сиздермә! — диде Идрис.

Сибай көлде:

— Табигать муллыкны ярата. Муллыкта бәрәкәт.

Шешә тирәләренә телем-телем колбаса, сыр турадылар, «Лечо», «Лобио» банкалары ачылды. Яшел кыярлар, помидорлар, суган кыяклары үз дәрәҗәләрен белеп кенә ашъяулык читләреннән урын алдылар. Уха пешеп, аның ләззәтле исе борыннарны өзмәс кытыклый башлагач,

Сибай балыкчыларны табынга чакырды. Аның һәр хәрәкәтендә, хуҗаларча күз йөртүендә ризыкка да, шушы тәмле ризыкларны ашарга җыенган утырдашларына да хөрмәт сизелеп тора иде. Аптекадагыча төгәллек белән, тамчысын да әрәм итмичә, савытларга шәрап койды.

— Ягез,— диде ул, Куртка башырып.— Кадерле кунагыбыз белән Идел утравында очрашуыбыз хөрмәтенә... Татарның борынгы бишеге Идел хөрмәтенә!.. Дуслыгыбыз хөрмәтенә чәркәләрне бушатыйкчы.

Күңелләр күтәренке иде, көлешеп чәкәштеләр, кыстатып, назланып торучы табылмады. Кичке тын һава, иркенлек, балык тотканда бушанган нервлар, чытыр-чытыр янган шат учак күңел ачу сорап торалар иде. Шәрабы да бер дә авырлык китермичә, тамакларны иркәләп шома гына, иркен генә төшеп китте... Мактый-мактый икешәр коштабак хуш исле, өреле уха ашадылар. Яшел суган, петрушка, укроп ише нәрсәләре чак туралган, кара борыч, лавр яфраклары кебек тәмләткечләр салынган уха ашап туйгысыз тәмле, ләззәтле иде.

Иң олы балыкны сосып Курт алдындагы ат кузгалагы яфрагына куйдылар:

— Чемпионга алтын медаль!

— Сибайның балыкчылык даны ерак-еракларга таралган, шушы егетлеге өстенә ул менә дигән пешекче дә икән! Аның саулыгына!

Идриснең бу тостын хуплап каршыладылар. Өченче тостны Курт тәкъдим итте:

— Рейн, Одер ярларында да шушылай туганнарча очрашыйк!

— Миссисипи, Амазонка ярларында очрашканда да зыян итмәс иде!

Уха янында кызыклы әңгәмә китте, мәзәкләр сөйләделәр, иң соңыннан учакның сүрән яктысында карта уйнадылар. Туклыклы аштан авырайган егетләрнең берсе дә утын җыярга барырга ашыкмады. Бераздан Сибай Идрисне читкә чакырып алды.

— Монда безнең бер этлек бар иде.

— Нәрсә ул?

— Төнгелеккә ау-җәтмә салып калдырмакчы булабыз.

— Салабыз әйдә!

— Кычкырма бик!.. Тыелган эш!.. Кунакны чөгә ухасы белән сыйларга дибез. Тик, рыбнадзор килеп тотып, җайсыз хәл чыкмасын.

— Безгә нишләргә соң?

— Кунакны алып китеп тор, без хәзер җайлыйбыз аны... Ул-бу килеп чыкса, сез күрмәгән дә, белмәгән дә...

— Яхшы.

— Йөреп килегез бар!

Идриснең Курт белән икәүдән-икәү генә иркенләп сөйләшәсе килә иде, ул куанып ризалашты. Алар, Иделгә төшеп, бит-кулларын юдылар. Ренат комга ышкый-ышкый корымлы казанны юып маташа иде.

— Айдар ни хәлдә? — дип сорады кинәт Идрис.

— Беразга котылдык,— диде Ренат, тураеп.— Көзгә хәтле җан тыныч.

— Шулай диген!..

## 36

Ренатның, артын күтәреп, комлы ярда корымлы казан чистартып азаплануын күргәч кенә Идрис ни өчен аның Луизаны ай-баена куймый кайтарып җибәрүен аңлады...

Кайчандыр, детсад ишек алдында, беренче тапкыр очрашканда аның егетләрчә кыяфәтен күреп, ул түбәнсенү кебегрәк тойгы кичергән иде. Хәзер ул Ренатны аңлады... Беренчелекне иртәрәк биргән аңа Идрис!..

Ренатка бөтенесен читләр, башка кешеләр әзерләп бирәләр...

Укытып чыгарганнар, киендергәннәр, ашатканнар...

Эштә ул хәлиткеч урынга үрелми, кем кул астындадыр жай гына гомер сөрә... Үз фикерен бер чакта да кычкырырга ашыкмый, ымсынып начальствоның авызына карый... Дачаны да аңа дусты салып куя... Хәтта менә шушы балык тотканда да ул һәрвакыт икенче дәрәҗәдәге вак эшләрдә йөри, чөнки өстенә җаваплылык алырга теләми!.. Бернәрсә өчен җавап бирми... Балык юк икән, Сибай гаепле! Башкалар гаепле!.. Тотсалар, чистарта, табак-савыт юа, шундый «карарак» эшләргә дә риза ул, башлап аны иярттсеннәр генә. Чөнки аның үзенең кармагы да, көймәсе дә, палаткасы да, бернәрсәсе дә юк... Әрсезлеге, казан корымын ышкырга әзерлеге генә бар. Шуның өчен ул бервакытта да Луизасын төнгелеккә калдырмый...

Шушы кеше үз кул көче, үз күңеле белән бала тәрбияли аламы?

Ихтыярсызлыгы, көчсезлеге белән ул үз баласы алдында әллә кайчан дәрәҗәсен югалткан!..

Матурлыкны яратканга түгел, Айдардан, кешеләрдән качып киләсез сез бу утрауларга, Кәрамовлар!..

Аяк асты хәзер кап-караңгы, Идрис, Куртның алдына чыгып, ботинка башлары белән жирне сыдырып-капшанып бара башлады. Әллә ни киң ара булмаса да, алар утрауның икенче ягына шактый озак чыктылар. Талларда сандугачлар өздерә, дымлы үлән араларыннан нидер кое чыгыры тавышы кебек үер-үер дип аваз сала. Идрис килгән саен шушы тавышны ишетә, әмма кайсы җан иясенең шулай үердәвен ачыклый алганы юк. Берәүләр сазлык бакасы кычкыра диләр, икенчеләр кәлтә җыланының бер төре шулай үерди бугай, ди.

Утрауның әллә ничә җирендә шулай үер-үер дип кое чыгыры әйләндерәләр...

Кич җылы булса да, черкиләр әллә ни бимазаламый, Идрис, иелеп куе тал ботакларын кочып бөкте дә, Куртка утырырга кушты:

— Рәхим итегез, утрауда иң яхшы көрси!

Үзе дә, ботаклар иеп, шундый урындыкка утырды.

Аргы як ярда чыршы уенчыклары кебек төрле төстәге утлар җемелди, анда-санда утрауларда учак ягалар, Идел өстендә сары, кызыл маяклар мелт-мелт итә, пыр да пыр килеп көймәләр уза. Югарыдан, Зөя тамагы ягыннан, утларын келпетеп өч катлы зур теплоход килеп чыкты, музыка тавышы яңгырады.

— Әгәр без бүген Усмановның чынын тапкан булсак!..

Куртның тавышында әрнү яңгырады...

— Курт, әле без бик аз эзләдек. Мин өметне җуярга җыенмыйм.

— Өметне мин бер чакта да югалтмыйм. Үзен тапмасак та Усманов кебек кешенең эзе бөтенләй юк югалмас!

— Эзе калырга тиеш, Курт...

Алар, теплоходтан яңгыраган музыка җаена тирбәнеп, бер-берсенә елышып сүзсез генә утыралар. Рәхәт, күңелле, баш ял итә...

— Ерактан торып халыкларны аңлау кыен,— дип башлады сүзен Курт.— Дөрес, әлбәттә, сәнгать, тарих күп нәрсәләрне сөйли!.. Менә Идел турында мең-мең тапкырлар укылган бит, киноларда күрелгән...

— Бездә, татарларда, бер сүз бар. Күз белән колак арасы дүрт бармак иңе генә, ә күргән белән ишеткәннең арасы җир белән күкнеке кадәр!

— Акыллы сүз...

— Әйе.

— Менә сезгә дә, Идрис, безнең Германиягә барырга кирәк.

— Барырга иде.

— Элекке заман кешеләре кебек эч пошканнан, хандрадан качып түгел, аңларга, белергә тырышып йөрергә кирәк хәзер дөньяда.

— Хәзерге заман туризмның асылы шул...

— Менә Германия... Яңа Германия... Аны укып кына, сөйләп кенә аңлап булмый... Ә Россия кешеләре Германияне аңларга тиешләр. Казанда кем белән генә сөйләшсәм дә, аңа сугыш кагылып узган...

Икесе дә бер үк уйлар тирәнлегенә чумып, тагын бераз тын утырдылар. Утрауның теге ягында сузып кына җыр башладылар.

— Бу Сибай! — диде Идрис, куанып.

— Йокламаганнар икән...

— Төн убыры, йоклыймы соң?..

Сибайга егетләр кушылды, Идрис аңлап алды, бу — аларга билге бирәләр, ауны салып бетергәннәр, кайтырга ярый...

Ләкин Куртның кузгалырга исәбе юк, Идрис үзе дә кинәнеп утыра бирә...

— Менә мин немец... Сезгә мәгълүм, бериш немецлар гомер-гомергә Иделгә омтылганнар. Идел — Уралга барып ялганган «бөек, мең еллык рейх» турында хыялланганнар... Менә мин шул атаклы елга ярында утырам... Без бер-беребезгә якын, уйларыбыз да, шушы матурлык та уртак!

Алар үзаралай син дип сөйләшүгә күчкәннәрен сизми дә калдылар.

— Син минем фикерләремне, сүзләремне тартып алдың, Курт... «Германиядән кунаклар килә» дигәч, мин кыенсынып, аптырап калган идем.

— Курыктыңмы?

— Юк... Безнең Казанда нәрсә карарга мөмкин инде дип уйлыйм... Бездә Лувр да, Эрмитаж да юк... Тадж-Махал Һиндстанда, Майя халкының Кояш храмы Америкада... Нигә киләләр ул немецлар безгә?.. Нәрсә карарга?.. Шуннан башыма бер-бер артлы фикерләр килә... Патша Россиясе халыклар төрмәсе булган... Дүрт йөз ел буе төрмәдә яшәгән халыкның Азатлык Октябренә хәтле үз телен, гореф-гадәтләрен, матурлыкка омтылу хисләрен, батырлыгын саклап кала алуы үзе бер тарих түгелмени?.. Аннан, без бит уртак ватанда яшәүче халыклар. Ленинград, Мәскәү калаларында салынган зиннәтле сарайларда, гүзәл храмнарда, һәйкәлләрдә безнең дә өлешебез юкмыни? Безнең халыкның да акылы, байлыгы кереп кушылган бит аларга! Ничә йөз еллар без патшаларга авызыбыздан өзеп налог түләп интеккәнбез. Бөек Россиянең бөтен тарихында безнең намуслы өлешебез юкмыни?.. Яуда бергә, эштә бергә, авырлык килсә — җилкәләр янәшә... Матурлыкка килгәндә генә кем безне читләтә алсын?.. Инде хәзерге көннәр синең күз алдыңда... Шушы илле елда без таң калырлык эшләр эшләмәдекмени?

— Менә кызыклы хәл,— диде аның фикеренә ялгап Курт.— Васяга Германиядә кыз бирмәгәннәр... «Кыргый татарлар арасына» алып китә дип курыкканнар... Европада татарларны киң яңаклы, тар маңгайлы, кысык күзле, төтенле шалашларда чи ит кимереп утыручы кыргыйлар дип белүчеләр хәзер дә күп әле. Чын, чын, көлмә!

— Ул яманат безгә монгол баскыннарыннан ябышып калган,— диде ачынып Идрис.— Безне тарихлар да, халыклар да бутыйлар. Ә чынлыкта исә без Идел болгарлары. Татар дигән исемне безгә дошманлык белән, мәңгегә кыен күрсеннәр дип, шовинистлар биргән булырга тиеш. Безнең интеллигентлар унтугызынчы йөз ахырларына кадәр үзләрен болгарлар дип атап йөрткәннәр.

— Алайса, сез европалылар булып чыгасыз?

— Әлбәттә! Икенче-өченче гасырларда безнең бабайлар Идел — Дон тамакларында күчеп йөргәннәр. Ленинград Эрмитажы Артамонов дигән галимнең «Хазарлар тарихы» дигән бик кыйммәтле китабын чыгарды. Анда болгарларның өченче-дүртенче йөзләрдә кайда булулары ачык күрсәтелә. Бишенче-алтынчы йөзләрдә болгарлар, Идел буйлап

өскә менеп, җирле кабиләләр белән аралашканнар, Кама, Идел буйларына урнашканнар, атаклы Бөек Болгар дәүләтен төзегәннәр. Без, Казан татарлары, шул халыкның турыдан-туры варислары.

— Менә ничек!

— Монголлар рус дәүләте белән бер очтан безнең ханлыкны да җимергәннәр, шәһәрләрне яндырганнар, халкыбызны талаганнар.

— Син бөтенләй мин белмәгән нәрсәләрне сөйлисең, Идрис.

Теге яктан тагын җырлый башладылар. Бу юлы тавышлар шактый тигезсез, чатан-потанрак чыкты. Ләкин җыр тиз өзелеп тынды, алар дөнья, Европа, Германия, Россия турында озак кына әңгәмәләшеп утырдылар...

Алар борылып чыкканда сандугачлар тынды. Егетләр дә, аркаларын учакка борып, комнан өелгән йомшак түшәкләрдә тавышсыз-тынсыз гына тугым бөгәләр иде. Бер Сибай гына тынмаган, ул изге Будда сыман аякларын бөкләп учакка карап утырган да тәмәке пыскыта. Аяк тавышларына ул башын күтәрде.

— Теге утрауда кызлар көлә,— диде ул, уйчан гына.

— Мәдинәңә әйтсәм әле! — дип янады Идрис.

— Юк... Су өстендә кызлар көлүе ничек матур янгырый дим мин...

— Ә-ә...

— Палатка Курт белән икегезгә! Кунаклагыз, хәерле төн!

Идрис белән Курт ялындырмый гына палаткага кереп яттылар. Сибай аларның баш очына хуш исле кипкән печән кертеп тутырган икән. Гәүдә-аякларның арганлыгы урынга яту белән беленде. Табан аслары кызышып, авыртып-авыртып китәләр...

— Нинди озын көн булды бүген, Курт.

— Әгәр кешенең һәр көне шулай уза торган булса, ул җирдә ин бәхетле кеше!

— Арылганмы, Курт?

— Бераз бар.

— Тыныч йокы, тәмле төшләр сиңа, Курт.

— Сиңа да, Идрис...

Идрис үзе арса да, башы саф иде. Ул уйланып ятты, тиз генә йокыга китә алмады. Палаткада башта эссе иде, соңыннан салкынайтты.

Йокылы утрауларны һу-һу дигән аерылышу авазлары белән күмеп теплоходлар узды...

Ул арада учак җылысына сырышкан егетләр уянды; мыдыр-мыдыр нидер сөйләштеләр. Идрис, каеш аелын чылтыратмас өчен, чалбарын түшенә кысып мукәләп палаткадан чыкты. Сандугачлар сайрый, димәк, төнге икеләр... Көн яктыра да башлаган, иртәнге салкын чык төшкән, тал яфраклары балланып дымланганнар. Сибай-колга кин кожанына уралып көймә янында басып тора, ул Идрисне шыпырт кына үз янына чакырды.

— Ренат кайда? — дип сорады Идрис, егетләрне күздән кичереп.

— Йоклаганга салышып ята, бармый,— дип көлде Сибай.

— Суык,— диде кемдер.

— Туңсаң ишкәккә утыр.

Чулт-чулт ишә-ишә ике йөз метрлар бардылар. Ауны утраулар арасындагы Сибай белгән чоңгылга төшергәннәр икән.

Егетләрнең берсе:

— Нигә шулай иртә алабыз? — дип мыңгырдаган иде, Сибай аны кистереп бүлдерде:

— Безгә артыгы кирәкми, көндезге ухалык эләксә — шул җиткән. Әле кармак белән дә бераз өстәрбез...

Идел өсте күзгә күренеп жанланды, Юдино, Васильево якларыннан көймәләр берсен-берсе куалап Олы Идел ягына уздылар.

Чөгә эләкмәсә дә, ауда унга якын олы гына кушбаш, ваграк кызыл канатлар, шәп кенә өч сыла бар иде. Берсе кило ярымнар чамасы булыр.

— Шәп ич бу, пәриләр! — диде гаҗәпләнеп Идрис.

Сибай, «дәшмә» дигән кебек, күз кысты...

Балыкларны җеп куканга тутырып суга җибәрделәр, ауны куак арасына кертеп кибәргә элделәр. Кояш чыгып бераз күтәрелгәч, алабуга, кызыл канат чиртә башлады, шыртлака кабып аптыратты. Кармаклар алып тал төпләренә урнаштылар. Чәй кайнады. Сибай Куртны уятырга кушты. Ул уяу яткан, ахры, бер эндәшүгә торып чыкты, алар Идрис белән ах-ух килеп коенып алдылар. Су керенеп чыккач, бик яратып, куян каны төсле кайнар чәй эчтеләр. Көн гаҗәп матур булырга тора иде.

— Хәзер мин сезгә бер әкәмәт күрсәтәм,— диде Сибай, серле генә.

— Сибайның өянәге башлана! — дип хихылдады Ренат.

— Моннан да ары тагын ни булыр икән? — диде Идрис.

— Егетләр калып торалар, кунакны Идел аръягына алып чыгып керәм.

Дачаларга кайтырга иртәрәк, көткәннән дә шәбрәк һава, Курт белән Идрис көймәдә сәяхәт ясап килергә шатланып күнделәр.

Өч кенә кеше утырган көймә җинел кузгалды, аның борыны, шактый күтәрелеп, суны хәтәр генә яра иде. Идел өсте көзге кебек типтигез. Сибай, камышлы вак-вак утраулар арасыннан борып-сарып аны җиңел генә алып бара. Аның кояшта янып беткән аксыл кашлары чак кына җыерылган, сирәк керфекле зәңгәр күзләре рәхәтләнеп йомылганнар.

— Ничәнче ялынны Иделдә уздырасың инде, Сибай?

— Штатта бухгалтер каралмаган! — диде ул, көлемсерәп.

Олы Иделгә чыктылар.

Утыз-кырыклап көймә бер уңайга тезелешеп якорьларда тирбәләләр. Сибай, агымга аркылы утырган ул көймәләрне кояш ягында калдырып, өскәрәк үрләде һәм моторның тизлеген киметте.

— Борылып карагыз! — дип кычкырды ул.

Кояш нурлары көмешләгән ап-ак су өстендә тирбәлеп утырган көймәләрнең кара силуэтлары искиткеч бер манзара иде. Балык чиртмәгәнгә, ахры, кешеләр күренмиләр, көймә төпләренә сузылышып ятканнар, күрәсең. Шушы тынлык, кешесезлек, серлелек өстеннән агылган сыек кына ак томан көймәләр патшалыгын әкиятләрдәгедәй сихерле ясаган иде.

Арырак, Казанга таба, тагын бер рәт көймәләр тезелешкән.

— Искиткеч! — диде Курт, куанып.

— Әйе...

Алар шушы йокымсыраган сихри тынлыкны ярып акрын гына йөзәләр. Идел уртасына житәрәк, борынга куе юкә чәчәге исе килеп бөркелде.

— Юкә чәчәк ата,— диде Сибай.— Чамалыйсызмы, бәхетле балыкчылар көне буе шушы исне иснәп утыралар! Ожмах! Балык эләксә, эләкмәсә дә ни кайгы?.. Ә син «Ничәнче ялыңны?» дип төпченәсең... Бәхетне үлчәп яки санап буламыни аны?..

Идрис көлә-көлә аның сүзләрен тәрҗемә итте.

Куе юкә урманы белән капланган уйчан таш таулар, күләгә сыман, һаман алар өстенә ишелеп киләләр. Көймә борыны кырт итеп вак ташлар арасына барып керде, авыз ачып барган Идрис белән Курт алга түнделәр. Резин итекле Сибай суга сикереп һәм, бурлаклар сыман

кыланып, көймә борынындагы авыр чылбырны иң өстенә салды, тарта башлады.

Иделнең ташлы текә ярына чыгып озак кына тамаша кылып тордылар.

— Фотоаппарат аласы калган,— диде Курт, үкенеп.

— Икенче кат килгәндә инде,— диде Сибай.

Ботакларга ябыша-ябыша өскәрәк менделәр, куак араларында күләгәдә шактый салкынча иде. Шау чәчәктә утырган юкаләрне меңләгән бал кортлары сарган.

Сибай чатнап, яргаланып торган соры таш өстенә менеп утырды, утырган җирдән генә итекләрен салып ыргытты, тәмәкесен кабызды, Идел, балыклар, балыкчылар турында тәмләп, бүрәнә өстендәге язгы авыл әкиятчесе кебек, озын итеп сөйләргә тотынды.

Сибайның мәхәббәте, гыйшкы бер яклы гына икән дип Идрис кичә дә уйлап куйган иде. Ул балыклар, ухалар турында сөйли башлауга, «Тын күл» белән очынып-очынып таныштырып йөргән бал авызлы Жаденко искә килеп төште. Алар бер-берсенә охшаганнар түгелме? Кайчандыр студент чагында бер-ике өметле хикәя язып, Минзәлә театрында бер пьесасын да куйдырырга ирешкән, чагыштырмача яшь журналист Сибай соңгы елларда баш-аягы белән тулаем Идел ирегенә тапшырылган иде.

Әнә, Жаденко да үз гомереңең көче ташыган чакта балалар шәһәрчеге салдырган, орден алган һәм шул урында тукталып калган. Моннан соңгы тормыш, сәнгать, театрлар, архитектура, кешеләр анын өчен бераз ерагайганнар... Ул шул шәһәрчеге белән канәгать, ул шуның белән яши... Сибай да үз яшәвеннән канәгать, ул аны бәхет дип саный, аңа берни дә кирәкми... Талпынып караганда, бәлки ул мәгънәлерәк, файдалырак эшләр дә башкара алыр иде?..

Кемнең бәхете кайда ачыласын кем белгән?..

Утрауга борылып кайтканда Идрис белән Курт кешеләрнең язмышы, эшчәнлеге турында сөйләшеп бардылар. Сибай юка борынын җилгә куеп бик тыңласа да, немецчасы «вас ист дас?»тан узмаганга, аны-моны абайламый калды...

Ренат аларны әрләп каршылады:

— Яңа кеше килсә, Сибай бер котырынып алмый туктамас инде,— диде.

— Туктамыйм,— диде Сибай, тегене үртәп.

— Хатыннар мине чәйнәклап бетерәчәк!.. Менә шул.

Идрис Ренат белән китүне кулай күрде:

— Без дә кузгалыйк, Сибай, хөрмәтегезгә рәхмәт,— диде.

Сибай үгетләргә, үгетләп тә эш чыкмагач, сүгәргә үк тотынды:

— Рәхәтләнеп бер кызынмагач та Иделне санламау була ул!.. Көндез уха пешерәбез, балык кыздырабыз... Ни пычагыма интегеп йөрдек без?.. Калыгыз дигәч калыгыз!..

— Кайтмый ярамас,— диде Курт та, хафаланып.— Тәмамлыйсы эшләр бар!

Мотор стартерын тоткан Ренат кыбырсып әрле-бирле карана иде, Идрис белән Курт көймәгә кереп утырдылар, Сибай кармак сапларын болгап аларны сәламлап озатып калды.

Бераз баргач та аларның нәкъ баш очында дөбердәп күк күкрәде.

— Шәбәртергә уйлый ич бу безне!

Зөя ягыннан Идел өсләп мыштым гына ябырылган болытлар килеп тә җиттеләр, кыеклап эре яңгыр коя да башлады. Бу шулкадәр көтелмәгәндә булды, муеннары, битләре чыланган егетләр көймәдә ни бар, шуның белән капланырга тотындылар. Идел өсте үзенә бер матурлык алды, тагын күк күкрәде, яңгыр көчәйде. Җил чыгып аларның көймәләрен агым унаена түбәнгә алып китәргә маташты. Ренатның мотор

белән дуслыгы көчле түгел иде, ахрысы, ул, каушап, көймәне унга, сулгаборгаларга кереште.

Бераз баргач, Идриснең кул аркасына берьюлы ике бал корты килеп кунды, башта сискәнеп, ул аларны сыпырып төшергән иде, аннары, яңгырга чыланган бөҗәкләрнең чагарга мазалары юк икәнлеген абайлап, кортларны учына алды. Ул арада бал кортлары берәм-сәрән көймә төбенә, алар ябынган иске плащка килеп куна башладылар. Ренат чәбәләнде, аның салам эшләпәсен, пиджагын кортлар сарган иде. Идрис абайлап алды: яңгырда-җилдә хәлсезләнгән кортлар көймәгә кунарга ымсынып очалар да, килеп җитә алмыйча, винт өереп чыгарган яшькелт-чал дулкыннар арасына төшеп һәлак булалар. Аръяктан юкә урманыннан кайталар ич болар!

...Яңгыр үтеп тә китте, ялтырап кояш чыкты, көймә артыннан кайнап-кайнап чыккан дулкыннарга төшеп аръяктан бал җыеп кайтучы кортлар һаман үләләр иде...

Озакламый тын култыкка кайтып җиттеләр. Яр башында, чык ялтыраган юеш үләннәр арасында, култык таякларына таянып, йокы белмәс каравылчы Хәким басып тора. Аннан арырак өстенә әйбәт плащ кигән Вася баскан. Көймәдәгеләрне танып, ул көлеп җибәрде:

— Хәерле иртә.

— Я, ни хәбәрләр бар? — дип Идрис, көймә туктауга ярга сикерде.

## 37

Туп-туры гостиницага кайттылар. Аларны күрепме, әллә үз вакыты җитепме, Виталий Петрович буфеттан килеп чыкты. Куртны озаткач ничек булыр, әлегә ул барында кичәге башбаштаклык өчен Жаденко Идрисне әрләп бер сүз дә әйтмәде.

— Сезнең мажаралы сәфәр артык озакка сузылды,— дип кечә куйды.

Идрис аклануны тиеш тапмады:

— Сез булсагыз да Займищега бармый калмас идек,— диде.

— Күздән югалуыгызны гына искәртүем...

Курт ГДР делегациясе составында бүген көндезге унбердә районнардан килгән колхоз партоешмасы секретарьлары белән очрашуда катнашырга тиеш икән.

— Җитәкчегезне күрдем, ул борчылып тора,— диде Жаденко аңа.

— Виталий Петрович — диде Курт Жаденконы холлдагы диванга чакырып.— Сез хәбәрдардыр инде?.. Хәзер акыл бирегез: нишләргә?

— Уйлашырга кирәк,— диде Жаденко гадәтенчә.

Ничек уйлашырга кирәклеген ул тәфсилләп тормады, әлегә гомуми сүзләр белән котылып калды. Кырынып, өс-башны алыштырып алырга кирәк булганга, Курт үз бүлмәсенә менеп китте.

Виталий Петрович белән Идрис урамга чыктылар.

— Нидер эшләргә кирәк,— диде Идрис, аны ашыктырып.

Жаденко сак кына уйлана иде, яшь журналистның капылтлыгы, ордым-бәрдем юлга чыгып китүе аңа бер тамчы ошамаса да, ул әлегә аны сиздермәде.

— Уйлыйк,— дип кабатлады ул салкын гына.

— Татвоенкоматка барып карарга кирәк,— диде Идрис.

— Бусы акыллы киңәш,— диде Жаденко.— Вася, кузгалабыз!

Исем-фамилияләре шактый якын берничә кешене хәрби комиссариат архивыннан эзләп тапсалар да, алар арасында Куртка кирәкле Бухенвальд герое юк иде. Хәрби комиссариатта җентеклəбрәк эзләргә вәгъдә биреп калдылар.

Свердлов урамыннан акрын гына «Кольцо»га кайттылар.

— Редакциягә кагылыйм булмаса,— диде Идрис.

— Ихтыярыгыз.
— Иптәшләр белән киңәшеп карармын.
— Ә мин... «Черек күл»гә кереп чыгыйм. Бухенвальдта булган кешеләр турында дәүләт иминлеге комитетында материал булмый калмас.

Шалтыратышырга сүз куешып, аерылыштылар. Идрис иң әүвәл чәчен төзәттереп, сакал кырдырып чыкты. Төннен-төн буена бер тапкыр да керфеккә керфек ормаган булса да, ул һичнинди арганлык сизми, киресенчә, өченче катка гадәттәгедән тизрәк, ике атласын бер атлап менеп җитте. Рәкыйп янына керде.

Тәүлек эчендә баштан кичкәннәрен тукми-чәчми редакторга сөйләп бирде, аннан ярдәм, киңәш сорады.

— Сезнең колакка чалынганы юкмы, Рәкыйп абый? Касыйм Усмановны белмисезме? — дип сорады.

— Әгәр ул кеше дөньяда бар икән һәм чыннан да Бухенвальд герое икән, ул турыда матбугатта булмый калмагандыр,— диде Рәкыйп хәтерләргә тырышып.

— Бәлки ул исән түгелдер?
— Үлгәннәрне дә эзләп табалар, анысын күреп торабыз.
— Нишләргә соң?
— Курттан әтисе турында истәлекләр яздырып ал. Чираттагы номерга бирербез. Кичкә өлгертәсеңме? Радиога шалтырат, алар да хәбәр таратсыннар.

Идрис үз бүлмәләренә керде. Монда бер үзгәреш тә юк иде. Шул ук өстәл, урындыклар; саннар, исемнәр белән аркылы-торкылы чуарланган өстәл календаре. Шулай да үзгәреш тойды, ят бүлмәгә кергән кебек булды... Димәк, үзгәреш аның үзендә икән!..

Редактор белән сөйләшкәндә ул үзендә ныклык, фикерләрендә ачыклык, сүзләрендә ышаныч сизде. Аның сүзләре Рәкыйп өчен дә кыйммәтле иде!

Тайчынып, иренеп тормаячак Идрис, Курт белән мәкаләне бүген эшләп бетерәчәк!

Ул хатлар бүлегенә кереп чыкты да радиога шалтыратты. Соңгы хәбәрләр редакциясендә эшләүче белеш егет:

— Язып керт, кичкә эфирга чыгарабыз,— диде.

Идрис бер утыруда радиога дигән хәбәрне язып та куйды. Җөмләләр саллы, төпле булып үзләреннән-үзләре җайга салынып тезелеп кенә тордылар. Аннан ул Әхәткә шалтыратты.

— Синме, картлач?
— Ә, дипломатларга сәлам.
—Ниләр кыйратасың? — диде Идрис, көлебрәк.
— Саламнан тәртә каерып, ары-бире чабабыз. Эшләгән эш юк, куандырган төш юк. Так себе.
— Чыны ничек?
— Өйләнгәндә икешәр смена эшлим дип ник кисәтмәдең? — ди Лида тутаң, ачулана. Шуннан хәлне аңла, сорашма.
— Кайчан үз болыныңа кайтасың?
— Җибәрмәскә итенәләр. Шеф әйтә: «Әхәт Нуруллин — телевидение өчен генә яралган асыл сөяк», ди.
— Югары күтәрелгән син алайса!
— Күтәрелгән-бәрелгән, сырт сөяге ярылган.
— Ә син кач!
— Яхшы сүз, тәмле тел белән сорадылар. Рәкыйп белән килешендек, бүлектә синең кебек батыр барында, торып торам әлегә.

Идрис Әхәткә Куртның тарихын кыскача гына сөйләде.

— Мин монда коллегалар белән киңәшим... Бераздан шалтыратырмын. Безнең өчен бик кызыклы материал яшеренеп ятмыймы?..

Идрис төшкә кадәр баш күтәрми эшләде, материалларны редакцияләде, машбюрога кереп диктовать итте, корректуралар укыды, секретариатка кереп, ТАСС хәбәрләрен күздән кичерде. Көндезге ашка икенче каттагы буфетка төште. Ашап-эчеп чыгып килгәндә аңа хатын-кызлар журналында эшләүче Кәримә Байбекова очрады. Бераз кынжыр, әмма оста каләмле бу яшь ханым Идрискә туктарга кушып, кыланыбрак башын иде.

— Ни сөйләрсең, матурым?

— Яңа хәбәрләр!

— Тыңлыйм.

— Идрис, безнең редакция бүген кич «Чыршыкай» кафесында кызыклы очрашулар кичәсе уздыра.

— Сөенчегә ни бирим?

— Чит илләрдә укытып, эшләп кайткан яшь татар галимнәрен чакырабыз.

— Кызыктырма, барыбер алданмыйм.

— Артистлар, режиссерлар, музыкантлар, гомумән, төрле халык булачак. Әлмәт музыка мәктәбеннән үзенең иң каттә жырчыларын төяп Әсгать Тимашов килде.

— Казан сылуларының йокысы качкан икән.

— Уенга алма инде,— диде иренен турсайтып Кәримә.

— Ни әйтим? — диде маңгаен җыерып Идрис.— Кичәгез уңышлы узсын. Безнең газетага бирәр мәкалә арттыра алмассыңмы?

Кәримә, Идриснең бөтенләй башка нәрсәләр турында уйлап торуын төшенеп, коридор тутырып көлде.

— Синең үзеңне шул кичәгә чакырам ич мин!

— Рәхмәт. Чит илләрдә эшләп кайтканым юк.

— Кунак немецыңны аласың да киләсең.

Аның башта ачуы килде, соңгы көннәрдә нишләп йөрүе бөтен Матбугат йортына фаш булганмы әллә?.. Аннары гына аңышты.

— Тукта, тукта, кемнәрне чакырабыз дидең?

— Галимнәрне... Киләсезме?

— Чит илләрдә эшләп кайткан яшь татар галимнәрен?.. Әһә! Болай булгач киләбез!..

Бүлмәдә телефон шалтырый иде, ул ишекне дә япмыйча йөгереп килеп трубканы алды.

— Бакиров тыңлый.

— Комитетта булдым. Алар эзләп карарга вәгъдә бирделәр. Иртәгә кичкә җавап алырбыз.

— Рәхмәт, Виталий Петрович... Монда безне кичкә очрашуга дәштеләр. Минемчә, күңелле мәҗлес булачак. Килә алмассызмы?

— Без кичкә Шамил Усманов урамындагы ике йортны кабул итәргә тиешле. Мин Дәүләт комиссиясе составында.

— Кызганыч.

— Менә шуннан минем кичке сәгатьләремә дә үзем хуҗа түгеллегемне аңлагансыздыр инде?

— Аңладым!

— Һәм каты хөкемегезне чыгармый торасызмы?

— Ә-э, сез һаман ул турыдамы?.. Сездән рөхсәт булса, Виталий Петрович, кунакны шул кичәгә алып барыр идем.

Жаденко башта эндәшми торды.

— Барырсыз,— диде ул бераздан.

Курт исә төштән соң гына шалтыратты:

— Ниһаять, бушадым!

Идрис аны «Чыршыкай» кафесына килергә чакырды.

— Теләсәгез, кичке ашны шунда гына ашарбыз.

— Мин риза,— диде Курт.— Тик син гостиницага килеп мәшәкатьләнмә. Сәгать биштә кафе янында булырмын.
— Табарсыңмы соң?
— Тырышып карыйк.
Сөйләшенгән вакытка Идрис Бауман урамына чыкты. Эссе һавадан янган резин исе килә... Урамның ике ягыннан да бик чуар киенгән халык агыла, бер минутка да тукталып тормый... Җәйге шат, көләч, ашыгучан халык...
Ул аны Бауман урамыннан килер дип көткән иде, Курт Кави Нәҗми урамы буйлап өстән килеп төште. Аның тузанлы туфляларына карап, Идрис:
— Син кайдадыр йөреп килдең, ахры? — дип сорады.
— Кремльне әйләнеп чыктым. Аннары Ленин урамын җәяү үттем. Гаҗәп икән ич: урам буйдан-буйга тау башында утыра. Кремль дә, Университет та тау түбәсенә урнашканнар.
— Әйе,— диде Идрис, хәтерләп.— Һәр яктан сөзәк урамнар менә.
— Архитектор өчен нинди кызыклы ландшафт,— диде кызыгуын яшермичә Курт.
— Ялгыз йөреп кул кычыта башладымы?
— Яшермим!.. Бу материал минем кулда булса, о!..
— Әгәр сиңа Әбүгалисинаның тылсымлы таягын биреп: «Теләгәнеңне башкар!» дип боерсалар, ни эшләр идең, Курт?
Курт чынлап торып илһамланган иде.
— Безнең бераз вакыт бармы? — дип сорады ул.
Идрис кафе ишеге тирәсендә төркемләнеп торган ят кешеләргә карап алды:
— Бар, бар.
— Йөреп килмибезме? Мин, шәп ат сыман, бер кузгалгач тиз туктата алмыйм.
Аулаграк булыр дип, Идрис Куртны Островский урамына чакырды. Тын гына янәшә бардылар.
— Татарстанның башкаласы буларак кимсетмим, ул яктан да шәһәрегезнең тарихи роле зур, әмма Казан Ленинның яшьлеге белән бәйле шәһәр буларак елдан-ел киңрәк дан, шөһрәт алачак. Ленин идеяләре дөньяга киңрәк таралган саен бу шулай булачак, шиксез. Шуның өчен без ераккарак карыйк!.. Күп шәһәрләр Казанның язмышына көнләшергә тиешләр!.. Димәк, Казан шәһәре мәгълүм бер дәрәҗәдә үзенең тышкы күренеше белән дә шушы идеяне яктыртырга бурычлы. Мин Казан университеты тиздән Мемориаль үзәк ителер дип уйлыйм.
— Шәһәр советында проектны карадык инде,— дип кыстырды Идрис.
— Хәтерлим, хәтерлим!.. Миңа калса, аз гына үзгәреш кертеп тә булыр иде ул проектка!.. Профсоюз урамын бетереп, Бауман урамы белән ике араны тоташ паркка әйләндереп булыр иде. Парк сөзәк тау буйлап өскә менә. Анда фонтаннар, һәйкәлләр. Ә университет тирәсендә күп катлы небоскреблар. Шәһәрнең кайсы ягыннан гына карасаң да алар, сүнмәс ялкын телләре кебек, биеклектә балкып торачаклар!.. Ә ул биек йортларны кичләрен нинди утлар белән бизәп булмас иде!.. Хәзер яктырту техникасы бик үсте, гаҗәп тәэсирле булыр иде ул!
Идрис Куртның сөйләгәннәрен шәһәр советында күргән проект белән чагыштырып барды да:
— Шушы идеяне тормышка ашыру чарасына керештек шикелле без. Синең фикерләреңдә дә бик кыйммәтле шул рациональ орлык бар,— диде.
— Күп шәһәрләр көнләшәчәк Казанның киләчәгенә, менә күрерсең!

Алар мавыгып, бәхәсләшеп киттеләр, чәчәк кибете янына житкәч, Курт кереп бер бәйләм гладиолуслар сатып алды.

— Менә бу чем каралары «Мисыр төне» дип атала аның... Әти мәрхүм бик ярата иде шушы чәчәкләрне...

Тагын сүзләр, тагын истәлекләр. Идрис Касыйм Усмановны эзләү чарасына керешүләрен сөйләде, табигый буларак, алар кичәгә соңга калдылар.

«Чыршыкай» кафесының ундагы кече залы кунаклар белән тулган иде. Тәрәзәләргә калын шторлар ябылган, бусының ни өчен икәнлеген Идрис башта аңламады. Алмалар, баллы сулар, кыйммәтле кәнфитләр куелган өстәл тирәләрендә өчәр-дүртәр утырышып, кунаклар хатын-кызлар журналында эшләүче кап-кара сумала чәчле Һажәр ханым Фәритова чыгышын тыңлыйлар иде.

Кунак каршылап, аларны урнаштырып йөргән Кәримә Идрисләрне үзе янына чакырды.

— Күптән башландымы?

— Тс-с... Әле генә... Сез кайда йөрдегез?

— Ачуланма, Кәримә...

Бераз күз ияләшкәч, соңга калып кергәндә була торган кыенсыну узды, Идрис залдагыларны караштыра башлады...

Европада «кыргый татарлар» дип саналып йөртелә торган халык вәкилләрен Куртка күрсәтерлекме бүген?.. Шуның өчен генә килде бит Идрис, мәсьәләнең «яшь галимнәр» дигәне аны кызыктырды...

Таныш, күз күргән кешеләр байтак булса да, ул белмәгәннәр дә күп кенә иде... Әнә, Һажәр ханым янындагылар галимнәр булса кирәк. Монда театр кешеләре... Кергәч тә сулда пианино янында чәчәк кебек чибәр кызлар арасында жырчы-композитор Әсгать Тимашов утыра. Кинәт ул бер почмакта үзенә ян белән утырган Һашимны — Булавинаның кайнатасын күреп алды. Ничек бу мәжлескә эләккән ул?.. Аны кем чакырган?..

Һажәр ханым сүз арасында баш ишарәсе белән Идрисне янына түргә чакырса да, алар кузгалмадылар.

— Атаклы әдибебез Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» исемле хикәясен барыгыз да хәтерли торгандыр,— дип дәвам итте Һажәр ханым.— Бик гыйбрәтле хикәя! Моннан алтмыш еллар элек кенә татар әдибенең фантазиясе кая кадәр барып житә алган?.. Ул татар клубына татар студентларының, галимнәренең, укымышлыларының, язучыларының бергә жыелуын төштә генә булуы мөмкин хәл дип тасвирлаган... Менә шушы матур залда, күңелле мәжлестә безнең бик кызыклы язмышлар кичергән дусларыбыз утыра... Мин аларның һәркайсысы белән үз чиратларында таныштырып барырмын... Шунсын да әйтеп куйыйм, дуслар, бу гарәфә кичендәге тәмле төш түгел, бу — өн, бу — безнең халкыбызның бүгенге көне... Беренче сүзне яшь галим, физик, Казан университетының профессоры фән докторы Юныс Сәмитовка бирәбез...

Идрис, гомуми тынлыкны бозмас өчен, Һажәр ханымның сүзләрен шыпырт кына тәржемә итеп торды, үзенең аңын һаман бер жавапсыз сорау тынгысызлады: «Һашим ага монда кунакмы, әллә очраклы гына килеп кергәнме?»

Күпертмә чәчләренә энже калфаклар кадаган, челтәр читле нәфис алъяпкычлар ябынган нәзек билле, озын аяклы татар кызлары көнчыгыш нәкышләре белән бизәлгән фарфор кәсаларга салып хуш исле кофе тараттылар. Ал грушовкалар, ак налив алмалары, «Шүрәле бармагы», «Күгәрчен канаты» исемле Казан кәнфитләре белән кунакларны сыйладылар. Колакларына чачаклы-чуклы эре-эре Бирма алкалары таккан чибәр официантка кыз Курт тирәсендә ешрак булырга тырышты.

Юныс Сәмитов болын кадәр маңгайлы, буйга кечерәк бик сөйкемле кеше икән. Төш-магнит резонансы методы белән молекулалар төзелешен өйрәнү өлкәсендә эшләүче бу галим байтак илләрнең университетларында лекцияләр укып, дөнья күләмендә атаклы фән кешеләре катнашкан симпозиумнарда чыгышлар ясаган икән. Сәмитов немец, инглиз телләрен белүеннән тыш татарча да бик килешле итеп, җанлы, мавыктыргыч тәгъбирләр белән үз эше турында, чит илләрдәге очрашулары турында сөйләде, аны бирелеп тыңладылар.

Галимне сәнгать кешеләре алыштырды. Әсгать Тимашовнын кызлары яңа җырлар җырладылар. Сүзне медицина галимнәре дәвам итте. Алар Африка илләрендә — Суданда, Алжирда, Мисырда берәр-икешәр ел эшләп медицина өлкәсендә генә түгел, этнография, көнкүреш, социаль тормыш шартлары җәһәтендә дә байтак гыйбрәтләр алып кайтканнар икән. Иң соңыннан сүзне udinstitut галиме алды. Мең тугыз йөз алтмышынчы елда Һиндстан хөкүмәте халык мәгарифен юлга салуны сорап Берләшкән Милләтләр оешмасына хат яза. Унике кешелек Халыкара комиссия төзелеп, халыкка урта белем бирүдә аерата уңыш казанган алдынгы ил вәкилләре белән беррәттән шуның составына безнең ил белгечләре дә кертелә. Арада Казан галиме яшь фәннәр докторы Илһам Макалеев тә була. Комиссия членнары Һиндстан мәктәпләре өчен программалар төзиләр. Доцент Макалеев биология буенча үрнәк программалар һәм дәреслекләр төзүгә җитәкчелек итә. Маклеев Һиндстан мәктәпләрендәге хәлләрне күп санлы диапозитивлары белән дәлилләп сөйләде.

Театр белән гастрольләргә китмәгән артистлар Фигейредонын «Эзоп» спектакленнән өзек уйнадылар. Тагын музыка яңгырады, тагын нәзек билле кызлар кофе тараттылар, сүз уртак булып китте.

— Курт, мөгаен, син дә сүз сөйләүдән котыла алмассың,— диде Идрис.

— Ярыймы соң?

Идрис җавап бирергә өлгермәде, Һаҗәр ханым урыныннан торды һәм, тонык кына гөжләгән залны тынычландырырга өндәп, кулын күтәрде:

— Кадерле дуслар! Безнең арада гаять зур тормыш юлы үткән, кызыклы язмыш кичергән бер иптәш бар... Ватан сугышына кадәр үк Хасан күле күгендә батырлык күрсәтеп Ленин орденына лаекле булган атаклы очучы... Немец фашистларына каршы көрәштә дә беренче көннән үк фронтта... Дошман самолетлары белән барган тиңдәшсез каты, тигезсез көрәштә ул самолеты белән яраланып дошман территориясенә егылып төшә... Шунда аягын югалта... Яралы хәлендә әсирләр лагереннан качып, концлагерьга эләгә... Аннан да качып үлем җәзасына хөкем ителә... Немец коммунистларының ярдәме белән генә исән калган бу герой әсирлектә буйсынмый, һаман көрәшә... 1942 елның декабрендә совет хәрби әсирләренең яшерен оешмасын төзүдә катнаша. Бераздан бу оешмалар башка милли оешмалар белән берләшеп Интернациональ коммунистик хәрәкәткә нигез салалар... Кыскасы, сүзне Ватан сугышы герое, карт коммунист Һашим ага Госмановка бирәбез.

Башкалар гөрләтеп кул чапканда Һашим карт уңайсызланып кына басып торды.

«Ни өчен Госманов, Булавин түгел!» дип уйлады Идрис. Ул, Һаҗәр сөйләгәннәрне Куртка тәрҗемә итәргә дә онытып, Һашимга текәлде, җавапны аннан көтте.

— Бухенвальдны барыгыз да беләсез,— дип башлады ул сүзен.

Идрис немецча кычкырып җибәрде:

— Курт, менә ул!

Алар икесе дә сикереп тордылар

— Кем, кем?
— Усанов, Усманов, Госманов!
Идрис Куртны житәкләп карт алдына килеп басты. Һәм татарчалап:
— Һашим ага, сез бу егетне таныйсызмы? — дип сорады.
— Нигә алай сорадыгыз? — диде Һашим, бер агарынып, бер кызарып.
— Бу егет сезнең Бухенвальдтагы көрәштәш дустыгыз Францның улы Курт Карл. Ул сезне эзләп Казанга килде!
Җыелганнар, өстәл-урындыкларын калдырып, аларны дәррәү сарып алдылар, Һашим чатанлый-чатанлый уртага чыкты һәм Куртны кочаклады...

* * *

Алар Һашим картларга өчәү кайттылар. Дустының улын карт үз яныннан беркая да җибәрмәде.
— Ничек соң Касыйм Усанов? — дип сорады өйгә кайткач кына Идрис.
— Лагерьда мин үземне шулай атап йөрттем. Бухенвальдка да шул кушамат белән килдем... Ә соңгы көннәрдәге ыгы-зыгыда чын исем-фамилияләрне әйтергә өлгермәдек... Вакыйгалар без көткәнгә караганда да катлауланды, безне Франц белән аердылар... Менә шулай...
— Ә нигә хатларга җавап язмадыгыз? Нигә эзләмәдегез?
— Анысы болай... Концлагерьдан кайткач, монда утырырга туры килде... Илле бишенче елның көзендә генә Казанга кайттым.
— Ничек боларны беркемгә дә сөйләмәдегез?..
— Башта кызыксынучы булмады, аннары, ничектер җае чыкмады...
— Бу бит, Һашим ага, чын батырлык!
— Батырларның барысы да үзләре турында кычкырып йөриләрме?..
Вакыт соң булса да, Нина Михайловна чәй өлгертте, Булавиннар өендә төне буе ут сүнмәде. Курт аларның өчесен дә ГДРга кунакка чакырды.
Кайдадыр якында гына әтәч кычкырды, таң атканын аңлап, дүртесе дә көлеп җибәрделәр...

## 38

Мөзәкирнең әнисе белән Мөнир бишенче көн рәттән печән чабарга чыгалар. Әнисе сыер саварга уяна да чоланга керә.
— Мөнир, тор, балам!
Ул мырлый-мырлый уянуга, Мөзәкир дә торып чыга.
Гаражда өйрәнчек слесарь булып йөргән Мөнир печәнгә күчүенә бер дә риза түгел, ул үзен түбәнсеттеләр, кимсеттеләр дип саный, юынганда да һаман мырлавында була:
— Бетмәгән печән булды инде... Йокы куралмассың хәзер!..
Печәнгә өч көн Мөзәкир дә барып йөрде. Ишле халык арасында зурлар белән эшләп йөрү аңа бик ошаган да иде югыйсә, көтелмәгән бәла аны өй сакларга калырга мәҗбүр итте. Әлеге дә баягы кычыткан чыпчыгы Рузилә иптәш кызларын җыеп кайткан да болдыр баскычы астына кереп «өйле» уйнарга тотынганнар, чоланнан түшәк-ястыкларны ташып бетергәннәр.
Урын-җирләр тавык тизәгенә буялып беткән, иң куркынычы — «өйле» уйнаганда шырпы алып чыгып, вак йомычкалардан учак та кабызганнар. Әле ярый, күрше Гөлбикә карчык күз-колак булыбрак йөрештергән икән, кызлары «өйле» уйнап Хәлилләр «өйсез» кала яздылар.
— Моннан болай өйдә торырсың инде, балам,— диде әнисе Мөзәкиргә.

Мөзәкир өйне саклап, тавык-чебешләрне, Рузиләне саклап өйдә калды. Эш юкта көн бик озын сыман тоелды. Лапастан чалгы алып чыгып бик җентекләп чүкеде, аны кер элә торган шома колгага атландырды. Тәрәзәдән дә, капка төбеннән дә күренә чалгы, елык-ялык итеп куя...

Бүген әнисе коймак пешерде.

Кичә Мөзәкирнең өйдә калуыннан файдаланып, Мөнир, түргә утырып, бик ирәеп, бик мыскыллап кына сөйләшкән иде, бүген тавышытыны чыкмады. Бүген Мөзәкир бәләкәй арба тартып Мукшы күле буендагы Торна сазына үзләренә печән кырмаштырырга бара. Беренче көннәрне үк күл буйларының чабардай җирләрен чабып, инде печәнен киптереп, ташып бетерделәр. Бушап калган болында куак төпләрен, түмгәк-мазар араларын кымту хәзер малай-шалайга калды.

Ул печәнгә барырга бик риза, өйдә генә яткырмасыннар. Ичмасам, Мөнирнең борыны да бераз төшәр, югыйсә кыланышы кырга сыймый. Бригадир әнисенә әйткән:

— Бер өй эченнән икәү йөргәч бик җитәр, былтыр да «курмы җитмәде» дигән идегез, үз җаегызны да карагыз,— дигән.

Бригадир, Түбән оч марие Сәвәли дәдәй, акыллы кеше шул...

Мөнир ишек алдына чыккан да, кер колгасыннан теге чалгыны алып, шәп чүкелгәнме дип, йөзендә бармакларын йөртеп караган була... Әһә, сүз әйтер җирең юкмы? Әтисе былтыр ук өйрәтте шул аны чалгы чүкергә!

Кеше үчекләмәсә Мөнир буламы соң ул, тьфу!

— Янаганда кулыңны кыеп төшермә, чалгы сабыңны җиргә нык терә, какшау булмасын,— дип өйрәтеп яткан була...

Өченче көн беренче пакусны чыкканда үзенең борыны мышкылдаганны оныткан, Мөслах абый:

— Шулай, нәнекәч, печән чабу, мастерскойда шөреп борып йөрү түгел,— дип кемнән көлде?..

Әнисенең дә һаман сүзе бетмәде, капкадан чыкканда:

— Рузиләне уятырга ашыкма, йокласын... Җитешерсең... Апаеңны ипләп карап йөрт, елатма,— дип үгетләп калдырды.

Боларны да Мөнир ишетте...

— Ярар, ярар,— диде Мөзәкир, кашын җыерып.

Печәнчеләрне озаткач, ул өйгә керде, Мөнирнең кичке уеннан кайткач салган чалбары урындык аркасында кояшта янып тора икән, аны күләгәгә күчерде, аннары түр тәрәзәне ачып, ике кулы белән янагына таянып, урамга карады.

Аргы очта да, монда да җанлылык. Кыш-яз җигелмәгән үшән алашаларны да тәртә арасына керткәннәр, түбән очтарак хатын-кыз машинага төялеп тора. Егет-җилән Мөзәкиргә эндәшеп узды:

— Күпер сукканны көтәбезме?

— Чолгау киптерәсеңме, Мөзәкир?

Өстәлдә Мөнирнең хушбуе... Беркөн кибеттән яңа галстук белән шушы саргылт сулы шешәне алып менгән. Мөзәкир хушбуйның бөкесен борып ачты, мул итеп учына салды һәм баш түбәсенә коеп җибәрде. Хушбуй бармак араларыннан агып биткә, күзгә төште, ачыттырды. Әлә-лә!

Бу Рузилә — йокы капчыгы тормаса, коймак суынып бетә ич!

Ул, почмак якка кереп, агач караватка таралып яткан кызыйны уятырга тотынды.

— Уян, Рузилә, тор!

— Әем,— диде, нәни тәпиләрен селкеп, кыз.

— Хәзер үк торсаң, арбага утыртып барам.

Кыз сыңар күзен ачты.

— Күлгә тиклеме?

— Барганда да, кайтканда да утыртам.

Рузилә жил очырткан мамык кисәгемени, шундук юынгыч янына барып басты, иренеп кенә аның чәмериен шалтырата башлады.

— Хәзер бүксәң кап булганчы коймак аша.

— Мин шикәр белән чәй генә эчәм, абый. Ярыймы?

Кызга коймакның «алтын сәгать кебек кызарып пешкәннәрен» генә биреп, аның хәтере өчен Мөзәкир үзе дә бераз чемченде. Калган коймакларны, кәгазьгә төреп, кызыл ашъяулыкка салды, аның янына олы гына ике телем ипи куйды, әйбәтләп төрде, термос белән чәй алды, биш-ун шакмак шикәр тыкты.

Мөзәкирләрнең кул арбалары зур, әмма көпчәкләре солидол белән майланган, тартырга үтә җиңел, юл тап-такыр, әйдә, бахбай!

Чытыр арбага охшатып баш-башына карама бөгеп, араталар белән чәлмәштергән биек чардуган эченә, кызыл төенчеген тотып, Рузилә утырды. Авызы ерылды кызыйның...

Урамны иплэп кенә үткәч, ындыр артлап басу юлына төштеләр. Сулда карабодай басуы булганга монда мал-туар кермәгән, юл аулак, бәбкә үләннәрне аяк йөзен кумәрлек.

— Нык тотын, Рузилә!

— Әйдә, бахбай! — дип куанды кызчык.

Мөзәкир шәбәеп чаба башлагач кына Зәйтүнәләрнең ындыр капкалары ачылды, аннан фанер көймәле бәбәй арбасы тартып ул үзе килеп чыкты.

— Ә мин сезне көтеп качып тордым, күрмәдегезме?

— Чалгыңны оныткансың,— диде Мөзәкир аның сүсәргән көймәле арбасын эшлекле караштырып.— Арбаң да бәләкәй, күпме печән керә монда? Ярты кочак...

— Бар булганы җитәр,— диде кыз олылар сыман.— Иярәсеңме?

— Урак белән кулыңны кисмәссеңме?

— Башта ук өркетеп барма, Мөзәкир.

Аллы-артлы бара башлаганнар иде, урман ягына борылгач, янәшәләнделәр. Малай Зәйтүнәнең иярүенә шат та, шат түгел дә иде. Иптәшең белән бергә булу куанычы анысы, әмма тирләп-пешеп печән тартып кайтканда Зәйтүнәнең аны күрүе малайны бераз рәнҗетә иде...

Кызның әтисе Фәтри ага гаҗәп уңган кеше, ул председатель белән дә ныгытып сөйләшә ала, печәнгә мохтаҗлыклары юк, кыз Мөзәкирнең кәефен күрер өчен генә, үзен аның белән тигезләргә теләп печәнгә барырга карар кылган, малай монысын ап-ачык сизенгән иде...

Юл аулак, юл такыр, кырлар өстенә чыңгырдавык тургайлар эленгән. Тургайлар, тургайлар, хисапсыз күп алар!

— Тиздән тургайлар сайраудан туктыйлар, беләсеңме. Питрау гына житсен.

— Бөтенесе дә туктыйлармы?

— Бөтенесе дә.

— Питрау житкәнне алар каян белә?

— Жәй үткәнне сизәләр. Жәй үтә, кошлар сайраудан туктый, күке тилерә.

Мөзәкир жил ягыннан барганга, кызның борынын ачы хушбуй исе кытыклый иде.

— Күз житә икән алайса... Тиздән мәктәпкә... Тагын укулар...

— Барасы килмиме?

Аларның бәләкәй арбалары тигез генә баралар да бер-берсенә орына башлыйлар, шул чак Рузилә чәрелдәп кычкыра:

— Абый!

— Барасы да килә, әллә ничек шунда,— диде Зәйтүнә уйчан гына.

— Тизрәк житсен диген син!.. Тизрәк укып чыгасы иде диген?

— Кая ашыгырга?

— Казанга!
— Без бүген коймак пешердек,— диде Рузилә кинәт.
— Шәпме Казан? — диде кыз тагын бер кат аны сөйләтергә теләп,
— Шәп... Бик шәп! Безнең җизниләр янында гына болын башлана.
— Кызык. Анда да болын бармыни?
— Булмыйча. Шәп-шәп йортларны болынга салганнар. Без әле аның белән шул болынга да чыгып кайтабыз!
Икесе дә адымнарын кызулаттылар, тәгәрмәч кигиләре кояшта чагылып кына кала.
Озакламый әрәмәләр башланды. Монда һава җиләсрәк, юл тузаны юкарак иде. Әрәмәләргә ялганып колхоз болыннары китте. Мондагы печәнне чабып ферма янына ташып та куйдылар инде.
Юл буенда ялгыз-ялгыз чатлы-ботлы камыр агачлары очрады, җимешләренең ярты яклары кызарган, тик бу турыда бүген Мөзәкир дә, Зәйтүнә дә сөйләшеп тормадылар, эшләре ашыгыч иде.
Торна сазына кадәр болынны кырып чапканнар. Күлнең аръягында биек-биек түмгәкләр тырпайган аулак болыннар башлана. Түмгәкләр сирәгрәк урыннарда ашъяулык-ашъяулык тигезрәк җирләр табып алырга мөмкин. Ул тигез җирләрдә сарут, ромашкалар белән баллы бабалар да үсә.
— Менә шушында чабабыз,— диде Мөзәкир арбасын күл буе калкулыгындагы каен чаукалыгында туктатып.— Урыны әйбәтме?
— Карап карыйк,— диде яулыгын чишеп Зәйтүнә.
— Син сак кына уйна,— диде Мөзәкир, оеган Рузиләне күтәреп арбадан төшереп.— Чаукалыкта жылан-мазар булмасын.
Рузилә сикергәләп күл буенда йөри башлады. Мөзәкир белән Зәйтүнә мавыгып аның артыннан киттеләр. Күлнең чит-читләрен вак аксыл-яшькелт яфраклы су үләннәре, юрган калынлыгы бака ефәге сарып алган. Эчтәрәк, су ачык урыннарда, сап-сары, олы-олы төнбоек чәчәкләре тирбәләләр.
Түмгәк араларында тәкәрлекләр кычкыра.
— Төнбоек чәчәкләрен беренче мәртәбә күрәм,— диде Зәйтүнә Аның чәчәкләрне йолыккаларга теләге бар иде.
— Шиңәләр алар,— диде Мөзәкир,— кайтканда җыеп бирермен.
— Ничек өзәрсең аларны? — диде кыз.
— Чалгы белән үреләсең дә кых!
Үзенең шундый гап-гади хәйләгә дә башы җитмәвенә исе киткән кыз Мөзәкирнең тапкырлыгына сокланды.
— Син менә шушыннан ура башла,— диде Мөзәкир түмгәк арарында иркен генә бер болынчык күрсәтеп.
— Моннан үзең чап, мин эчкәрәк керәм.
— Сиңа ташырга уңай булыр.
— Ярар тагын.
Мөзәкир тагын эчкәрәк керде, печәнлекләрне җентекләп чамалады, эшкә керешеп бер-ике селтәнүгә, Рузилә чәрелдәде:
— Абый, әллә ни бар!
Ул, чалгысын атып бәреп, сеңелесе янына очты.
— Кайда?
— Әнә, әнә, кыштырдый.
— Кәлтә җылан гына ич!.. Китмә, шушында гына урал.
Малай өй урыны тикле урынны тикшереп, караштырып чыкты. Куак төпләрендә чабылмый калган үлән арасында кызыл җиләкләр балкып күренә иде, өзеп бераз җыйды да Зәйтүнәгә алып керде.
— Мә, сыйлан.
Зәйтүнә кырт-кырт урды, учмалары бер дә үрчемәде. Әниләре яшь чакта бөтен кырларны шушы бөкре тимер белән урып чыкканнар, ничек хәлдән таймаганнар диген? Кыз ура-ура да Мөзәкиргә карап ала. Ул

аякларын ирләрчә нык ерып баскан да тешләрен кысып кизәнә, ап-ак башлы ромашкалар, күпертмә зәңгәр чалма башлы баллы бабалар, песи койрыклары тигезле-тигезсез пакус булып яталар. Малай, ялтыраган маңгаен кулъяулыгы белән сөртә дә, акланган сыман Зәйтүнәгә эндәшә:

— Урыны тигез түгел, иркенләп селтәнеп булмый...

— Әйбәт чабасың,— дип юатты аны кыз.

— Рузилә, тырманы ыргыт!

Рузилә тырманы бик нык ыргытып ыргыткан иде, үз аягы янына ук килеп төште. Зәйтүнә, якынрак торганга, болынчыгыннан чыгып тырманы алып керде.

— Ни эшлисең аның белән?

— Чабылганын корырак урынга таратам. Кипсә тартып кайтырга да җиңелрәк булыр, күбрәк тә сыяр.

Чалгы янаган тавыш күңелләрне җирсетеп агач араларында зыйңзыйң янгырый, Зәйтүнәнең урак йөзе ялтырый да башлады, аның аркасы тирләде, муен тирәләренә үлән орлыклары коелып кычыттырды. Учмалары күзгә күренеп артты...

Туктаусыз тәкәрлек кычкырды...

— Тәкәрлек, тәкәрлек, тәңкәң булса миңа бир!

Күл ярында сыңар аяклап сикергәләгән Рузилә кошларга кычкырды.

— Мөзәкир, тәкәрлек күкәе очраса, ватма,— диде тирен сөртеп Зәйтүнә,— сипкел чыга диләр.

— Әллә кайчан бала чыгарды инде алар...

Кинәт урман ягыннан ят тавыш ишетелде. Башта черки безләгән кебек кенә янгыраган тавыш көчәйгәннән-көчәйде... Машина килә! Анда аулак урман юлы, көз-яз чыга алмаслык баткаклар, әнә моторы зарланып ничек үкерә...

Зәйтүнә куркынып Мөзәкиргә карады.

— Машина килә, Мөзәкир.

— Килсен.

— Кемнәр йөри икән?

— Белмим.

— Безне ачуланмаслармы?

— Кем орышсын ди, юләр? Ни өчен?

— Председатель.

— Йөри ди председатель бу якларда!

Шулай да малай чалгысын, тырмасын тотып, Рузилә янына чыкты. Зәйтүнә дә аңа иярде. Алар урман авызына карап көтеп калдылар. Менә агачлыктан ялтырап җиңел машина килеп чыкты.

— Степанов! — диде агарынып Зәйтүнә.

— Килсә, узып китәр,— диде малай, өметләнеп.

Тик машина узып китмәде, чабылган болын өслəп, куак-агачларны урый-урый, туп-туры аларга карап юнәлде.

Зәйтүнәнең тез буыннары калтырадылар...

## 39

«Кызыл йолдыз» колхозының дүртенче бригадасы моннан өч-дүрт километрда урман артына урнашкан. Егерме ике йорттан торган нәни генә мари авылы, бәләкәй бригада. Колхоз председателе Николай Степанов авыл советы председателе Ирек Хәйдәров белән шуннан кайтып килә. Машинаның шоферы бүген печәндә, шуңа рульдә Степанов үзе утырган...

Өч бригаданың өчесенә дә былтыр ук водопровод белән су керттеләр, дәүләт челтәреннән электр уздырдылар, әнә шул бер бәләкәй авыл

гына читтә кыерсытылып килде. Степанов, район оешмалары белән мәслихәтләп, гомуми колхоз җыелышына куеп ул авылны колхозның иң олы бригадасына кушарга карар чыгарткан иде. Чөнки нәни поселок тоту колхозга һәр яктан уңайсыз иде. Эш көчләре дә санаулы, җыен карт-коры утырып калды диярлек...

Кичә печән өмәсеннән кайтышлый шул бригададан өч кеше идарәгә керделәр.

Алар:

— Председатель, быел да җәй узып бара, кайчан безне утлы-сулы итәсез? — диделәр.

Степанов өзеп кенә җавап бирмәде:

— Таңнан сезгә барам, шунда җыелып сөйләшербез,— диде.

Дүртенче бригаданыкыларның күбесе ул килгәнче үк сүз берләшеп өлгергәннәр иде, Степанов әйбәтләп аңлатып та бетермәде, арадан берәү:

— Күчмибез, кушылмыйбыз! — дип кычкырды.

Аны куәтләп икенчесе:

— Ата-бабалар яшәгән әле,— дип куйды.

Степанов белән Хәйдәров алмаш-тилмәш халыкны тәмле тел белән озак кына үгетләделәр. Бригадир, арадан тагын өч-дүрт кеше:

— Нәрсәгә ябышып ятабыз?.. Күчәргә кирәк, беренче бригада үзебезнең авыл кук ич! — дип председательне хуплагач, Степанов җиңеләеп елмайган иде, күпчелек исә күчәргә каршы төште.

— Безгә ут-су үткәрегез! — диделәр алар.

Кызмыйм дип ант итеп килсә дә, председатель кайнарлана башлады:

— Шулай китереп куясызмы?.. Егерме ике хуҗалык өчен ут-су үткәрергә безнең җилдән җыйган акчабыз юк... Колхозның һәр тиене тир бөртекләреннән сыгып алына... Күчмисез икән, әнә, үзегез әйткәнчә, ата-бабаларыгызча яшәгез!.. Күчим дигән кешеләргә шушы атнада тракторлар җибәрәбез, өен, сүтми-нитми, яңа урынга тарттырабыз. Ихатасын торгызырга агач, такта, ярдәм, транспорт бирәбез. Йорткурасы иске кешеләргә колхоз бушлай бура, шифер, кадак-кодагын бирә. Гомуми җыелышның карары шундый. Акылыгыз булса, үзегез исәпләгез...

Килешенә алмадылар. Степанов бригадирга чәйгә дә кереп тормады, машинасына утырды китеп барды.

Хәйдәров, Степановның төрле чакларын күргән кеше булса да, колхоз председателенең бүгенге кебек кызган, ярсыган чагын хәтерләми иде. Шуңа күрә ул аңа эндәшергә дә базмыйча тик кенә кайта. Степанов бара-бара да башын селки:

— Ата-бабалар яшәгән, диләр! Ә үзләренең бабаларынча түгел, кешечә яшиселәре килә!.. Күчәргә теләгәннәрне иртәдән кузгата башларга, ә калганнар...

Урман юлы чокыр-чакыр, машина бер менә, бер төшә, анысы да рульдә утырган председательнең теңкәсенә тиде. Урманны үтеп җиңел сулыйбыз дигәндә генә алар күл буенда кешеләрне күреп алдылар. Кулларында чалгы, яннарында арбалар, председательнең борын яфраклары калтырап китте:

— Бу нинди стахановчылар тагын?

Хәйдәров, караштырып:

— Бала-чага гына маташа, Николай Васильевич,— диде.

— Ну-ка, якынрак барыйк, Ирек,— диде Степанов.

Үсмер малай янында берсе олы, икенчесе бәләкәй ике кыз да бар. Степановның күзләре үткен, күлдән ерак та түгел кыеш-мыеш тезелгән пакусларны ялт абайлады, өерелеп ишектән чыкты.

— Нишлисез монда? — диде ул.

Малайның тавышы калтыранды:

— Печән чаба идек.
— Кемгә чабасыз?
— Үзебезгә.
Степанов, кызып, мари, татар сүзләрен буташтырып сөйләде:
— Кем җиреннән чабасыз?
— Болын җиреннән.
Малайның тәтелдәп җавап бирүе, курыкмыйча күзгә карап торуы председательне ачуландырды.
— Кем малае син?
— Көтүче Хәлил Мортазин улы,— диде Хәйдәров, машина ишегеннән башын тыгып.
Рузилә, абыйсы артына посып, мышык-мышык еларга кереште. Зәйтүнә аны тынычландырырга теләп башыннан сыйпый иде.
— Кем рөхсәте белән чабасыз?
Олы гәүдәле Степанов янында Мөзәкир шәрәкәй арык кына, курач кына булып калган иде.
— Сыерга печән кирәк,— диде ул, аска карап.
— Сыерга кәтлит кирәк түгеллеген синнән башка да беләм,— диде Степанов.— Син нәрсә телгә бик остардың алай? Үзең икелегә укыйсыңдыр әле?!.
Малай борылып сеңелесен юатты:
— Курыкма, Рузилә, курыкма.
Малайның курыкмаска өндәве соңгы чик булды, Степанов:
— Хәзер үк таегыз моннан, эзегез булмасын!.. Кара нинди батыр... Күрерсең менә «курыкма»ңны! — дип кычкырды.
— Печәнсез кайтмыйм,— дип, малай да үҗәтләнеп кычкырып куйды.
— Нәрсә-ә?!
Бригада җыелышыннан соң суынып өлгермәгән Степанов һич үзенүзе тыя алмады. Кычкырмаска кирәген дә белә иде, әмма, ничектер үзен-үзе тыя алмыйча, кызганнан-кыза барды. Аларның икесе өчен дә хафаланып, Хәйдәров машинадан төште дә бер кырыйдан, Степановка күренмичә, төрлечә ымлап, малайга тыелырга ишарәләп карады.
Малайның күзләре яшьләнгән сыман булды.
— Арба тутырып печән чапмыйча кайтмыйм! — диде ул, аяк башы белән болынны тырнап.
— Әтиеңне идарәгә чакыртып штраф түләтсәк?
— Түләтә алмассыз. Болын колхозныкы булса, безнең абзарда да колхозчы сыеры. Безнең өй эченнән дә дүрт-биш кеше колхозда эшли. Әллә үз җирегезме?
Хәйдәров, ике йодрыгын күкрәгенә терәп, һаман малайга тыелырга куша иде. Степановка малайның тә-тә әреплэшүе, челәеп карап торуы бер дә ошамады булса кирәк:
— Яле, ну-ка, бир чалгыңны! — диде ул.
Мөзәкир калтыранды, әмма чалгысын бирмәде.
Аларның баш очыннан гына ике торна кычкырып узды, Степанов Мөзәкиргә таба атлады, шулкадәр тын иде, малай торна канатларының һавада җилпенүенә кадәр ишетеп торды.
Ул чалгы сабын эләктереп алды, малай исә сапка тагын да ныграк ябышты:
— Моның өчен җавабын бирерсез! — диде.
Степанов шунда, тәмам кызып, чалгы сабын ике-өчкә сындырды да күлгә тондырды.
— Артык тәкелдәмә, олылар алдында телеңне тыя бел! — дип туктаусыз тезде ул.
Кызлар елаштылар, Мөзәкир, хәтта йодрыкларын йомарлап, нәрсәдер кычкыра-кычкыра Степанов янына килде.

— Әле син алаймы? — диде Николай Васильевич һәм җиңелчә генә этеп малайны сай күлгә төшерде.— Сөйләш, әрепләш әнә үзең ише кәрәкәләр белән!

Малай җылымса суда лычтырдады, аяклары ләмгә батты, ә су өстендә сап-сары дәү төнбоеклар тирбәлделәр...

Машина кузгалып китеп тә барды.

Мөзәкир тиз-тиз генә мүкәләп күлдән чыкты, аның күзләре чокырларыннан атылырга теләгәндәй зурайдылар. Күлнең болганчык суында чалгы сабы сыныклары тирбәлә. Баягы торналар тагын баш очында әйләнделәр. Ул кинәт ыргылды, ялтыравык дәү машинаны туктатырга теләгәндәй, кулларын алга сузды һәм илереп елады. Зәйтүнә белән Рузилә, сүз әйтергә базмыйча, нишләргә белмичә дер калтырап, аны күзәтеп тордылар.

Малай, ыргылып Зәйтүнә арбасына барып ябышты да:

— Тизрәк, тизрәк, җыеныгыз! — дип кычкырды. Аннан шып тукталды, су агып торган чалбар балакларына карады, учлары белән бот буйлап сыдырып тезенә хәтле төшерде.

— Ашыгыгыз, ашык!

Үзе машина килгән юл буйлап башта ни өчендер урманга таба йөгерде, аннан авылга таба борылды.

— Әйдәгез инде!

Зәйтүнә үлән яфраклары ябышкан урагын, кая куярга белмичә, кулыннан-кулга күчерде, алыргамы-алмаскамы дип аптырап, арба тәртәсенә тотынып карады, ахырда, Рузиләне җитәкләп малай артыннан җан-фәрманга чаба башлады.

— Елама, апаем, елама!

Малай байтак җир узган иде, кызның:

— Мөзәкир! — дип кычкыруына, һаман шул тирәдә очкан торналар гына «трой-лыйк» дип җавап бирделәр.

Ул урагын юл читенә атып бәрде.

— Шушында гына тор, апаем!

Үзе, күл буена кире кайтып, ашъяулыкка төрелгән ризыкларны җыештырып алды, аларны арба көймәсенә аннан-моннан ыргытты, сыңар кулы белән тәртәне эләктереп, Рузилә янына чапты. Рузилә юл буенда утырган да:

— Абый, абый,— дип шыңшый.

— Ныграк ябыш! — диде Зәйтүнә, кызчыкны да көймәгә чөеп.— Төшеп калма!

Тәгәрмәчләр тузан туздырып, елык-ялык тәгәрәделәр. Мөзәкир ачыграк күренә башлады.

Малай Зәйтүнәнең инәлеп чакыруларын, ялынулы дустанә тавышын аермачык ишетте, ләкин тукталмады, борылып карамады, кыз белән сөйләшерлек көч тә, уй да калмаган иде анда. Аның исәңгерәгән башында бары бер генә уй кайный иде: «Нишләргә? Нишләргә? Ни кылырга? Үчнең кайсысын сайлап алырга?!»

Болай гына калдырырга һич ярамый, юк, юк... Степанов аның әтисен чакыртачак, штраф түләтәчәк...

Менә әтисе идарәгә барып керер... Утырырга кыймыйча, ишек төбендә таптаныр... «Малайлар, файда урынына, зарар ясый башладымы?» дип, идарәдәгеләр аннан көләрләр... Әтисе акчасын чыгарып салыр... Аннан пошмый-нитми генә җәйләвенә китеп барыр... Бизрә буйлап атлар... Бульдозерлар белән буып, бар булган балыгын комсыз ач әрвахлар җәбер-җәзасыз гына сөзеп китә торган елга ярыннан атлап барыр да барыр... Шушы яр буенда малаен браконьерлар тукмап киткәндер дип уйлап та карамас...

Чаба торгач, малайның башына тагын бер уй килде: Степанов өенә ут та төртә алмаячак ул, почмактан торып ата да алмаячак... Тегесенә

дә, бусына да кул күтәрә алу һич мөмкин түгел! Ярамый да! Тере кешенең күкрәгенә ничек мылтык төбисең?.. Тир түгеп салынган агач йортның ни гаебе бар?.. Бүгенме-иртәгәме Мөзәкир бу хәлне дә онытачак, гафу итәчәк... Әнә, теге чакта, мыеклы белән җирәнне гафу итте бит, эзләп караган булды, белмәмешкә салышып, күрше-коланнан сорашты, аннан онытты... Гафу итәргә ярамый иде бит аларны! Үзенне тукматып, үз суынны узгынчы читләрдән талатып, йомарланган йодрыкны кесә төбендә йөртү егет кеше эшеме?

Ә ул кичерде...

Ничек кеше күзенә карый алды икән?.. Зәйтүнә белән ничек сөйләшә алды икән?

Әллә бүген үк Казанга чыгып китәргәме?

Җизнәсе аңлар, ачуланмас... Диләә апасы да сүз әйтмәс...

Беркемгә дә күренмичә җиенырга да чыгып китәргә... Зәйтүнәгә дә, Степановка да күренмәскә... Казанда торыр, шунда укып зур кеше булыр. Шул чагында гына озын ялга кунакка кайтыр.

Алаен алай да, апасы белән җизнәсенә хәлне ничек аңлатыр? Нигә килдем диер?

Ул Степановның рәнҗетүе турында уйламый да иде хәзер, аны күбрәк җәй башында булган хәл, җирән белән мыеклының Бизрә буенда тукмап ташлаулары борчый, шуңа үртәлә, әрни, үз көчсезлегеннән үзе буылып елый иде...

Степановның рәнҗетүен җизнәләренә әйтергәме?

Ә Ирек абыйсы, Ирек абыйсы!..

Мөзәкир беренче класска баргач, мәктәп болдырына чыгып, каршылау сүзе сөйләгән иде ул. Ап-ак күлмәктән, җиңнәрен сызганган, кара галстук бәйләгән, ботинкалары карлыгач канаты күк ялтырый...

«Сез зур тормыш юлына аяк бастыгыз... Кыю, намуслы, бер-берегезгә ярдәмчел булыгыз... Олыларны хөрмәтләгез... Укытучыларыгызның кадерен белегез», дигән иде...

Кечкенәләрне дә кадерләгез дип олыларга берәр чакта әйтә микән ул?..

Ә хәзер... Эх, Ирек абый!

Зәйтүнә булып Зәйтүнә «тимәгез аңа!» дип чәчрәп чыкты, ә ул ник бер сүз әйтсен... Ник бер сүз!.. Зәйтүнә бичара: «Аларга печән кирәк!» дип тә ялынып карады.

Печән, печән...

Печәнлек, әрбәлек...

Кайтырга да печәнлеккә менеп күмелеп, качып ятырга...

— Мөзәкир!.. Тук-та-ал!

Бу шулай Зәйтүнә өзгәләнде. Ул, борылып, аңа карады. Арба көпчәкләре нәкъ аның өстенә тәгәриләр... Бөтен якта ап-ак кояш... Нурлардан агарган туп-туры юлдан арба тартып кыз йөгерә... Хәзер килеп җитәчәк, менә хәзер...

Аның белән бер урамнарда йөрергә, тыкрыктан су буена төшәргә, бер партада утырырга... Үч алам дип мактанды бит әле җитмәсә... Мылтык сорап йөргән булды! Җебегән салма...

Ә баш очында тургайлар чыны!

Чырылдапмы чырылдыйлар!..

Ваемсыз, уйсыз-хәсрәтсез тургайлар... Әһә! Питрау җитәр, сез дә чырылдаудан туктарсыз!.. Туктарсыз, беләм!.. Күке дә тилерер, кешеләрнең гомерләрен санаудан тыелыр...

Туктарсыз, тургайлар, ваемсыз-уйсыз кошлар!..

Мөзәкир күзеннән юл тузанына ачы су тып-тып төшә дә тузанда тургай күзе хәтле генә нәни чокырчыклар уелып кала...

Бу нинди киртәләр булды тагын? Әһә, ындыр арты...

Аулак ындыр арты юлының бөдрә чирәмендә тана башы хәтле ак таш ята... Бая күрми үткән иде, хәзер абынды... Тырнак төбе купты, ахры, сызлый, үтереп сызлый...

Әллә бакча баганасы өстендә кукраеп утырган кара канатлы иләмсез дәү козгын да «Му-за-кир» дип кычкырды инде?

Зәйтүнә куып җитеп тә килә, тыны бетте малайның, арба тәгәрмәчләре, әнә, күз иярмәслек тиз тәгәриләр...

Ә тургайлар чырылдапмы чырылдый...

Питрау гына җитсен... Туктарсыз, тургайлар!

Тыкрык буйдан-буйга күренә. Буп-буш... Төкле туралар, укалы чикмәннәре белән мактанып, сукыр кычыткannaр өстендә быз-быз очалар...

Тыкрык башында уңга-сулга каранды... Кеше-мазар күренми. Баягы качкын сарыклар клуб тирәсендәге күләгәдә яланып, иснәнеп торалар, төртенмешләр.

Клубта бүген кино... «Кәл һәм алмаз».

Теге баштан машина тавышы килә. Малай телефон баганасы артына сеңде. Төшлеккә кайталар. Печәнчеләр!.. Ишек алларында кешеләр күренгәли, ап-ак төз морҗалардан сыек кына зәңгәр төтен тарала... Вакыт шулай күп узды микәнни?..

Киртә-корталар ышыгында тузанда аунаган тавык-чебешләр шырылдап юлга атылдылар, ул, тып-тып басып, урам буйлап өйләренә кадәр йөгерде. Капка ачык, керде, япты, як-ягына куркынып каранды.

Болдырда, ялтыравыклы җиз таска аягын тыгып, эшем иясе Мөнир утыра. Мөзәкирне күргәч, ул көлми түзә алмады:

— Күрегезче кабарган бер күркәне, талашып кайткан! Ха-ха-ха!

Өй алды ишегендә тавыш ишетеп чыккан әнисе күренде, ул, кулындагы самоварын тиз-тиз идәнгә утыртып, аның янына төште.

— Нәрсә булды, улым?.. Мөнир, җитәр дим сиңа! Кешнәмә!

Мөзәкир, эче катуны үткәреп җибәрә алмыйча, мышнап басып торды. Ул үзенең әле һаман тавышсыз гына үксүен сизенде.

— Рузилә кайда, балам? Печәнгә баргансыңдыр ич?.. Арбаңны кайда калдырдың?.. И-и, бала, бала. Нигә сөйләмисең, үзәгемне өзәсең.

Урам яктан инәлгән аваз килде:

— Мөзәкир!

Хәзер, хәзер... Капка ачылыр... Аннан Зәйтүнә керер, күрер, сөйләр... Бизрә буендагы хәлләрне дә сөйләр, күл буендагысын да... Менә, менә...

Яулыгы иңбашына сыдырылып төшкән, чәчләре тузгыган, янган-көйгән Зәйтүнә капкадан килеп керде... Рузилә, кызыл ашъяулыкны күкрәгенә кысып, арбадан сикереп төште.

— Без җиләк ашадык, кәлтә җылан күрдек,— диде ул, шатланып.

Малай тиз-тиз чоланга кереп китте, келәне элде. Ана, каушап, кызларга таба атлады.

— Ходаем, бәла-казага тап булдыгызмы әллә?

Дәү-дәү юеш эзләр калдырып, Мөнир дә болдырдан төште.

— Зәйтүнә, кызым, ни булды? — дип инәлде ана.

Кыз, яулыгын чишеп ташлап, капка янындагы бүрәнәгә утырды һәм еларга кереште.

Ана да:

— Ниләр генә булды икән? — дип күз яшьләрен сөртте.

Зәйтүнә, күз яшьләренә, кичерешләренә буыла-буыла, күл буенда булган хәлне сөйләп бирде:

Степанов абый килеп чыкты да тотынды ачуланырга!.. Мөзәкиргә кычкырам: «Кач!» дим... Качмый гына... һаман басып тора, җитмәсә сүзләшә... Шуннан Степанов аның чалгысын эләктереп алды да сындырып бетерде!.. Аннан Мөзәкирне... Мөзәкирне...

Ана, әчке сиземләве белән хәлнең күңелсез икәненә төшенеп, хәсрәткә батып беравык катып торды:

— Үзекәйләрем генә гаепле шул!.. Баланы печәнгә мин җибәргән иен, мин... Сәвәләй дәдәй рөхсәт итте, сораган иек, димәгәндер, юктыр... Карыша торган гадәте барырак шул... Аталары урынына көтүгә улымны чыгарып, печәнгә үзе барган булса кана... Малай-шалайны санга сукмавыдыр инде...

Ул, кереп, чолан ишеген сак кына тартып карады.

— Балам, балакаем, бу мин иен, әниең, ач.

Ишек keләсе, катырак тартуга, үзе ачылды. Почмакта, идәндә йөзләрен тезе белән томалап Мөзәкир утыра иде.

— Әйдә, улым, бит-күзләреңне ю... Мә, коры ыштан ки... Аннары ял итәрсең... Хәзер самовар терелтеп җибәрәм... Монда бик эссе, бөркү. Без абыең белән ике-өч кочак яшел печән алып кайтып, лапас шүрлегенә тараттык. Бар, шунда менеп хәл ала тор... Карының да ачкандыр инде, балам... Әй, дөнья!.. Бар шул җайсыз чаклары дөньяның, әйдә, үтәр әле!

Ихтыярын бермәлгә югалткан улын, җитәкләп, ана ишек алдына алып чыкты, бит-күзләрен үзе юды. Мөзәкирнең күзләре кып-кызыл, йөзе көл төсле күм-күмгәк иде. Ул иелеп, коры ыштанын тотып, хәлсез генә атлап лапаска кереп китте. Зәйтүнә аңа иярергә иткән иде, ана:

— Тимә,— диде.— Үзе генә барсын, азрак тынычлансын!..

## 40

Яшьләр газетасының шимбә санында, икенче биттә Фаина Наумовна Гринбергның «Ата-аналар турында бер уйлану» исемле зур мәкаләсе басылып чыкты. Мәкаләнең нигезендә теге чакта балалар бакчасында Идрис белән сөйләшенгән, мәгълүм дәрәҗәдә Луиза белән Ренат Кәрамовларның уллары Айдарга булган мөнәсәбәтләрен күзәтүдән туган борчылулы фикерләр ята иде.

Идрис бу материалның чыгуын түземсезлек белән көтте. Бердән, халыкның, укучыларның бу турыда ни уйлавын беләсе килсә, икенчедән, Кәрамовларның үзләренең реакциясе аның өчен бик мөһим иде. Соңгысы аны ныграк та кызыксындырып, борчып торды шикелле...

Алар газетаны, әлбәттә, көнендә үк укыган булырга тиешләр. Үзләре укымасалар да (яшьләр газетасын тансыклап тормауларын аңлый Идрис!), белешләре, танышлары күреп хәбәр иткәннәрдер дип өметләнә иде. Фаина Наумовнаның күзәтүләре нигезле, фикерләре төпле, гаепләрендә уйландыра торган ачы хакыйкать ята.

Якшәмбедә Идрис Айдар янына барырга җыена иде. Ике-өч көн рәттән малайга картон тартмалар эзләп юл уңаендагы аптекага керә йөрде. Шимбә көнне аңа тартмалар әзерләп куйдылар.

— Улыгызга аласыздыр инде? — диде аптекачы ханым, теләктәшлек белән.

— Әлбәттә!

— Кирәк булса, тагын кирәгез. Тартмаларның ныграклары, тәбәнәкләре булганый. Аларына уләннәр ябыштырырга да, бөҗәкләр шырпыларга да бик уңай. Берәүләр бездән шундый каплар алып өйләрендә курчак театры ачып җибәрделәр. Беренче спектакльне карарга улым белән мин дә бардым.

— Шәп фикер! — диде Идрис, баш бармагын турайтып.— Рәхмәт сезгә!

«Улыгызгамы?» дигәндә ул ни өчендер кызарынмады. Үзенең шушы сагынылган сүзне тыныч, хәтта ки шулай кирәк сыман кабул итә алуына гаҗәпләнеп баскычтан менеп барганда аңа Һашим Госманов очрады. Идрис мактанган сыман:

— Иртәгә мин Айдар янына барам! — диде.
Һашим моны ишеткәндә аны-моны әйтмәгән иде, колагына салып куйган икән, иртүк Идрисләрнең ишекләрендә звонок шалтырады. Барып ачса, кулына пәрәмәчләр тулы целлофан пакет тотып Нина Михайловна басып тора.
— Керегез, күрше, хәерле иртә.
— Сезне «Тын күл»гә бара дигәннәр иде.
— Дөрес сүз. Тик ул хәбәр дә бөтен шәһәргә таралганмы?
— Сирәк барганга, тарихи факт итеп шаккатып сөйләшәләр.
— Моннан болай ешрак барырга сүз бирәм.
— Шуның өчен миннән сезгә бүләк! Үзегез дә сыйланыгыз, Айдарга да алып барыгыз.
Идрис чын күңеленнән:
— Рәхмәт, рәхмәт,— дип кабатлады.
— Кичкә шулпалы бәлеш пешерәм, — диде Нина Михайловна.— Туры безгә кайтыгыз.
— Сез мине тәмам бозарга ниятлисез, ахрысы?..
Ничек кенә булмасын, шушы иртәдә ул «Тын күл»гә барырга җыенганда башкаларның да Айдар турында уйлаулары, малайны уртага алып сөйләшүләре аның өчен рәхәт иде. Газета укыган байтак кешеләр Айдар турында сөйләшәләрдер бүген!

Кәрамовлар өендә нинди җилләр, дулкыннар купты икән?..
Беләсе иде...
Бүген якшәмбе. Ата-аналар көне... Кәрамовлар да бүген тик ята алмаслар, тәмле-татлы ризыклар күтәреп барып җитәрләр... Фаина Наумовнага әр сүзләрен әйтергә теләп булса да барырлар... Әгәр Идрис алар белән очрашса?.. Айдар әти-әнисе белән булса?..
Теләсә ни булсын, аның Кәрамовлардан качарга, уйларын яшерергә җыенганы да юк.

Уникенче автобуска шау-гөр килеп керделәр.
Һәркемнең кулында яшелчә-җимеш, татлы ризыклар, тәрәзәләрдән бөркелеп-бөркелеп июль җиле бәреп керә, бүген лагерьларда, дачаларда ата-аналар көне. Кешеләрнең тотышларында, сүзләрендә шул тантана сизелә.

Ранглары тигез, мәшәкатьләре, мазалары уртак кешеләр.
Ат-аналар...
Булачак кодалар-кодагыйлар...
Булачак әби-бабайлар...
Идрис тә шушы кешеләр арасында...
Ул ата-аналар көне дип атала торган якшәмбе явында беренче тапкыр катнаша...
Мәктәп тукталышында уникенчедән төшеп, тагын да ныграк кысыла-кысыла, Казан — Юдино автобусына күчеп утырдылар. Ата-аналардан вәкилләр күбәйде, үзара танышлар артты, сүзләр куерды.
Аккош күле тирәсендә халык...
Автобустан төшкәч Идрис тә шулар арасына кереп буталды, лотоктан ярты килограм виноград, берничә кып-кызыл алма алды. Волгоград алмасы, винограды Болгариядән...

Таныш юл.
Виталий Петрович, Нина Михайловналар белән беренче тапкыр бергә узылган юл... Аннан соң Курт... Вася... Бүген шул юлда ул ялгызы. Уйда Айдар... Кәрамовлар... Алар бүген дүртәү очрашалар... Үзүзләрен ничегрәк тотарлар икән?..
Кинәт Дилә хәтергә төште... Ямансулады Идрис, моңайды... Дилә өйдә булса бу юллардан йөрелмәс тә иде бәлки... Ул ничек икән шушы минутларда? Сагынамы?

Кемнәрдер җинел машиналарда аны куып уздылар, алар тукталмады, ул үзе кул күтәрмәде. «Тын күл»гә барып җитәрәк Айдар турында гына уйлады.

Дача тирәсендә бүген җанлылык, халык ишле. Берәүләр балаларын җитәкләп агачлыкка кереп баралар, анда да, монда да көлешкән, шаярышкан тавышлар ишетелеп кала.

Ул ялгыз-йолгыз йөргән балаларны җентекли-җентекли байтак кына әйләнгәләде, Кәрамовлар да, Айдар да күренмәде. Галия апаны, яки Фаина Наумовнаны күрәсе иде дип эзләнә башласа да, алар да очрамадылар. Ул беренче очраган тәрбиячедән:

— Айдар Кәрамов кирәк иде,— дип сорады.

— Айдар? — дип кабатлады тәрбияче сәер генә карап.— Юк ул.

— Әтиләре алып киттеме?

— Каядыр качканмы, югалганмы, белмибез.

Идрис үзендә эчке бер көчсезлек тойды.

— Кайчан, ничек?

— Кайчан дип... Иртәнге ашта ук юк иде! Ничек икәнен кем белгән!

— Фаина Наумовна кайда?

— Эзлиләр. Барысы да эзлиләр. Монда мин берүзем,— дип тәрбияче еламсырады,— Галия апа да китте, Таня да, Анна Ивановна да... Бүген бит монда кыямәт, ә мин берүзем!..

«Менә сиңа, мә, кыямәт! Тапты сүзен!»

— Сез Айдарның кеме буласыз соң? Минем сезне бер дә күргәнем юк.

— Дусты. Дуслар без аның белән.

— Дусты? — дип кабатлады тәрбияче ничектер ышанмыйча.— Алай икән...

Ничек, кайчан һәм нигә качарга?..

Кая китүе ихтимал Айдарның?..

Идриснең башы тимер белән китереп суккан кебек авырланды, аның зиһене таркалды. Аяусыз малай!..

— Шушы төенне алып куйсагызчы! — диде ул, китә башлаган җиреннән тукталып.

— Нәрсә бу?

— Күчтәнәч... Айдарга тартмалар, ашамлыклар...

— Тамагы тук иде лә аның!.. Менә башка яклары гына...

Тәрбияченең артык сөйләшеп торырга вакыты да чамалы, теләге дә юграк иде, ул, халат итәкләрен җилфердәтеп, күлгә таба китеп барды.

Идрис хәзер инде ашыкмыйча, уйларын нигезләргә тырышып уйлап, фикерләрен үлчәү табасына салмак кына тезә-тезә шоссега чыга башлады.

Бәлки малай беркая да китмәгәндер? Күренмәс өчен качып кына утырадыр?.. Беткәнмени урманда куелыклар...

Аңа ата-аналар, машиналар, яшь җилкенчәкләр очрады, ул аларны, ниндидер сүз көткән сыман ымсынып, озатып калды.

Беркая да югалмагандыр! Кая бара ала ул: бөтен җирдә кеше, юлларда милиция. Автобуска керсә, аны кондуктор туктатырга тиеш. Урман юлында бәләкәй малай очрый калса, берәү дә йомык күз белән үтеп китмәс...

Аккош күле тукталышында ул Галия апаны күреп алды. Галия апа, баласын җуйган каз кебек башын боргалап, халык куелыгын ерып йөрүчә иде. Идрис аның каршысына килеп чыкса да, ул аны күрми торды.

— Исәнмесез, Галия апа,— диде кычкырып Идрис.

— Ә, Идрис... Исәнме.

— Күрми торасың...

— Булыр, булыр, бик булыр... Гөмбәгә баргач шомыртка күз төшми, аска карап йөрисең, шуның сыман... Бәлага тарыдык, Идрис, казалы булдык.
— Ишеттем.
— Әллә шәһәргә дә хәбәре барып җиттеме?
— Мин «Тын күл»гә барган идем...
— Менә син агай!.. Сине ял итәргә чакырып, утка керттем бит, юләр баш...
— Айдар янына килгән идем.
— Эх, ичмасам төнәгеп килгән булсаң, бер-бер файдаң тими калмас иде.
— Кичә килергә булган да бит!
Галия апа саран гына чыккан күз яшьләрен сөртеп алды.
— Интерәтте ул малай безнең газиз башларны. Хәзер кем белгән: тереме ул, үлеме... Бик башсыз, тотар да күлгә чумар...
— Фаина Наумовна кайда?
— Милиция белән кинәшләштеләр дә, энә теге челтәр капкалы лагерьдан, «Спартак» комбинатында эшләүчеләрнең балалары ди, пионерларны җыештырып чыктылар. Урманнан эзлиләр инде, хәерле булсын... Пионерларның аталары килгән, алар пыр туза, әби-сәби балавыз сыга, кәмит инде бер уйласаң! Мине күз-колак булырга шушында бастырдылар. Калага шыларга ниятләсә, шәт, җәяү китмәс әле, юлын беләме ул, кашык сабы хәтле малай...
— Миңа нишләргә икән соң?
— Телэгем бар дисәң, эзләшәсең инде.
— Каян?
— Каян икәнен белсәм, Тимер Казык йолдыз күк монда басып торыр идемме?.. Чәй эчмәгән, башым әйләнә, көне эссе...
Идрис китәргә ашыкмады, тагын бер кат юлны, урманны күнелеңнән кичереп чыкты.
— Иптәшләреннән сораштыгызмы?
— Сорамаган кая, җыеп та сөйләштек, берәм-берәм дә чемчекләдек. Белгәннәре дә авызларын чамалап ачалар.
— Нигә?
— Куркалар шул имансыздан!
— Галия апа, алайса мин үземчә эзләп карыйм, яме.
Айдарның Һашим карт алачыгы янына кайтып китүе бик ихтимал иде. Теге вакытта әйткән иде бит: компас белән, туп-туры урман аша шунда барырга җыенганнар. Ул теге чакта «алачык янды» дигән хәбәргә тамчы да ышанмады, хәтта Идрискә ышанычы какшады, башкалар белән сүз берләшеп аны җиңәргә, тыңлатырга тели дип уйлады. Малайның, бердән, Рексны күрәсе килгәндер, икенчедән, Идрис сүзенең хаклыгын тикшереп карарга ниятләгәндер. Дөрес сөйләгәнме, юкмы?!.
Мөгаен, ул шушы юлны сайлагандыр... Шәһәрнең кайда булуын чамалый, тәвәккәллек җитәрлек, киткән дә барган!..
Җил юк. Тып-тын. Биек-биек, шома нарат кәүсәләрен ураган һава кояш нурыннан бик эсселәнгән. Кипкән инәләр инлегендәге калын җир юрганы яңа коелган нарат күркәләре белән чигелгән. Үләннәр андасанда гына, нәзек сабаклы... Наратлар биек-биек, очларына карасаң, баш әйләнә... Сукмаклар чәбәләнгән, кайда матуррак алан, шунда барып кергәннәр, палатка урыннары калган, учак көлләре суынып ята... Сукмаклар чуалган, барасың, барасың да алданасың... Ә малай?.. Аның мондый урман юлларыннан ялгыз йөргәне бармыни? Юдино якларына китсә, адашса?..
Идрис, бара-бара да, учларыннан торба ясап:
— Айда-ар! — дип кычкыра.
Тыңлана, уңнан да, сулдан да кемнәрдер аңа эндәшәләр.

Кеше очраганга аның кәефе генә килә, әгәр малай бу тирәләрдән узса, юл сорагандыр... Тора-бара сукмаклар сирәгәйде, аның ымсынып кычкыруларына тоныкк кайтаваз гына җавап бирде, кошлар чыркылдады.

Кыш көне чаңгы шуа торган юлга төшкәч, ул байтак кына таптанып, тыңланып торды. Урман үзенә генә хас моң белән гөжелди иде. Җил кузгала, ахры? Әнә җиңел-җиңел уенчак болытлар да зәңгәр күктә тирбәләләр...

Бераздан ул утырып ял итеп алды, тамагы бик кипкән иде, картайган балтырган көпшәсе сындырып шуны суырды. Тәмам хәле бетеп төш алдыннан гына Һашим карт алачыгы урынына барып чыкты...

Әрәмәләр өстендә каргалар оча...

Алар кар-кар килеп җилгә каршы баралар, биеккә күтәреләләр. Янгыр булыр, ахры, уч төпләре кычытып, коргаксып тора...

Җил төрле якларга сибеп тараткан көл ятмаларын яңгыр җиргә сендергән... Әнә, янган велосипедның кәкре тимерләре... Әнә янган чиләк...

Ян-якта беркем юк, күңелне шомландырып, кычкырып-кычкырып каргалар очалар...

Кая барырга?

«Тын күл»гә җәяү кайтырлык хәл юк, арылган.

Иң элек Айдарларның өенә кагылырга карар кылып, Идрис шәһәргә юл алды. Звонок буш өйдәге тынлыкны сискәндереп шалтырады, тик эчтә шушы коры, зәһәр шалтыраудан башка аваз-өн ишетелмәде.

Үз өенә дә кагылып чыгарга булды Идрис. Кереп азрак хәл җыярга, куе чәй белән киңәнергә кирәк...

Икенче кат... Монда бераз салкынчарак. Һашимнарның ишеге ачык, ул, ирексездән тукталып, звонок бирде.

Эчтән:

— Керегез, кер,— дип эндәштеләр.

Һашим ага залдагы урындыкта утыра, аның янына бик пошынган кыяфәттә Нина Михайловна баскан иде. Идрис сәлам бирде.

Һашим карт торды, протезы шыгырдап куйды.

— Сиңа телеграмма бар,— диде ул Идрискә, каш астыннан караштырып.— Монда иптәшең килгән иде. Әхәт атлы, хатыны белән...

— Әхәт?

— Без телеграммага кагылмас та идек, Әхәт ачты.

— Кайда соң алар үзләре?

— Сине кыдырып эзләп «Тын күл»гә киттеләр.

Нина Михайловна өстәлдә яткан телеграмманы алып бирде. Идрис дүрткә бөкләнгән кәгазьне эчке бер куркыну белән ачты, тәүдә имзаны карады. «Диләдән!»

Сүзләрне бер укыды, ике, аңлатып бирүләрен өметләнеп картка карады, Һашим иңнәрен генә җыерды, Идрис һаман берни дә аңламады. Ниндидер ребус, көтелмәгән сүзләр язылган табышмак иде бу телеграмма.

«Тизлек белән кайт. Мөзәкиргә син кирәк. Диләә»

«Ни өчен Дилә?» дип сызлады аның чигәләре. «Дилә ерактa бит, санаторийда... Мөзәкир анда ничек барып чыкты икән?..»

Дилә турында уйлап, ул телеграмманың чын мәгънәсенә һаман барып җитә алмый иде.

— Кемегез ул Мөзәкир? — дип сорады Нина Михайловна.

— Мөзәкирме? Минем кайнеш...

— Телеграмма кайдан?

— Маридан,— диде ул, шунда гына бераз аңына килеп.— Чепуха бу! Нишләп Дилә анда булсын?.. Шаярту бу!

— Әллә нәрсәләр булыр, Идрис, ут бар, су бар,— диде Һашим ага.— Сиңа хәзер үк юлга чыгарга кирәк. Әхәт тә шулай диде.
— Юлга чыгарга?
Ул сәер телеграмманы тагын бер кат күздән кичерде.
— Сәгать ничә?
— Беренче ярты.
— Поезд киткән инде... Хәзер төнге бердә генә була.
— Самолет очадыр,— диде Һашим.
Идрис ике тиенлек бакырын тотып автоматка чапты. Аяк арганлыгы онытылды, тәндә кайсы төш авыртканын анык әйтеп булмый торган бимазалы сызлану башланды.
— Йошкар-Олага?.. Самолет очты. Иртәгәгә билетлар сатылып бетте.
Ул трубканы урынына элә алмыйча озак кына азапланды.
Нидер эшләргә кирәк иде... Урамнан кайтышлый ул телеграмманың сүзләрен тагын күздән кичерде... Төнге бергә хәтле көтәргә һич чамасы, түземе юк иде, Идрис хәзер үк, шушы мизгелдә үк юлга чыгып китәргә талпынды... Мөэәкир, Айдар турындагы уйлар, өзек-өзек аның күңеленә бәрелеп, йөрәген тырнадылар.
Һашим белән Нина Михайловна, урамга ук чыгып, аны көтәләр иде.
— Самолет киткән,— диде ул.
Өчесе дә тын калдылар.
— Бер юл бар,— диде Нина Михайловна, кызарынып.— Бар!
— Әйт соң,— диде Һашим, аны ашыктырып.
— Үзем эштә булмагач санэпидстанция машинасын җибәрү кыен... Бәлки машинаны Виталий Петровичтан сораргадыр.
Баягы телефон будкасына өчәүләшеп бардылар. Иң кирәклесе — Виталий Петрович өйдә иде. Аның белән Булавина сөйләште.
— Идрис Булатовичка бер көнгә машина кирәк... Мари республикасына барып кайтырга...
Жаденко сүзне тиз очлады:
— Бер кая да чыкмагыз, хәзер барып җитәрмен!
Кайтып, сөйләшмичә генә чәй эчтеләр.
— Айдар турында сөйләмәдегез,— диде Нина Михайловна, чәй урынын җыештыра башлагач.
— Айдар югалган, эзлиләр... Мин анда барырмын дигән идем!
— Хәзер үзем «Тын күл»гә китәм,— диде кинәт Һашим.— Сине озатам да малай янына барам.
Көтү минутлары, йөрәккә кадый-кадый, кан тамырлары буйлап актылар. Ике туларга якынлашканда ишектә звонок яңгырады. Виталий Петрович бүген гадирәк киенгән, өстендә җәйге, җиңсез күлмәк кенә.
— Машина булды,— диде ул, хәл-әхвәл алышкач.— Танышың Васяны юлыннан туктаттым...
— Рәхмәт сезгә, Виталий Петрович,— диде Булавина.
— Әхәт монда кагылмый калмас, әйтегез, редакторга шалтыратсын.
— Әткәй, мин дә сезнең белән барам,— диде Нина Михайловна.
— Сез кая җыендыгыз? — дип сорады Жаденко.
— «Тын күл»гә.
— Рөхсәт итсәгез, мин дә сезгә иярер идем.
Булавина, сиздермичә генә әткәсенә карады да, ашыгып:
— Әйдәгез, бергә күңеллерәк булыр,— диде.
— Вася-Василек, дустым! Сәфәрнең күңелсезен дә безгә бергә ясарга язган икән! — диде Идрис, шоферның аркасыннан кагып.
— Дөнья ул! — диде Вася.
Булавина, Һашим, Виталий Петрович аларны озатып калдылар. Машина күздән югалгач кына өчесенең дә хәтеренә бер нәрсә төште:

Идрислар нәкъ алар җыенган «Тын күл» янында узып китәчәкләр... Машинада тагын өч кешелек урын бар иде... Бергә генә утырып китәсе булган, акыллары җитмәде, бер көнне, бер үк минутларда диярлек ике бала турында ишетелгән кайгылы хәбәрләр аларны да пошаманга төшергән иде...

## 41

Әнисе Мөзәкиргә озак кына ялынды:

— Төш инде, балам, тамагыңа берәр нәрсә кап. Чәй-мазар эчсәң, башың җиңеләеп китәр...

Лапас өрлекләренә тезелгән киртәләргә капланып яткан малай төшмәде, җавап та бирмәде, ара-тирә аның көрсенеп-көрсенеп куюы гына ишетелә иде...

Аптыраган ана кичкә кырын җәйләүгә ире янына китте. Хәлил агай хатынының сүзләрен бик борчылып, кашларын җыерып тыңлады да:

— Тукта, кайтып килми ярамас алайса,— дип куйды.

Бик озак үгетләгәч кенә Мөзәкир яткан җиреннән торып җиргә төште, башын аска иеп өйгә керде, берәүгә дә күтәрелеп карамады, ирен кыймылдатып сүз әйтмәде. Хәсрәткә баткан Хәлил агай киңәшкә мәктәп директоры Якуб Нанкиев янына барды. Директорны уятып керде.

Якуб иртән иртүк Хәлил агайларга килеп җитте. Мөзәкир тезләрен кочаклап чолан идәнендә утыра, ул йокламагач әти-әниләре дә керфек какмаганнар иде.

— Мөзәкир,— диде йомшак кына итеп Якуб Нанкиев.— Ата-анаңны болай җәзаларга кирәкми.

Малай идәнгә бөгелеп төште дә тавышсыз гына үксергә тотынды. Аны артык борчырга кирәк түгеллеген аңлаган директор кул хәрәкәте белән әти-әнисенә чоланнан чыгарга кушты. Үзе дә чыгып болдырда уйланып басып торды, аннан Зәйтүнәләргә китте.

— Зәйтүнә,— диде ул, кызның маңгаен сыйпап.— Торна сазы буенда син дә булгансың икән... Степанов белән ничек-ничек очрашуыгызны әйбәтләп, түкми-чәчми генә сөйләп бир, каушама.

Кыз байтак кына вакыт ык-мык торганнан соң, өзек-өзек булса да бик аңлаешлы итеп күл буенда булып узганнарны сөйләп бирде.

Нанкиев туры Степанов янына идарәгә барды. Эмма Степанов «малайга кул якмадым» диде. Хәйдәров та чатнатып шуны раслады: «Малай әрепләшергә тотынды, шуннан соң Николай Васильевич, әлбәттә, урынсызга кызып китеп, тегенең чалгысын сындырып атты»,— диде.

Мөзәкир икенче, өченче көнне дә сөйләшмәде, чоланнан чыкмады. Кешеләр «врачка күрсәтеп карарга кирәк» диештеләр. Хәлил агай мәктәп директоры белән киңәште дә Диләгә чакыру телеграммасы сукты.

Дилә хәбәрне алуга кайтып та җитте. Бер тәүлеклек хәсрәтле юлда ул тагын ябыгып, борчылып, таланып калды.

Мөзәкир тамагына аз-маз капкалый башласа да, Дилә апасына да тел язмады, үгетләүләр, ялынулар, киңәшләр берсе дә ярдәм итмәделәр, ул шыпырт кына чоланында утыра бирде.

Өй эчләре белән ни кылырга белмәделәр. Өченче көнне Дилә:

— Идрисне чакырып карыйк,— диде,— безгә киңәшергә кирәк...

Икенче көнне иртән Казанга мәгълүм телеграмма очты...

Атаклы мари урманнары...

Уралып аккан көмеш тулы вак-вак елгалар...

Юып чыгарылган кебек чеп-чиста комлы юллар... Болыннарда кояш нурыннан коелган түгәрәк печән кибәннәре... Юлларда атлар, машиналар... Марилар, татарлар шау килеп базардан кайталар...

Шушы бетмәс-төкәнмәс төрлелек, мул матурлык чагылышына караган саен күз алдына Мөзәкир килә, малайның туган якларына якынлашкан Идриснең күңеленә шом тула бара иде...

Ялгышмаса, болары инде Озын ял авылы кырлары...

Менә Идрис өчен бик истәлекле чокыр...

Дилә белән өйләнешкәч, алар авылга ялга кайткан иде. Бер көнне Дилә өй эшләрен караштырып йортта калды, Идрис «Гауя» исемле транзисторын асып кырга чыгып китте. Урман буйларында йөрде һәм шушы чокырга тап булды. Бәләкәй арбага коры-сары утын төягән озын буйлы карчык таучыкка менәргә азаплана иде. Утыны да әллә ни түгел, шулай да карчык арган, шабыр тир ага үзеннән, чаларган чәчләре сидрәгән яулык читеннән бүселеп чыкканнар. Ул аны күрүгә йөгереп чокыр төбенә төште, әбинең хәл-әхвәлен сорашты һәм утынлы арбасын сөйрәп өскә үк менгереп куйды...

Кичкә Озын ял авылында ят хәбәр таралды:

— Мәликә карчык урманнан кайтышлый Хөзерильяска тап булган... Яшь кенә чибәр егет кыяфәтендә йөри ди... Мәликә карчык арба тартып изаланганда хәзрәти Хөзерильяс бәләкәй генә китабын тотып килеп чыккан... Арбасын һавада очыртып өскә менгергән... Аннан хәерле юл теләп калган... Хөзерильясның үзен музыканнар уйнап, җырлашып фәрештәләр озатып киткән...

Бу яңалык Хәлилләр өенә дә килеп ирешә. Хөзерильясның Идрис икәнен, «серле китап»ның гади транзистор булуын аңышкач, барысы да тыела алмыйча көлешкәннәр иде...

Мөзәкир гаять шук булса да, өй арасындагы эшләргә гел катнашып йөрүче йорт җанлы малай иде. Сораулар биреп җизнәсен йөдәтеп бетерде... Тиктормас малай «Гауя»ны муенына асып кай арада Мәликә карчыклар өенә барып җиткән.

— Мәликә әби, Хөзернең китабын күрәсең киләме? — дип кычкыра икән...

Әнә авыл...

Шифер түбәләр... Колгаларда сыерчык оялары...

— Килеп җиттек, Вася...

Таныш капка... Капка төбендәге кеше дә үтә таныш...

Ул машинаның ишеген каерып ачып җиргә ташланды:

— Дилә!

Дилә аны кочаклап алды, бите белән аның тузанлы иңбашына капланды һәм бер генә сүз әйтте:

— Мөзәкир!..

* * *

Кич шундый гүзәл!..

Тымызык, җылы... Читән белән бүленгән аралык артында исәйгән каз бәбкәләре саташып ара-тирә «кыйң» дип моңсу тавыш белән сузып куялар...

Тәлинкәләрдәге бүленгән ашлар ашалмаган. Самовар күптән сүнгән. Ачылырдай тәрәзәләр, ишек шар ачык. Шулай да мул аш пешкән өй эчендә бөркү, эссе. Кысып кына куйган радиодан Казан концерты тапшыралар...

Хәлил аганың өстәлдә ята торган дәү куллары янында эре-эре ипи телемнәре... Сүзләр сөйләшенеп беткән, аңа карап күңелләр җиңеләймәгән... Рәхмәт әйтеп аш яныннан берәм-берәм тордылар.

— Кызым, урынны кая җәярмен икән? — диде Гөлбикә апа пошынып.

— Кая да ярар, әнкәй...

— Без чак кына йөреп керикме әллә, әнкәй? — диде Идрис.

— Барыгыз, бар,— дип тиз үк ризалашты әниләре.

Хәлил ага ишек алды уртасында нидер уйлый... Читән коймa артында канатлары каурыйлана башлаган каз бәбкәләре «кыйн» дип моңаеп аваз салалар... Аяк өсте генә йокымсыраган ана каз мыдыр-мыдыр сөйләшеп ала; йоклагыз, йокла, бибиләрем, без монда эткәгез белән икәү, уяу торабыз дип юатамы ул?..

Абзарда озак итеп сыер уфылдый...

Сарыклар, эссегә чыдый алмыйча, бер почмактан икенче почмакка дөбердәп күчәләр.

Чыннан да кич җылы, тымызык!..

Июль төненең йолдызлары аксыл-сары... Әле шәфәкъ тә сүнеп бетмәгән. Кояш офыкка ингәнгә байтак вакыт узса да, күк гөмбәзендә тожым-тожым нурлар уйный.

Капка шыгырдап ачыла, Хәлил ага Идрис белән Диләне күз белән озата, күз белән аларның икесен дә иркәли, юата. Капканы да үзе яба...

Алар урам чирәмен таптап янәшә баралар... Диләнең җылы терсәге Идриснең учында. Аның да учы кайнар, яна...

— Василий кайчанрак кайтып җитәр?

— Төнлә көндезге тизлек белән куа алмас. Без очтык кына... Шулай да яктырганда өйдә булырдыр.

— Кунарга гына каласы иде.

— Хәзер иртә яктыра!

Иң кыска төннәр...

— Иртәгә дүшәмбе, эшкә барасы бар.

Алар бөтенләй башка нәрсәләр турында сөйләшсәләр дә, икесенең дә уйлары уртак.

Икесе дә, байтак аеры торсалар да, бер-берсе турында бөтенләй сорашмыйлар... Бүген алар көне түгел... Бүген алар киче түгел... Бүген Мөзәкир көне, аның киче. Сүз, уй, игътибар, үткән һәм киләчәк — барысы да аңа...

— Дилә, әйдә Ирек Хәйдәров янына барабыз!

— Соң түгелме икән? Авылда бит иртә яталар. Эш өсте...

— Уятып керербез.

Ирекләрнең өе түбән очта... Тәрәзәләрендә тонык утлар. Биек капка такталарында кадак башына кигертелгән ак калайлар ялтырашып тезелешкән. Читтән караганда капкага нидер язылган төсле.

Капка эчтән эленгән иде, Идрис келәне сак кына шалтыратты. Ишек шыгырдаган тавыш килде, лыбырдап сарыклар күчкәне ишетелде, капканы сорамый-нитми генә ачтылар. Ирекнең хатыны башлангыч мәктәп укытучысы Зөләйха аларны танымады. Ул кер юа иде, ахрысы, беләкләрен сызганган... Таныгач, юеш куллары белән Диләгә чытырдап ябышты:

— Сез икәнсез, сез, Дилә... Кайтуыңны ишеткән идем. Ирек күреп сөйләштек тә дигән иде... Әйдә, өйгә узыгыз...

— Ирек өйдәме?

— Өйдә, өйдә!.. Йокларга яткан иде, хәзер уятам...

Лапас астыннан иснәнеп йөнти эт килеп чыкты, хуҗа хатынның кунаклар белән ягымлы сөйләшүен ишеткәч, ялагайланып койрыгын болгап Идриска килеп сырпаланды.

Керделәр. Мич буендагы кайнар сулы агач тагаракта керләр җеби. Мич акшарына, идәнгә бала учы-бала учы күбек кисәкләре чәчрәп ябышкан. Зөләйха ут яктысына кергәч, әллә өйнең җыештырылмаган булуыннан, әллә сидерәгән халатының чачаклы итәгеннән оялып, Ирекне уятырга кирәклеген дә онытып Диләгә текәлеп торды. Алар бергә, бер класста укыдылар бит, яшьтәшләр... Дилә үз чордашының чигә-

сендә вакытсыз сибелгән чал, күз төпләрендә тормышның җиңелдән түгеллеген раслаучы кара күләгәләр күреп бик гаҗәпләнде.

— Көндез кер кузгатырга вакыт җитми,— диде Зөләйха, тиз-тиз җыештырынып.— Безне дә печәнгә йөртәләр.

Шунда гына ул кунакларның берсүзсез ишек катында торуларын искәреп, Иректе уятырга кирәклеген исенә төшерде: «Ай, хәтер!» дип чыгып йөгерде.

Почмакта, чаршау белән күләгәләнгән караватта, ике сабый таралып йоклап яталар, Дилә аларның иңнәренә хәтле салынып төшкән одеялларын рәтләде...

Чоланнан йөткергән ирләр тавышы килде, битенә мендәр җөенең эзе сызылып төшкән, чәбәләнгән чәчле, майкачан гына Ирек чалбар төймәләрен эләктерә-эләктерә килеп керде.

— Кунаклар бар икән, хуш килдегез,— диде ул шат кына.— Исән-аман гына йөрисезме, туганнар? Күзгә-башка күренмәвегезгә биш былтыр!

Салкын гына кул бирештеләр.

Зөләйха сорау белән иренә карады.

— Чәенне яңарт, карчык,— диде Ирек аның соравын аңлап,— кадерле кунаклар килгән. Сирәк күрешә торган туганнар...

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез,— диде Дилә, Идрис аны куәтләде:

— Чәй эчә үк тормабыз...

— Эчик инде! Күрешмәгәнгә дә бик күптән,— дип ялынды Зөләйха. Аның шушы кырыслыкны йомшартып, күңелле генә гәпләшеп утырасы бик килә иде.

— Режимга күчтеңме, кордаш? — диде Ирек елмая-елмая.— Фигураны саклыйсың инде, йөрәк-бавырны? Кичке сәгатьләрдә сыеклыкны эчмим дисең!.. Ә без, авыл кешеләре, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында торабыз да чыгып чабабыз, утырабыз да ашыйбыз.

— Без Ирек белән йөреп керик булмаса,— диде Идрис.— Монда җайсыз. Балалар да йоклый, Зөләйха ханым да эш кузгаткан.

Ирек як-ягына каранды.

— Күлмәгеңне юарга салган идем,— диде Зөләйха, комод ишеген ача-ача. Комод тартмасы бик авыр ачылды, Зөләйха ашыкты, тартышкан яңакларына тимгел-тимгел кызыл чыкты.

— Сине кыстамыйбыз, Зөләйха,— диде Дилә.

— Башка вакытта керегез,— диде Зөләйха, кыяр-кыймас кына.— Әллә ничек булды, ташлаштык бит... Йөрешмибез дә, бер-беребезне белешмибез дә, дөнья куган булабыз... Керегез, яме?

Ирек, иңенә пиджак салып, алдан үзе чыкты.

Урамда шигәеп тыңланып торды, аннан Идрискә күтәрелеп карады. Идрис кул ишарәсе белән аны йөрергә чакырды. Урамның нәкъ уртасыннан бара башладылар.

— Сез ниләр кырасыз? — дип сүз башлады Идрис.

— Һаман шул инде! Печәнгә төшкәннән бирле йокы тими. Мал башын арттырабыз, ә болыннар шул ук. Бүген әзрәк черем итеп калып булмасмы дип яткан идем...

Бизрә буена яшьләр төшкән, ахры, гармун тавышы ишетелеп-ишетелеп китә, әллә тып-тып бииләр, әллә шап-шап кул чабалар, аңлап булмый, кайтаваз таулардан тавышны бозып китерә.

Өчесе дә бер-берсенең сулышын, шуның белән бергә аның ни уйлавын, ни әйтерен тыңлаган кебек, сак киеренкелектә атлыйлар.

— Саулык ничек?

Идриснең тавышы да ят кебек тоелды Диләгә, әллә ничек карлыккан, көне буе җилдә кабык төшергән яки балта чапкан кеше сыман сөйләшә.

— Зарланган юк. Тынычлыкка гына туеп булмый. Авыл советының эше, теге, кем әйткәндәй, унган тавык та чүпләп бетерерлек түгел! Һәммәсе өчен җавап бирәсе...

— Алай...

— Ирек,— диде Дилә, сабырсызланып,— сөйлә!.. Ничек булды...

Тик Хәйдәров ашыкмады. беравык урам уртасыннан аларның аяк тавышлары гына чожтырдап барды.

— Сөйлә, Ирек,— дип кабатлады Идрис.

— Нәрсә ничек?.. Ә-ә, аңлыйм, Мөзәкирне соравыгыздыр...— диде Ирек түшенке тавыш белән.— Беләсездер инде. Ишеткәнсездер.

— Белмибез,— диде Идрис, каты гына.— Син үзеңчә сөйлә!

— Без маридан кайтып килә идек... Николай Васильевич белән икәү... Балалар күл буенда мәшәләнәләр. Берсе чаба, икенчесе ура. «Туктатырга кирәк боларны!» диде Николай Васильевич. Иплән кенә тегеләргә аңлатты... Ярый торган эш түгел инде, үзегез беләсез. Ә Мөзәкир каршы әйтә дә әйтә. Шуннан, бала-чагадан ук усал сүз ишетү җиңел булмагандыр, күрәсең, Степанов та кызып китте.

— Сөйлә, сөйлә! — дип ашыктырды аны Идрис.

— Чалгысын сорады, бирми... Кайтып кит, ди... Кайтмыйм, ди...

— Шуннан ни булды?

Ирек авыр-авыр атлап тагын сүзсез барды.

— Чалгысын сындырды...

— Ә нигә?.. Үзен нишләтте, үзен?

— Алай тел күтәреп әйтерлек берни эшләтмәде,— диде Ирек Идриска туп-туры карап.— Рас шулай.

Дилә ярсыган Идрисне дәшмичә генә юата, тынычланырга өнди иде.

Шушы кеше белән бергә укыдылар бит алар! Ризык, хыял бүлешетәләр... Шушы кеше аша Дилә белән таныштылар. Шушы кеше аларның туйларында кияү егете булып утырды, җырлады, биеде...

— Ялганлыйсың син, Ирек! — дип кычкырды Дилә.

— Нигә алайса мине алып чыктыгыз, мыскылларгамы?

Ирекнең аскы ирене калтырый иде.

— Чоланында тыныч кына йоклый алмасын дип алып чыктык.

— Ә теге чакта, Мөзәкирне Бизрә буенда кемнәрдер кыйнап киткәч, ник азрак кыймылдамадың? — диде Дилә.

— Нинди кыйнау! — Ирекнең болай да нәзегрәк тавышы бөтенләй чәрелдәп янгырады.— Сез чамалабрак...

— Бульдозерлар белән Бизрәне бууларын ишеткәнсеңдер бит?

— Әллә кайчангыларны казып эчне пошырмагыз сана!

— Хәзер Николай Степанов янына барабыз! Хәйдәров, син дә иярәсең!

...Степанов иңенә чуар дәү шәл салып болдырда тәмәке тарта иде, капка артындагы сөйләшүне ачык ишетте, лап-лап атлап килеп капка ачты.

— Николай Васильевич,— диде еламсыраган тавыш белән Хәйдәров,— менә сине күрергә дип килделәр.

— Кемнәр?

— Бу без,— диде Идрис, алгарак чыгып.— Мөзәкирнең туганнары. Аның апасы Дилә... Мин Диләнең ире, Казаннан кайттым.

— Өйгә керегез.

Керделәр. Степанов ут кабызды. Түргә узды. Идрис белән Дилә күз дә алмыйча аңа карап торалар иде. Ул керүчеләргә урын күрсәтеп кулын сузды:

— Хатын өйдә юк... Кайнана әҗәл якасында ята, шунда куна калды. Чәй белән сыйлыйммы?..

Степанов татарча бик дөрес итеп, әмма бераз уйлап, акрынрак сөйли иде.

— Николай Васильевич,— диде Идрис, нык итеп.— Дәресен әйткәндә, без кунак булырга кермәдек. Рәхмәт, Мөзәкир өчен бик борчылабыз...
Дәү куллары белән яңагына таянып утырган председатель аягүрә басты:
— Мин борчылмыйммы? Борчылам дип чәч йолкып, бакырып йөреп булмый... Гаебем булса, хөкем итегез,— диде.
— Эш хөкемдә генәмени, Николай дәдәй? — диде Диләә.— Ничек була алды соң бу хәл?
— Ничек, ничек? — Степанов юан папиросын пышкытып идән буйлап йөренә иде. Мич арасыннан чыккан песи аның белән очрашкач ялт кына чыгып сызды.— Печән өсте бит, уттай эш!.. Хуҗалык болай да күп тармаклы, чуалчык, ә печән-урак өсләрендә эштән чыгып арыйсың. Аңлыйсыздыр, ә ул үзенә печән әзерләп ята... Аннан күреп башкалар да үз якларына каерылсалар колхоз болынын кем эшкәртә? Һәр минуты, һәр кешесе чутлы хәзер колхозның.
Идрис, ничегрәк җавап бирергә икән дип уйлаганда, сүзне Диләә алып китте:
— Әнкәй белән Мөнир ул көнне колхоз печәнендә булганнар. Әти белән Нәгыйм көтүдә...
— Аннары, үсмерләрне көчләп эшләтергә закон кушмый, Николай Васильевич... Аларны эшкә тартуның башка формаларын табарга иде.
— Форма дисез сез... Шушындый зур хуҗалыкта һәркемнең күңеленә ятышлы төгәл форма табып кара менә! Әгәр ул законга турылыклы булып калыйм дисәң, һәркемгә аерым устав кирәк.
— Ул болын чабылган булган ич, Мөзәкир кеше кермәслек калдыкпостык урыннарны гына җыештырган.
— Эш анда түгел, эш принципта... Алар чабып яталар... Яннарына килдек... Минем характерның бераз крутарак икәнен үзегез дә беләсез... Чалгынны бир, дим... Бирми. Кайтып кит, дим, китми...
Степанов әле өстәл янына килеп утыра, әле стенага терәлгән диванга барып урнаша, туктаусыз тәмәке пыскыта, зәп-зәңгәр ачы төтенне җил тегермәне канатлары кебек дәү куллары белән куып тарата башлый, кая гына барса да аңа җайсыз, уңайсыз икәнлеге күренеп тора иде.
Ишек катында сүзсез генә басып торган Ирек Хәйдәров аңа карап көрсенеп куйды...
...Ат, башын җиргә иеп, аларны көтеп тора иде, кешеләрне күргәч сөенеп, ишетелер-ишетелмәс кенә кешнәп тә алды. Степанов озатырга чыкмады, сүзсез-нисез болдырында басып калды.
— Эх, Ирек, Ирек,— диде Диләә, бераз баргач,— әткәй белән әнкәй янына кереп тә чыкмадың ич син!
— Ерак торабыз бит...
Идрис ыргылып тарантастан сикереп төште.
— Тр-р, туктат! — дип үкерде ул.— Диләә, бир кулынны, төш!
— Төшәм, Идрис.
— Ялгыз кайтсын Хәйдәров! Ялгыз калсын... Аның белән моннан болай ризык та, һава да, урын да бүлешә алмыйм.
Ирек мыгырдап аягына басты, дилбегәсен болгап ат артына сыптырды, үшән генә кайткан алаша башта гаҗәпсенеп борылып карады, аннан арт санын сикертеп тырт-тырт юрта башлады.
— Сиңа суыкмы?
— Түгел...
— Нигә калтырыйсың соң?
— Миңа куркыныч...
— Әйе... Миңа да!

— Син үзгәргәнсең, бик үзгәргәнсең, Идрис... Әллә моңарчы без бер-беребезне белми йөргәнбезме?

— Без барыбыз да үзгәрәбез. Акрынлап олы кеше булып барабыз. Җир өчен дә, халык язмышы өчен дә, үткәннәр өчен дә, киләчәк өчен дә җавап бирә башларга бик вакыт. Без үзгәрергә тиеш тә!

— Идрис!

— Эх, Дилә!

— Бер сүз әйтимме?

— Сөйлә, Дилә... Минем синең тавышыңны, кеше тавышын ишетәсем килә.

— Тик син бик күңелсезләнмә...

— Тырышырмын...

— Безнең бәби булмаячак, Идрис...

Башта ул берни дә эндәшмәде, аннан Диләне үзенә табарак тартты, кысып кочаклады.

— Миңа моны санаторийга баргач та әйттеләр... Ләкин мин синең янына кайтырга курыктым... Медицинаның кодрәтенә ышанып, бәлки чарасын табарлар, шифасы булмасмы, үзгәрмәмме дип өметләндем.

— Аңлыйм,— диде Идрис. Алар шулай кочаклашып бара башладылар.— Мин моны синең хатларыңнан сизенә идем... Дөньяда барысы да син һәм мин теләгәнчә генә бармас... Ләкин мин яшәүнең иң ахыргы, иң асыл мәгънәсе нәсел калдыру дип хатарак уйлаганмын... Яшәү — үзең турында, үз балаң турында уйлау гына түгел, яшәү — дөнья турында, андагы халыклар, илләр турында да уйлый, кайгырта алу, шуларның язмышына актив катнаша алу да ул. Дөнья, кешелек бәхете өчен яшәү шулай иң изге, олы максат түгелмени?

Дилә сабыр гына елый...

Хәлил агайларның тәрәзәләре шар ачык...

Тымызык, җылы... Читән белән бүленгән аралык артында каз бәбкәләре моңсу тавыш белән «кыйң» дип тавыш биреп куялар.

Икенче көнне алар районнан врач чакырттылар. Врач, малайны бик җентекләп карагач, аңа бары тынычлык кына кирәк диде. Шул ук көнне Идрис Казанга китте. Дилә, әти-әнисеннән, Мөзәкирдән аерыла алмыйча, бер атнага алар янында калды. Казанда эшләр бераз көйләнгәч Идриснең җәйге ялында алар Озын ял авылына кайтырга булдылар.

Идрис утырган колхоз машинасы теп-тигез юлдан тәгәри.

Уңда тау битендә колхоз сыерлары таралган.

Аклы-каралы нәселле сыерлар...

Кыя тау өстендә бәләкәй генә Нәгыйм баскан. Ул җизнәсенә озак итеп кул болгый, Хәлил ага күренми...

Күренми...

Бәлки ул күренмичә генә машиналарны озатып каладыр?.. Тау башында офыклар киң, юллар озын, юллар ерак — еракларгача күренеп торалар...

## 42

Идрис станциядә газеталар сатып алды.

Кузгалып киткәч тә ул тәрәзә янындагы бәләкәй өстәлгә таянып «Известия»не укырга тотынды. Официаль бүлектә аның игътибарын бәләкәй генә бер белешмә җәлеп итте. «Уллыкка ничек алырга?» дигән белешмәдә мондый юллар бар иде:

«Балигъ булмаган балаларны гына уллыкка алырга рөхсәт ителә. Әгәр, ата-анасы исән икән, алар балаларын тәрбияләүдән баш тартсалар, уллыкка аларның ризалыгыннан тыш та бирергә мөмкин...»

Юридик белешмәнең шушы соңгы сүзләре Идрисне тетрәтеп җибәрде...

Диләнең бәбәе булмаса, дигән куркынычлы фикер соңгы көннәрдә аның күңеленә еш килә иде. Айдарның хәл-әхвәлен якыннан белеп, Ренат-Луизалар белән танышкач, ул ара-тирә: «Нәрсәгә инде боларга бала?.. Артык йөк кенә!.. Гомер буе кагып, читкә тибәреп яшәячәкләр... Нәрсәгә инде?» дип уйлаштыра иде. Ренат-Луизаларның тормыш принциплары шулай корылган ки, анда балаларга да, башкаларга да урын калмаган. Бары үзләре генә, үзләре генә умырсыннар!..

Әгәр Айдарны алардан уллыкка алсаң?

Ул чыдый алмыйча күлмәк якасын ычкындырды.

Әмма бу бик катлаулы, мәшәкатьле, җәнҗаллы эш булачак.

Беренчедән, Дилә ризалашырмы?.. Ул, мөгаен, риза да булыр... Ә Кәрамовлар? Бар чагында кадерен белмәсәләр дә, юкка кала башлагач, тартәне тибеп сындырмаслармы?.. Ансат кына күнмәсләр, дау белән Югары судка барып җитәчәкләр... Монда закон гына ярдәмгә килә ала, ул җиңә ала Кәрамовларны. Әгәр закон нигезендә Ренат-Луизаның бала тәрбиясеннән тулаем баш тартуларын раслап булса, ул чагында ник Генеральный Ассамблеяга барып җитмиләр!..

Тәрбияләмиләр дип әйтергә нигез бармы, житәрлекме?..

Әчеп, урамда сугышып йөрмиләр, икесе дә тулаем алганда тыныч, әйбәт яшиләр... Ә бала акрын гына әрәм була... Ул озакламый әнә шул куш көбәкле мылтык күтәргән малайларга ияреп китәчәк... Тик аны бирергә ярамый, әрәм итәргә ярамый...

Аннары, аннары...

Юк, юк...

Поезд тәгәрмәчләре бер җайга гына тәгәриләр... Выжт-выжт... Тәрәзә аша күренеп кырлар, урманнар, авыллар кала. Сукмакларда кызлар, малайлар... Кемнәрнеңдер яшьлеге, балачагы уза торган авыллар... Кемнәрнеңдер салкын тәннәрен мәңгелеккә үз иткән җирләр... Авыллар, кырлар алышынып тора, күренешләр үзгәрә, әмма Идрискә бер уй, фәкать бер фикер генә ияргән.

Юк, Айдарны харап итәргә юл куймам, бусы булмас!

Гомереңне яшьлеккә, балаларга, димәк, дөньяның киләчәгенә багышлау нинди олы эш икән! Әгәр берәр сәбәп табылып Идрискә газетадан китәргә туры килсә, ул үзенең педагог икәнлеген хәтеренә төшереп, һичшиксез, эшкә мәктәпкә китәр.

Класска керер:

— Исәнмесез, балалар...

Ул шушы үзе уйлаган сүзне кычкырып ук әйтте, вагондагылар аңа сәерсенеп карадылар...

— Исәнмесез, балалар...

Дөньяның киләчәге илле күз белән аңа карап тора...

Егерме биш баш аны сәламләп иелә...

Ул — укытучы, ул шушы егерме биш кешене дөньяның киләчәге белән тоташтырырга тиеш...

Юк, Айдарны ул сипкелле малайларга бирмәс!..

Юлдашларыннан берсе аннан газеталарын сорады.

Идрис «Известия»не сузды.

— Югалта күрмәгез, кирәкле материалы бар...

Газета — бүген Идрис кулындагы корал ул. Шәфкатьсез-кешелексез ата-аналарны бөек хокуктан мәхрүм итеп була икән. Моның законлы юлы бар!.. Әйбәт закон, кирәкле закон! Әшәке ата-ана әле ул баласына күлмәк-ыштанга дигән акчасын да эчеп бетереп кайткан йолкыш кына түгел, әшәкелекнең бик нечкә, күзгә чалынмаган куркынычлы формалары бар...

Әһә, Казанга якынлашалар!

Юдино... Сулда урманнар, унда Идел... Урманнар артында балалар

шәһәрчеге «Тын күл»... Шәһәрләр артында болыннар... Юк, балаларны болында уйнаудан мәхрүм итәргә ярамый...
Айдарны кем, ничек тапты икән?
Кайдан?
Фаина Наумовнамы?
Галия апамы?
Әхәтме?
Әллә Касыйм Усмановмы?
Пионерлар таптымы әллә?
Бәлки милициядер?
Идрискә ачулыдыр малай... Тагын очраша алмадылар...
Менә Юдино белән Казан арасындагы вак-вак тукталышлар.
Казан вокзалыннан ул иң элек Әхәткә шалтыратты. «Аппаратныйда» диделәр. Ул инәлеп аны чакыруларын үтенде.
— Бу мин, картлач.
— Идрис? Кайтып җиттеңме? Ни хәбәрләр?
— Начар, бик начар...
— Ачыкла.
— Ундүрт яшьлек үсмер күңел ярасы алган.
— Теге кайнешеңме?
— Үзе... Сөйләрмен, тукта... Киңәшәсе дә бар! Айдар табылдымы?
— Урманда, куелыкта качып утырган.
Идрис елмайды:
— Күңелемә килгән иде... Хәзер ул кайда, дачадамы?
— Дачага бармыйм ди. Анда этиле малайлар гына тора, ди. Кәрамовлар ирле-хатынлы Румыниягә сәяхәткә киткәннәр. Ул бездә.
— Менә ничек!
— Каян шалтыратасың?
— Вокзалдан.
Телефон-автомат янына чират җыелды, алар сыздин-быздин язулар белән чуарланган ишеккә чиртә-чиртә Идрисне кабаландырдылар.
— Картлач, эшкә барып җитим әле, шалтыратышырбыз.
— Көтәм.
Матбугат йортын гадәттән тыш сагынып, ашкынып кайтты Идрис. Монда аның эш урыны гына түгел, фикердәшләре, теләктәшләре, көрәштәшләре. Бүлмәсенә атылып керде, киереп тәрәзәләрне ачты. Аннан, аз-маз эшен караштыргач, Рәкыйп янына керде. Редактор янында тәмәке пыскытып ничектер юашланган, картайган Ниса Чәймилова утыра иде. Икесе дә аның белән ягымлы күрештеләр.
— Тиз кайткансың, бусы өчен мактыйм,— диде Рәкыйп.
— Мондагы хәлләрне чамалыйм бит.
— Анда ниләр бар?
— Каян башларга да белеп булмас, Рәкыйп абый!.. Рөхсәт итсәгез, шул турыда язып чыгар идем!
Ул бер-ике сүз белән Мөзәкирнең тарихын, Степанов, Ирек Хәйдәров белән очрашуларын сөйләп бирде.
— Язарга кирәк бу теманы! — диде кабынып Рәкыйп.
— Безнең республикада булган хәл түгел,— диде Ниса да озак кына баш чайкап, ай-һайлап утыргач.
— Гринбергның мәкаләсенә дәвам рәвешендә бирергә була,— диде Идрис.
— Әйбәт булыр,— дип хуплады Рәкыйп.— Тиз кайтуың яраган, шуның өстенә яңа фикерләр белән кайтуың тагын да шәбрәк булган!
Идрис чыгып киткәч, Ниса Рәкыйпне акрын гына үгетләргә тотынды:
— Рәкыйп туган, артык четерекле мәсьәлә. Безнең көннәр өчен типик хәл түгел... Сак булырга кирәк... Иң элек, киңәш, сораш... Бәлки,

киресенчә, кирәкмәгәнгә катышып йөргәне өчен Идрисне бераз йөгәнләргә кирәктер?

— Нәкъ мена шушы сыйфат житми иде аңа! — диде Рәкыйп.

Сүз озайтуның файдасызлыгын аңлаган Ниса, әллә Мөэәкирне, әллә редакторның үзен җәлләп, уфылдый-уфылдый чыгып китте.

Телефон шалтырады. Рәкыйпне комсомолның Өлкә комитетына чакырдылар. Август ахырларында Совет һәм япон яшьләренең Иделдә очрашуын оештыру комиссиясенең утырышы билгеләнгән икән, аны шунда дәштеләр. Өстәл тартмасын бикләгәндә ул: «Идрисне дә шушы эшкә якыннанрак тартканда начар булмас иде!» дип уйлады.

Идрискә Ниса хатлар кертеп бирде. Гринберг мәкаләсенә Казаннан бернича фикер бар иде инде. Ул беренче чиратта шуларны номерга әзерләде. «Таудан таш тәгәри башлады», дип уйлады канәгатьлек белән. Аннары Жаденкога шалтыратты.

— Барыннан да элек, сезгә зур рәхмәт, Виталий Петрович.

— Ничек йөреп кайттың?.. Миңа Вася барын да сөйләде, авыр борчылу булган икән... Уртаклашам!

— Виталий Петрович!

— Тыңлыйм, Идрис Булатович!

— Сезгә бер көтелмәгәнрәк үтенеч димме, сораумы шунда...

— Сөйләгез, булдырып булса, эшләрбез.

Идрис, ничегрәк аңлатырга икән дип аптырап, кыюсызланып торды. Аннары берьюлы:

— Уллыкка алырга иде! — дип әйтеп салды.

— Уллыкка? Балалар йортыннанмы? Ничә яшьтә?

— Бөтен авырлыгы да шунда шул, детдомнан түгел... Бала әтиәнисе янында...

Жаденко сызгырып ук җибәрде:

— Теге качкын малайнымы?.. Сез аның әтиләрен ата-аналык хокукыннан мәхрүм итмәкче буласызмы?

— Дөрес аңладыгыз.

— Авыр бу, Идрис Булатович.

— Бала кирәкми аларга, бөтенләй кирәкми.

— Артык дәрәҗәдә четерекле, буталчык нәрсә.

— Шулай икәнен сизмәсәм, сезне борчырга җөрьәт итмәс идем!

— Моның өчен зур әзерлек, бик күп раслаучы документлар, судның карары кирәк. Йорт идарәсеннән, детсадыннан, күршеләрдән, туганнарыннан, балалар бүлмәсеннән шаһитләр кирәк. Әгәр алар бертавыштан һәм чыннан да нигезле итеп ата-ананың баланы ташлавын, тәрбия итмәвен раслый алсалар, ул чагында... ул чагында...

— Суд мәсьәләне уңай хәл кылырмы? — диде канатланып Идрис.

— Ул чагында да җиңел булмас!

— Фактлар җитәрлек җыелачак, Виталий Петрович.

— Алайса «добро»! Тик белгечләр, юристлар белән алдан киңәшегез. Аткач аткач, тигерерлек булсын, каш ясыйм дип күз чыгармагыз... Шуны да әйтим, теге вакытта Нина Михайловна белән нык чаптык без ул малай артыннан... Хәер, рәхмәттән башка сүзем юк аңа!

Жаденконың ни өчен рәхмәт укыганын Идрис сизенде, сүзне озайтмады:

— Нина Михайловна ни хәлдә? — дип сорады.

— Ял итә... Кәефе начар түгел сыман...

— Хушыгыз, Виталий Петрович.

Инде эшкә тотынам дигәндә генә Әхәт шалтыратты:

— Төшке ашка безгә кайтабыз, буфетта авыз ачарга кабаланма.

— Төшке ашка дигән вакытымда котыпка барып кайта алмыйм.

— Мин сине махсус экипаж белән кереп алам.

«Телевидение» дип язылган ябык машинада озакламый Әхәт килеп житте. Киров районына киттеләр.
— Бая сорамаганмын, Дилә кайчан кайта?
— Минем хатын сагындырып йөри бeләl
— Санаторийга кабат бармыйдыр?
— Юк, картлач, житәр... Синең эшләр кайсы югарылыкта?. Кайнана белән мөнәсәбәтләр ничегрәк?
— Әкренләп чәнечкеләре коела, ләкин минем кинәтлекне һаман кичерми... Син югында бер тантана булып алды. Адашып чит фамилиядә йөргән кызга Нуруллина фамилиясен бирдек.
— Язылыштыгызмы?
— Бәлеш ашарга нигә чакыралар дип уйлыйсың соң?..
— Алайса, мин коры кул белән ничек сезгә керим...
— Буләксез дә ярар!.. Без бит теге көнне сине чакырырга барган идек...
— Теге көнне... теге көнне!..
Кунак өчен бар кешедән дә Айдар шатланды. Ул кыска җиңле ак күлмәк кигән, чиста, кызарынган. Алар Лида белән яңа гына су кереп кайтканнар икән.
— Мин сине урманда күрдем,— диде ул көлә-көлә.
— Нигә чыкмадың?
— Кыйнарсың дип курыктым.
Идрис, аны олы кеше санап, кулын суздыз
— Мин сине берчакта да кыйнамам, кыйнатмам да.
Өй токмачы артыннан вак бәлеш белән чәй эчтеләр.
— Иртәгә тагын киләсеңме? — диде Айдар, моңаеп.
— Кунарга килермен,— диде Идрис.
— Берүзең буш квартирада мингерәп ятмассың, кил,— дип чакырды Лида.— Су керенергә барырбыз. Иртәгә әнкәй дә килә, танышырсыз.
— Әгәр бүген шәплəп сөйләшә алсам,— дип күз кысты Әхәт.
Алар Матбугат йорты каршысында бик җылы саубуллаштылар.
Ул, редакциядә көндәлек эшләрдән арынгач, Мөзәкир вакыйгасын язарга утырды... Уйлар көзге житез җилдә агылган болытлар төсле өзлексез килеп тордылар. Әллә кайчаннан ата-аналар, зурлар һәм балалар турында фикерләр кузгатып йөргәнгә, аның каләме бер секундка да туктап тормады. Язып, соңгы ноктаны төрткәндә караңгы инә башлаган иде. Ул ут яндырып тормады, узган төндә бөтенләй йокламавын хәтерләп, утырган жиреннән кат-кат киерелде. Тизрәк өенә кайтасы, юынып ятакка авасы килде. Такси чакырды. Тиз жибәрергә вәгъдә итсәләр дә, машина ярты сәгатьтән соң гына килде. Ул арткы урынга чумды да күзләрен йомды. Йокымсырады.
«Нарат урманы» тукталышына житәрәк, ул тротуарда сәер бер хәрәкәт барын абайлады. Маңгай күзе белән түгел, күңел күзе анда йогышсыз бер эш барын күрде.
— Акрын барыгыз әле,— диде ул шоферга. Таза гына өч егет берәүне кыйныйлар иде. Текәлебрәк карагач, Идрис кыйналучының Әхәт икәнен таныды.
— Тукта! Көт мине!
Ул мәче житезлеге белән машинадан чыкты, ыргылып алар янына барып житте, ике аягын терәп киракле җай алды һәм егетләрнең иң гәүдәлесенә алагаемга берне сылады. Жан ачуы белән сукты, егет атылып барып төште, ыңгырашты. Идрис үзе дә аһ итеп мекердәп куйды. Әхәткә кунып-кунып аны төйгән ике егет аптырашып калдылар. Идрис икеләнерлек урын калмаслык итеп Әхәткә кычкырды:
— Ә син сыпырт моннан! — Тегеләргә тагы да катырак боерды.— Сез, әйдәгез минем белән!

Әхәт бер мизгел исен җыя алмыйча торды да, төшенеп алып, кафе ягына йөгерде. Ике егет каушап-шүрләп Идрис артыннан ияределәр. Егылган егет исенә килсә дә, машинадан төшкән ят куркыныч кешенең чакыруын ишетеп, мүкәли-мүкәли, йортлар арасына кереп шылды.

Идрис кулларын кесәсенә тыгып барды да кинәт борылды:

— Сез кемнәр? Исем-фамилиягез? Тиз, тиз бул! — дип кычкырды ул тегеләрнең борын тирәсендә бармагын йөртеп.

Сугыш чукмарларыннан сасы аракы исе аңкый иде, алар каушап акланырга тотындылар:

— Безмени? Ул үзе... Троллейбуста бәйләнә башлады.

Идрис алар сизмәгәндә генә тагын аякларын тераде һәм менә дигән худ белән егетләрнең икенчесенең аяк астына тондырды. Егет аһ итеп барып төште, өченче егет бу хәлне күреп торып чапты. Идрис машинага керде һәм:

— Киттек! — дип кычкырды.

Шофер елмаеп:

— Таза кундырасың... Нык өйрәттең, онытырлык итмәдең... Таза!.. Егет икәнсең,— диде.

Идриснең бөтен тәне калтырый, кул бармаклары авыртып сызлыйлар, шулай да йөзендә елмаю иде. Кафе каршысында Әхәт аларны көтеп тора иде, Идрис ишекне ачып аңа урын бирде.

— Рәхмәт сиңа, Идрис.

— Мондый очракта тизлек һәм кинәтлек факторы җиңә!

— Троллейбуста бер яшь кызга бәйләнәләр... Эчеп алганнар да сөйләгәннәрен эт җыймаслык! Бер әйттем, ике, туктадылар... Карасам, минем арттан төшкәннәр... Монда аулак, халык йөрми, чалып ектылар, искәрми калдым...

— Акылларына килерләр,— диде шофер.

— Йөрәгең җитеп чыктың бит,— диде Әхәт, сокланып.

— Минемме? — диде аңа борылып Идрис.— Күп нәрсәләргә җитәргә тиеш минем йөрәк... Юк, мин сине дә, үземне дә, башкаларны да хаксызга кимсетергә ирек бирмәм. Шуңа ышанасыңмы?

— Ышанам.

Алар Идрисләргә кайттылар. Бергәләп чәй кайнатып эчтеләр. Байтак утыргач кына, төн урталарында Әхәт Идрисләрдән кайтып китте.

* * *

Бер атнадан Дилә кайтты.

Үзен каршылаучы Идрис янында бәләкәй генә, житү чәчле юка малайны күреп яшь хатын бик нык гаҗәпләнде. Малай, бер дә ычкынырга җыенмаган кебек, Идриснең олы кулына чытырдап ябышкан иде.

— Бу кем? — дип сорады Дилә.

— Бумы? — Идрис җан җылысы белән малайның җилкә чокырын сөйде.— Бу безнең улыбыз Айдар.

Малайга бу сүзләр көлке булып тоелды, ул тирә-якны яңгыратып көмеш кыңгырау чыңлагандай көлеп җибәрде. Аннан олыларга күтәрелеп карады.

Идрис тә, Дилә дә көлмиләр иде, алар бер-берсенә сагынышып караганнар да сагаеп нидер тыңлыйлар...

1968—1969,
Казан — Мәскәү.

## Рәдиф Гатауллин

# ТӨРЛЕ ДӘФТӘРЛӘРДӘН

## Таулар

Борын-борынгыдан таулар биек,
үзән җирләр — түбән.
Таудан җиргә ташлар гына төшкән,
тауга — Кеше менгән.
Кыюлыкның, җитезлекнең башы —,
тауга баскан Кеше.
Хәзер — биегрәк аның юлы!
Таулар бик түбәндә калган
безнең көннәр өчен!

Ләкин таулар — һаман тау ул, уйда —
биеккә беренче чик.
Таулар —
мәңгелеккә символ, шигъри образ,
Кешенең
үткән юлына үзе салган
горур һәйкәле күк.

## Шагыйрь Зыя Ярмәки каберендә

Ир егеткәй белән, әй, ат башы
кайда булмас, кабере.. ак ташы?
Кайда кемнең икән минем өчен
Чәчәк булып сибелер пакъ яше.

Ярмәгендә түгел, чит җирләрдә
тәяк тапкан икән сөяген:
Мәргеланның[1] таш бер зиратында
йоклау язган икән, күрәсең...
Нинди җилләр исеп китергән дә
нинди җепләр монда тартканнар?

---

[1] Мәргелан Үзбәкстанда шәһәр.

Куплэр монда алар...
миллион бар —
(Ә үлгәннәр күпме?)
Урта Азиядә — татарлар.
Мәгърифәт һәм белем таратучы,
я кунагы илнең — миһманы;
килгән алар монда дус-тугандай,
бергә җиңгән яуда дошманны.
Бергә яшәү өчен калган күпләр
Нәвои һәм Хәмзә җирендә.
Шагыйрьне дә язмыш тарткан
монда,
шунда тапкан икән
каберен дә.
Үзбәк җиренең матурлыгына
табынып,
Сөенеп көлә иде күңелем;
очраттым да сине монда килеп,
моңга талдым әле мин бүген.
Туган җирләр сагындырды кинәт —
юксындыргандыр бит сине дә —
шул Ярмәкнең тыныч таңнары?
Анда һаман синең каенның шаулый,
«гөрләп тора һәркөн тау яны».

## Дагстан кызы Айшәткә

Сездә кызык кызлар исеме!
Патимат ул, я Аминат.
(Бездә Фатыйма, Әминә!)
Синең исемең икән — Айшәт.
— Гайшә! дияр иде бездә
сиңа Гали янсә Әхмәт.
Матур исем! Исемеңә
җисемең килә синең, Айшәт.
Чая кыз син, горурсың син
Кавказ тауларында яшәп.
Биектән бер кара әле,
нел әле миңа, Айшәт?
Илкәеңнең тарихы бар,
яулар үткән күкрәп-яшьнәп;
легендар ир Шамилнең бер
оныгымы син әллә, Айшәт?!
Гунибта мин күрдем сине,
җыр тыңладым. Тавышың —
ай, шәп!
Бәхет турындадыр җырың,
бик бәхетле идең, Айшәт!
Мин — шат. Дагстанга килеп,
очратуга сине, Айшәт.
Үзеңне алып киталмадем,
сәламнәрең житкерермен
инде туган илемә, Айшәт.

## Күңел—Гулливер

Нигә килгән монда?
Нәрсә эзли —
монда — бакча, монда —
гөл иле,
чәчәкләрне сыйпап, уйланырга
тукталганмы юлчы Гулливер!
Лилипутлар, я алыплар түгел,
үз калыбы аның — илендә,
ә ул һаман яңа ярлар күзли,
маҗаралар — армас күңелендә.

Бер ишетүе — бер гомерлек җырлар
яңгырармы чит, ят җирләрдә? —
Бәхетстаннарда яшәсәң дә,
күңел бәхете җитми ирләргә.
... Чынлык белән болай дус шикелле,
киләчәккә күзләр төбәлгән,
Дон-Кихоттай,
рыцарь заманнарын
тик романнар укып өйрәнгән,—
нәрсә эзләп икән —
вакыт-вакыт
чыга юлга Кеше күңеле?
Тормыш белән күбрәк танышканда
арый хыял,
әмма җиңелми.
Упкын кебек уйлар,
күңел тирән,
нәрсә аңа тамган яшьләрең.
Барысы да — кыйммәтлеме, юкмы,
җыйган, чәчкән күңел ташларын.
Шулар белән һаман уйный,
армый,
сөюе, көюе,
ташлар — һәммәсе:
тын яшәргә, эзләнмичә генә
мүкле таш түгел баш — янәсе;
Шулай — Кеше. Шулай яши матур
Поэзия җире, гөл иле.
Чәчәкләрне сөеп, серен сөйли,
мәңгелеккә бара Гулливер,—
ирләр күңеле.

●

Бер йотым су!..
Бер тамчы су! —
Булды — аның яңгыр булып,
иренемә тигән чагы,
булды — хыял сурәтендә
аңа диңгез сыйган чагы.
Бер йотым су! —
кыйммәт ләкин
сусаганда,
тиңсез дару,
ком чүлендә янып,
телең кипсә,
кемдер бирсә,
«соң чиккә» — дип үзенә
калдырганны —
тик бер тамчы...

Бер йотым су! —
Үлем белән тартышып та,
ялгышып та,
саташып та,
шул тамчыны —
йотым суны —

мине үзенә бурычлы итәр,
аннан
хурлык юлына сөйрәр
дошман кулдан алмасамчы!
Шундый хәлгә калмасамчы!

## Китмә

Олылар
йортта, я бакчада
яшь баланы калдырганда
аны —
алма, я уенчык биреп,
юатырга итә.
Күз яше аша әйтә бала.
— Әйдә, бергә-бергә уйныйк,
алманы да бүлик,
кал тик. Китмә?
... Бүлмә, бакча түгел,
бу дөньяның үзен
бер калдырасы бар.

Бәлки кемне дә булса
баладай —
ялындырасы бар.
Хәтта
әйтер кебек берәү:
— Дөньяны иркен
калдырамсың? —
рәхмәт!
Исәннәрне бәхетле иту уең? —
әмма алай итмә:
Берәү кимсә дә, тулы булмас
кебек дөнья,
кал мәңгегә. Китмә!

## Йолдыз җиле

Мин — Марстан. Юк, йолдыздан түгел,
Җирдәге бер матур авылдан.
Әмма миңа бераз йолдыз җиле,
йолдыз җене диләр кагылган...
Мин — Марстан, тик марсиян түгел,
мин — Җирский:
тузан бер, бала.
Күкләр күптән ачылса да күзгә,
әлегә китә алмам: җир кала.
Җир кызлары кала. Сөюем монда,
монда — җирдәй җылы күңелем.
Йолдыз гөлләренең яме күптер,
тансык һаман монда кыр гөле.
Җирнең —
һәр куагы, кошы, кешеләре,
эчкән суым, һава, икмәгем —
беләм, ныграк яраттырыр өчен
мине
күк юлына илче иткәнен.
Ерак планеталар чакырганга
күптән җырда йолдыз кабынган;
юкса, шагыйрьдә әлегә — җир паспорты,
мин дә Марс дигән авылдан.
Йолдыз җене... шунда кагылган.

## Һейне—тауларда

*Мин тауларга китәм...*
*Һ. Һейне.*

Туйдырдылар вак җанлылар аны,
ачу итеп менә аларга —
утлар-гамьнәр янган зур йөрәген
ул күтәрде биек тауларга.
Ә тауларда тын, мәһабәт дөнья,
тик болытлар яннан агыла —
әрсез түгел алар, кагылмыйлар
фамильярлык белән җанына.
Таратмыйлар — эч серенне урлап,
тема итеп дошман телләргә,
түбәнлекләр — түбәндәдер, монда
чишмәләр — саф, уйчан — җилләр дә.
Оныттырыр таза тау һавасы
«дус» буләген — яла ярасын;
Оныттырыр — кыен җырны бәлки,
хәтта усал ярның карашын...
О, кешеләр, сездән бизмәде ул,
нәфрәте тик — түбән җаннарга.
Сезне көтә, чакыра биеклеккә,
тик горурлар,
тик бөркетләр иле — тауларда.

## Ялгышлар

Мин ялгыштым... Һаман ялгыштым.
Әллә шулай иде язмышым? —
Тууымны ук ялгыш булды дисәм,
Гөнаһ... Әмма бик күп ялгышым...
Булды
яшь чакларда бакчалардан
балак бәйләп, кыяр чәлмешем.
Әнкәй тиргәп күпме акыл бирде,
шул акылны алмый ялгыштым:
сабагыма күнел бирми йөрдем,
күп гыйлемнән надан калмышым...
Хәзер —
бәлки, тоткан юлым үзе ялгыш:
шигырь дигән чиргә сабыштым.
Ялгыштым —
күбрәк сөйләп,
дөнья белми,
илләр гизми,
яисә
космонавт булмый ялгыштым.
Бүген
дуслар минем ялгышларны
кабатламас диеп, ялгыштым:
берәүләр абынып,
берәүләр — ялгышларсыз
яшәмәкче булып ялгышты.

Инде — мин аларның
ялгышларын
күрсәтергә теләп,
янсә соңлап күреп ялгышам...
Сүнгән учак тергезеп,
кайчак салкын суга өреп,
кайчак утка төкереп ялгышам.
Күккә, Айга өреп ялгышам...
Кеше, ахры,
хали түгел — хата-ялгыштан.
Бәлки хәзер
ялгышларым язып ялгышам?.

## «Бишташ» уены

Син дә, мин дә — бала,
Сабый әле, бик яшь...
Уен гына уйда,
Уен исме — «бишташ».
Әй чөелә ташлар!
Әй иелә башлар.
Кызык шундый уен,
Аерылуы кыен!
Җитезлегең сыный
Шомарган ак ташлар,
Менә яшьтәш арыр,
Ташы төшә башлар.
Биш ташың — биш якка!
Җыйсын тик биш бармак...
... Ә күңел уенда
Остармак, шомармак.
Син дә, мин дә — үскән,
Күңел — һаман бик яшь.
Югыйсә, каян ул
Уенда — уен... таш.
Әй чөелә ташлар,
Иелә чал башлар.
Безгә түгел дә уен,
Аерылуы кыен.
Күңелдә, күңелдә
Ташларның барысы...
Һәммәсе — тормыштан
Үзебез җыйнаган
Тәҗрибә, ахрысы!
Килегез, күрегез,
Ташларым,
дус-иптәш!
Сезгә соң — таньшмы
Тәҗрибә ташлары? —
Биш түгел, бик күп таш.

О, Сальери түгел элеккечә!
Ул бөтенләй башка...
Баксаң да —
танымассың...
(Вакыт-чорга китереп
модный костюм кия шайтан да.)
Ул бөтенләй башка: шат чырае,
сүзе, үзен тотышы, адымы.
Халык, хаклык исеменнән сөйли,
булу мөмкин аның... ордены.
Сәнгатьне ул җаны күреп яклар,
яңалыкны мактар,—
чаралары булыр яшеренрәк...
Агу бирмәс, дару бирер сиңа,
дусың булып, әләк әзерләр.
Максат, Моцарт өчен генә түгел,
мәнсап өчен —
җанны сату күптән чүп нәрсә!
Әле шайтан үзе шикләнмичә
бизнесына якын җибәрсә...
Төгәл, шома, нәзакәтле, көяз,
эчеп, йөреп — чыкмас исеме;
Картлар сүзен тота, яшьләргә — дус,
карьерага — дошман...
кем яратмас шундый кешене?!
Һәм кем таныр? Аерым сыйфаты юк,
билгесе юк... чиста, саф йөри.
Хәтта һәркем аны Моцарт дип эндәшә,
бик үзгәргән шайтан — Сальери!

## Гәрәй Рәхим

### Туган як имәннәренә

Ә бит алар һаман мине көткән,
Иңнәренә көзне ябынып.
Сагынуларын сары яфрак иткән
Имәннәргә йөрим табынып.
Берәм-берәм башым иеп узам:
— Исән-саумы, әй, имән агай,
Таныйсызмы, мин бит сезнең белән
Бергә балигъ булган җор малай.
Сезнең хәлне белер өчен монда
Минем яшьтәшләрем кайтамы?
Тазамы сез, әле тамырларда
Йөз яшәрлек тагын хут бармы?
Һаман әле безнең керәшеннәр
Балта тотып килгәч бирегә:
— Ай-һай шәп үсәләр, кызганыч,— дип,
Кисми китәләрме кирегә.
Ә көегез һаман шул ук икән —
Гуелдисез горур, ирләрчә.
Кайсы гасырларга барасыз сез
«Кара урман» дигән көйләрдә?!
Мин бит сезне бик сагынып кайттым.
Мин ич шушы җирнең баласы.
Имәннәрем, сезнең яшәештән
Килә минем өлге аласым.

### Тегермән

Болын уртасында утырып калган
Карачкыдай иске тегермән.
Әйтерсең, ул ачы каргышларны,
Аһ-зарларны тыңлап тилергән.
Болын уртасында утырып калган
Инеш күптән акмый бу ярдан —
Каргышларны ташлап качкан инеш
Һәм үзенә яңа юл ярган.

Тегермәнче Сандыр дәдәй монда
Күпме аһ-зар, каргыш ишеткән.
Он тартырга килгән авылдашлар
Килеп керү белән ишектән

Зарланганнар еллар ябыклыктан,
Аһ, язмыштан юк, дип, узмышың,
Шул тегермән таш тешләре белән
Чәйни диеп безнең язмышны
(Ягъни, өч-дүрт соскы арышны).

Дөрес, авылдашлар аңлаганнар
Гаеплеләр монда бүтәннәр.
Алпавытка теш үтмәгәч кенә
Тегермәнне тотып сүккәннәр.
Эләккәндер Сандыр дәдәйгә дә,
Тик мескен карт каршы дәшмәгән.
Тегермәне кебек сабыр гына
Эшләгән ул, шулай яшәгән.

Аннан инде еллар үзгәргәннәр.
Халык ирек алган, җир алган.
Олау-олау икмәк төяп килгән
Мөшкә тутырып бодаен салган.
Ә тегермән һаман элеккечә
Үз көенә генә әйләнгән.
«Тизрәк чәйнә, патша калдыгы!» — дип
Халык тагын аңа бәйләнгән.
Сүккән халык Сандыр дәдәйне дә:
«Чарыгыңа пычак кергере,
Җәтрәк бөтер әле ташларыңны,
Тегермәнең янып киткере!»

Дөрес, авылдашлар аңлаганнар,
Гаеп юк Сандырда һич кенә,—
«Совет бодайларын тарту өчен
Бу тегермән артык кечкенә».

Аннан соң да байтак каргыш күргән
Байтак зар ишеткән тегермән.
Сугыш елларында таш тешләре
Бер уч бодай күрми тилмергән.
Авыл халкы тагын бар ачуын
Иске тегермәнгә селтәгән:
«Дуслар каны кебек кадерле он,
Тик бик аз он ага мөшкәдән.»

Авылдашлар яхшы аңлаганнар
Бу кытлыкның нидән икәнен —
Сугыш тегермәне белән алар
Он иткәннәр Гитлер дигәнен.
Аннан соң да әле авыр булган,
Ул елларны ничек оныгасы.
Тегермәндә бодай оны түгел,
Очмагандыр хәтта онтасы.

Шуннан инде халык тәмам кызган,
Бөтен авыл белән кузгалып —
Электрлап, мәңге тукталмаслык
Зур тегермән салган шул халык.

Сандыр дәдәй күптән дөнья куйды
(Котылгандыр, диләр, тиргәүдән).
Болын уртасында басып тора
Карачкыдай иске тегермән.

Болын уртасында басып тора,
Инеш күптән акмый бу ярдан.
Каргышларны ташлап качкан инеш
Һәм үзенә яңа юл ярган.

## Шобагалар

Сөю бакчасында йөргән чакта
Бер-беребезне артык яратып —
Кем күбрәк сөя икән диеп,
Без шобага тотып карадык.
Шобагалар белән үлчәдек без
Кемгә күпме бәхет тиясен.
Белгәнбездер, ахры, кайгыларның
Безгә болай да күп киләсен...
Шобагалар тотып үлчәдек без...
Һәм кайгырдык күреп еш кына
Берәүләрнең мәхәббәтне ташлап
Китүләрен нәфрәт йортына.
Алар сөю шатлыкларын түгел,
Дөнья малын бүлеп арыйлар.
Ызгышалар, тәмам аптырагач
Шобагалар тотып карыйлар.
Шобагага салына туй күлмәге,
Ишек алды, кош-корт, бүлмәләр,
Җирне, чәчәкләрне, хәтта кайчак
Сабыйларны шулай бүләләр.
Дөнья җаен, бәхет, мал-мөлкәтне
Җыйсалар да тотып шобага,
Кайгыларны шобагасыз гына
Калдыралар безгә, дөньяга.

Шобагалар тотып сыныйбыз без
Кемгә күпме бәхет тиясен.
Беләбез шул, безгә кайгыларның
Шобагасыз гына киләсен.

●

Күзләреңне кара димәдем,
Битләреңне алма димәдем,
Иреннәрең чия димәдем —
Мин, ахрысы, бер дә кешегә
Охшаш итеп сөя белмәдем.
Мин башкача сөйдем, ахрысы,
Үзем генә сөя белгәнчә.
Җирдә әле башка беркем дә
Сөя белмәгәнчә — бүтәнчә.
Мин үкенмим ләкин хәзер дә,
Сөю кануннарын эзләмим.
Мин сөям ич сине үземчә —
Күзләреңне кара димичә,
Битләреңне алма димичә,
Иреннәрең чия димичә
Сөям сине нәкъ син көенчә.

**Николай Хайтов**

# ХИКМӘТЛЕ ХИКӘЯЛӘР

*Николай Хайтов — Болгария Халык Республикасының күренекле язучысы, бик күп хикәяләр һәм очерклар, пьесалар авторы.*

*Татар укучылары Николай Хайтов иҗаты белән беренче мәртәбә танышалар. Аның укучыларыбызга тәкъдим ителә торган «Туй» һәм «Дәрвишевлар орлыгы» исемле хикәяләре «Иностранная литература» журналының 1969 елгы 2 саныннан алынды.*

## ТУЙ



Берәр кешенең «Имән гөмбәсе» дигән кушаматымны әйткәнен ишетсәм, йөрәгемә пычак кадалган кебек була, югыйсә бу кушаматның таралуына бары үзем генә сәбәпче бит, башкаларның берниндн дә гаебе юк.

Ә барысы да шул бер кыз аркасында килеп чыкты. Хәтте исемле кыз иде ул. Нәкъ безнең пучинкә каршысында ук биек, калку җир бар, ул җир кызның әтисе Җирән Сөләйманныкы иде. Шул калкулыкка аның сөрү җирләре, көтүлекләре, сарык абзарлары һәм башка каралты-курасы урнашкан. Элекке заманнарда безнең Лыкавицада тәртип шундый иде: һәр кешенең үз калкулыгы бар, һәм шунда ул үзалдына яши бирә. Җомга һәм бәйрәм көннәрдә генә, намаз укырга дип, картлар авылга мәчеткә төшеп менәләр, калган вакыт һәркем үз тавында көн итә. Шунда алар дөньяга киләләр, шунда өйләнәләр һәм шунда бала тудыралар — һәммә эш шунда эшләнә.

Белмим, бала табуы ничек булгандыр, әмма өйләнүе кыен эш иде. Әйтик, синең берәр чибәргә күзең төште ди, сиңа инде йорт яки ишек алды тирәсендә генә түгел, тау хәтле тау тирәсендә бөтерелергә туры килә. Ә тау дигәнем — үзе бер крепость ул, аннан да яманрак хәтта.

һәркемнең мылтыгы бар, бүредән дә усалрак ун-унбиш эте бар; чебенең дә очып керә алмас, кыз янына якын бару турында инде сөйләп тә торасы юк. Чибәреңне бер күрер өчен генә дә атналар буе сагалап-каравыллап йөрергә кирәк, анда да әле кызның үзенә юлыгасыңмы, этисенәме — ансын ходай белә.

Ә минем Хәттемнең этисе үтә холыксыз бер адәм иде. Ул жирән айгырга атланып йөри, «Жирән» дигән кушаматы да шуннан таралган. Айгырының ияр өзәнгеләре бакыр, авызлыгы чын сәдәф кабырчык белән капланган, нуктасына калай тәңкәләр тезелгән. Сөләйманның үз киеме дә гел укалап чиккән, сүтеп, сузып карасаң, тауны ике мәртәбә әйләндереп чыгарга житәрдер шәт. Йөзе — һәрвакыт чытык, караңгы чырай белән йөрер. Аз сүзле кырыс кеше — бер сүзе бер алтын бәһасе. Аның каравы кызы Хәтте бөтенләй икенче, ул жырлап жибәрсә — бөтен табигатең, барлык жан ияләре тынып кала.

Кереп урнашты бит тавышы минем йөрәгемә, әһә, мин әйтәм, өлешемә тигән көмешем шушы икән! Тик моны кызның үзенә ничек белгертергә? Бәйрәмнәргә йөри торган кыз булса, эш жиңелрәк булыр иде дә, этисе аны беркая да жибәрми шул. Тотындым мин болар тирәсендә уралырга. Әлеге калкулык балдан болайрак тарта башлады бит мине, ник дисәң, кайвакытларны Хәтте шунда кәжәләрен көтәргә чыга иде. Ә мин — ярның икенче ягында басып торам, әле зур-зур ташларны аска тәгәрәтәм, әле агач сындырырга тотынам, яисә жырлап ук жибәрәм: бәлки, аңлар, гашыйк булуымны сизәр, мин әйтәм.

Хәтте, башыннан яулыгын салып, миңа яулык болгаганчы бик күп таш тәгәрәтергә, бик күп агач сындырырга һәм байтак жырларга туры килде. Шул ук кичне мин Пәһлеван карчыгы янына йөгердем. Әллә нинди дарулар ясап, шуларны өй саен кереп сатып йөри торган бер карчык ул. Теләсә нинди йортка килеп керә, аны авылның һәр эте диярлек таный.

— Әби,— дим мин моңа,— Сөләйман Хәттесенә әйт әле: бер чибәр егетнең йөрәге яралы, дигән, аңарда шул яраны төзәтә торган дару юк микән? Әгәр шундый дару алып кайта алсаң, сиңа йон мана торган ал буяу алып бирермен,— димен.

Пәһлеван карчыгы тәжрибәле әби иде, миңа нинди зәхмәт жиле кагылганын бик тиз сизенде, һәм икенче көнне, йокысыннан тору белән үк, минем Хәттем янына китте.

— Хәсән сиңа күп сәлам тапшырырга кушты, сиңа аның күңеле төшкин, сине хатынлыкка алырга тели,— дигән.

— Ул да миңа ошый. Тик онытма: эти сизсә, жанымны алачак. Кешегә ишетелә күрмәсен,— дигән Хәтте.

Пәһлеван карчыгы шушы хәбәрне алып кайткач, шатлыктан йөрәгем шартлар дәрәжәләргә житте, нигә, мин әйтәм, күк гөмбәзе кыңгырау түгел икән, шуның теленә үрелеп тотынып идем дә сөйгән ярымның исеме бөтен тауларга, кырларга яңгырарлык итеп кагар идем. Нишлисең, күк гөмбәзе кыңгырау түгел шул, мин үземнең кечкенә кыңгырауларымны кәжәләрем муенына тактым да, аларны Усое аша утлауга куып киттем. Тау башында Хәттенең яулыгы күренгәнче куып йөрттем бичара малларны. Бу — безнең беренче очрашуыбыз иде. Икенче, өченче очрашу булганчы инде үләннәр көеп корды, агач яфраклары саргайды, тау өсләре, яшеллеген жуеп, чуар төскә керде — көз житте. Игеннәрне жыеп алып суктылар, туй ясый һәм кыз ярәшә торган вакытлар якынлашып килә иде. Күктән мине нинди кояш яктыртканын эти дә, әни дә сизәләр, билгеле, тик белмәмешкә салышалар. Шулай да эти бер тапкыр әйтеп куйды:

— Син, улым, кыңгырауларыңны алай бик шалтыратма, анда әнә син йөри торган болынга икенче берәү сукмак салып ята! — диде.

Яшен суккандай итте мине аның бу сүзләре, шулай да кайтарып сорарга кыймадым. Пәһлеван карчыгын Хәтте янына йөгерттем. Аннан ул, шифалы дару урынына, агу алып кайтты.

— Минем таякка бәйләнгән яулыгымны күргәч, мылтык белән ханҗар алып, Хәсән мине чокырда көтеп торсын,— дигән Хәтте.

Бүтән бер сүз әйтмәгән.

Ә кич җиткәч, бөтенесе ачыкланды. Бер заман Баклар мәхәлләсенең барабанчылары Лыкавицага юнәлделәр. Аларны Дәли Мәхмүт чакырган. Иртәгә Җирән Сөләйманда барабан кагабыз, дип мактандылар. Димәк, Дәли Мәхмүт үзенең малае Брахомны Сөләйман кызы Хәттегә өйләндермәкче.

Бу хәбәр тамак төбемә сөяк булып утырды: тынсыз-өнсез калдым. Башка берәү булса, нидер эшләр идең: я алачыгына, я өенә ут төртер, берәр ничек курку салыр идең, әмма Дәли Мәхмүт бит ул! Бозык башларны Батакка кеше суярга һәм таларга ияртеп йөргән кеше. Бу канечкеч байның теләсә кемне куркытырлык һәм тез чүктерерлек кодрәте бар. Инде Сөләйман шундый кешегә үзенең Хәттесен бирергә ышандырган икән — аның кулыннан кызны бер алла гына тартып алса алыр.

Шулай да караңгы күктә миңа карап җемелдәрлек бер йолдыз калган икән әле калуын. Хәтте миңа чокырда көтеп торырга кушкан бит. Әмма, дөресен әйтим, ул миңа берәр төрле ишарә ясар, үзе әйткән чокырга килер дип ышанып та бетмим.

Иртәгесен көн кичкә авышкач, ике көпшәле мылтыгымны алып, Сөләйман калкулыгы каршындагы Бөркет кыясына мендем. Бервакыт тыңлыйм: «Бам-бара-бан, бам-бара-бан» дип барабан сугарга тотындылар, Лыкавицадан Сөләйман утарларына таба, чуар бер төркем булып, туйга килүчеләр күтәрелә башлады. Төркем күтәрелә барган саен, барабаннар тагы да катырак дөберди, минем чигә тамырларым шулхәтле шаулый: менә-менә шартлап китәрләр кебек. Әнә, кунакларны каршылар өчен, Сөләйман атына менде, капкадан чыгып, пистолеттан атып җибәрде. Астагылар унлап мылтыктан гөрселдәтеп җавап кайтардылар, бөтен таулар дары төтене һәм сөрем эчендә калды. Төтен таралгач карыйм: гадәттә Хәтте чыгып утыра торган зур ташка бер таяк сөялгән, таяк башына ак яулык бәйләнгән. Димәк, хода-тәгалә мине дә рәхмәтеннән ташлап бетермәгән икән әле! Туйга чакырылган кешеләр аларга килеп җиткәнче, Хәтте минем янга йөгерер дип уйлаган идем, әмма ул зирәгрәк булып чыкты: яктыда юлга чыкса, Дәли Мәхмүт кешеләре аны куып җитеп, тотып алырга мөмкин, кыз көтәргә карар иткән. Караңгылана төшсен, кунаклар ныграк исерешсен, менә шунда качарга да булыр, дигән.

Нәкъ шулай итә дә. Туйга чакырылган кешеләр килеп бетә. Ашарга, эчәргә тотыналар, төн уртасына кадәр музыка уйныйлар, җырлыйлар. Шул чак Хәтте әнисенә:

— Син инде, әни, арып беткәнсеңдер, кая, бозауларга печәнне үзем илтим әле,— ди.

Капчык белән печәнне күтәрә дә чыгып китә. Капкадан чыгу белән юк та була. Артыннан абыйсы Рәсимне җибәреп карыйлар, ләкин ул печәнле капчыкны гына табып керә. Һушыннан язып, әнисе гөрселдәп идәнгә ава, Сөләйман әллә нинди бер ерткычка әйләнә, кунакларның ачуы кабара. Билләренә пычак һәм пистолетлар тыгып, аркаларына мылтыклар асып, барысы да ат менеп куа чыгалар.

Мин исә әле һаман чокыр төбендә кызны көтеп утырам. Аның аяк тавышын өч йөз метрдан сизеп алдым. Килеп тә житте:

— Кая теләсәң, шунда алып кит,— диде.

Кулыннан җитәкләдем дә алып киттем. Әмма, югарыракка, тауларга менеп, берәр тау тишегендә атна-ун көн көтәсе һәм тавыш-гауга ба-

сылгач кына әйләнеп кайтасы урында, мин, ахмак нәрсә, Крушовка илтә торган сукмак буйлап киттем! Үзебезнең пүчинкәгә!

Без өйгә якынлашканда, яктыра башлады. Шунда гына мин Хәттене беренче тапкыр якыннан күрдем: тип-тигез, ап-ак тешләр, тулып, пешеп җиткән бөрлегәндәй алсу иреннәр — мин аларга орынырга да кыймадым... «Вакыты килер, орынырмын», дип уйладым ул чагында, ә вакыт дигәнебез санаулы минутлар гына иде.

Яктырып җиткәндә, өйгә кайтып кердек. Бөтен күрше-күлән җыелды — безнең Крушовка шундый чибәр килен килгәнгә туганнар да, чит-ят кешеләр дә бик шатланышты.

— Берегез тизрәк мулланы чакырырга йөгерегез, аларга никах укырга кирәк, юкса, теге бәдбәхетләр килеп тә җитәрләр,— диде эти.

Кыз эзләүчеләр исә каңгырып йөриләр-йөриләр дә, таң атканда аптырашып, Сөләйман йортына кайталар, кая китәр бу кыз — җир йоттымы, әллә җәһәннәмгә олактымы? диләр. Ахырдан, күршеләрдән сорашып карарга кирәк, дигән фикергә киләләр. Шуннан соң инде Сөләйманның кычкырганы ишетелде:

— О-һо-һо-о-о! Крушовлар! Ишетәсезме? Безнең кыз сездә түгелме? — диде.

— Нишләп бездә булмасын? Тик сезнеке түгел, б е з н е к е инде ул хәзер! Бик беләсегез килсә, б е з н е к е булды! — дип җавап кайтарды эти.

Аның «безнеке булды» дигән сүзен ишетүгә, тегеләр бер мәлгә тынып калдылар, аннары шундый зур гауга куптардылар, әйтерсең, өч йөз бүре берьюлы уларга тотынды. Һәм шул минутта ук Дәли Мәхмүт атлылары Сөләйман таулыгыннан туп-туры безнең пүчинкәгә таба ыргылдылар.

Нишләргә хәзер? Туйның нәкъ кызган чагы, ә мулла һаман юк та юк. Кунакларыбыз — туганнан туган абыйлар, апалар, абзыйлар һәм башкалар — әүвәл гайрәт орган, кычкырынган булганнар иде, Дәли Мәхмүт башкисәрләре якынлаша башлагач, кикрәкләре шиңде, шыпырт кына кайсы кая качып та бетте.

Ә теге башкисәрләр томырылып киләләр! Авызларында — хәнҗәр, кулларында — мылтык, җан-фәрманга киләләр! Минем тирәдә кемнәрдер калган әле.

— Болар безне таптап-изеп бетерәчәк, Хәсән. Әле соң түгел, качарга кирәк,— диләр.

Эти дә:

— Сине яклый алмыйм! Нибары ике патроным бар, ә ул бандитларның букчалары тулы,— ди.

Тегеләр инде килеп тә җитте, әнә дагалары чак-чок ташка бәрелә. Мылтык аткан тавышлар яңгырады, һәм Дәли Мәхмүт:

— Бөтенесен ут төртеп яндырырга, аналарын...— дип акырып-сүгенеп җибәрде.

Карыйм: янымда беркем калмаган! Арт капканы төртеп кенә ачтым да тау буйлап өскә сыпырттым. Таунын нәкъ түбәсенә җитеп әйләнеп карасам, янымда Хәтте юк, аста калган. Ишек алдына Дәли Мәхмүт кешеләре килеп тулган, түбәнгә төшәргә йөрәк җитмәде...

— Син ниеңне югалттың монда, сөйрәлчек? — дип җикеренде кызына Сөләйман.

— Югалтканымны таптым инде, эти,— диде Хәтте.

Әтисе ишек алды уртасында басып тора, кызы аңа тәрәзә аша җавап кайтара.

— Чык монда, тиз бул!

— Юк, эти, исән килеш мин моннан китмәячәкмен.
— Кем белән качтың? — дип сорый Дәли Мәхмүт.
— Минем белән, Мәхмүт ага,— дип җавап кайтара калын гына тавышлы бер ир һәм шул вакыт тәрәзә каршында торган Хәтте янына, беләсезме, кем килеп баса? — этинең энесе, Сәлим абый.

Ул үзе буйдак бер ир иде, аның берәр вакыт берәр кызга яучы җибәргәне дә булмады, чөнки Сәлим абыйның уң кулы гарип, шуңа күрә сөрә дә, җир дә казый алмый иде. Гел өйдә утыра, безнекен ашый, балаларга ук, җәя, төрле уенчыклар ясап бирә, җәен кукуруз җирләрен бурсыклардан саклый. Аның бөтен битен шадра каплаган, тешләре көрәк кадәр, шул кеше мондый эшкә сәләтле булыр дип кем уйлаган? Бактың исә, сәләтле икән!

Мин алып киттем аны, Мәхмүт ага! — дип кабатлады Сәлим һәм сул кулына тоткан наганын — барабанлы наган — алга сузды. Аннары болай дип кычкырды: — Дәли Мәхмүт! Минем бер револьверым һәм нибары бер пулям бар! Әгәр арагызда Хәттене миннән артыграк яратучы берәр кеше бар икән — алга чыксын! Атышабыз, кем исән кала, шул Хәттегә өйләнә,— диде.

Дәли Мәхмүт егетләре шаулаша башладылар, ләкин ул аларны шунда ук туктатты:
— Башлап кем ата? — дип сорады Дәли Мәхмүт.
— Барыбер, телисез икән, сезнең як атсын,— диде Сәлим абый.
— Брахом! Дөмектер тизрәк бу мактанчыкны, өйгә кайтырга вакыт,— дип кычкырды Мәхмүт улына.

Һәммәсе артка чигенде. Ишек алды уртасында Брахом гына торып калды. Ул игътибар белән мылтыгын күздән кичерде, аннары, күз турына күтәреп, төзи башлады. Озак төзәде. Яңадан мылтыгын аска төшерде, яңадан төзи башлады, ә Сәлим абый, тәрәзә яңагына таянган да көлемсерәп тик басып тора, үзе туп-туры тегеңә төбәлгән:
— Төзә, төзә, Дәли Мәхмүт Брахомы, әгәр исән калдырсаң — мин синең анаңнан әчкән сөтеңне костырам! — дип сөйләнә.

Болай ул кычкырып әйтмәде, әмма тирә-як шундый тын — аның һәр сүзе ишетелерлек иде. Ул акрын гына әйтсә дә, бу сүзләрдән чәчең үрә торырлык иде...

Шул чак «гөрс!» итеп мылтык шартлады, ишек алдын төтен басты, төтен таралгач, карасам: Сәлим абый исән-сау басып тора.
Дәли Мәхмүт имгәге тиз генә атын борды да табан ялтыратты.
— Тукта, фәлән дә фәсмәтән! Тукта дилэр сиңа! — дип кычкырды этисе.

Ә Брахом качуын белә, артыннан, кәгазь елан шикелле, доламасы[1] гына җилфердәп бара. Дәли Мәхмүт атып җибәрде, малае алай да туктамады. Шуннан ул Сәлимгә таба борылды да әйтте:
— Минем имгәк мондый киленгә иш түгел, Сәлим ага! Сиңа бәхеткә булсын,— диде.

Шуннан соң атларын бордылар да китеп бардылар. Аннары качкан-поскан җирләреннән безнекеләр дә чыга башлады, мин дә өйгә кайттым. Сәлим белән Хәтте икәү янәшә утырганнар, бер-берсеннән күзләрен ала алмыйлар.

— Хәсән,— диде кыз, мине күргәч.— Мин сезнең йортта калам, тик синең белән түгел, Сәлим белән!
Мин Сәлим өстенә ташландым, бугазга-бугаз килеп сугыша да башлаган идек, ләкин эти килеп бик тиз аерды безне.
— Гаделлек буенча — килен Сәлимнеке. Әгәр ул булмаса, безнең йортта таш өстендә таш калмаган була иде,— диде.

[1] Долама — постаудан тегелгән ирләр киеме.

Шунда башкалар да сүзгә кушылды, алар да миңа каршы сөйләде... Шулай итеп, Хәтте Сәлимнең хатыны булып калды.

Ә аннары... Аннары нәрсә дим инде мин? Шушында туктау хәерлерәк булыр иде дә, син «Имән гөмбәсе» дигән кушамат каян килеп чыкты? дип сорадың бит әле. Шул чак, хурлыгымнан кая барырга белмичә, мин имәнлеккә качтым, тоташ берничә ай анда яшәдем, шуннан бирле инде мине «Имән гөмбәсе» дип йөртәләр.

Киек җәнлек кебек, япа-ялгызым өнемә кереп бикләндем! Кая гына борылмыйм, кая гына карамыйм — һәммә җирдән күзләремә башка бер Хәсән карап тора сыман: «Нигә качтың? Нигә?» — дия сыман. Күзләремне алып, икенче якка карасам, анда Хәтте: «Их, син! Куян йөрәк!» — дия кебек. Тыштаниләр барын күрмәс өчен, чытырдатып күзләремне йомам, берни күрмим, ә эчтәгесеннән, күңел күзләреннән, күз йомып кына котылып булмый, яңадан бөтенесе — Хәттенең ак яулыгы, кыз белән очрашуыбыз, туйга килүче кешеләр, җырлары — барысы, барысы күз алдына килә! Һәм аннары бер-берсен җитәкләшкән Сәлим белән Хәтте килеп баса!

Уң яктан сул ягыма әйләнеп ятам, арка белән яткан җирдән йөзтүбән әйләнәм, ә күңел күзе һаман күрә, күңел колагы һаман ишетә. Шуннан баш вата башладым: озак газапланырмынмы болай, нигә икесен дә юк итмим, бәлки, бу газаплардан котылырмын, дим.

Хәттене ничек итеп үтерүем төшләремә үк керә башлады. Үзем уң кулым белән пистолет төзим, ә сул кулым аны иркәләп сөяргә сузыла. Йөрәкнең яртысы катып ташка әйләнде, ә калган яртысы гел йомшак. Күңелне суындыру өчен ниләр генә эшләмәдем: чи килеш төлке ите ашадым, бөркет тырнаклары пешереп карадым, кыргый мәченең сөтен эчтем! Ахыр чиктә төш керми башлады, һәм мин үз-үземә: «Вакыт җитте, Хәсән, бар, үтер аларны!» — дидем.

Өйгә әйләнеп кайттым, миннән беркем берни сорашмады. Үзем дә сөйләмәдем.

Тотындым пычак кайрарга... Үзем кайрыйм, үзем уйланам. «Кемгә кадалыр икән бу пычак: Сәлим аркасынамы, әллә Хәттенең сөттәй ак күкрәгенәме? дим. Ул бу якты дөньяда чакта тагын бер генә тапкыр карап калыйм, тагын бер генә тапкыр тавышын ишетим», дим. Тәрәзә каршына бастым да, Хәттенең зифа буен күреп бер сокланыйм дип, ишек алды буйлап суга киткәнен сагалап торам. Мин тәрәзә аша күзлим, ә Сәлим бусагага аркылы утырган да шуннан карап тора — ишектән чыгып капка төбендәге чишмәгә җиткәнче берәр яры югала күрмәсен дип курка, күрәсең. Күзләре зур булып ачылган, күзләре зәңгәр аның... Их, Сәлим... «Ярый, карасын, аз гына булса да карап калсын», дим.

Хәтте үз бүлмәләренә әйләнеп кайта да җырларга тотына. Өйдә беркем юк, һәммәсе кырда. Хатыны җырлый, ире дә кушыла. Хәтте үзе җырлый, үзе чырк-чырк көлә. Шулай көн-төн көлә ул, тик төннәрен көлүе башкачарак була, гүя аны кемдер кытыклый, гүя Сәлим аны сакаллары белән чәнчи. Чыркылдап көлеп кенә җибәрә, тегесе тыя, тагы көлеп кенә җибәрә, тегесе тагы тыя, таң атканчы шулай...

Алар үз бүлмәләрендә, мин үз бүлмәмдә булсам да, барыбер ишетелә. Ишетмәс өчен юрганымны баштан ук бөркәнеп карыйм, колакларны томалап карыйм, ә торып тышка чыгып китмим. Мин йокысыз калдым, ашаудан калдым, кибеп-саргаеп беттем, аякларымны көчкә сөйрим.

— Үләргә җыенсаң, бар, Хәсән, үзеңә кабер казып куй,— ди эти.— Әгәр инде яшәргә теләсәң, әнә суканы ал да кырга — җир сукаларга, ашлык чәчәргә бар! — ди.

Шул вакыт мин үз-үземә: «Иртәгә тегеләрне бетерәм, аннан ни булса, шул булыр!» — дип сүз бирдем.

Безнекеләр, яктыра башлауга, кырга китте. Хәтте су алырга дип ишек алдына чыкты. Сәлим бусагага утырып аны карап тора. Ә мин, хәнҗәремне тотып, арттан гына аңа якынлашам. Сәлим яланбаш, колак артына чәчәк кыстырган. Әллә эт үләне, әллә аксыргак, күз алларым томаланып китте — һич аера алмыйм. Ә аның колагы янында, нәкъ этинеке кебек, кукуруз бөртеге чаклы миңе бар икән. Ничектер шуңдый бер хәлдә калдым: гүя мин Сәлимне түгел, үз этиемне үтерергә җыенганмын. Кулымдагы хәнҗәрнең идәнгә төшеп киткәнен сизми дә калдым. Сәлим борылып миңа карады, хәнҗәрне алып кесәмә салды да:

— Хәсән акыллым, ана бөркетне үләксә белән түгел, ә тере ит белән кулга ияләштерәләр! Ычкын, ычкын моннан! — диде.

Киттем мин, башка әйләнеп кайтмадым. Төрле җирләрдә төпләнеп карадым, булмады, тагын киттем. Төркиягә барып чыктым, аннан кире кайттым, берничә тапкыр әйләнеп тә карадым, әмма Сәлимнең әлеге сүзләре һич күңелемнән китмәде: «Бөркетне үләксә белән кулга ияләштермиләр!» — диде ул.

Китүе кыен түгел икән, ә кайтуы... Бер киткән урыныңа гомер буе кайтсаң да, барыбер кайтып җитеп булмый икән...

**Ф. Мөхәммәтов** тәрҗемәсе.

# ДӘРВИШЕВЛАР ОРЛЫГЫ



Дөресен генә әйткәндә, бик күптән төйнәлгән төен инде бу, дустым. Ул чагында миңа әле ундүрт тә тулмаган, ә минем инде этием дә, әнием дә юк иде. Этиемне күрше сыеры сөзеп үтерде, әнием испанка авыруы белән авырып үлеп китте. Мин бабай белән әби тәрбиясендә үстем. Әбиемнең уң кулын паралич сугып, ул йорт эшләрен эшли алмас булгач, бабай мине өйләндерү турында уйлана башлады. Өйләнәсең киләме, юкмы? — дип минем үземнән сорамадылар. Ул заманда синең ризалыгыңны сорап тормыйлар, картлар үзләре генә хәл итәләр иде. Мин бары бер тапкыр гына әби белән бабайның икәү шул турыда сөйләшеп торганнарын ишетеп калдым.

Әби:

— Яшь бит әле! — дигәч, бабай кырт кисеп:

— Яшь булса, үсәр! Кыз күзле башларга кирәк! — диде.

Бабай кая барып ниләр күзләгәндер, аңсын әйтә алмыйм, тик бер тапкыр кәҗәләрне көтеп өйгә кайтып керсәм, безнең өйдә биленә зур кайчы кыстырган дәү генә бер абзый утырып тора иде.

— Рамаданчо, менә сиңа чалбар тектерергә тегүче чакырдым. Ниндине тектерик: сорынымы, әллә бүтән төсленеме? — диде бабай.

Шуннан бүтән берни әйтмәде, берни сорамады. Миңа кыз яучылап, туй ясап, башлы-күзле итеп тә, бөтен сорагаңнары бары шул бер тапкыр: «Ниндине тектерик: сорынымы, әллә бүтән төслеме?» — дигән сүз генә булды.

Тегүче безгә чәршәмбе көнне килгән иде, атна кичкә көрән төстәге, каптырмалы, укалы чалбарны тегеп тә китерде, ә җомга көнне инде безнең ишек алдына барабанчылар килеп, даул[1] кага башладылар. Дебер-шатыр китереп даул кагалар, казаннарда быгырдап ит пешә, ә үзем һаман әле кәләшемнең нинди кеше икәнен дә белмим.

Шунда мин, кыюлыгымны җыеп, әбидән сораган идем, әби:

— Күчкән авылдан булыр, үзебезнекеннән түгел! — диде.

Кем кызы, нинди нәрсә ул? Ансын әби миңа әйтмәде, үзем дә авыз ачып сорарга кыймадым.

Кем кызы, нинди нәрсәкәй икәнен кич җиткәч кенә белдем. Мулла никах укып, барабан кагылгач, безгә икебез генә калыр вакыт җитте. Кыз янына керер алдыннан бабай мине бер читкә чакырып алды да әйтте:

— Ничек итсәң дә ит, әмма иртәнгә каны булсын! Ир булгансың икән, ирләрчә эш ит! Юкса бөтен авылга хур булырбыз! — диде.

Шулай дип, мине бүлмәгә төртеп кертеп җибәрде дә шалтыратып бикләп тә куйды.

Мин, тел тибрәтеп эндәшергә дә, чаршауны ачып карарга да кыймыйча, ярты сәгать чамасы бүкән шикелле катып тик утырдым. Шуннан соң кәләшем чаршауны үзе ачты. Мин инде бабай миңа буй җиткән дәү бер кыз алып кайткандыр дип уйлаган идем, карасам, ни күрим: каршыма күбәләк шикелле генә бер кыз бала килеп чыкты: йөзе сөттәй ак, шундый-шундый керфекле күзләре. Моңа мин кыргый бер җәнлек баласы шикелле карап катканмын да калганмын, ә кыз миңа күзен сирпеп торды-торды да чыркылдап көлеп җибәрде.

— Оялясыңмы әллә? — ди бу.

— Оялам шул,— мин әйтәм.

— Нәрсәдән оялясың? Шундый киң балаклы матур чалбар кигәнсең. Әнә нинди билбау бугансың. Әйдә, бөтерчек уйныйбызмы? — ди.

Мин «ә» дип тә, «җә» дип тә әйтергә өлгермәдем, кыз мине билбавымнан эләктереп алды да бөтерчек кебек әйләндерә-әйләндерә, билбавымны сүтәргә дә керешә. Шулхәтле мавыгып уйнап киткәнбез без, беренче әтәчләр кычкырганны да ишетмәгәнбез.

Тик шул чакта гына мин, тегеләй кан исемә төшеп, борчыла башладым. «Менә хәзер яктырып җитәр дә кан турында сорарга килерләр. Нишләрмен?» — мин әйтәм. Кәләшем минем шулай борчуга сабышканымны сизде, ахры, ни уйлап бу кадәр кайгыга калдың? — дип сорады.

— Кан турында,— мин әйтәм.

— Мин аны хәзер булдырам! — ди бу. Битләре бузарынып кызарганчы бер көчәнде дә борыныннан кан килә башлады... Калганын сөйләп тормыйм инде,— үткән эшкә салават,— шуннан соң без Сильвина белән ирле-хатынлы булып тора башладык. Бер үк вакытта ул әле кыз бала да, өлгереп җиткән хатын-кыз да иде. Кызларда бала чакларыннан ук хатын-кызлык сыйфаты була бит. Керфекләрендәме, тырнак асларындамы шул сыйфат яшеренгән була, ә егетләр — башка. Кызлар битен кытыкларлык сакал-мыегы булмаган егет егет түгел ул. Йөрәгең хатын-кызга омтылса, башыңнан да, сакалыңнан да сорап тормый икән ул. Минем белән дә нәкъ шундый булды. Без Сильвина белән, уйный-көлә, бөтерчек булып бер бөтерелә, бер сүтелә торгач, минем йөрәк тә, билбавым кебек, кызга уралган һәм, шуны сүтәргә дип тарткач, йөрәгемне төбе-тамыры белән йолкып алдылар.

Турысын әйтим: бу хәлнең ничек булганын беребез дә сизмәдек. Безнең тормыш язгы ташу суы кебек шаулап-гөрләп ага башлады. Су

---

[1] Төрекләрдә зур барабан.

астында кыя ташлар булыр, көймәбез шуңа бәрелер дә челпәрәмә килеп ватылыр дип беребез дә башына китермәде. Сильвина күбрәк өйдә утыра, әбине карый, ботка пешереп куя, безне көтеп тора. Өй эчен җыештырып, идәннәрне себереп чыгаргач, безнең иске генә йортыбыз кояштай балкып, көлеп тора сыман. Матча булып матчалар да көлеп тора шикелле — Сильвина аларны төрле чәчәк, үлән сабаклары белән бизәгән, ә бүлмә тәрәзәсен инде ул көненә өчәр тапкыр юып сөртә. Һәм һәр иртәне тәрәзә пыяласына карап чәчен тарый. Аның чәчләре менә монда тикле, бер карасаң,— аксыл-сары, чак кына читебрәк карасаң — җемҗем итеп кызгылт-сары булып күренә, тагы да арырак китеп күз салсаң,— кызыл алтын төсенә кереп, өстендә елык-елык иткән нурлар уйный. Ул чәчен тарый башладымы, мин аның янына килеп, тик карап торам.

Шунда бабай:

— Әй, Рамаданчо, кәҗәләрең ачтан үлә бит! — дигәч кенә исемә килəм.

Мур гына кырсын инде ул кәҗәләрне! Җәйге кояш иренеп кенә төшлеккә менеп җитә дә шунда туктап оеп кала. Авылда минем яшь хатыным барлыгы аның исендә дә юк, күккә сикереп, аны таяк белән сугып төшерәсе иде дә бүтән бер дә чыкмаслык итеп җиргә күмеп куясы иде.

Гел төн генә булып торсын иде дә мин Сильвина янында гына ятсам иде, яисә аның керфекләренә өреп уйнасам иде. Безнең икебезнең үзара уен сымак бер шаяруыбыз бар иде: мин иртән, йокыдан уянгач, Сильвинаның керфеге керфеккә тигәнче сулыш өрә башлый идем. Мин аңа, бабай белән Филибегә[1] ярминкәгә баргач, керфегеңне тарарга сөяк тарак алып кайтырмын дип вәгъдә дә иткән идем. Тик вәгъдәм вәгъдә булып кына калды. Бер көнне без бабай белән болынга печән чабарга киттек, кич белән кайтып өйгә керсәк — минем яшь хатыным өйдә юк, өй эче буп-буш, караңгы иде. Сильвинаны абыйлары килеп алып китте, диде әби. Әби аны бирмәскә дә тырышкан, Сильвинаның абыйлары әбине читкә төртеп җибәргәннәр дә сеңелләрен алып киткәннәр, Сильвина бирнәсен алып китеп бетермәде әле, дигәннәр. Атларына атланганнар да, кеше-кара җыелганчы, тизрәк урманга чапканнар.

Үземнең нинди хәлгә төшкәнлегемне сөйләп бирә алмыйм инде. Бабай минем пычакка үрелгәнемне күрде дә, мине бөтереп алып, әбигә:

— Бау китер! — дип кычкырды.

Әби бау китереп биргәч бабай мине коймага бәйләп куйды һәм:

— Алай-болай качарга уйлама! Син миңа нәсел орлыгына кирәк. Иң әлек шушы өйдә Асан Дәрвишевнең оныгы чырылдап кычкырып ятсын, аннары теләсәң кая кит, теләсәң кем белән сугыш,— диде.

Шуннан соң атка атланды да әбигә:

— Бу Дәрвишевлар орлыгын ычкындырасы булма, юкса муеныңны барып ташлармын! — дип, атын чаптырып ишек алдыннан чыгып китте.

Бабайның холкын бик яхшы белә инде әби, шуңа күрә ул мине коймадан чишмәде.

Минем йөрәгемә берьюлы йөз сөлек ябышкан кебек булды, йөрәгем үлеп-түнеп калды. Сильвинаның абыйлары бәлки чыннан да шул бирнә аркасында килгәннәрдер. Алар аңа чит-ят кеше түгел бит, үз абыйлары! — дигән бер өмет кенә тилпенеп куйгалый иде күңелдә.

Иртә таң җитеп, бабай кайтып кергәнче мин шул өмет белән юанып яшәдем. Бабайның аты ап-ак күбеккә баткан, үзенең, куак араларында

[1] Пловдив.

сыдырылып йөри-йөри, өс-башы таланып-ертылып беткән иде. Ул минә ак бүлмәгә кертеп җибәреп, өстемнән бикләп алды да үзе әби белән икәү үз бүлмәләренә кереп бикләнде. Бу ике бүлмә арасы стена белән генә бүленгән, стенаның урта бер җирендә моржа салынган. Шул моржа кырыенда стена юкарак, күрше бүлмәдә ни сөйләшкәнне ишетерлек иде. Мин колагымны стенага куйдым да тыңлый башладым. Бабай каты кычкырып сөйләмәсә дә, мин аның сүзләрен ачык ишеттем.

— Безнең килен юк инде хәзер! Абыйлары, эт җаннар, аның кыз икәнең сизгәннәр. Ике кәҗә тәкәсе бәрабәренә Руфатка биргәннәр,— диде.

— Хәзер алар кайда соң? — дип сорады әби.

— Аның белән урманда качып йөриләр. Кайчан кайталар,— шайтан белгән. Кайтса да, карынында чит нәсел орлыгы булгач, миңа нигә кирәк ул? — диде бабай.

— Инде ни эш кылырга уйлыйсың? — дип сорады әбием.

— Ни эш кылыйм? Мин ул Руфатлар токымын ике көбәкле мылтыгым белән атып-кырып, бет урынына сытып-изеп бетерер идем. Кырып бетерәчәкмен мин аларны! Тик хәзер түгел. Менә Рамаданны өйләндерим, онытым тусын, аннары ул Руфатның әнисеннән кан-яшь түктерермен әле!

Бабайның шушы сүзләрен ишеткәч, мин мичкә тагы да сыена төшкәнмен һәм иртәнгә чаклы көл өстендә утырып чыкканмын! Иртән бабай мулла алып килеп, мине асылынып та, суга батып та үлмәскә... беркем белән талашмаска, сугышмаска... иң элек бабайга онык китерергә, аннары гына үч алырга дип ант иттерде.

Шуннан соң булганнары инде менә шушы йөрәк аша энә кебек кадалып узды! Беренче энә йөрәгемә Сильвина авылга кайткач кадалды. Руфат безнең күрше егете иде, ике ара койма белән генә бүленгән булса да, аларның кайчан ничек кайтып кергәнен беркем дә күрмәде. Сильвина бер ай буена күзгә-башка күренмәде, чөнки элеге Руфат хәшәрәт аның битләрен тешләп, чәйнәп бетергән, шунлыктан Сильвина кеше күзенә күренергә оялган. Соңыннан инде без ул хәлнең ничек булганын барысын ишетеп белдек.

Руфатның аңа беренче көнне безнең ишек алдында күргәч үк күнеле төшкән булган — ул аны күзләр өчен коймага тишек тә тишкән. Руфат миннән җиде яшькә олырак, гаҗәп ялкау бер егет иде. Утын җыярга да, кырга да бармый, әтисенә терлек суйганда гына булыша. Аракы эчеп ала да масаеп, сугышып йөри иде.

Руфатларның дәү сакаллы ике кәҗә тәкәләре бар иде. Аларның муенына зур гына кыңгырау тагылган, шул кыңгырауларның чыңлаганы бөтен тирә-юньгә ишетелә иде. Сильвинаның Рәҗәп һәм Ямер исемле абыйлары кәтүче булып, бик көмсыз кешеләр иде, алар өчен дөньяда шул кәҗә тәкәләре белән кыңгыраудан да кадерлерәк нәрсә юк иде. Менә шуннан инде алар Руфат белән килешкәннәр. Алар элеге ике кәҗә тәкәсен сораганнар, ә Руфат аларның сеңелесен сораган. Сильвинаның әле һаман кыз икәнен сизгәннәр дә, бездән алып китеп, Руфатка биргәннәр.

Минем Сильвинаны бик күрәсем килсә дә, һич күрә алмыйм: теге вәхши аны өендә бикләп тота икән. Шулай да бер әмәлен таптым мин: караңгы төшә башлау белән, үзебезнең өй түбәсенә менәм дә, моржа артына посып, Руфатлар тәрәзәсенә карап торам. Аларның тәрәзәләре менә мондый бәләкәй генә, шулай да керосин лампасын кабызып куйгач, тыштан да күрерлек. Бөтенесе үк күренмәсә дә, аларның табын янына утырганнарын, урын җәюләрен, йокларга ятуларын күреп була... Әнә Руфат билбавын чишә... Сильвинаның күзләре күренми, әмма башы

тотрыксызланып калган кебек аска иелгән. Руфат бармагы белән аның иягеннән тотып башын күтәртә дә шашынып үбә башлый...

Лампа янып торганда, минем йөрәк тә шәм кебек сызып яна. Исен китәр, ничек ул бөгенләй янып бетмәгәндер дә икенче, өченче кичкә дә житкәндер! Әби минем моржа артына посып карап торганымны күреп, бабайга әйтте, бабай исә аны сүзеннән кырт кына өзеп:

— Менә шулай, бераз ут йотсын әле Эченә ачу жыйсын! Кызлар янында егет була белергә өйрәнсен! — диде.

Бабайның бу сүзе дөрес булгандырмы, юкмы — анысын әйтә алмыйм, әмма ачу жыюга килгәндә, дөрес әйтте ул! Гарьлегең чигеннән ташып ашканда синә шул ачу-ярсу гына ярдәм итәр, сине коткарыр. Саламнан ясаган карачкы күргәнең бармы синең? Аның эче буп-буш була! Йөрәге дә, сөяге дә юк, саламнан гына тора. Шуның шикелле, минем дә бөтен эчем тоташ ачу-гарьлек, Руфаттан аласы, Руфаттан кайтарасы үч-ачудан гына тора иде. Уемда һаман шул гына иде. Ятсам да, торсам да, кырга-басуга китсәм дә, көн-төн Руфатны балта белән чабып ташлау яисә, озаграк ятып газапланып үлсен дип, эченә пычак тыгып чыгару турында гына уйладым. Аның эчәкләрен савып, таптап, тырнакларым белән өзгәләп бетерүемне күз алдыма китердем. Миңа алай итү генә дә аз кебек тоелды: пычак белән эчен ярсам, әллә ни озак азапланып ятмас дип, икенче төрле жәза уйлап таптым. Руфатны мин әкренәкрен буып үтерәчәкмен. Бер әләктерсәм, мин аны ычкындырмаячакмын инде! Әмма бу уемны да әйбәт дип тапмадым, Руфатка янадан-яңа газап уйлап чыгара тордым. Мин аны йөз тапкыр үтереп, йөз тапкыр терелттем. Мең тапкыр турап ташлап, мең тапкыр тиресен тунап алдым. Минем баш ут кебек яна, кулларым йодрыкланып йомарлана, тешләрем шыкырдап кысыла иде. Шул хәлдә йөри торгач, карачкы эчендәге саламга ут капты, һәм мин, авыруга сабышып, урынга яттым.

Бабай, бу хәлне күреп, тәмам куркуга төште. Минем өчен түгел, Дәрвишевлар орлыгы өчен курыкты ул, әлбәттә. Мине култыклап алды да Триградка — Юан Гайшә янына алып китте. Юан Гайшә миңа әллә нинди эчемлекләр эчертте, тәнемә әллә нинди үлән сулары сөртте һәм бер атна эчендә миндәге зәхмәт авыруын чыгарып, аягыма бастырды. Ләкин бабай мине яңадан авылга алып кайтмады, Триградта Дәли Юмәр кәжәләрен көтәргә калдырды, ә Юан Гайшәгә, син аңа теләсәң ни эчерт, әмма авылга сакал-мыек үстермичә кайтмасын, диде. Шулай булды да: әллә үлән суының файдасы тиде, әллә вакыты килеп житкән идеме, берничә ай эчендә минемияк-яңакларыма сакал-мыек шытып чыкты. Сакал дигәнем әллә ни искитәрлек булмаса да, барыбер сакал иде! Әлеге үләннең дә шифасы тиде, ахры (аның суын эчкән кешенең рухы терелә икән), жаным тернәкләнә башлады. Менә шуннан соң инде бабай мине үзебезнең авылга алып кайтырга дип килде.

— Житте, булды, сине өйләндерергә вакыт, ул Руфатның энисеннән үч кайтармыйча түзәрлегем калмады! — диде бабай.

— Өйләндерәм дисәң өйләндер, жиргә күмеп куям дисәң, күмеп куй,— теләсәң ни эшләт, әмма Руфатка тимә! Мин аннан үзем үч алачакмын! — дидем бабайга.

Бабайны Руфатка тимәскә ант иттереп, шунда Триградта ук өйләнеп тә куйдым. Бу юлы инде уйнап кына өйләнмәдем, чынлап торып өйләндем: эчке күлмәк мәсьәләсе дә тиешенчә хәл ителде, балабыз да тугыз айга калып түгел, жиде айда ук дөньяга килде. Бабасының көтәрлек чамасы калмаганлыгын ул да сизгән, күрәсең, ике айга вакытыннан элек туды.

Ни гомер яшәп тә бабайның көлгәнен-елмайганын күргәнем юк иде, минем бала дөньяга килгәч, ул шатлыгыннан елмаеп жибәрде...

Һәм шунда ук үләргә ятты! Оныгы туып өч көн тулуга, бабам елмаеп йөргән килешеннән урын хастасы булып егылды, сул кашы тартыша башлады. Шунда ул мине янына дәшеп алды да:

— Рамадан улым, менә Дәрвишевлар орлыгын күрдем инде, әтиеңнән сөенче алырга китәм. Руфатны сиңа калдырам! — диде.

Шул сүзләрен әйткәннән соң, бабай, миңа баланы, хатынымны һәм Руфатны калдырып, дөньядан китеп барды. Я менә, Рамадан, карап карыйк инде хәзер: берүзең берьюлы өч йөкне күтәрә алырсыңмы икән! Өч йөк бит: дошманым, балам һәм хатыным! Ә салам карачкы, аягында нык басып торсын дип, саламын ныгыта. Кәҗәләр көтә, җир сөрә, ашый-эчә. Ә йөрәгең итче Руфат кулында, ул аны пычак белән телгәли.

Иң элек балам бераз үсә төшсен инде, әнисе имидән аерсын, аннары Руфатның корсагына пычак тыгып чыгарырмын, дидем. Аннары, балам тәпи йөри башласын, дидем. Балам тәпи йөреп киткәч, Сильвина да, кулына бәби күтәреп, тышка чыгып йөри башлады, ул бик ерак юл кайтып арыган кеше шикелле, әкрен генә атлап ишек алдында йөри. Мин аның битен каплаган бөркәнчеге астыннан йөзен күрмәдем, әмма күзләре белән мине эзләп еш-еш каранулын сиздем.

Мин, сарай стенасына тишек тишеп, аны күзәткәли башладым. Мин шуннан Сильвинага карап торганда, Руфат тәрәзәдән хатынын күзли, ә мине үз хатыным күзәтеп тора. Ярый әле, кычкырмый, тиргәнми торган юаш бер хатын туры килде. Кешегә күрсәтмичә генә балавыз сыга да шуның белән тына. Шулай итеп, көн артыннан көн үтә: мин җир сөрәм, җир казыйм яки кәҗәләр көтәм, шулай да өйгә яктыдарак кайтып җитәргә ашыгам. Сарайдагы тишеккә киләм дә Сильвинаның күренгәнен көтәм. Аны күрү белн ару-талуым да, ачу-ярсуым да су белән юып ташлаган кебек юкка чыга. Күрмәсәм — төн буе тешемне кысып йокламый чыгам: Руфатны җәзалыйм, буып үтерәм, агулыйм, ләкин йөрәк ярсуымны ничек тә баса алмыйм. Мин аны әллә ничә тапкыр инде юк итәргә җыендым, тик төрмәгә кереп утыргач, тишектән Сильвинаны күрә алмаячагымны уйлап, карарымнан кире чиктем. Шул рәвешчә көн артыннан көн, ел артыннан ел үтте. Әгәр балаларым үсеп, өйләнеп, үзләре дә бала-чага үстерә башламасалар, мин күпме гомер узганын да белмәгән булыр идем. Безнең ике арадагы имән койма инде череп бетсә дә, үзебезнең ике арада төйнәлгән төен һаман да чишелмәгән иде. Руфатка да һәр кичне карга ятып, боздан торуы җиңел булмагандыр. Чөнки, ник дигәндә, элек ул эчеп-кызып, типтереп йөргән генә булса, хәзер тагы да яманрак эчүгә сабышты. Рәхәт тормышыннан да колак какты — аның ит кибетен тартып алдылар. Бу хәлне бик авыр кичерде ул. Кайгысын башка берни белән дә баса алмагач, аракы белән юарга кереште. Аракы зәхмәте аркасына төшеп, аны урын хастасы итте. Кызы икенче авылга кияүгә киткәч, Сильвина Руфат белән ялгызы гына торып калды. Моннан бер ай элек мин теге черегән койманы аягым белән төртеп аудардым да, Сильвинаны үземнеке санап, алар ишек алдына кердем. Аннары ишек алдыннан Руфат бүлмәсенә кердек. Кырык ел эчендә беренче тапкыр өчәү бергә җыелдык, беренче тапкыр Руфат белән күзгә-күз караштык һәм Сильвина беренче тапкыр безнең арага басты. Гөнаһлымын, дустым, дөресен әйтим: Сильвинаны Руфат күз алдында кочып алмакчы идем, үзем гомерем буена хыялланганча, аны кулларыма күтәреп Руфатка күрсәтмәкче идем, тик Сильвина рөхсәт итмәде.

— Безнең шушында бергә булуыбыз да җиткән! Ул кансыз булса да, син андый булма! — диде.

— Ә хәзер ничек соң? — дип сорарсың инде.

Хәзер болай. Руфат өйләрендә туңып-өшеп ята. Сильвиналарның ишәкләре юк. Сильвина утын ташып интекмәсен, Руфатны җылытыр

өчен мичкә ягып азапланмасын дип, утынны мин китереп бирәм. Урман каравылчысы минем өстән бер акт язды инде, икенчесен язарга җыенып йөри, шуңа күрә мин утынга төнлә генә барам. Кайвакыт ботак чәчрәп күземне бәреп чыгарырдай була, кулларым талып өзелеп төшәргә җитешә, шулай да мин утын кисәм, урман каравылчысы йоклау белән утынны чокыр аша чыгарып өйгә ташыйм, йөрәгемне утка салган кеше өчен эшли-эшли имгәнеп бетәм инде. Кырык ел буе үземне газапта интектергән кешене җылытам бит! Шулай итми хәлем юк. Мин эшләмәсәм, утынны Сильвина ташырга тиеш булачак. Ул гынамы соң, кайвакыт Руфатны ашатам да әле мин: гәүдәсе таш кебек авыр үзенең, аны күтәреп торгызырга, урын-җирен алмаштырырга кирәк, хәтта, гафу итегез, астын да җыештырырга туры килә. Хатын-кызның андый эшләргә көче җитәрлекмени?! Шуннан соң инде шул: Руфатны әлеге дә баягы Рамадан багарга тиеш була! Бакмый булмый да, югыйсә бөтен авырлык Сильвина өстенә төшәчәк. Авыл халкы кайвакыт минем хакта әйтә: «Исең китәр, мена нинди кеше, мена нинди күрше!» — ди. Минем эчемдә ни кайнаганны күрмиләр шул... Эчемдә сумала казаны кайный бит, агай-эне! Мин, Сильвинага өйләнермен дип өметләнеп, Руфатның үлгәнен көтәм, ә ул явызның үләргә исәбендә дә юк әле. Эчемне ут урынына көйдергән сумала әнә шул инде! Минем Сильвина белән, ир белән хатын кебек, бергә ятасым килә, аннары ни булса да булыр... Хатыным, балаларым, бер көтү оныгым аркылы атлап чыгып, Сильвина янына барыр идем, тик безнең арада бүкән шикелле каткан Руфат ята шул, тормый да, кымшанмый да! Ә гомер дигәнең узып бара, дустым, дәрт-дәрман да яшь чагындагыча түгел инде, кем белә бит: Сильвина белән ир-хатын булып ятарсың, ә иртән абый белән сеңел булып уянырсың. Вакыт-вакыт күңелгә шундый уй да килгәли: Руфат үзе дә газаплана, безне дә газаплый, әллә, мәйтәм, тәмуг капкасын ачып, аны шунда гына кертеп җибәрим микән, икенче ел җәһәннәм ишеген шакый бит инде, дим. Мин аны буып үтерергә дә, суга батырырга да җыенмыйм, бер өч көн суыкта калдырсам, үзе дә катып үләчәк. Шулай дип уйлыйм уйлавын да, уйдан гамәлгә күчәргә вакыт җиткәч, Сильвинаның күзен тутырып миңа каравын күз алдыма китерәм дә, Руфатны җылытырга утын кирәк бит дип, тагы урманга чыбык-чабык җыярга китәм.

Мена мин хәзер дә шул ике юл чатында баскан килеш нишләргә белми тик торам: уңга китәргәме, сулгамы, әллә әлеге төеннең үзе чишелгәнен көтәргәме? Белсәң, әйт, дустым, әйтә алмасаң, мена ишәгем сыртына утын төяш, аннары мин кайтып китәрмен, югыйсә теге явыз, салкыннан калтырана-калтырана, мине көтеп ятадыр.

*Я. Халитов тәрҗемәсе.*

**Виктор Щекачев**
Рус шагыйре

## Аучылар

Дулкыннар ярны кагалар
Уйнап язгы җилләрдә;
Аучылар ауга чыкканнар —
Юл капчыгы иңнәрдә.

Аучыларны үртәгәндәй
Кычкыра кыр үрдәге,
Үрдәк тавышы булып тоела
Һәрбер аваз җирдәге.

Батып-чумып йөрегәнче
Салкын суда, тирәндә,
Рәхәтрәк бит гәп сатуы
Учак ягып чирәмдә.

Капчыкта зәм-зәм суы бар,
Кесәләрдә тәмәке.
Бер уйласаң кемгә тия
Мондый дөнья рәхәте?

Аучылар учак янында,
Чишкәннәр биштәрләрен.
Һәрберсе сөйләп юана
Башыннан кичкәннәрен.

●

Кара төндә якты таңны уйлап,
Томан аша көнне күрә бел;
Бер карауда кешегә билге куйма,
Йөрәкләргә үтеп керә бел.

Җир дә үзенең кыйммәт байлыкларын
Яшереп саклый әчтә, тирәндә.
Чынлап баксаң нинди матур хисле
Кешеләр яши синең тирәңдә.

ФӘНИС ЯРУЛЛИН тәрҗемәсе.

# ЗУР ТОРМЫШ

Алдымда, өстәл өстендә, кордашым, дустым Мәхмүд Максудның хатлары ята, шкафымда аның талантлы каләме белән иҗат ителгән әсәрләре, китаплары, том-том тәрҗемәләре өелеп тора.

Хатлары төрле елларда язылган: аларның күптән, моннан 40—45 ел элек язылганнары да, илебез өчен авыр сынаулы көннәрдә, Бөек Ватан сугышы фронтыннан килгәннәре дә, шинелен салып, җиң сызганып, яңадан иҗат эшенә бирелгәннән соң, үз квартирасыннан, Мәскәүдән җибәрелгәннәре дә бар. Кайберләре инде еллар үтү белән саргайганнар, таушалганнар, хәрефләре, аерым сүзләре тоныклана төшкән, хәтта аларны зурайткыч пыяласыз укып та, танып та булмый. Шулай да, ничек кенә булмасын, бу хатларның һәр юлыннан, һәр сүзеннән Мәхмүд тавышы ишетелә, аның характеры, үзенчәлеге, кешеләргә булган җылы мөнәсәбәте, кайгыртучанлыгы, әдәбиятыбыз турында уйланулары, борчылулары, иптәшләренә карата гына түгел, үзенә карата да принципиаль таләпчәнлеге, барыннан да бигрәк, партиялелеге ачык сизелеп тора. Шуның белән бергә, бу хатларда Мәхмүд Максудның зур тормыш юлы, әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге дә беркадәр чагыла. Мәсәлән, аның бу журналга кертелмәгән, хәзергә әле архивта гына саклана торган хатларының берендә үзенең тормыш юлы турында түбәндәге сүзләр бар:

«Партиябезнең Икенче Программасы кабул ителгән елда мин партия сафларына кердем һәм шул Программаны тормышка ашыруда намуслы хезмәт иттем. Язучы булып кына түгел, Мәскәү татар эшчеләре арасында агитатор һәм пропагандист булып, Мәскәү өлкәсендә беренче колхозларны төзүдә МК[1] агитаторы булып, Мордва республикасында, Чиләбе өлкәсендә политбүлек газеталарын редакцияләүче һәм оештыручы булып катнаштым. Моны мин мактану өчен түгел һәм шәхси хезмәтем дип тә түгел, бәлки язмышымның бәхетле булуын күрсәтү өчен әйтәм.

Икенче Программабызны тормышка ашыруда актив катнашкан шикелле, партиябезнең Өченче Программасын тормышка ашыруда да мин көч җиткән кадәр катнашырга телим», ди ул һәм бу юлларны каты авырып яткан көннәрдә яза.

Бу хатның мәгънәсе ачык, аны, яңадан кабатлап, тәфсыйллап аңлатып торуның кирәге юк. Тик бер нәрсәне генә искә төшереп китәргә кирәк. Әгәр кулыбызда, матбугатта, Мәхмүд Максудның басылып чыккан биографиясе булмаса, без аның турында бары хатларындагы шушы өзек-өзек юллардан гына чыгып хөкем итәргә мәҗбүр булсак, шул очракта да без аның илебез, халкыбыз белән бергә зур тормыш юлы узганын һәм бу юлның ленинчы коммунист юлы икәнен ачык күрер идек.

Данлы юл, матур юл, мактаулы юл!

Бу юл, 1918 елда «Чулпан» газетасы редакциясендә хезмәт итүдән башланып, гражданнар сугышы окоплары аша, беренче бишьеллыклардагы көрәшләр, әдәби-иҗтимагый эшләр, МТСлар, политбүлекләр, төрле газета-журналларда эшләүләр, редактор-

[1] МК — КПССның Мәскәү комитеты — А. Ш.

лык итүләр, йокысыз төннәр аша үтә. Ниһаять, бу юл Бөек Ватан сугышы фронтлары, аның беренче авыр көннәре, кайгылары, шатлыклары һәм халкыбызның җиңү тантанасы аша да уза.

Бу — солдат юлы, язучы юлы, коммунист юлы!

Кайчакларда мин, аның китаплары янында туктап, уйланып, басып торам, дустымның әдәби-иҗтимагый юлын күз алдыма китерәм. Аның иҗат юлы да ихтирамга, мактауларга лаеклы!

Китапларының кайберләрендә Мәхмүднең автографлары бар. Алар — миңа бүләк итеп бирелгән китаплар. Мин аларны бик кадерләп, саклап тотам, битләренә кер төшермим, тузан да кундырмыйм. Шулай да кайчакларда мин бу китапларның язмышлары турында уйланам: «Бәхетле китапларым алар, әллә бәхетсезләрме?» — дим.

Бу уем, бәлки, кайберәүләргә сәер тоелыр. «Ничек инде ул? Китапларның бәхетләре, бәхетсезләре буламы икәнни?» — диярләр. Ләкин миңа, гомер буе китаплар арасында яшәгән, язу-сызу белән шөгыльләнгән кешегә, ничектер бу уй табигый булып тоела. Чөнки, минемчә, китапларның да бәхетләре һәм бәхетсезләре бар.

Күптән түгел генә мин республикабызның берничә китапханәсендә булдым, әдәби әсәрләрнең, тәрҗемәләрнең ни дәрәҗәдә укылулары белән кызыксындым. Миңа М. Максудның 1960 елда, Казанда басылып чыккан бертомлыгын күрсәттеләр. Том күп кулларда булган, укыла-укыла тапланган, тузган, читләре тетелгән, хәтта кулга алмаслык дәрәҗәгә җиткән, күпергән.

Шулай ук М. Максудның тәрҗемәләре белән дә кызыксындым. Алар да укучылар кулыннан кайтып кермиләр икән.

Дөрес, укучылар бу китапларны, беренче чиратта, тәрҗемәләре өчен түгел, ә кызыклы, әһәмиятле, тирән эчтәлекле булганнары өчен ала торганнардыр дип уйлыйм. Чөнки бу китапларның авторлары — бөек язучылар, классиклар, иҗатлары белән бөтен дөньяга танылган атаклы затлар. Алар — А. Пушкин, Л. Толстой, Н. Некрасов, И. Тургенев, М. Горький, Низами, Гёте, Гейне һәм башкалар. Шулай да бу әсәрләрнең тәрҗемә икәнлекләрен аларның М. Максуд каләме белән эшләнгәнлекләрен, татар укучыларына аның тырышлыгы белән бирелгәнлекләрен истән чыгармаска кирәк. Димәк, шулай булгач, бу китапларның татар укучылары тарафыннан яратылып укылуларында, кулдан-кулга йөрүләрендә аның өлеше дә кечкенә түгел.

Билгеле, бу тәрҗемәләрнең сыйфатлары барысының да бер үк дәрәҗәдә түгел. Аларның үрнәк итеп йөртерлекләре булган кебек, кайбер әдәби эшкәртелүне, редакцияләнүне таләп итә торганнары да бар.

Бу мәкаләмдә мин М. Максуд тәрҗемәләренең әдәби сыйфаты, аның уңышлары, кимчелекләре турында сөйләргә җыенмыйм, бары тик тәрҗемә эшенең бик җаваплы һәм күп көч сорый торган чын иҗат эше икәнен генә әйтеп утәм. М. Максуд исә бу өлкәдә чын мәгънәсендә әдәби батырлык күрсәтте. Аның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегенә, тырышлыгына, үз-үзен аямыйча эшләвенә гаҗәпләнмичә һәм сокланмыйча мөмкин түгел.

Китапханәләрдәге таушалган, укыла-укыла тәмам искергән китапларны күргәч: «Бәхетле китаплар, бәхетле тәрҗемәләр!» — дип уйладым мин.

М. Максуд кырык елдан артыграк дәвам иткән иҗади гомерен татар совет әдәбиятына багышлады, чорыбызның күренекле язучылары белән бергә, аның беренче нигез ташларын салышты, аны үстерүдә, ныгытуда актив катнашты, әдәбиятыбызның бүгенге биеклеккә менүе өчен күп өлеш кертте.

М. Максудның әдәбиятыбыз тарихында маяк булып торырлык, аның борылыш моменты итеп санарлык зур әсәрләре булмаса да, аның тирән эчтәлекле, революцион пафослы, сокландыргыч нәфис нәсерләре совет әдәбиятының алтын фондында мактаулы урын алып торалар.

Ул — совет нәсерен тудыручыларның берсе һәм иң күренеклесе. Кош теледәй кыска бу нәсерләрнең күбесен ул гражданнар сугышы елларында, фронтта, окопларда, походларда, аннары, соңыннан, илебез хуҗалыгын аякка бастыру өчен барган каты көрәш чорында иҗат итте. Бу нәсерләрнең лейтмотивлары — яшь Совет Ватаны өчен, азатлык өчен, яңа кеше, яңа мораль өчен, яңа тормыш, яңа мөнәсәбәтләр өчен көрәш. Революцион романтика белән сугарылган, лирик образлар белән тулы, сокландыргыч бу нәсерләр укучыларыбызны коммунистик рухта тәрбияләү эшендә бик зур роль уй-

надылар. Укучылар аларны ул елларда басылып чыгу белән күңелдән ятлыйлар, казармаларда, клубларда, әдәби кичәләрдә декламация итеп сөйлиләр иде. Яхшы шигырьләрне ятлаган кебек, болай гына, үзләре өчен дә ятлыйлар иде аларны.

Хәзер дә алар үзләренең сугышчан эмоциональ көчләрен югалтмаганнар, укучыларны көрәштә дә, хезмәттә дә батыр булырга, тормышны яратырга, бервакытта да төшенкелеккә бирелмәскә, халык бәхете өчен яшәргә, эшләргә һәм көрәшергә чакыралар.

М. Максуд күп кырлы, талантлы язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, ялкынлы публицист һәм таләпчән редактор. Ул үзенең күп санлы нәсерләре, шигырьләре, тәрҗемәләре, оста каләм белән язылган публицист һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән татар совет әдәбиятына, татар культурасына гаять зур өлеш кертте. Аның әсәрләре, китаплары халык кулында. Алар халык белән бергә матур киләчәккә, Коммунистик җәмгыятькә баралар.

Әгәр М. Максуд бүген исән булса, аңа январьның 15 ендә җитмеш яшь тулыр иде. Татар совет әдәбияты өчен әһәмиятле бу датаны ул безнең белән һәм меңнәрчә-меңнәрчә укучылары белән бергә каршылар, бәйрәм итәр иде. Кызганычка каршы, хәзер ул арабызда юк — 1962 елны, ноябрьнең салкын, күңелсез көннәренең берендә, әдәбиятыбыз турында, аның бүгенге торышы һәм киләчәге хакында бер якын иптәше белән чын күңелдән бирелеп, янып, көеп сөйләшеп утырганда вафат булды.

Бу юлларны язу белән мин салкын үлемне, кайгыны тагын бер кат искә төшерергә җыенмыйм, ә, киресенчә, моның белән мин таныган коммунист әдипнең, шагыйрьнең, ялкынлы журналистның соңгы сулышына кадәр солдатларча постында торуын, әдәбиятыбызның сафлыгы, партиялелеге өчен көрәшүен, януын, көюен расларга гына телим.

Матур гомер, сокландыргыч гомер!

Түбәндә мин Мәхмүд Максудның миңа язылган кайбер хатларын укучылар игътибарына тәкъдим итәм. Алар 1958—1961 елларда язылганнар, әдипнең соңгы елларадагы уйларын, хисләрен, тормышка карашларын беркадәр тулы чагылдыралар. Шуңа күрә аларны әдәбият сөючеләр кызыксынып укырлар дип өметләнәм.

**АФЗАЛ ШАМОВ**

1958 ел, 22 июль.

**Хөрмәтле Афзал дус,**

**сиңа күп сәлам күндереп, какшамас сәламәтлек һәм иҗат эшләреңдә дә, житәкчелек эшләреңдә дә зур-зур уңышлар теләп калам!**

**Бу хатны ашыгыч бер үтенеч белән язам. Фәйзи [1] белән мин Верховный судка Крымов [2] турында гариза биргән идек (ул гариза Фәйзи Казанга китәр көннәрдә генә почтага тапшырылды). Гаризаның Мәскәү прокуратурасына җибәрелүе турында миңа хәбәр килде һәм Мәскәү прокуратурасыннан да шул ук көнне язылган кәгазь килде,— кайчан һәм кайда туганын сораганнар. Ашыгыч рәвештә. Анда эшне тиз йөртәләр булса кирәк. Союзга [3] барып тикшерткән идем, списокларда исеме генә бар, анкета-фәләннәр калмаган. Авылының Бурнаш [4] исемле икәне хәтеремдә, ләкин районын белмим, туган елын да анык белмим (98 тирәсе булса кирәк). Син инде, зинһар, анда ничек тә тикшертеп, миңа хәбәр ит. Фәлән район, фәлән авылда фәләнчә елны туган дип кенә телеграм бирсәгез, бик яхшы булыр иде. Туган елын ачык белмәсәгез, районын һәм авылын гына күрсәтерсез.**

**Мин китәр алдыннан, вакытыңны кызганмыйча, озаклап сөйләшеп утыруың бик кәефемә килде. Минем кайсы урамда һәм кайсы шәһәрдә яшәвем зур әһәмиятле**

[1] Фәйзи — Әхмәт Фәйзи (1903—1958), шагыйрь һәм драматург, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты. (Искәрмәләрнең барысын да Афзал Шамов язды. Редакция.)

[2] Крымов — Мансур Крымов (1898—1940), шагыйрь. Ул 1937 елда, тиешсезгә гаепләнеп, кулга алынган иде. М. Максуд һәм Ә. Фәйзи иптәшләрнең тикшертүләре нәтиҗәсендә аның гаепсезлеге һәм Верховный суд тарафыннан 1940 елның 17 февралендә үк акланганлыгы билгеле булды.

[3] Союз — СССР язучылары союзы идарәсе.

[4] Бурнаш — Чури-Бурнаш авылы, Татарстан республикасы, Апас районы.

мәсьәлә түгел, мин үземне сезнең коллективның бер кешесе дип исәплим. Дәрман чималы булса да, эш дәрте бик зур. Мин һәрвакыт Татарстан язучылар оешмасының һәм партия оешмасының ярдәменә таянырга телим (тормыш рәхәтлекләре мәгънәсендә түгел, партиячел тәнкыйть һәм иҗади ярдәм мәгънәсендә әйтәм).

Кош теледәй генә булса да, бер кат язуыңны үтенәм. Фәйзинең хәле ничегрәк?[1] Ул минем аеруча якын иптәшем бит. Хәле начар диләр, ышанасы килми. Акыл белән хис көрәшә... Бәлки, Әбүбәкер абый[2] да карар, дигән өмет белдергән иде, моны эшләгәнсездер.

Кайтканнан бирле врачларга йөрдем, бик күп анализлар (кайберсен кат-кат) үттем, ләкин миңа кирәкле (Мәскәү янында кардиологический) санаторийга ноябрьсыз путевка юк, август 2-сендә семьям белән Коктебельгә китәм.

Ихтирам белән Мәхмүд.

1958 ел, 9 август.

Хөрмәтле Афзал дус,
сәламнәремне һәм матур теләкләремне кабул ит!

Хатыңа вакытында җавап яза алмадым, Крымга китәргә җыенып яткан чак иде. Хәбәрне тиз бирүең өчен зур рәхмәт (моның шулай буласына мин алдан ук ышана идем). Табигый, прокуратурага җавап җибәрдем. Тизрәк хәл итсеннәр иде!

5 августта Гөлсем[3], Алик[4] һәм мин Коктебельгә килеп төштек. Хосусый тәртиптә бүлмә алып яшибез. Докторлар миңа эссе айларда Крымга йөрмәскә кушалар (катгый тыялар). Мин бераз үземчә уйладым. Иртә-кич, һәркөн ике тапкыр, диңгездә коенам, көндез өйдә утырам, кулагәдә җилдә басып торам. Бик нык ышанганга күрәме, диңгезнең бик зур ярдәме бар, дип хис итәм. Бераз эшлим.

Фәйзи турында өметле, матур хәбәрләрең белән куаныч китердең. Бөтен көчне куеп, терелтсәгез иде инде сез аны! Кичә мин аңа хат салдым, җыйнак һәм тыйнак язарга тырыштым. Мөмкинлек булганда, үзең дә, Зәки[5] дә миңа кыска гына хатлар җибәргәләсәгез иде! (Зәкигә күп сәлам!)

Ярый, күп язып вакытыңны алмыйм.

Житәкчелек эшләрендә һәм иҗат эшләрендә зур уңышлар теләп, өчебездән дә сәлам һәм ихтирам белән мәгълүмең

Максуд дәю белгәйсең.
Мәхмүд.

Крым, Планерное, до востребования Максудову М. Г.

1958 ел, 21 сентябрь.

Хөрмәтле Афзал дус,
бик күп сәламнәр күндерәм!

13 сентябрьдә Крымнан кайттык. Эш Мәскәүдә дәвам итә. «Анна Каренина»ны тәмамлап киләм[6], октябрь ахырында нәшриятка җибәрәчәкмен. Эш арасында гына берничә мәкалә язып ташларга да исәп бар. Сәламәтлегем беркадәр ныгыды кебек. Дәрт зур, дәрман ничек булыр.

Фәйзинең үлем хәбәре[7] тирән кайгы китерде. Бик күп уйландырды. Бик күп кич-

---

[1] Фәйзинең хәле ничегрәк? — Әхмәт Фәйзи бу вакытта Казанда каты авырып ята иде.

[2] Әбүбәкер абый — Әбүбәкер Гәрәй улы Терегулов (1885—1966), медицина фәннәре докторы, профессор, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе.

[3] Гөлсем — М. Максудның тормыш иптәше.

[4] Алик — улы.

[5] Зәки — шагыйрь Зәки Нури. Бу вакытта ул Татарстан язучылары союзы идарәсенең җаваплы секретаре иде.

[6] «Анна Каренина»ны тәмамлап киләм — «Анна Каренина» романы тәрҗемәсен тәмамлап килү.

[7] Фәйзинең үлүе хәбәре — Әхмәт Фәйзи 1958 елның 10 августында Казанда вафат булды.

ләрне, диңгез шавын ишетмичә генә, яр буенда монаеп йөрдем. Дөрес, аның үлемсез эшләре күп. Ә шулай да иртә китте ул. Үзе дә, авыруының нәрсә икәнен белсә дә, үләргә түгел, бәлки яшәргә уйлый иде. Нишлисең, үлем бер хак. Димәк, тормышның мәгънәсен аңларга, гомерне бушка уздырмаска кирәк.

Мин сиңа бу хатымда терелүләрнең берсе турында матур хәбәр язам. Крымов реабилитацияләнгән. Язуның копиясен җибәрәм. Анда әйтелгән белешмәне соратып ала алганым юк әле, ләкин безгә, Крымов турында иркен сөйләү өчен, шушы хәтлесе дә җиткән. Правлениедә[1] аның мәкаләсен карарсыз, дип уйлыйм. Минемчә, 1959 елда аның кечерәк (10 табак чамасы) бер җыентыгын бирергә кирәк. Планда булмаса да, моны эшләү мөмкиндер дип беләм. Ә 1960 ел планына аның ике томлыгын янсә 30—35 табак чамасында зур бер томлыгын кертергә кирәк. Беләсеңдер, 1931 елларда ук аның дүрт томлыгы чыга башлаган иде инде, ничәсе чыкканы хәтеремдә юк.

Катлам-катлам съездларга һәм конференцияләргә әзерләнү мәшәкатьләре күп вакытыңны аладыр. Хат язуыңны үтенеп борчымыйм. Язмасаң, үпкәм юк, язсаң, һәрвакыт шат булырмын.

Үзеңә, семьяңа, иптәшләргә сәлам белән

Мәхмүд.

1959 ел, 20 март.

Хөрмәтле Афзал дус,

сиңа күп сәлам күндереп, Республикабыз Верховный Советының депутаты булуың белән котлыйм. Син инде Президиум члены булып та өлгергәнсең. Җилкәңә зур бер яңа эш йөкләнде дигән сүз. Ләкин бу эш синең үз иҗатың өчен дә, татар әдәбиятының үсеше өчен дә файдалы булыр, дип ышанам. Мин, коммунистлар белән партиясезләр блогында катнашкан бер сайлаучы буларак, депутатларның барысын да үзем сайладым, дип исәплим һәм, синең Сессиядәге чыгышыңны хуплап, ихлас күңелдән рәхмәтләр укыйм. Верховный Советка төкле аягың белән килүең булсын. Бик кирәкле мәсьәләләр күтәргәнсең. Яшьләр журналы зур мәсьәлә. Тәрҗемә әдәбият турында әйткәннәрең миңа аеруча ошады, җаннарым рәхәтләнеп китте. Гадәттә, тәрҗемә турында сүз ачылганда, русчага тәрҗемә турында гына сөйлиләр бит. Бу, әлбәттә, дөрес түгел. (Әле шушы көннәрдә генә Гомәр[2] кабинетына кереп, шул турыда гәп кузгаткан идем.) Съездагы чыгышыңда да шуны искә алып китсәң иде. Пермяклар фикере[3] гомумән ялгыш булу белән бергә, Автономияле республикалар өчен аеруча зарарлы. Бездә секцияне бетерү[4] әдәбиятыбызның үсешенә зур зыян китерәчәк. Бетерү турында түгел, эшен яхшырту турында сөйләргә кирәк.

Үзем бер көйгә нык кына эшләп яткан булам. Майда (ахырында) Анна[5] белән саубуллашырмын дип өмет итәм (ул барыбер үлә инде). Миңа тереләр, бәхетле тормыш тәзүчеләр кирәк. Нефтькә китәм. Анна белән генә түгел, гомумән тәрҗемә белән,— һәр хәлдә шушы җидееллык буенча,— саубуллашырмындыр. Берничә мәкалә генә бирермен. Күбрәк эшлисе килә. Коммунизм төзүчеләр турында ялкынлы, пафослы әсәрләр иҗат итәсе килә. Һәрзаман фатихәдә бул!

Хәзергә!

Сәлам һәм ихтирам!

Мәхмүд.

---

[1] Правление — Татарстан язучылары союзы идарәсе.

[2] Гомәр — Абдулла Гомәр, ул вакытта «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы.

[3] Пермяклар фикере — рус язучысы Е. А. Пермякның рус матур әдәбиятын СССР халыклары телләренә тәрҗемә итү янсә итмәү мәсьәләсе турындагы фикере.

[4] ...секцияне бетерү — Татарстан язучылары союзы янындагы тәрҗемәчеләр секциясен бетерү.

[5] Анна — сүз Лев Толстойның «Анна Каренина» романын тәрҗемә итеп бетерү турында бара.

Фатыйма Ибраһимова

# БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ, АНЫҢ УҢЫШЛАРЫ

Азат тормышның беренче көннәреннән үк диярлек «Правда» газетасының 1918 елгы февраль санында «Онытылган корал» исемле бер мәкалә басылып чыга. Сүз анда балалар әдәбияты турында бара. Мәкаләдә балалар әдәбиятының сыйнфый көрәш коралы булуына басым ясала, бу коралны буржуазия кулыннан тартып алу һәм балалар өчен язылган әсәрләрне зарарлы идеяләрдән арындыру кирәклеге әйтелә. Балалар язучылары алдына эшче һәм крестьян тормышын сурәтләү, сыйнфый көрәш, революция язмышын чагылдыру бурычы куела. Мәкаләнең дөньяга чыгуы бик вакытлы була.

Иске әдәбияттан балаларга калган мирас шактый чуар иде. Үзебезнең татар балалар әдәбиятын алып карасак, анда без, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Н. Думави, З. Ярмәки кебек язучыларның реалистик әсәрләре белән бергә, дини әчтәлекләрен дә күп очратабыз. Революциядән соңгы беренче айларда чыга башлаган «Балалар дөньясы» журналы битләрендә дә алла һәм пәйгамбәрләр рухына гыйбадәт кылырга чакырган, азан моңнары белән ләззәтләнеп язылган шигырь һәм хикәяләр, дини әкиятләр байтак очрый.

Ләкин гомерен кичергән иске традицияләрне дәвам иттерергә теләүчеләр никадәр генә тартышмасыннар, яңалык барыбер юл яра. Бу урында «Кечкенә иптәшләр» (1924—1928 елларда Мәскәүдә чыгарыла) журналының яңа әдәбият өчен көрәштәге ролен аеруча ассызымлап күрсәтәсе килә. Дөрес, «Кечкенә иптәшләр»не «Балалар дөньясы»на каршы куярга ярамый. Алар һәр икесе нигездә революция интереслары белән яшәделәр. Шулай да, «Кечкенә иптәшләр» журналында зарарлы дини хикәяләр, патшаларны, ханнарны мактаган әкиятләр күренми диярлек, басылган әсәрләрнең күбесендә революциянең ярлы баласына бәхет китерүе, аны ачлыктан, кимсетелүдән тартып алуы, җәмгыятькә файдалы кеше булып үсү өчен бөтен мөмкинлекләр тудыруы сурәтләнә.

Үткән турында да әсәрләр язылмады түгел. Әмма Октябрьның баштагы елларында бүгенге көн темасы өчен көрәш балалар әдәбиятында аеруча кискен төс алды. Социалистик системаның өстенлеген чагылдыру, яңа тормышка мәхәббәт тәрбияләү бөтен җитдилеге белән килеп басты. Революция дулкыннары белән әдәбият мәйданына күтәрелеп чыккан яшь каләмнәрдән Һ. Такташ, Г. Толымбай, И. Госманов, Г. Гали, М. Крымовларның шигырь һәм хикәяләрендә башлап яңа, совет чынбарлыгы сурәтләнде, шулар татар совет балалар әдәбиятының беренче, нигез ташларын салышты. Заман темасы өчен көрәштә бу язучыларның әсәрләре аеруча зур роль уйнады. Мисалга Һ. Такташның

«Караборынның дусты», Г. Толымбайның «Ленин бабай янында» һәм «Минем әти», И. Госмановның «Кечкенә көрәшче үлми», К. Әмиринең «Завод мәктәбендә», Г. Галиең «Бәхет» кебек әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Бүгенге көн таләпләреннән чыгып караганда, элеге әсәрләрнең байтагы әдәби яктан шактый йомшак эшләнгән. Тик шунысы әһәмиятле: революция яшь буынга нәрсә бирде, аның рухи дөньясында нинди үзгәрешләр китереп чыгарды — ул әсәрләрнең үзәгендә әнә шул идеяләр торды.

Яңаны сурәтләү, татар совет балалар әдәбиятының үсеше зур кыенлыклар белән барды. Әдәби форма мәсьәләләренә битараф карау очраклары, социалистик эчтәлекне примитив формалар ярдәмендә сурәтләү күренешләре булгалады. Байтак язучылар бала авангардлыгы кебек ялгыш тенденцияләр белән мавыгып киткәләделәр. Мондый әсәрләрдә бала адәм ышанмаслык эшләр башкара, хәтта әти-әнисеннән дә өстен торып, аларны үзе өйрәтә иде.

Социализмның кызу темплар белән алга атлавы, балалар тормышындагы үзгәрешләр (гомуми мәҗбүри укыту кертелү, пионер оешмасы төзелү һ. б.) әдәбият алдына яңа таләпләр куйды. Балалар әдәбиятының әһәмияте күтәрелде. Яшь буынны тәрбияләүдә ул гаилә һәм мәктәпнең ышанычлы булышчысына әйләнде. Укыту программаларын камилләштерү өчен көрәш тә балалар әдәбиятына үзенең эзен салды. Егерменче еллардагы татар балалар әдәбиятының үсеше чорның яңа темаларын эзләү, югары идеялелек өчен көрәш юнәлешендә барды. Утызынчы елларда исә әдәби осталыкны күтәрү мәсьәләсе дә көн тәртибенә басты. Балалар әдәбиятына күп санлы яшь каләмнәр килде: А. Алиш, Г. Бакиров, Г. Гобәй, М. Әмир, Ф. Хөсни, А. Әхмәт, Ф. Кәрим, Л. Гыйльми, Г. Галиев, Ә. Айдар, Ш. Гәрәй, Х. Кави һ. б. 1928 елда Гыйльми үзәк каршында балалар әдәбияты комиссиясе оештырыла. Комиссия балаларга багышланган әсәрләрне тикшереп бастыру, булганнары арасыннан яраклыларын сайлап алып, кечкенәләр кулына тәкъдим итү эшләрен үз өстенә ала. 1931 елда илебездә балалар әдәбиятын тикшерү айлыгы үткәрелә. Әсәрләрнең сыйфатын күтәрү нияте белән, яхшы хикәя, шигырь һәм поэмаларга конкурс уздырыла. Моңа кадәр балалар өчен язылган әсәрләр төрле нәшриятларда (СССР халыклары Үзәк нәшрияты, Татарстан дәүләт нәшрияты, Гәҗур һ. б.) чыгып килә иде. Бу — рәссамнарның һәм язучыларның иҗади сәләтләрен бер максатка туплауны кыенлаштырды. Шуны күздә тотып, 1933 елда Детгиз, оэекламый Татарстан китап нәшрияты каршында балалар әдәбияты редакциясе оешты, аның баш редакторы итеп талантлы шагыйрь Ф. Кәрим билгеләнде. Балалар әдәбияты редакциясе төзелү әдәбият тирәсенә яңа әдәби көчләр туплау, китапларның темаларын һәм бурычларын киң перспектив планда билгеләү өчен зур уңайлыклар тудырды.

Бу елларда балаларның үз иҗади сәләтләрен үстерү мәсьәләсенә дә игътибар арта башлый. 1934 елда яхшы әсәрләр язу өчен балаларның үзләре арасында конкурс игълан ителә.

1934 елда Татарстан язучыларының беренче съезды булып уза. Балалар әдәбиятының торышы турында Ф. Кәрим доклад ясый. Яңа балалар әдәбияты нинди юнәлештә үсәргә тиеш — докладның төп моменты әнә шуңа кайтып кала. Тәрбияви яктан зарарлы китапларны кысрыклап чыгару, илебезне социалистик нигездә яңа баштан үзгәртеп кору процессын югары художестволы образларда чагылдыру бурычы куела. Күрелгән чаралар эзсез калмый. Бер яктан, балалар китабы сан ягыннан ишәя, икенче яктан, әдәби әсәрләрнең сыйфаты күтәрелә. А. Алиш әкиятләре, М. Җәлил шигырь һәм поэмалары, Г. Гобәй, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Айдар повесть һәм хикәяләре татар совет балалар әдәбияты формалашуда һәм аның сәнгатьчә үсешендә яңа этапны билгелиләр. Бүген дә үзләренең эстетик көчләрен югалтмыйча, яшь укучыларның яратып укый торган әсәрләреннән исәпләнүләре, кат-кат басылулары шул хакта сөйли.

Заман таләпләренә бәйле рәвештә, әдәбиятның проблемалары да үзгәрә тора. Егерменче еллар татар балалар әдәбиятының үзәгендә бәхет мәсьәләсе торган иде, хәзер исә тормыш яшь совет укучысының батырлыгын чагылдыруны алгы планга куя. Утызынчы еллар авылда да сыйнфый көрәшнең кискенләшүе белән характерлы. Ул елларда социализм дошманнары, кулак корткычларга каршы көрәштә балалар зур булышлык иттеләр. Герой пионерлар турында газета-журнал битләрендә хикәяләр, очерк, мәкаләләр басылды. Кыю пионер Павлик Морозов, Оля Балыкина исемнәре илебездә киң таралды, балаларны

батырлыкка дәртләндерде. Совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында сөйләгән докладында А. М. Горький батыр пионерларның үлемсез образларын әдәбиятта чагылдырырга чакырды. Чорның героик вакыйгалары татар балалар язучыларын да җәлеп итми калмады. Прогул ясауга, эчкечелеккә, һәртөрле искелек калдыкларына каршы яшь пионерның героик көрәше татар балалар әдәбиятында киң урын алды.

Бу еллар яңа тема һәм проблемаларны сурәтләү белән генә түгел, аларны мавыктыргыч итеп чишү алымнарын эзләү белән дә характерлы. М. Әмир, Г. Гобәй, Ә. Айдар повестьлары, А. Алиш әкиятләре белән, мәсәлән, татар балалар әдәбиятында романтик юнәлеш калку төс ала. Мисалга Г. Гобәйнең «Каланча» һәм «Маякчы кызы», М. Әмирнең «Батыр исемле малай турында хикәяләр», Ә. Айдарның «Ташбай» кебек әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Авторлар тормышның вак-төяк мәшәкатьләренә, икенче дәрәҗәдәге күренешләренә әллә ни илтифат итмиләр. Әсәрләрнең сюжетында очраклылыклар, гадәттән тыш вакыйгалар, мәҗара элементлары байтак. Аларда социализм өчен көрәшкә, олылар белән беррәттән, кечкенәләрнең дә катнашулары күтәренке-патетик стильдә сурәтләнә, бүгенге бәхетле тормышның зур корбаннары хисабына яулап алынуы турында сөйләнә, революция көчләренең җиңелмәслегенә ышаныч тәрбияләнә.

А. Алиш әкиятләрендә аеруча пейзаж оста гәүдәләнә. Аның әкиятләрен укыганда, бала мул уңыш бүләк иткән киң кырларда йөри, аны тук башаклар, әкрен искән җил белән сәламләп каршы ала. Автор һәр агачның үзенә хас шаулавын ишетә, болындагы һәр чәчәкнең исен тоя, төсен күрә, һәр бөҗәкнең холкын белә, телен аңлый. Алиштагы табигать сине күтәренке хисләр дөньясына алып керә. Табигать белән бергә, А. Алиш кеше образларын да романтик планда сурәтли. Моның өчен ул халык әкиятләрендәге җанландыру, метафора, гипербола, шартлылык элементларын уңышлы файдалана. Батыр егет («Капкорсак патша»), Шмидт («Бозлар-явызлар») образларын искә төшерик. Алар гадәттән тыш көчкә ияләр, халык әкиятләрендә сөйләнә торган батырларны хәтерләтәләр. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, А. Алиш татар балалар әдәбиятында совет чынбарлыгына нигезләнгән хәзерге заман әкиятләренең беренче матур үрнәкләрен бирде. («Бозлар-явызлар», «Чуар тавык», «Нечкәбил», «Кем көчле?» һ. б.)

Героик характер тудырганда, А. Алиш, Г. Гобәй, М. Әмир, Ә. Айдарлар романтик сурәт чараларына мөрәҗәгать итсәләр, Ф. Хөснидә реалистик тасвир зур урын ала. «Җәйге кич» хикәясендәге кечкенә Фәриданең ындырдан ашлык урлап киткән ике каракны колхоз идарәсенә килеп әйтүе — һәр совет укучысы булдыра ала торган гадәти эш. Ф. Хөсни көндәлек тормышны гади детальләр белән салмак тонда хикәяли. Монда бернинди идеаллаштыру да, күпертү дә юк. Язучы хәтта кечкенә Фәриданең авыру әнисе дә, сыерларының көтүдән кайтмый калуы да кызыксындыра. Шулай итеп, татар балалар әдәбиятында тормышны эстетик сурәтләү алымнары шактый төрләнә бара.

Утызынчы еллардагы татар балалар әдәбияты тема һәм жанр ягыннан киңәйде, язучылар тарафыннан масштаблы повестьлар иҗат ителде. (Л. Гыйльми. Чын мәхәббәт; Г. Гобәй. Маякчы кызы; Ә. Айдар. Ташбай). Язучылар яңа төзелешләрдә, колхоз кырларында балаларның олыларга булышып йөрүләрен өйрәнәләр. Нәтиҗәдә яңа жанр — кечкенәләрнең үз хезмәтләрен яктырткан очерклар дөньяга килә. (А. Алиш. Кабан җиңелде; Г. Разин. Әгер уллары; Ш. Гәрәй. Яңа совхозда.)

Ерак тарихка күз ташласаң, татар балалар әдәбиятында драма жанры да Октябрь революциясеннән соң гына туган дигән карашка киләсең. Балаларга багышланган пьесалар егерменче елларның беренче яртысында күренә башлый. 1922 елда Ф. Бурнашның «Оҗмах кошы» исемле пьесасы басыла. Озакламый Г. Бакировның «Беренче җиңү», С. Әдһәмованың «Хәзер бул», «Авыл тормышыннан бер күренеш» пьесалары дөнья күрә. Шуннан бирле балалар өчен драма әсәрләре системалы чыгып килә.

Утызынчы елларда Х. Кави үзенең географик елъязмалары белән таныла («Кавказ таулары аркылы җәяү», «Боз диңгезенә таба» һ. б.). Ф. Кәрим фән мәсьәләләренә багышланган «Электр фонарьлары» исемле әдәби әсәр иҗат итә.

Ватан сугышының дәһшәтле көннәрендә дә балалар әдәбиятына игътибар кимемәде. Сугышның иң кызган вакытларында Н. Исәнбәтнең «Татар халкының балалар фольклоры» исемле хезмәте, «Безнең балалар», «Яшь патриотлар» исемле җыентыклар басылып чыкты. Соңгы икесенә рус

язучыларының сугыш кырындагы батыр пионерларга багышланган хикәя һәм очерклары тәрҗемә итеп урнаштырылган. Ф. Хөсни белән А. Әхмәт кыска хикәяләр өстендә эшләделәр. Әдипләрнең хикәяләрендә бүгенге балаларыбызга хас күркәм сыйфатларның үткәндәге героик традицияләребезгә барып тоташуы чагыла. Ф. Кәримнең бу еллардагы поэмалары татар балалар әдәбияты үсешендә зур вакыйга булды. Аның «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл», «Үлем уены» поэмаларындагы балалар немецларга каршы көрәштә һәркайсысы үзенчә бер батырлык эшли. Ф. Кәрим сүз уйнатмый, купшы эпитетларга, катлаулы чагыштырулар һәм метафораларга да артык исе китми аның. Поэмалар шул яклары белән күңелгә кереп калалар: аларның сюжеты динамик, автор табигатьтәге тынычлык һәм гармония белән фашизмның ерткычлыгын контраст куя, сугыш вакыйгалары арасыннан иң киеренке бер моментны сайлап ала, шул моментта эчке көче һәм тышкы хәрәкәте ачык беленеп торган җанлы образ пәйда була. Шагыйрь көндәлек тормышта еш кулланыла торган гади сүзләрнең эчке матурлыгын ача.

Сугыш чоры татар балалар әдәбиятында 30 еллардан ук килә торган героикромантик линия тагын да җанлана төште. 1944 елда Г. Кутуйның «Рөстәм мажаралары» повесте басылып чыкты һәм шунда ук яшь укучыларның мәхәббәтен казанды. Әсәр күтәренке-патетик тонда язылган, романтик рух, көрәш пафосы белән сугарылган. Явызлык һәм яхшылыкның кискен бәрелеше, сюжетта искәртмәстән борылышлар ясау, гадәттән тыш вакыйгаларны соңгы чиккә кадәр җиткереп кискенләштерү кебек фантастик жанрга хас алымнарны автор совет пионерының героик характерын, типик образын ачу өчен гаять оста файдаланган. «Рөстәм мажаралары» повесте татар балалар әдәбияты үсешендә эзсез калмады, фантастик жанрның үсешенә этәргеч ясады. Ватан сугышыннан соң А. Расихның «Бәхет орлыклары», Л. Ихсанованың «Җир астында җиде көн», А. Тимергалиннның «Җир уллары» исемле мажаралы повесте һәм хикәяләре дөньяга чыкты. Киеренке сюжет төзү ягыннан дисеңме, яшь буында батырлык, туган илгә мәхәббәт тәрбияләүгә нык игътибар бирелү ягыннан дисеңме, ул әсәрләр «Рөстәм мажаралары» повесте белән аваздаш яңгырыйлар.

Ватан сугышыннан соңгы тыныч төзелеш елларында татар балалар әдәбияты яңа баскычка күтәрелде. К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Ш. Маннурның матур һәм образлы шигырьләре, А. Шамовның «Озын мыеклы абый», «Югалган билет» кебек балалар психологиясен белеп язылган хикәяләре яшь укучылар арасында зур кызыксыну уятты. Вакыйгаларының мавыктыргыч булуы, үсмерләрнең рухи ихтыяҗларына җавап бирүе ягыннан Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» повесте балалар арасында зур популярлык казанды. Н. Исәнбәтнең «Пескаем» исемле китабы яхшы әсәрләргә уздырылган конкурста югары бәя алды. Х. Туфанның кечкенәләргә багышланган җылы лирик шигырьләре нәшриятта да, «Ялкын» журналында да әледән-әле басылып торды. Г. Хуҗиев, Ә. Давыдов шигырьләре һәм поэмалары татар балалар әдәбиятын публицистик рух һәм гражданлык мотивлары белән баетты. Каләм көчен тулысы белән яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган язучылардан Г. Бакиров, Г. Гобәй, Ж. Тәрҗеманов, Ә. Бикчәнтәева, Л. Ихсановаларның сугыштан соңгы еллардагы иҗади активлыгын ассызымлап билгеләп үтәсе килә.

Сугыштан соң татар балалар әдәбияты яңа баскычка күтәрелде дибез икән, бу үсешне З. Нури, Г. Мөхәммәтшин, Ш. Рәкыйпов, Г. Ахунов, Ә. Маликов, Б. Камалов, Р. Мингалимов һәм башка язучыларның әсәрләреннән башка күз алдына китерү кыен. Ш. Галиевның юмористик шигырьләре татар балалар әдәбиятында үзенә аерым урын тота.

Балалар өчен язылган әсәрләрнең саны елдан-ел арта бара. 1945 елда, тәрҗемәләрне кертмичә, ни бары 5 исемдә китап басылып чыккан булса, 1969 елда аларның гомуми саны 90 га җитте. Балалар өчен язылган иң яхшы әсәрләрдән сайлап алып, «Мәктәп библиотекасы» сериясе чыгарыла башлады.

Татар балалар әдәбиятының географик офыгы тагын да киңәйде. Бүгенге яшь укучы, үз илебездәге күп төрле вакыйгаларны күреп тору өстенә, Америка балаларының ачы язмышы белән дә таныша (Ж. Тәрҗеманов. Судан табылган хат), солтан Төркиясе буенча сәяхәт итә (М. Юныс, Р. Батуллин әсәрләре)...

Әдәбиятта беркайчан да искерми, эстетик һәм тәрбияви әһәмиятен югалтмый, буыннан-буынга күчеп килә торган мөһим темалар була. Батырлык — балалар әдә-

биятындагы шундый темаларның берсе. Батырлык проблемасы татар балалар әдәбиятының буеннан-буена сузылып килә. Утызынчы елларда татар язучыларының герой пионер образын сыйнфый көрәшнең иң кызган учагы — колхоз авылы тормышыннан алып чагылдыруларын әйткән идек. Ватан сугышыннан соңгы елларда моңа немец фашистлары белән көрәш вакыйгалары бай материал бирде. Г. Гобәйнең «Замана балалары», Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» кебек сугыш темасын белеп һәм тирән итеп ачкан повестьлары, Г. Бакировның «Партизан малай» әсәрләре дөньяга чыккан көнгә байтак вакытлар үтте. Хәзерге көндә «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә хәрби-патриотик темага багышланган әсәрләр еш басыла. Аларның күбесендә сугыш елларындагы бала язмышы алына, аны геройлыкка этәргән патриотизм көче ачыла. Язучылар хәзер сугыш елларындагы кеше язмышының төрле якларына күз төшерәләр. Фронт сызыгы белән генә чикләнмичә, совет кешеләренең дошман тылында алып барган көрәшләрен дә яктырталар. Мисал өчен Н. Дәүлинең «Җимерелгән бастион» романын, Ә. Давыдовның «Муса абый» повестен күрсәтергә мөмкин.

Бөек Октябрьның һәм Совет Татарстанының 50 еллыгы, В. И. Ленинның 100 еллык юбилее уңае белән, героик традицияләребезгә игътибар аеруча көчәйде. Соңгы вакытта Ленин темасы өстендә эшләүче язучыларның саны артты. Чөнки илебездәге бөек тарихи борылыш — иске җәмгыятьтән яңа җәмгыятькә күчү, бүгенге совет кешеләренең искиткеч могҗизалары турыдан-туры аның исеме белән бәйле.

Ә. Давыдовның «Илнең ямендә», З. Мансурның «Сүнмәс дәрт», Ш. Мөдәрриснең «Ильич чаңы», Ә. Юнысның «Яз хикәясе» шигырьләрендә Ленин шәхесе аша революция һәм илебез язмышын күрү, юлбашчы тәгълиматының бөеклеге һәм үлемсезлеге турында уйланулар, халыкның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген Ильич исеме белән бәйләп карау зур урын тота.

> Күрәмен мин Ленинны
> Илнең бөтен ямендә.
> Ачлык-коллык дөньясын
> Ул юк иткән мәңгегә,—

ди Ә. Давыдов «Илнең ямендә» исемле шигырендә.

60 елларда Г. Хуҗиевның юлбашчы образына багышланган шигырь һәм поэмалары «Ялкын» журналы битләрендә басылып килде. «Идел хикәясе», «Бирелә Ильич яшәгән», «Күнел яктысы» поэмаларында Г. Хуҗиев Ленин биографиясендәге мәгълүм даталарны теркәп бару белән генә чикләнми, юлбашчы эшчәнлегенең эчке асылын, фәлсәфи мәгънәсен, кешелек тарихында тоткан урынын яктырта. Ленин идеяләре вакыт үткән саен заман рухына якыная бара, ди автор. Ленинизмның яшәүчән көчен ул татар халкының язмышында чагылдыра. Мәсәлән, «Күнел яктысы» поэмасында исә шагыйрь үзәк образ итеп нәкъ менә татар хатыны Нурдидә апаны сайлап ала. Чөнки күпләр белән бергә, Нурдидә апаны да революция караңгылыктан тартып чыгарган, аңа тулы хокук биргән. Поэмада Ильич эшенең үлемсезлеген ышандырырлык итеп күрсәтерлек тапкыр чагыштырулар бар. Нурдидә апа, Ленин турында уйлаганда, туган елгабыз мәңгелек Иделне күз алдына китерә. Шушы бер деталь юлбашчының кешелекле образын шактый тулы җанландыра. Нурдидә апаның кичерешләре хезмәт ияләренең юлбашчыга булган җылы мәхәббәтен чагылдырырлык югарылыкка күтәрелә.

Татар балалар әдәбияты битләреннән Ленинның тулы тормыш юлы үтә. Алда әйтелгән шагыйрьләрнең шигырьләрендә һәм Г. Хуҗиев поэмаларында Ленинның үсмер вакытлары һәм бөтендөнья хезмәт ияләренең, Коммунистлар партиясенең җитәкчесе булып формалашкан еллары сурәтләнсә, М. Ногман үзенең «Кокушкино таңнары» поэмасында Ильичның балачагын яктырта. Кечкенә Володяның характеры шул чордагы социаль каршылыклар тәэсирендә формалаша. Поэмада сурәтләнгән Кокушкино авылы дөньяның бер идиллик почмагы түгел. Крестьяннарның моңзарлары, ярлылык һәм хокуксызлык сабый Володяның күңелен тирәнтен җәрәхәтли, аны яшьтән үк социаль тигезсезлекнең сәбәпләрен эзләүгә этәрә.

Гомумән, хәзер яшь буынны героик шәхесләребез үрнәгендә тәрбияләү җитди төс алды. Тарихыбызда тирән эз калдырган байтак күренекле шәхесләрнең әдәби образлары иҗат ителде: «Муса абый» (Ә. Давыдов), «Көмеш дага» (Җ. Тәрҗеманов), «Тукай турында хикәяләр» (И. Нуруллин), «Чәчәкләр сөйли белә» (Ш. Рәкыйпов), «Йолдыз тапкан егет» (К. Латыйпов), «Идел баһадиры» (А. Сәләхетдинов) һ. б. Бу әсәрләр бүгенге совет кешеләрендәге күркәм сыйфатларның тирән

тамырлары ерак үткәнгә барып тоташуы турында сөйлиләр, героик характерның формалашу этапларын чагылдыралар.

...60 еллар татар балалар әдәбиятында психологик анализ алымы шактый нык сизелә башлады. И. Газиның «Ак сирень», Г. Мөхәммәтшинның «Без әле җирдә яшибез», Б. Камаловның «Көзге яңгыр» әсәрләрендә лирик башлангыч өстенлек ала. Б. Камаловның «Көзге яңгыр» хикәясендә, мәсәлән, вакыйга юк диярлек. Монда бөтен нәрсә Рафис исемле малайның табигать халәтендәге иң нечкә үзенчәлекләрне тоя белергә тырышуына кайтып кала. Рафис өчен көзге яңгыр табигатьнең бер күңелсез күренеше генә түгел, аның тамчылары, калай түбәдә биешеп, сихри бер көй көйлиләр, аларда гүя көзге муллык дәрте, хисләр канатлануы бар, әйтерсең лә, яңгыр тамчылары келәтләрне тутырган гәрәбәдәй бодай бөртекләре булып сибеләләр, борчак «ядрәләр» булып биешәләр.

Югары сәнгатьчәлек, заман темасы өчен көрәш һәрвакыт татар совет балалар әдәбиятының үзәгендә торды һәм ул шулай булып кала да. Заман темасын сәнгатьчә гәүдәләндергәндә килеп туган кыенлыкларны, һәртөрле ялгыш тенденцияләрне җиңә барып, Совет власте елларында инде берничә буын балалар язучылары җитеште. Шуның белән бергә, зурлар өчен иҗат итүче талант ияләре яшь буынны матур сүз ярдәмендә тәрбияләүгә үз өлешләрен кертә килделәр. Нәтиҗәдә татар совет балалар әдәбияты яшь буынны идея-эстетик тәрбияләүнең куәтле чарасына әверелде. Үзенең юлын кыска-кыска шигырь һәм хикәяләрдән башлап, зур масштаблы повестьлар, роман һәм зур күләмле поэмаларга кадәр үсте, гражданлык мотивлары белән баеп, бөтендөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы В. И. Ленин образын иҗат итәрлек югарылыкка күтәрелде. Ил һәм балалар тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар аның битләрендә үзенең чагылышын тапты. Милли рамкалар эчендә генә калмыйча, татар балалар әдәбияты Бөтенсоюз аренасына чыкты. Татар балалар язучыларының күп санлы әсәрләре, рус һәм бүтән телләргә тәрҗемә ителеп, халкыбызның уртак хәзинәсенә әйләнде.

**Энҗе Сәгыйдова,**
педагогия фәннәре кандидаты

# ТУКАЙНЫҢ ИКЕ ҖЫЕНТЫГЫ

«Казан утлары» журналының 1968 елгы 4 санында Кәрим Сәгыйднең халык шагыйре Габдулла Тукай турындагы бер истәлеге басылган иде. Кәрим Сәгыйд архивында, шул истәлек һәм башка материаллар белән бергәттән, Г. Тукай иҗатына бәйләнешле ике хат та сакланган. Берсе, шагыйрьнең үз кулы белән язылып, «Мәгариф»[1] җитәкчеләреннән Гыйльметдин Шәрәфкә адресланган. Сүз анда Тукай шигырьләренең беренче басмасын чыгару турында бара. Хатларның икенчесе, халык шагыйренең «Җан азыклары» исемле җыентыгы чыгу уңае белән, Кәрим Сәгыйд тарафыннан язылган. «Җан азыклары» — шагыйрьнең үзе исән вакытта чыккан соңгы җыентыгы. Тагын шунысы игътибарга лаек, әлеге җыентыкларның икесе дә бер үк «Мәгариф» нәшриятында басылган.


«Мәгариф» нәшрияты һәм басмаханәсе Октябрь революциясенә кадәр яшәгән татар матбагалары арасында зур урын тотканы һәм шактый эз калдырганы. «Мәгариф» чыгарган китапларның күбесе матур әдәбият әсәрләре, фәнни-популяр әдәбият һәм балалар өчен язылган әсәрләр була[2]. Н. В. Гоголь, И. С. Тургенев, Л. Н. Толстой, А. П. Чехов, А. Н. Островский, Д. Н. Мамин-Сибиряк, М. Горький кебек күренекле рус язучыларының әсәрләрен татар телендә беренче мәртәбә башлыча шушы нәшрият чыгара. Профессор Р. И. Нәфиков күрсәтеп үткәнчә, «Мәгариф»нең аеруча әһәмиятле хезмәтләреннән берсе — аның революцион эчтәлекле әсәрләрне бастырып чыгаруы һәм аларны халык арасында пропагандалавы. Һәм, үзенең беренче җыентыгын бастырыр өчен, яшь Тукай нәкъ шушы нәшриятны сайлаган икән, бу — тикмәгә түгел.

Габдулла Тукай белән «Мәгариф» матбагасы арасындагы мөнәсәбәтләргә туктанып, Гыйльметдин Шәрәф болай яза: «Шагыйребез белән беренче танышуым мәктүп аркылы 1907 нче сәнә майда булды. Безнең «Шигырь мәҗмугалары» нәшер итәчәге-

---

[1] «Мәгариф» — XX гасыр башында «Камалетдинов (Галиәсгар Камал — Э. С.) вә ширкәте» нигезендә төрле кешеләр керткән пайларга төзелгән китап нәшрияты. Соңыннан ул «Борадәран Шәрәф вә К°», «Мәгариф», «Үрнәк» һәм янәдән «Мәгариф» дип йөртелә.

[2] «Мәгариф» нәшриятының прогрессив роле Р. И. Нәфиковның «Формирование и развитие переводой татарской общественно-политической мысли» (Казан, 1964.) дигән хезмәтендә, «Мәгариф» китап нәшрияты тарихыннан» исемле мәкаләсендә («Совет әдәбияты» журналы. 1962 ел. 12 сан. 130—133 бит) һәм безнең «Тукай һәм «Мәгариф» исемле мәкаләбездә («Дружба народов» журналы. 1967 ел. 8 сан.) яктыртыла.


Въ г. Казань Уральскъ Гост. «Казань»
А. Тукаеву.

*Тукай хатының фотокүчермәсе.*

безне һәм бер-ике нәшер иткән мәҗмугаларыбызны күреп, безгә: «Сез могтәбәр татар шагыйрьләренең шигырьләрен нәшер итә башлагансыз икән. Мин дә үземнең берәр мәҗмугамның шулар арасында булуын телим»,— мәфһүмендә [1] бер хат яза.

Без шигырьләрен кабул итәбез... 1907 сәнәнең җәендә «Мәҗмуга»сын нәшер хакында 5—6 мәктүп яза» [2].

Үкенечкә каршы, Габдулла Тукай язган ул хатларның һәммәсе дә сакланмаган. Татар телендә беренче мәртәбә игълан ителә торган бу хат [3] Г. Шәраф телгә алган әлеге «5—6 мәктүп»нең берсе булса кирәк [4].

Хат гарәп хәрефләре белән 9×14 см зурлыктагы почта открыткасына язылган. Датасы куелмаган. Бәхеткә каршы, ачык хатның өске ягында, почта штемпельләрендәге числолар ачык укыла. Шулар буенча шагыйрь бу хатын Уральскидан 1907 елның 9 июнендә җибәргән, һәм ул 16 июньдә Казанга килеп җиткән, дип санарга мөмкин. Ачык хат өстенә Гыйльми Шәраф: «Җавап язылды» дип куйган. Менә ул хат:

> «Хөрмәтле Гыйльметдин Шәраф әфәнде!
>
> Тарафыңызга, заказной бандероль уларак, «Әшгар мәҗмуга»мны җибәрдем. Шигырьләрнең мөкатдәм муаххар [5] басылуын рәкымнар [6] илә яздым. Үзегез аерырсыз. Зинһар, яхшылап тәсхих [7] итеп басыгыз. Азсын-

---

[1] Диган фикердәрәк.
[2] Тукай турында замандашлары. Казан. 1960 ел. 97—98 битләр.
[3] Русчага тәрҗемәсе «Дружба народов» журналының 1967 елгы 8 санында басылды.
[4] Бу хатны К. Сәгыйдкә, ул Тукай турында материаллар җыярга керешкәч, Шәрәфләрнең берсе (Гыйльметдин яки Галимҗан) биргәндер дип уйлыйм. Алар әтинең якын дуслары иде.
[5] Басылу тәртибен.
[6] Саннар.
[7] Төзәтеп, дөресләп.




*Хатның адрес язылган ягы.*

сагыз, ошбу арада тагы бәгъзе тәхрират[1] җибәрермен. Үзегез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсагыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча җибәрегез. Ихтимал, аннан соң Казанга үзем барып, китабымны лично тәсхих итеп бастырырмын. Әгәр разый булмасагыз, китапны кире үземә кайтарыгыз. Инде мин сезгә бөтенләй тапшырдым. Ничә мәртәбә бастырсагыз да рөхсәт. Җавап көтәм. 7 нче июньдә мәктубегезне алдым. Шартыгызны кабул итәмез димешсез. Бәндәгез: Г. Тукаев.

Адресым. Въ г. Уральскъ. Гост. «Казань» А. Тукаеву».

Югарыдагы хат, Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүдә мөһим документ булу белән бергә, аның «Мәгариф» нәшрияты, Шәрәфләр матбагасы белән мөнәсәбәтен дә бераз яңача һәм башка күзлектән карап бәяләргә ярдәм итә.

Хатның тоны һәм андагы: «Инде мин [китабымны — Э. С.] сезгә бөтенләй тапшырдым. Ничә мәртәбә бастырсагыз да рөхсәт»,— дигән сүзләр Г. Тукайның «Мәгариф»кә тулысынча ышанып каравы, мәҗмугасын бу нәшриятка үз теләге белән тәкъдим итүе һәм ничә мәртәбә бастырсалар да риза булуы хакында сөйлиләр. Әлегә кадәр Тукай иҗатын өйрәнүчеләр бу мәсьәләне Габдулла Кариев истәлегенә генә таянып аңлаталар иде. Сүз дә юк, Г. Кариевның хатирәләре гаять әһәмиятлеләр. Ләкин икенче бернәрсәне дә истән чыгармаска кирәк: ул үзенең истәлеген «...бердән, Габдулла әфәнденең һәм минем Уральск мәдрәсәсеннән чыкканыбызга җиде ел чамасы вакыт үтте, икенчедән, Габдулла әфәнденең магыйшәтендә булган һәр хәл вә һәр вакыйгасына игътибар итәргә тиешле булган зур бер шагыйрь булачагы ул вакытларда мәгълүм түгел иде. Өченчедән, мин үзем күз алдымнан үткән һәр вакыйгага вә һәр хәлгә аерым бер игътибар белән карый алмый идем. Шуның өчен дә Габдулла әфәнде хакында минем исемдә калган мәгълүмат бик әтрафлы түгел, бәлки, берберсенә мөнәсәбәте булмаган җөзьи беркадәр хатирәләрдән генә гыйбарәттер»[2],— дигән кисәтүле сүзләр белән башлап китә. Шулай булгач, бу мәсьәләдә Габдулла Тукайның үз кулы белән язылган сүзләргә ышану дөресрәк булыр кебек.

Тукайның үтенечен искә алып, борадәран Шәрәфләр җыентыкны «Шүрәле» исемле шигырь белән ачалар. Шагыйрьнең «Шүрәле», «Китмибез!», «Пар ат», «Бездә истигъдат бар», «Алтынга каршы» һәм башка шигырьләре беренче мәртәбә шушы җыентыкта дөньяга чыгалар.

«Г. Тукаев шигырьләре»нең беренче басмасына нәширләр тарафыннан шактый кызыклы кереш сүз бирелгән. Анда шундый сүзләр бар: «Милләтебез ифрадының гомумән тәрәккъыйга хәрәкәтләре арту нисбәтендә, шигырьгә һәвәсләре арта бара.

---

[1] Язу, хат.
[2] Тукай турында замандашлары. Казан. 1960 ел. 54 бит.

«Бакырган», «Мөхәммәдия» илә канәгатьләнми торган яшьләремез яңадан-яңа шигырьләр телиләр.

Бинаән галәйһи без газем итдекемез шигырьләр китапханәсе дәвам итдереп, бу 3 нче дәфтәрдә үткен телле сәекле шагыйребез Габдулла Тукаевның шигырьләрене укучыларга тәкъдим итәбез».

Демократик интеллигенция вәкилләре һәм тәнкыйтьчеләр шагыйрьнең бу беренче җыентыгын хуплап каршы алалар. Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек күренекле әдипләрнең мәкалә-рецензияләре чыга[1]. Ф. Әмирхан, мәсәлән, үзенең рецензиясендә: «...мәҗмуга әдәбиятыбыз белән иштигаль итүчеләрнең җөмләсенең дикъкатьләрен җәлеп итәрлек вә Габдулла әфәнде муаффәкыяте белән шаян тәбриктер.

Рисалә табгысы җәһәтеннән дә бик гүзәл вә нәфистер.

Шәрәф матбагасының шигырь мәҗмугалары нәшере белән әдәбиятымызга иткән хезмәте — эш, әһле кулында булганда, никадәр файда китерә ала икәнене дөрес бер мизандыр»[2],— дип яза.

«Г. Тукаев шигырьләре»нең 1907 елгы беренче басмасы 4000 данә тираж белән чыга[3] һәм бик тиз таралып бетә. Ләкин шагыйрьнең эшче халыкка мәхәббәт белән сугарылган һәм демократик идеяләрне яклап язылган шигырьләре патша цензурасына ошамый. 1911 елның ноябрь аенда Эчке эшләр министрлыгының матбугат эшләре Казан вакытлы комитеты Тукайның бу беренче җыентыгын арестовать итәргә һәм шагыйрьнең үзен хөкемгә тарттырырга әмер бирә[4].

1911 елның декабрь урталарында, сәламәтлеге начарлану сәбәпле һәм полиция күзәтүеннән дә бераз котылып торыр өчен, Тукай ашыгыч рәвештә Казаннан Өчиле авылына Кәбир абыйсы янына кайтып китә. Тукай һәм «Мәгариф» нәшрияты арасында беренче җыентык басылу уңае белән башланган, соңыннан гомер буена дәвам иткән дуслык һәм эшлекле мөнәсәбәт ул авылда чагында да өзелми. Шагыйрь, үзенең шәхси тормышы, саулыгы, кәефе турында язып, Г. Шәрәфкә хатлар җибәреп тора, аңардан Грибоедов, Лермонтов китапларын сорατып ала[5].

Тукай Казанда чагында ук «Мәгариф» җитәкчеләре белән үзенең яңа җыентыгын чыгару турында сөйләшеп куйган була. Авылда башлыча ул шул җыентыкка кирәргә тиешле шигырьләр өстендә эшли. Г. Шәрәфкә язган бер хатында Тукай болай ди: «Теге рәкымнар астында языла торган нәрсә 20 рәкымнан артты. [Син күргәндә 7 рәкым иде]. Әгәр хөсне хатимә белән тәмам булса, исемен дә «Рәкымнар астында» куярбыз. «Рәкымнар астында» пессимистический рух белән башланган иде. Монда бөтенләй оптимистландым, ахры»[6].

Баштарак Тукай җыентыгын «Рәкымнар астында» дигән исем белән чыгарырга уйласа да, соңыннан бу фикере үзгәрә. «Ялт-Йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиевка язган хатыннан күренгәнчә, 1912 елның маена Тукай аңа «Җан азыклары» дигән шагыйранә исем таба[7].

«Йолдыз» газетасының 1912 елгы 15—16 ноябрь саннарында басылган игълан буенча хөкем йөрткәндә, Тукайның «Җан азыклары» дигән китабы шул елның ноябрь башларына дөньяга чыккан булырга тиеш. Җыентыктагы 44 шигырьнең 31 е беренче мәртәбә басылган. Алар арасында, «Үтенеч», «Татар яшьләре», «Казан вә Казан арты», «Ваксынмыйм» кебек шигырьләр белән бергә, Пушкин, Майков, Ушинский һәм башка язучылар әсәрләреннән ирекле тәрҗемәләр, аларга ияреп язган шигырьләр бар.

---

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. II том. Казан. 1958 ел. 183—186 битләр; Г. Камал. Әсәрләр. II том. Казан. 1951 ел. 216—217 битләр.

[2] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. II том. 183—186 битләр.


[3] Татарстан үзәк дәүләт архивы. 420 фонд. 1 тасвирлама. 88 эш. 175 бит.

[4] Х. Хәсәновның «Габдулла Тукай и царская цензура» (Габдулла Тукай. Сборник. Казань. 1968 г. Рус телендә. 209—215 битләр.) исемле хезмәтен һәм «Г. Тукай һәм патша цензурасы» («Совет әдәбияты» журналы. 1940 ел. 7 сан.) исемле мәкаләне кара.

[5] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 нче том. Казан. 1956 ел. 226 бит,

[6] Шунда ук.

[7] Шунда ук, 219—220 битләр.



*Кәрим Сәгыйд хатының фотокүчермәсе.*

«Җан азыклары» Петербургка килеп җитү белән Кәрим Сәгыйд, җыентыкка карата үз фикерен әйтеп, Тукайга хат яза. Югарыда әйтелгәнчә, хатның караламасы К. Сәгыйднең архивыннан табылды һәм матбугатта беренче мәртәбә игълан ителә.

Кульъязмада хатның датасы куелмаган. Чама белән ул 1912 елның ахырында яки 1913 елның башында язылган булырга кирәк. Ул вакытта Тукай Казанда, К. Сәгыйд Петербургта торганнар. Каралама 21×26 см зурлыктагы икегә бөкләнгән кәгазь битенә, гади кара карандаш белән язылган. Сул яктагы битнең югары почмагы азрак ертылган.

Хатның тулы текстын китерәбез:

«Тукай!

Мин соңгы көннәрдә «Җан азыклары» дигән соңгы шигыреңне кулга төшереп укып чыктым. Моңа кадәр әсәрләрең арасында «Халык әдәбияты» дигәнен бигрәк тә тәкъдир иткән идем. Инде бу «Җан азыклары» минем сиңа булган өметемне арттыра гына түгел, көткәнемне тәкмил итәр дәрәҗәсенә җитештерде. Алты юлдан гыйбарәт «Тәләһһеф» ниһаять фәсих вә балигъ, чын ихласыңнан әйтелгән дөрес шигырь. Фәкать уртадагы ике юлы, астагы һәм өстәге дүрт юлның шәрхе булганга (шөбһә юк, гөл исә дә), аны, үзегез әйтмәенчә, шәрхләргә калдырсагыз, артыграк булачак иде дип, зан итәмен. «Тәләһһеф»нең соңгы ике юлы бигрәк фәсих, тәркибе дөрес, пакь, мәгънәсе бөектер.

«Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылып чүпләрем»[1] дип, нигә һазым[2] нәфес итәсең! Бакчабызда чүп-чар булмыймыни!

---

[1] «Җан азыклары» мәҗмугасында басылган «Үтенеч» шигыренең азаккы юлы.
[2] Үзләштерү, сеңдерү.

«Мин үлгәчтән, карагыз, типмәсенләр нәгъшемә» [1],— дигән васыятеңне, кишә алла, онытмамын. Дошманнар, нәгъшеңә тибү түгел, тәкъдис [2] итәргә мәҗбүр булырлар дип, зан итәмен. Ләкин «дөньядан туйдым, өметем юк» [3], дигән яңа сүзләрең мине кайгырталар. Соңгы хасталыкларың шулай әйттергәндер дип уйлыйм.

«Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна» [4] дип, җитмәсә тагын күңелне бутыйсың.

«Сагынып вакытлар» дигәндә син ник үзеңне иблискә тәшбиһ[5] итәсең!

«Көзге җилләр» өчен мин сине адәм дип кенә түгел, ходаның иң сөекле адәме дип тәкъдир итәм.

«Йолдыз»дан да куркучы авыл татары — бака, бу бик удачно.

«Буран»: «Йә тишелгәнме ходайның бихисап зур мендәре» — бу җөмләгә татарлар һич риза булмаслар дип зан итәм.

Минем бу сүземә «Мөнәкъкыйд» [6] дигән ачы хакыйкатьле шигырьләреңне җырлап җавап бирмә. Ачуны китермә.

«Һич берәүнең дә чәчәккә инде китмәс исләре»[7], дигәндә «берәү» мөфрәт [8] сыйгасы [9] булып, аның мөзафи [10] булган «исләре» сүзе җәмегъ сыйгысы булуга мин гаҗәпсендем. «Минем исләрем китте» дигән сүз хата бит, минем исем китте диләр.

Бу сүзләрем өчен мине «Бу хаким ишәк, мәхәббәтсез килемшәк икән» [11] дип сукмә. Хәер ихтыярың» [12].

Шул кадәресен дә әйтик, Габдулла Тукайның «Җан азыклары»н халык ифрат яратып укый, китап бик тиз сатылып бетә. Шуңа күрә «Мәгариф» нәшрияты ул җыентыкны 1914, 1915, 1917 елларда тагы басып чыгара.

---

[1] «Дошманнар» дигән шигырьдән бер юл.
[2] Изге санау.
[3] «Дошманнар» шигыреннән.
[4] Шул ук шигырьдән.
[5] Охшату.
[6] Тукайның «Мөнтәкыйд» дигән шигыре күздә тотыла.
[7] «Интикатка мөтәгалликъ» дигән шигырьдән.
[8] Берданбер.
[9] Форма.
[10] Кушылган, арттырылган.
[11] «Интикатка мөтәгалликъ» шигыреннән.
[12] Соңгы ике юллык абзац кулъязмада җиңелчә сызылган, ләкин укырлык.



# ШАГЫЙРЬНЕҢ ТАГЫН БЕР РӘСЕМЕ

**Быел, Тукай бәйрәме көнендә, пенсионер Ибраһим абый Искәндәров миңа шушы кыйммәтле рәсемне бүләк итте. Шагыйрьнең бу рәсеме заманында матбугатта игълан ителгән ителүен. Ләкин рәсеме артында үз кулы белән язылган язу бар:**

*«Иптәшем Мәхмүдкә ядкяр. Г. Тукай. 3 октябрь. 1912 сәнә».*

**Кем соң ул Мәхмүд! Нинди шартларда шагыйрь аңа рәсемен бүләк иткән.**

**Мәхмүд Алиев (Дулат-Али) — Фатих Әмирханнар белән бергә үскән, укыган һәм эшләгән кеше; беренче татар большевигы Хөсәен Ямашевның кардәше, шәкерте, көрәштәше; архив материалларыннан расланганча, 1907 елдан РСДРП члены.**

**1912 елның мартында Хөсәен Ямашев кинәт үлә. Мәхмүднең дә патша ялчылары тарафыннан кулга алыну куркынычы туа. Эзне яшерү өчен, ул Казаннан китәргә мәҗбүр була. Китәр алдыннан якын дусты авыру шагыйрь Габдулла Тукай янына бара. Бу — аларның соңгы күрешүләре. Саубуллашкан чакта Тукай аңа әлеге рәсемен бүләк итә. Рәсемнең оригиналы Мәхмүднең зур кызы, Ибраһим Искәндәровның тормыш иптәше Ләйлә ханымның альбомында саклана. Хәзерге көндә Мәхмүд Дулат-Алиның тормыш иптәше Нәгыймә ханым исән. Аңа 78 яшь. Ләкин хәтере яхшы әле. Ул гаҗәп истәлекләр сөйли. Минемчә, бу истәлекләрне бик тиз арада язып алырга кирәк.**

**Миңа калса, бу рәсем һәм Тукайның ядкяр язуы тикшеренүчеләргә уйланыр өчен шактый азык бирә. Моңарчы Тукайның партия эшенә якынлыгы турында бик томанлы сөйләнелә иде. Хәзер бу мәсьәлә шактый ачыклана. Тукай Мәхмүдләрнең ишек алларындагы чарлакта тора, ә шул чарлакның базында яшерен прокламацияләр басылган. «Бу эшкә Тукайның бер дә катнашы булмадымы икән!» — дигән сорау туа.**




**Ахырда, шул рәсем уңае белән, халыкка мөрәҗәгать итәсем килә: халык кулында Тукай хакында да, башка күренекле әдипләребез турында да истәлекле әйберләр, документлар, рәсемнәр, китаплар, хатлар, язулар сакланган булырга тиеш. Тора-бара аларның эзсез югалып бетүләре ихтимал. Шуңа күрә иптәшләр аларны тиешле оешмаларга яки музейларга тапшырсалар, культурабыз, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез тарихы өчен бик зур ярдәмнәре булыр иде.**

**Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ.**

# КӨРӘШ ҺӘМ ҖИҢҮ ҖЫРЛАРЫ

Композитор белән безне күпьеллык иҗат дуслыгы бәйли. Мин аның квартирында еш булам. Аның тынгысыз булуына, һаман эштә булуына сокланам.

Аның иҗаты күпкырлы. Совет җыры, татар совет композиторлары халыкка биргән җырлар турында сүз кузгалса, беренчеләрдән булып, Җәүдәт Фәйзи исеме телгә алына. Кырык елга якын халыкка бөрәзлексез җырларын бүләк итеп килә ул. Ул җырларны мин заманыбызның музыкаль елъязмасы дип атар идем. 1932 елда Һади Такташның «Урман кызы» поэмасының бер өзегенә язган бик ягымлы, җылы хисле, яңа яңгырашлы җыры белән Җәүдәт Фәйзи кыю рәвештә музыка сәнгатенә кереп китте. Иҗатының беренче башлангычыннан ук ул үз заманының зур вакыйгаларын шатланып җырлауны, аларны олылауны үзе бурыч итеп аңлый, шул омтылыш белән яши.

30 еллар — илебездә социалистик төзелеш киң колач алган, һәр өлкәдә җиңүләр яулаган, халык күтәренке күңел белән яшәгән чор. Нәкъ шул елларда концерт залларында Җәүдәт Фәйзинең шатлык сирпегән, рух ныклыгы белән сугарылган дәртле җыр-маршы «Шауласын, гөрләсен безнең җыр» яңгырый. Илебезнең якты киләчәге өчен корбан булганнарның берсенә — «Ярлы кызы комсомолка Гөлсара»га багышланган җыры, Совет Ватанын сакларга хәзер торучы комсомолец егет турында кавалерия җыры «Атым, чайка башыңны» туа. Бөек Ватан сугышының иң киеренке көннәрендә иҗат ителгән «Канга кан» җыры җиңү сәгатенә кадәр сугышчыларыбызның күңелләрендә дошманга ачы нәфрәт, җиңүгә нык ышаныч тәрбияләде. Тыныч төзелеш еллары... Республикабызда беренче нефть вышкалары күтәрелә башлады. Ә радиодан композиторның «Татарстан нефтьчеләре маршы» яңгырады.

Мондый мисаллар чиксез күп. Җәүдәт Фәйзинең җырларында халыкның йөрәк тибешен, аның көр күңелен, батырлыгын һәм шаянлыгын, тапкырлыгын ишетәсең. Ул җырларда — тарих, көрәш, җиңү. Композиторның үз теле, Җәүдәт Фәйзинең үз стиле бар. Аның көйләре бик гади, ләкин сокланырлык затлы. Алардан ныклык, сәламәт рух бөркелә. Ачык аңлаешлы көйләре күңелгә тиз кереп урнаша. Алар ихлас күңелдән, совет кешесен ихтирам итүдән, аның хезмәтен зурлаудан туганнар. Аларда сүнмәс яшьлек ялкыны. Шуңар күрә дә композиторның җырлары картаймыйлар, искермиләр, алар һаман сафта. Моннан 37 ел элек язылган «Урман кызы» 1965 елда гына иҗат ителгән «Гөлшаһидә» белән янәшә яши. Концерт программаларын, 1966 елда Тукай премиясе белән бүләкләнгән «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Җәлил йолдызлары», «Исеңдә тот, иптәш» кебек көрәш җырлары белән бергә, моннан күп еллар элек иҗат ителгән җырлар да тулыландыралар.

Халыкның музыкаль көнкүрешенә күптән үтеп кергән җырлар, үз чиратында, халык иҗатына билгеле бер матур эз салдылар. Безгә Җәүдәт Фәйзи йогынтысында халык чыгарган «Райхан», «Вәгъдә» кебек бик күп хәзерге заман көйләре мәгълүм.



Композиторның иҗаты җырлар белән генә чикләнми, әлбәттә. Татар совет музыка сәнгатендә комедия жанрының барлыкка килүе дә Җәүдәт Фәйзи исеме белән бәйле, «Башмагым» музыкаль комедиясе совет музыкасының алтын хәзинәсенә керде. Ул — рус, украин, үзбәк, бурят, тува халыклары телләренә тәрҗемә ителгән, илебезнең бик күп музыкаль театр сәхнәләрендә үзенә урын алган әсәр. «Акчарлаклар», «Идел буенда» музыкаль комедияләре һәм «Тапшырылмаган хатлар» операсы Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында күп тапкырлар уйналдылар. Скрипка, симфоник һәм тынлы оркестрлар өчен язылган әсәрләр, республикабызның драма театрлары спектакльләренә иҗат иткән музыкаль оформлениеләре ничаклы! «Хуҗа Насретдин», «Шәмсекамәр», «Тормыш җыры»» «Ташкыннар»га язылган җырларны кем генә белми?!.

Мәктәп балаларының бер генә кичәләре дә Җәүдәт Фәйзинең аларга адресланган җырларыннан башка узмый. Әгәр дә сез, хөрмәтле укучы, бу көннәрдә Татарстан дәүләт симфоник оркестрының балалар өчен көндезге ял концертларының берсенә бәрсагыз, анда да сез Җәүдәт Фәйзи иҗатының күпкырлылыгын чагылдырган күренешкә очрарсыз. Концерт алдыннан композиторның «Кызыклы кунаклар» дигән шигъри әсәре укыла. Ә ул әсәр симфоник оркестрдагы музыка кораллары белән образлы телдә, кызыклы, күңелле итеп таныштыра.

Җәүдәт Фәйзи — үткен каләмле язучы да. Аның «Тукай һәм музыка», «Татар халык көйләрен башкаручылар», «Музыка, башкаручы, тыңлаучы» кебек мәкаләләре, киң катлау масса белән әңгәмә формасында, гади телдә музыка сәнгатенең үзенчәлекләре белән таныштыручы «Музыкаль кичәләр» дигән китабы, радио аша һәм матбугат битләрендә алып барган әңгәмәләре, күренекле сәнгать эшлеклеләре турында очерклары, истәлекләре музыка турындагы әдәбиятыбызга кыйммәтле өлеш кертәләр.

«Ленин турында җыр», «Ай, дуслар», «Яшә, минем республикам», «Рамай», «Матур булсын» — хәзерге заман көйләре. Боларны һәм моннан башка йөздән артык яңа татар халык көйләрен Татарстан районнарына барып җыючы, аларны өйрәнүче, аларның барлыкка килү процессын күзәтүче; җыйган көйләрне зур җаваплылык, саклык белән нотага салып, эшкәртеп, күренекле җырчыларыбыз аркылы халыкка кире кайтаручыларның берсе дә Җәүдәт Фәйзи. Хәзерге заман көйләрен ул кырык елдан артык өзлексез җыеп, өйрәнеп, аларның тарихын язып бара. Бу тиңсез, киеренке күпьеллык хезмәт нәтиҗәсен без озакламый күрербез. «Халык җәүһәрләре» исемле хәзерге заман көйләре җыентыгын композитор Татарстан китап нәшриятына тапшырды.

Менә ничә ел инде халык талантларына республика күләмендә уздырыла торган смотрларда аңа жюри председателе вазифасы йөкләтелә. Йомгаклау смотрына гадәттә берничә йөз кеше җыела. Җәүдәт Харисович бу чакта үзен оста оештыручы да, таләпчән, принципиаль музыкант та һәм игътибарлы кеше, педагог итеп тә күрсәтә. Аның белән очрашкан һәвәскәр җырчылар, һәвәскәр композиторлар музыкаль зәвык, музыкаль-эстетик тәрбия буенча кыйммәтле киңәшләр алып китәләр.

Мин композитор квартирасына һәр баруымда гадәттәгечә аны эш өстәле яки рояль янында очратам. Я ул җыр өчен яңа интонацияләр, яңа алымнар эзли. Яки килгән хатларны укый. Белоруссия белгечләренең җибәргән яңа китаплары белән

таныштыра. Әнә Казагыстанның күренекле музыка эшлеклесе, композитор, академик Әхмәт Жубанов турында Казагыстан фәннәр академиясе Җәүдәт Фәйзидән истәлекләр сорап хат язган. Истәлекләр язу гына Җәүдәт Харисовичны канәгатьләндерми. Ул Казагыстанның талантлы улының Казанда булуын чагылдырган документларны табарга тели, эзләнә, кирәкле кешеләргә телефоннан шалтырата. Ул эштә. Ә мин аны күзәтәм. Башкортстан композиторы Заһир Исмәгыйловның Җәүдәт Харисович җырларын бирелеп җырлавын искә төшерәм. Заһир Исмәгыйлов аның иҗаты турында ялкынланып сөйли. Радиодан чуваш композиторларының җырларын тапшыралар. Ул җырларда Җәүдәт Фәйзи алымнарының матур йогынтысын ишетәм. Җәүдәт Харисович эшчәнлеген барысын бергә тупларга тырышам. Күз алдыма күе яфраклы яшел имән килеп баса. Аның тамырлары бик тирәнгә кергән. Яфраклары төрле якка таралган. Композитор да үзенең иҗаты белән халык тормышына, аның музыкаль көнкүрешенә әнә шулай тамырларын тирәнгә һәм еракка җибәргән.

Татарстанның халык артисты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты, композитор, фольклорчы, киң колачлы музыка эшлеклесе Җәүдәт Фәйзигә 60, иҗатына 40 яшь. 40 ел ару-талуны белмәс, дәртле, ялкынлы иҗат юлы. Бу иҗади юл киләчәктә дә якты булсын, һаман югарыга күтәрелсен!

Меңнәр аңар яңа иҗат үрләре телиләр.



## Җәүдәт Фәйзи

# ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ[1]

## Автордан

Халык җәүһәрләре — ул халык көйләре генә, халык иҗатының энҗе-мәрҗәннәре генә түгел, ул — халык көйләрен күңелләрендә саклаган музыка сөючеләр дә, аларны башкаручы халык җырчылары да, халык көйләрен профессиональ музыка сәнгатенә алып керүче композиторларыбыз белән җырчы артистларыбыз да, көйләргә җырлар язып, аларга яңа сулыш өргән шагыйрьләребез дә.

Менә шулар турында сүз бара бу китапта. Халыкның безнең заман көйле җырлары, күп еллар буе төрле урыннарда җыелган 235 җыр тупланды монда.

Төп максат: зур тарихы булган халкыбызның социалистик Татарстан шартларында туган музыка иҗатын җыеп, аны өйрәнү һәм үзенчәлекләрен тәгаенләү иде. Ләкин Татарстанда яшәгән татар халкы иҗаты белән генә чикләнү күздә тотылмады. Чыккан җирләренә карап, Татарстан, Оренбург, Пермь, Төмән һәм Тобольск якларында язылып алынган көйләр аерым төркемнәргә бүленеп каралмады.

Хәзерге заман халык көйләре дип әйтәбез икән, бу әле революциядән соң гына чыккан көйләр дигән сүз түгел. Халык иҗаты ул кайнап чыккан чишмә кебек ага да ага. Аның суын бер борылмасыннан икенчесенә кадәр сөзеп алып булмаган кебек, төрле күчмә сүзләргә җырланган халык көйләрен дә бер этаптан икенчесенә кадәр

[1] Шул исемдәге әсәрдән өзекләр.

тегэл бүлеп булмый. Шуңа күрә бу җыентыкта революциягә кадәр чыккан кайбер көйләр очрый икән, моңа әллә ни гаҗәпләнмәскә кирәк.

Халык көйләре бөтен тарих буенча җәмгыять интересларыннан, кешенең шәхси кичерешләреннән аерылгысыз. Г. Тукай: «Безнең җырланмакта булган көйләребез һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган», дигән. Димәк, һәрбер көйнең, кечкенә генә булса да, тарихы бар. Кызганычка каршы, фольклорчыларыбыз Г. Тукай традициясен оныттылар, хәзергә хәтле көйләрнең чыганагына игътибар итмәделәр. Бу җитешсезлекне бераз гына булса да бетерү теләгеннән чыгып, монда урнаштырылган халык җырларының туу сәбәпләренә, алар турындагы риваятьләргә, ишетеп белгән тарихларына тукталу кирәк саналды.

Халык көйләре һәр чакта җырчылар телендә яши. Һәр җырчы исә көйне башкарган чагында, үз зәвыгыннан чыгып, аңа азмы-күпме үзгәрешләр кертә. Шуның өчен көй тапшыручы халык җырчылары яки профессиональ башкаручылар турында да кайбер мәгълүматлар бирү күздә тотылды.

Халык көйләренең композиторларыбыз иҗаты өчен илһам чыганагы булуы мәгълүм нәрсә. Катлаулы зур әсәрләр язар өчен кыйммәтле материал булу белән бергә, алар үзләреннән-үзләре дә, эшкәртмә төсендә, музыка сәнгатебездә кыйммәтле хәзинә булып сакланалар. Халык көенең шушы якларына, ягъни аның профессиональ музыка белән үрелеп яшәвенә дә игътибар ителде.

Халык көйләре үзләреннән-үзләре тумаган, билгеле. Элек-электән аларны кайләрдадыр, кемнәрдер башлап җырлаганнар. Димәк, аларның авторлары булган. Телдән-телгә күчеп, алар шомарганнар, безне сокландырырлык хәлгә килгәннәр. Ислам диненең музыканы хәрам санавы аркасында, культурабызның бу өлкәсе караңгылыкта булган, җырларыбызның авторлары билгесезлек томанында кала килгән. Безнең чорда исә гасырлар буенча торган бу билгесезлек томаны таралды. Күп кенә көйле җырларыбызның авторлары безгә билгеле инде. Я алар музыкага сәләтле аерым кешеләр, я үзешчән коллективлар. Араларында берничәшәр көй чыгарган иптәшләр дә очрый. Башта «көйче» булып кына саналганнарның кайберләре, берникадәр музыка белеме алганнан соң, «үзешчән композитор» исеме белән йөртелү дәрәҗәсенә дә күтәрелделәр. Ләкин бу «ярым профессиональ» иптәшләр турында түгел, ә исемнәрен гадәт буенча яшереп калырга тырышкан көй чыгаручы авторлар турында да сөйләнә бу китапта.

Халык көйләренә сюжетлы яңа җырлар язып, аларның гомерләрен озайту традициясе, Г. Тукай башлаган традиция безнең заманда киң канат җәйде. Шагыйрьләребез аерым көйләргә яңа сүзләр язып, аларның заманча яңгырауларын тәэмин иттеләр. Шул ук вакыт халкыбыз талантлары, үз нәүбәтләрендә, шагыйрьләребезнең күңелгә ятышлы җырларына яңа көйләр дә чыгардылар. Бу китап битләрендә безнең чор өчен хас шушы матур күренешкә дә урын бирелде.

«Татар халкы бик музыкаль халык» диләр. Хаклы сүз бу. Музыка сөймәгән, халык көйләрен белмәгән кешеләр аз бездә. Колхозчылар һәм эшчеләр, укучылар һәм студентлар, укытучылар һәм галимнәр — барысы да халык көйләренең искесен дә, яңасын да беләләр. Алар тапшырган көйләргә таянып язылды бу хезмәт.

Татарстанның Мамадыш районы Яңа Комазан авылында укыткан Ленин ордены кавалеры, 1964 елда мәрхүм булган Рәшид Диярович Мозаффаров; Татарстанның Чаллы районы Борды авылы уку йорты мөдире (хәзерге көндә Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артисткасы) Раиса Тимофеева, Татарстан радиосы хезмәткәре, җырчы Флера Сөләйманова үзләре генә дә берсеннән-берсе матур иллегә якын җыр тапшырдылар.

Культура дәрәҗәсе үскән бүгенге укучының таләпләрен барлык яктан да канәгатьләндерү теләгеннән чыгып, тупланган материал өч кисәккә бүлеп бирелде.

**Беренче кисәк** үзе ике бүлектән тора. **Беренче бүлек** — «Җырлар эзлим» дип атала. Анда, шушы китапка урнаштырылган күп кенә җырларны җыю тарихын ачу теләге белән, төрле елларда язылган көндәлектән өзекләр китерелә, фольклористикага караган кайбер тарихи мәгълүматлар бирелә.

Икенче бүлек — «Җырларыбыз турында уйлануларъ» дигән кереш мәкалә. Анда җырларыбызга тематик яктан һәм җыр көйләренә музыкаль төзелешләре ягыннан мөмкин кадәр тәфсилле анализ ясала. Көйләрнең төзелешләренә карап жанрларга бүлүгә, сүзләрнең көй белән ярашуына һәм халык җырларын башкаруга бәйләнешле мәсьәләләргә кагылган кайбер яңарак фикерләр әйтелә.

Икенче кисәк — көйле җырлар. Барлыгы 10 тематик бүлеккә аерылган, 235 сандагы хәзерге җырларыбызның көйләре һәм сүзләреннән тора ул. Бу кисәктә һәр җырга җентекле аңлатмалар бирелә. Аларның музыкаль төрләрен билгеләү белән, тарихи чыганакларын да ачыкларга тырышылды.

Өченче кисәк — көйсез җырлар. Төрле көйләргә җырлана торган күчмә текстлардан тора ул. Үзләренә беркетелгән көйләре булмаса да, алар халыкның хәзерге заман поэтик иҗаты буларак игътибарга лаеклылар. Аларда замандашларыбызның шәхси кичерешләре, рухи дөньясы чагыла. Интим-лирик җырлар, күңелле җырлар һәм такмазалардан торган бу өч бүлеккә 223 куплет җыр урнаштырылган.

Әгәр бу тыйнак хезмәт заманыбызның татар музыка фольклорын өйрәнү эшенә кечкенә генә бер өлеш кертә алса, автор үзен бик бәхетлеләрдән санар иде.



## 24. Кошлар кебек




һаваларда очкан кошлар кебек
Ярсый-ярсый канат кагынып, шул,
Туган илем, кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

Өермәдәй чиксез далаларда,
Урелдем мин ерак юлларга, шул,
Алтын кырлар, матур кызларыбыз,
Бик сагындым сезне мин анда.

Дулкыннардай ярсу, диңгезләрдәй
Давылланды егет йөрәге, шул,
Сезне сагынып иртә, кичләрендә
Тыныч көннәр бер дә күрмәдем.

* * *

Кырыгынчы еллардан башлап, татар халкы арасында зур популярлык казанган бу көй артистларыбыз репертуарында да, Татарстан җыр һәм бию ансамбле репертуарында да зур урын алган иде. Ләкин 1947 елда бу көй шушы сүзләре белән башкарылудан тукталды. Тик моңа карап кына көй яшәүдән туктамады. Музыкантларыбыз аны төрле инструментларда уйнадылар, ә Җыр һәм бию ансамблебез яңа сүзләр белән җырлавын дәвам итте. Ул яңа сүзләр Хәмит Ярминең «Татар халык иҗаты» китабында «Аккошлар җыры» исеме астында басылган (1951 ел, 87 бит) иде. Билгеле, биш куплеттан торган бу җыр халык тарафыннан әлеге көйгә чыгарылган бик күп вариантларның берсе генә булырга тиеш. Чөнки Х. Ярми иптәшнең әйтүенә караганда, ул үзе үк шушы җырның тагын бер вариантын язып алган (6 искәрмә, 502 бит).

Ләкин Х. Ярми варианты репертуарда озак сакланмады. Концертларның берендә бу җыр башкарылган вакытта залдан бер иптәш:

— Нигә сүзләрен бозып җырлыйсыз! — дип кычкырды.

Көйне эшкәртүче автор үзем булганга, мин аны филармония репертуарыннан да сыздырдым, радио аша да тапшырырга рөхсәт итмәдем. Соңгы елларда гына ул яңадан үзенең тулы яңгырашын тапты.

Төзелеш формасы белән «Авыл көйләре» төренә кергән бу җыр ике музыкаль теземнән тора. Соңгы тезем кабатлана. Тезмнәрдәге һәр өч җөмләнең бер үк мотив белән башланып китүе дә яңалык түгел. Әмма күтәренке матур көе, күңелгә якын интонация алымнары һәм ритмик ачыклыгы белән бу көй үзенең бик күп «Авыл көе» төрдәшләреннән өстен тора.

Мин аны 1940 елның кышында Татарстан дәүләт академия театры артистлары Касыйм Шамил һәм Фоат Халитов иптәшләрдән язып алган идем. Алар көйнең исемен дә, кайдан отып алуларын да әйтмәделәр. «Зимагорлар көе» бугай, диделәр. Исемен минем үземә табарга туры килде. Көйнең характерыннан һәм җырның эчтәлегеннән чыгып, мин аны «Кошлар кебек» дип атадым, эшкәрткәндә дә шул образдан чыгып эш иттем.

Икде туган илгә мәхәббәт көйләгән бу җырның сүзләренә килик. Җырның сүзләрен Фәтхи Бурнаш язган булып чыкты. «Яшь йөрәкләр» опера-либреттосының куптән түгел басылып чыккан беренче пәрдәсендә аны Хәйри җырлый («Казан утлары» журналы. 1968 ел, 1 сан, 102 бит). Кайберәүләрдә шикле фикерләр тууы мөмкин. Янәсе, ни өчен «Яшь йөрәкләр»нең 1917 елда язылган һәм аннан соң редакцияләнгән вариантларда бу җыр юк! Янәсе, бу либреттода булган текстларның күбесе халык җырларыннан алынган ич. «Кошлар кебек»нең дә шулай булуы мөмкин бит? Җитмәсә, Ф. Бурнашта ул җырның ике юллык өстәмә кушымтасы да бар. Мондый шикләнүләргә урын юк. Бердән, язучы халык иҗаты белән файдаланырга хаклы гына түгел, тиеш тә. Икенчедән, халык бит ул җырны отып алып башкаручы гына түгел. Ул — тәнкыйтьче дә, ул — редактор да. Ятышсыз сүзләрне ул төзәтә, кирәк тапмаганнарын кабул да итми. Шуңа күрә, халык җырлаган сүзләр белән Ф. Бурнаш язган сүзләр арасында аерма булуы бик табигый.


Күп еллардан соң тагын бер сер ачылды. Көйне тапшыручыларның берсе Фоат Халитов сүзләренә караганда, 1939 елда «Яшь йөрәкләр» сәхнәгә куела. Ф. Бурнаш язган яңа җыр спектакльгә кертелә. Ә көен шул елларда гына Тау ягыннан отып кайтканнар икән.

Шушы урында нокта куярга да булыр иде. Әмма, бу мәсьәлә тулысынча ачыклансын өчен, көй турындагы кайбер ялгышуларга тукталмыйча ярамый. И. Надиров иптәш үзенең «Татар халык җырлары» китабында «Кошлар кебек» җырын борынгы җырлар бүлегенә керткән. Ә искәрмәсендә ул җырның Татарстан радиокомитеты архивыннан алынуын һәм ансамбль репертуарында булуын гына әйтеп китә. Бу бит әле «Кошлар кебек»не борынгы җырлар дип санарга нигез була алмый. Радиога да, ансамбльгә дә җырны мин тапшырган идем. Җитмәсә, бу җырның яңа сүзләре Х. Ярми китабында да бар. Һәм ул «Аккошлар җыры» исеме астында Совет чоры җырлары бүлегенә урнаштырылган. Искәрмәдә аның 1947 елда гына язылып алынуы күрсәтелгән. Димәк, бу мәсьәләдә И. Надиров иптәш хаксыз шикелле.

«Кошлар кебек» — совет чоры фольклоры. Сүзләрен Ф. Бурнаш язган. Мин бу урында халык теленә кергән вариантны урнаштыруны тиешле таптым.

# 45. Һаман истә

Ашыкмыйча ♩=44




Йомшак кына җемелдиләр
Йолдызлар айлы кичтә.
Туган якның зәңгәр күге
Истә, һаман да истә.

Маңгай чәчем тибрәндереп
Таңнарда җилләр исә.
Туган якның таң җилләре
Истә, һаман да истә.

Яшел шәл ябына каен
Сандугачлы яз килсә,
Шәлен болгап озатып калган
Сердәш каеннар истә.

Яктыра күңелем кырлары
Шат кояш нурын сипсә.
Күңелемнән чыкмый һич тә,
Истә, туган як истә.

* * *

Ләбиб Айтуганов сүзләре белән җырлана торган бу җырны мин беренче мәртәбә 1965 елның язында радио буенча бирелгән концертта ишеттем. Аны яшь җырчы Флера Сөләйманова башкарды. Әйтерсең лә, бу көй белән Флераның тавышы аерылгысыз булып үрелгәннәр иде. Көй шул кадәр матурмы, әллә һавада йөзгән төсле тигез, бәрхеттәй йомшак тавыш аны шулай моңлы итеп яңгыратамы! Ни генә булмасын, җырның тәэсире гаять көчле булды. Ләбиб Айтугановның чын йөрәктән язылган сүзләре белән бу көй арасында тулы бердәмлек бар.

Апостроф (,) куелган урында аваз йотылып кала.

Ахырдан ачыкланды: бу кәйне башлап җырлаучы Илһам Шакиров булып чыкты. Үзенең әйтүенә карагаңда, аның дөньяга тууы болай булган. Ләбиб Айтугановның бу матур сүзләрен бик охшатып, бер һәвәскәр композитор аңа көй яза. Җырны Илһам Шакировка тапшыра. Ләкин ул көй Илһамны дулкынландыра алмый. Ә сүзләре күңел-гә кереп кала. Ул аларны шыңшып йөри. Көннәрнең берендә, үз тавышына контроль ясау теләге белән, магнитофонга:

Йомшак кына җемелдиләр
Йолдызлар айлы кичтә,—

дип көйләп җибәрә. Үз тавышын тыңлап карый. Үзе белмәгән яңа көй. Тик ахры юк. Бу матур көйгә җыр строфасының соңгы ике юлын да җырлап карый. Шулай итеп озын көйләрнең бер теземле төренә кирәклек хәзерге заман көе барлыкка килә. Җырлаган саен көй шомара һәм хәзерге матур хәленә килә.

Мин бу җырны беренче ишеткәнемчә, ягъни Флера Сөләйманова җырлаганча яздым.

## 62. Ату кырлары

Кызурак ♩=112




Сугышчылар менеп йөри
Ялтырап торган атларга.
Без алдынгы ударниклар
Совет илен саклауда.
Кушымта:
Эх, матур була ату кырлары,
Комсомолецларның шатлык җырлары!

Ату кырына барабыз,
Бер җан, бер күңел белән.
Әй, сугышчы, төз атарга —
Ворошиловча өйрән.
Кушымта:
Эх, матур була ату кырлары,
Комсомолецларның шатлык җырлары!


* * *

1936—37 елларда бу җырны Казан урамнарында солдатлар җырлап узганны ишетергә туры килә иде. Ул вакытта марш характерындагы бу көйне хәрби тынлы оркестрлар да башкаралар иде.

Жанры белән кыска көйләрнең кушымталы төренә кергән бу җырның авторлары соңгы елларда гына билгеле булды. Аның сүзләрен драматург Зәйни Шаһиморатов

[Ш. Зәйни], ә көен РСФСРның халык артисты мәрхүм Нәҗип Гайнуллин чыгарганнар. Бу — бик күптән булган хәл. Ул турыда Нәҗип Гайнуллин үзе болай сөйләгән иде: «1926 елда без Зәйни белән 1 нче татар полкында — лагерьда хезмәт иттек. Безнең анда драма түгәрәге бар иде. Ш. Зәйни лагерь тормышын чагыштырган «Ату кырлары» исемле пьеса язды. Без аны сәхнәгә куйдык. Аз-маз музыкаль сәләтем булганга, җырның көен миңа маташтырырга туры килде. Халык яратты үзен»...

# 100. Галиябану




Тәрәзәдән карыйсың ла,
Карап кемне таныйсың?
Карап күзең талдырганчы,
Галиябану, сылуым иркәм,
Ник чакырып алмыйсың?

Тәрәзәңне ачык куеп,
Кемгә көлмәк кистең син?
Кара кашым, карлыгачым,
Галиябану, сылуым иркәм,
Кем бәхетенә үстең син?

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал;
Сөюләрең чыннан булса,
Галиябану, сылуым иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал.

* * *

Татар халкының «Кара урман», «Әллүки», «Салкын чишмә», «Һаваларда йолдыз» кебек классик көйләре рәтенә кергән «Галиябану» — аеруча игътибарга лаеклы әсәр. Шушы көй белән илһамланып Мирхәйдәр Фәйзи язган «Галиябану» драмасыннан татар театр сәнгатендә яңа жанр — музыкаль драмалар жанры башлана.

«Галиябану» музыкаль драмасының язылуы очраклы хәл түгел, әлбәттә. Халык иҗатының матур үрнәкләрен җыеп туплавы белән Мирхәйдәр Фәйзи Габдулла Тукай традицияләрен дәвам итүчеләрнең иң өлкәне.

...1916 елда, элекке Орск өязе, Дүрт Күл авылында Мирхәйдәр Фәйзи бик моңлы көйләнгән «Сәгадәтбану» исемле яңа җыр ишетә. Бу җыр аның күңеленә шул кадәр

хуш килә ки, ул: «Мин бу җыр турында бер әсәр язачакмын», ди. Шул елның җәендә үзенең туган яклары Малмыж һәм Татарстанның хәзерге Балтач районына кайта. Озак кына Шода авылында яши. Авыл яшьләре белән аралаша. Аларның чишмә буйларындагы уен-көлкеләрен, җыр-биюләрен күреп соклана. Нәтиҗәдә, хыялында йөргән «Сәгадәтбану» көенә карата сәхнә әсәре язу фикере формалаша һәм әсәр языла. Бу кечкенә тарихны шушы хәлләрнең шаһите Сәгыйт ага Фәйзуллин сөйләде.

«Сәгадәтбану» драмасы 1917 елда Оренбургта куелырга тиеш була. Әсәрне сәхнәгә куючы режиссер Вәли Мортазин-Иманский киңәше белән «Сәгадәтбану» «Галиябану» га алыштырыла.

Драмада «Сәгадәтбану» [хәзер инде «Галиябану»] көен әсәрнең төп образы үзе чыгарган итеп күрсәтелә:

«Ай, шушы көй, өзә бит минем үзәкне. Бер көн кайдан, күкрәгемнең кайсы җиреннән алып кына җырладым икән соң мин бу көйне. Инде менә үз исемемне кушып җырлый башладылар. Мин аны үземнең сөйгәнем өчен генә җырлаган идем; ул каршымда булган вакытта гына җырлый алган идем бит...» ди ул.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без «Галиябану» көенең баштагы исеме «Сәгадәтбану» булуын, аның 1916 еллар тирәсендә генә чыгуын һәм «Галиябану» буларак безнең совет чорында гына, Мирхәйдәр Фәйзи әсәре буенча гына киң популярлык алуын раслый алабыз.

«Катлаулы көйләр»нең эндәш сүзләре тәрәнә кергән бу «Галиябану» көе, үзенең форма тегәллеге, интонацияләренең яңалыгы белән композиторларыбызның иҗат игътибарын җәлеп итте. Аның интонацияләрен без Нәҗип Җиһановның «Алтын чәч» һәм «Намус» операларында ишетәбез. Рөстәм Яхин аны үзенең фортепиано өчен концертында файдаланды. Ниһаять, Мансур Мозаффаров Ә. Ерикәйнең М. Фәйзи мотивлары белән файдаланып язылган «Галиябану» либреттосына операсын иҗат итте. Ул опера 1940 елда безнең театр сәхнәсендә куелды. Соңгы елларда М. Мозаффаров аның икенче редакциясен тәмамлап калдырды. «Галиябану» драмасына Салих Сәйдәшев тә, Александр Ключарев та музыка яздылар. Аларның «Галиябану» увертюралары хәзерге көндә дә концерт программаларында урын тота. Әнә шундый бәхеткә ирешеп мәңгеләште ул «Галиябану» көе.

## 101. Асылъяр




Әйдә барыйк сахраларга, сахраларга,
Гөлләр араларына, Асылъяр;
Асылъяр, гүзәлем,
Өзелә лә үзәгем.
Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына, Асылъяр.
Асылъяр, күгәрчен,
Күрми ничек түзәрмен.
Яшьлек безнең багыбыз, багыбыз,
Гөлләр үпкән чагыбыз, Асылъяр,

Матур яр, кошкаем,
+
Аерылабыз, дускаем.
Түтәлдәге гөлләр кебек, гөлләр кебек,
Гөрләп үскән чагыбыз, матур яр,
Асылъяр, аппагым,
Ни теләгең бар тагын?
Агыйделне киң диләр, киң диләр,
Яр буйлары җим диләр, җим диләр,
Матур яр, кенәри,
Бергә булырбыз әле.
Сөймәгәнне димлиләр, димлиләр,
Без сөйгәнне белмиләр, Асылъяр.
Асылъяр, сандугач,
Сагынып кайттым, ишек ач!

* * *

Бу көй шушы исеме белән 1920 елда Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр» пьесасы сәхнәгә куелганнан соң халкыбыз теленә керде. Асылда ул бик күптән чыккан көй. Кайчандыр «Матур яр, кенәри» дип аталган. Моның шулай булуын Н. Надировның «Татар халык җырлары» китабыннан да күрәбез [1965 ел. 157 бит]. Җырның искәрмәсендә аның 1907 елда Казанда басылган «Менә диген шәп җырлар» китабының беренче бәйләменнән алынганлыгы күрсәтелә. Сүзнең, мегаен, шушы җыр турында баруы: «Матур яр, кенәри» җыры «Асылъяр» диген исем белән дә йөри» диген искәрмә белән дә раслана.

А. Ключарев бу көйне «Никрутлар җыры» дип саный. «Татар халык көйләре» җыентыгына ул аны «Асылъяр, кенәри» исеме белән һәм шул эчтәлекне ача торган сүзләре белән урнаштырган. [1941 ел. 89 бит]. Көенең ике вариантта язылуы, типографик хаталар очравы көйнең сафлыгына комачаулык китерә. Дөрес, А. Ключарев үзенең икенче китабында бу кимчелекләрдән арынган һәм аны Гөлсем Сөләйманова җырлаганча урнаштырган [1955 ел. 100 бит].

Мин исә бу көйнең тарихын егерменче гасыр башы белән генә чикләмәс идем. Ул борынгырак көй булырга тиеш. Чөнки И. Надировның шул ук китабында борынгы дәфтәрдән күчереп алынган тагын бер «Матур яр» исемле җыр урнаштырылган [175 бит].

Озын көйләр калыбындагы бу җырның икенче, дүртенче юлларындагы өчәр иҗекле сүзләрнең кабатлануы нәтиҗәсендә, алар 12 иҗекле булып күренәләр. Хәлбуки, өчәр иҗекле ул сүзләр көйгә яраклашу өчен генә шулай кабатланырга мәҗбүр булганнар. Бәлки, шул өстәлүләр тора-бара «Матур яр» диген өч иҗекле мөрәҗәгать сүзләре белән алыштырылганнардыр. Шулай булмаса, ни өчен соң бу җырның исеме «Матур яр» булып та, әлеге сүзләр җыр текстында юк!.. Димәк, кайчандыр «Матур яр» диген көй булган. Бәлки, А. Ключаревның беренче китабындагы Исмәгыйль Мусин тапшырган көйнең беренче вариантындагы кайбер мотивлар шул борынгы «Матур яр»ның истәлекләредер!..

Ни булса да бу көй, бик борынгы булып, үз гомерендә өч үзгәреш дәвере кичергән диясе килә. Беренче дәвер эндәш сүзсез озын көй, икенчесе — эндәш сүзле катлаулы көй һәм өченчесе — хәзерге хәлендәге, кушымта сыман эндәш сүзләрен эченә алган форма.

Халык җырлары, халык көйләрен ифрат хөрмәт иткән драматург Мирхәйдәр Фәйзи «Галиябану»дан соң, бу көйне дә күздә тотып, 1920 елда «Асылъяр» пьесасын яза. Шушы көйгә ул Шәрәф белән Ләләне җырлата. Бу ике мәхәббәт шушы көй белән вакытлыча аерылышалар һәм шушы көй белән, мәкер-явызлыкларны җиңеп, кавышалар.

«Асылъяр» көенең халык тарафыннан чыгарылган җырлары бик күп. Аларны төрле китапларда очратырга мөмкин. Нигездә алар, М. Фәйзидәгечә, турылыклы мәхәббәт турында сөйлиләр.

+ бергә килгәндә, сузык аваз йотыла һәм яңа аваз ясала.

# 102. Хәмдия




Тәрәзәләрдән караган, ай, караган,
Түшләренә мәрҗән кадаган.

Кушымта:

Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы.
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы.

Яргынай булып яралмаган,
Җаннар көйдерер өчен яралган.

Кушымта.

Су буена чыклар төшкән, чыклар төшкән,
Иртә үк тә генәй суга кем төшкән?

Кушымта.

Синең миңа буласың юк, буласың юк,
Мәхәббәтем сиңа ник төшкән?

Кушымта:

Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы.
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы.

* * *

**Мирхәйдәр Фәйзи 1923 елда үзенең өченче музыкаль әсәре «Ак калфак»ны яза. Кайбер иптәшләр бу драмада да «Хәмдия» көенең тарихы язылган дип уйлыйлар. Бу дөрес түгел. М. Фәйзи бер вакытта да әсәрләрендә көйләрнең чын тарихларын**

язуны максат итеп куймаган. Көйләр аның әсәрләренә музыкальлекне көчәйтер өчен зарури компонент буларак кына кергәннәр.

«Галиябану», «Асылъяр» көйләре турында сөйләнде инде. Драматург ул әсәрләрне нәкъ шул көйләргә таянып язган. Моны авторның: «...Урамнан «Галиябану» көенә», яки «Шәрәф... «Асылъяр» көенә» дигән ремаркалары да раслый. «Хәмдия» көенә карата исә андый күрсәтмә юк. Чөнки «Ак калфак» драмасы сәхнәгә куелганга кадәр «Хәмдия» исемен йөрткән көй булмаган. Моны карт музыкантыбыз Мөхәммәт ага Яушев та раслады.

Алай булгач, бу «Хәмдия» көен спектакль өчен махсус чыгарганнармы әллә! Бәлки, М. Фәйзи үзе дә шуны өмет иткәндер! Әсәрнең төп образы Хәмдиянең: «Ах, Тәфтиләүләр, Ашказарлар, Мәдинәкәйләр кебек минем дә үз көем булса!.. Мин исемемә көй чыгаручы егетне мәңге иркәләр идем. Ах, никадәр телим үз атыма бер көй булуын» кебек сүзләре шул хакта сөйлидер!.. Һәрхәлдә, «Ак калфак» драмасының билгеле бер көйгә нигезләнеп язылмаганлыгы ачык. Хәзер безгә билгеле «Хәмдия» көенең җыр үлчәүләре дә моны раслый. Аның көе 12—9 һәм 8—7 үлчәүле җыр калыбына гына туры килә, М. Фәйзидә исә, 9—9 һәм 8—7 үлчәүле җырлар. Шуңа күрә:

Тәрәзәләрдән, ай, караган,
Түшләренә мәрҗән кадаган,—

дигән юлларны сәхнәдә җырлаган артистлар да, халык та:

Тәрәзәләрдән караган, ай, караган,
Түшләренә мәрҗән кадаган,—

дип җырлыйлар. Җырның кушымта өлеше үзгәрешсез.

Әгәр дә берәр музыкант «Хәмдия» көен язган булса, ул авторның җыр үлчәвен бозмаган булыр иде. Мондый ритмик үзгәреш җыр сүзләрен нинди дә булса билгеле бер әзер көйгә яраклаштырган чакта гына була ала. Чыннан да, тикшерә торгач, «Ак калфак»тагы «Хәмдия» көе күптән билгеле «Шакир солдат» көенең бераз үзгәргән варианты булып чыкты.

Мөхәммәт Яушевның сөйләвенә караганда, «Шакир солдат» революциягә кадәр төрле инструментларда уйнала торган көй булган. Аны «Сәйяр» драма труппасы каршындагы милли оркестр да бик еш башкарган. 1924 елда, Казанда, «Ак калфак» драмасын сәхнәгә куйганда Бакый белән Хәмдия мәхәббәтләре әнә шул «Шакир солдат» көенә җырланган икән. Соңыннан гына ул, бераз үзгәрә төшеп, «Хәмдия» булып йөри башлаган. «Шакир солдат» көе егерменче елларда «Талга басып» исеме белән дә билгеле иде.

Талга басып, тал тибрәтеп
Сайрый сары сандугач.
Җырлау түгел, еларсың да
Өзелеп-өзелеп сагынгач,—

дигән кушымта белән җырлаганга, аны шулай атаганнар булса кирәк.

Бу җырны Әхмәт Фәйзи үзенең «Качкын» либреттосына керткән. Нәҗип Җиһановның операсында бу көй Кирәмәт белән хор башкаруында дулкынландыргыч көчле яңгырый.

«Хәмдия» җыры безнең халык теленә бик күптәннән кергән булса да, сүзләренең төзелешен бозып, көенә үзгәрешләр, кыскартулар кертеп башкарулар хәзер дә очрый әле. Минем карашымча, А. Ключарев язмасы арада дөресе. Ләкин көйне тапшыручы артистка Динә Сираҗетдинова сүзләрне көйгә җайсыз урнаштырган. Җырның ритмик төзелеше 8—12 булып чыккан. [Татар халык көйләре. 1941 ел. 125 бит]. Шул ук җитешсезлекләрне Әнһәр Абдуллин да кабатлый [Вопросы татарской музыки. 1967 ел. 9 бит]. Мин сүзләрне редакцияләп, көйне үзем белгәнчә язып урнаштырдым.

«Хәмдия» катлаулы көйләрнең кушымталы төренә керә.

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ ҖЫРЛЫЙ

*Башкортстан татарларының авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү буенча Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы зур эш алып бара. Татарлар яшәгән районнарга татар бүлегендә укучы студентлардан һәр ел саен махсус экспедицияләр оештырыла, читтән торып укучылар да бу мөһим эшкә җәлеп ителә. Нәтиҗәдә, кафедра карамагында хәзерге көндә бик бай фольклор материаллары саклана. Әлбәттә, күпкырлы бу бай иҗат әле ныклап тикшерүне, күмәк көч белән тәртипкә салуны сорый. Шулай да аларның үз вакытында язып алынуы бик әһәмиятле булуы бәхәссез. Без хәзергә укучылар игътибарына Башкортстанның төрле районнарында 1968 елда язып алынган берничә борынгы җырны тәкъдим итәбез. Алар тематикасы белән төрлеләр, художество эшләнеше ягыннан да бер дәрәҗәдә түгелләр. Әмма халыкның бай рухын, олы талантын күрсәтү җәһәтеннән, һичшиксез, игътибарга лаеклар.*

**Риф МӨХӘММӘТҖАНОВ,**
Башкорт дәүләт университеты укытучысы,
фольклор экспедициясе җитәкчесе.

## Көчләп бирелгән кыз

Кыз: Астымдагы менгән күк толпарым
Аяклары таеп сөренде.
Күк толпарга карап уйлап торсам,
Әҗәл генәм якын күренде.

Ата: Толпар тайса, балам, ат табылыр,
Ата сүзен истән чыгарма.
Тәңре хакы, диләр, ир хакында,
Киявемне кулдан җибәрмә.

Кыз: Тәңре хакы иткәч, бала иткәч,
Ник соң күз яшемне күл иттең.
Алтмыш яшьлек картка көчләп биреп,
Ник соң балаң хакын оныттың?

Ата: Тыңла атаң сүзен, куйма, балам,
Сакла хәтереңдә ир хакын.
Ахирәттә рәхәт күрә алмас
Тыңламаган хатын ир затын.

Кыз: Яшь башымны бәйләп карт кияүгә,
Сөргәме аны тиң итеп?!
Үз сөйгәнен эзләп типкән йөрәк
Рәхәт күрмәс бәхет, мал көтеп.

Ата: Урнаштырдым сине, хур булмас дип,
Дәүләт эре кунган бай җиргә.
Өстең бөтен булыр, тамагың тук,
Шат булырсың, балам, гомергә.

Кыз: Син ата дип тордым, хөрмәт иттем,
Яшь башыма савап алам дип.
Аяусызлык иттең, малга саттың,
Зинһар, әйтмә миңа балам дип.

Бәләбәй районы Яңа Шах авылында яшәүче 64 яшьлек Хөсәен ага Баязитовтан язып алынды.

## Ике җирән, пар кашка

Атлар чаба такырдин,
Дагалары бакырдин,
Дусларым,
Үзем җырлыйм, үзем елыйм,
Ахры, язам акылдин.

Ике җирән, пар кашка,
Басып тора вак ташка.
Ашый да алмыйм, эчә дә алмыйм
Сез дусларымнан башка.

Атым арый башласа,
Дага юклыктан күрәм,
Дусларым,
Юлга чыксам, юлым уңмый,
Бәхет юклыктан күрәм.

Ике җирән ат симерттем,
Гөл яфрагы ашатып.
Инде кемнәргә карармын
Сез дусларга охшатып.

Яшел тарантас, җиктем пар ат,
Җибәрдем чәчем тарап,
Дусларым,
Чыкты озата, калды карап,
Сау бул, җаныем, дип елап.

Туп-туп баскан туры атлар
Урта юлга бер баса.
Ялгыз башым нишләр иде
Сез дусларым булмаса.

Чакмагыш районы Иске Калмаш авылындагы 97 яшьлек Мәфтуха әби Акчуринадан язып алынды.

## Айһайлүк

Берне генә куйдым,
Дүртне генә куйдым,
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү
Яланнарда кибәнем.
Айһайлүк!
Чатта сайрый пар чыпчык,
Дусларың килгәч, каршы чык[1].

Берәү генә калды,
Бик жәл калды,
Берәү калды, бик жәл калды
Чит илләрдә туганым.
Айһайлүк!
Чатта сайрый пар чыпчык,
Туганнар килгәч, каршы чык.

Бәләбәй шәһәрендә яшәүче ирле-хатынлы Хәмзә һәм Сафия Тажиевалар яздырган бу җырның да көе борынгы булырга тиеш. Җырлап күрсәтүчеләр: «Без аны Оренбург якларындагы картлардан отып алып кайттык», диделәр.

## Киек казлар

1. Ерак җирдин бугай килә очып
Тәмам арыган ялгыз киек каз.
Киез каз.
Оча да ул туктап, туктап кына,
Тагын оча хәлен җыеп аз,
Җыеп аз.

2. Үзе артта калган, җиргә карый,
Белмим нидән, һаман каерылып,
Каерылып[2]... . . . . . . . .

3. Туган илләремдин мин аерылдым.
Сахраларга чыгып югалдым,
Югалдым.
Өзелеп төшкән мескен гөлчәчәктәй,
Мин дә өзелеп сулдым, уңалдым[3],
Уңалдым.

4. Бармыйм дидем, әнкәй, син, бар, диден —
Мәҗбүр иттең шундый сәфәргә,
Сәфәргә.
Үз иркемә куймыйча, көчләп үк
Салдыгыз ла утлы хәтәргә,
Хәтәргә.

Бу җырны яздыручы Хәлимә апа Әсхәдуллина. Тәтешле районының Зиримзибаш авылыннан.

---

[1] Соңгы өч юл (кушымта) ике тапкыр кабатлана.
[2] Бу куплетның азагын Хәлимә апа хәтерләми. Белүчеләр булса, хәбәр итәрләр дип ышанабыз.
[3] Уңалдым — төсем уңды мәгънәсендә (редакция).

## Мыртин тавы

Кошлар да чыгар Мыртиндин,
Мыртин тауларының артындин.
Инде үкенсәк тә җитәлмабыз
Яшьлек гомерләре артындин.

Сикереп тә мендем мин тирәккә,
Тирәк яфраклары кирәккә.
Тирәк яфракларын дару диләр,
Уттай дөрләп янган йөрәккә.

Алты атлар җиктем, берләр сабан,
Урта буразналар бер табан.
Бергә йөрүләре — бер-бер заман,
Аерылышулары бик яман.

Бакалы районының Бәжыр авылындагы Куприян Сергеевич Кутлин агайдан язып алынды.

## Киҗелекәй чаршау

Киҗелекәй чаршау, чите бурлат,
Теккән җебе аның күпме икән?
Узган гомеремнең юк хисабы,
Киләчәктә гомерем күпме икән?

Кыйблалардин искән, ай, җилкәйләр
Толпар башкайларын селкетә;
Картаелгач тормыш бигрәк авыр,
Карт йөрәккәйләрне җилкетә.

Аргы яккайларның ай шепкәнен,
Җилләр кагып китә җиткәнен.
Белми генә калдым, күрми калдым
Яшь гомерләр кая киткәнен.

Миркә районы Сатый авылында торучи Гани Абдуллин бабай белән Җиһан Ногманова әбидән язып алынды.

# ШИФАЛЫ ЯҢГЫР

Караңгы күк гөмбәзен чәлпәрәмә китереп, тармакланып-тармакланып, яшен яшьни. Утлы камчылар әле бөтен офык буенча сызылып китәләр, әле уктай кадалып җиргә төшәләр. Нәрсәдер булыр сыман, табигать нидер көтә. Бераздан баксаң, бернәрсә дә: давыл да, җил дә, яңгыр да юк. Бары тик кайдадыр еракта-еракта, ялгыз юлчының шырпы сызуын хәтерләтеп, мескен генә, хәлсез генә ниндидер ут җемелдәп-җемелдәп куя.

Икенче вакыт яшен сабыр-салмак яшьни. Агачлар да алай нәрсәдер көтеп шауламыйлар. Әмма һич уйламаганда шыбырдатып яңгыр ява башлый. Урманнарны, басуларны рәхәтләндереп, аларга тәкәнмәс яшәү көче биреп ява ул. Төн буе ява, авыл картлары иртән: «Менә, ичмасам, яңгыр», дип әйтерлек булганчы ява.

Нәби Дәүли поэзиясен әнә шундый сабыр-салмак яңгырга охшатам мин. Яшеннәре алай искиткеч ялтырамаса да, яңгыры рәхмәтле, шифалы аның. Сүз Нәби Дәүли әсәрләренең беренче томы хакында бара.[1] Иң әлек китапның оформлениесенә тукталыйк. Андагы шигырьләрнең аерым темаларга бүленмәве яки классик әдипләребезнең сайланма әсәрләрендәге шикелле хронологик тәртипкә салынмавы укучыга гомуми нәтиҗә ясарга күпмедер дәрәҗәдә комачауласа да, китап матур чыккан. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты да тулысынча яктыртылган, рәсеме дә бирелгән. Тышлыктагы «Н» һәм «Д» хәрефләрен кара белән язу гына ничектер бераз сәеррәк. Ирексездән, эх, яшел фонда көмеш кенә булсачы, дип куясың.

Инде китапның эченәрәк керик. Нинди мөһим проблемалар күтәрә соң шагыйрь үзенең әсәрләрендә? Укучы күңеленә нинди эстетик орлык сала, аңа нинди рухи ләззәт бирә? Шигырьләрнең тәрбияви тәэсире нинди? Шагыйрьнең гражданлык хисе ни дәрәҗәдә олы? Кая чакыра, нәрсәгә өнди ул укучыларны? Хәзерге чорда, социалистик идеология белән буржуаз идеология арасында кискен көрәш барган чорда, совет поэзиясеннән таләп ителә торган сорауларның иң әһәмиятлеләре әнә шулар.

Китап торналар артыннан йөгереп, ләкин аларны куып җитә алмыйча, җиргә егылып калган һәм шул көнне тәүге тапкыр үзенең җиргә мәңгегә бәйле икәнлеген тойган малай турындагы шигырь белән ачылып китә. Шигырьнең күләме гаять дәрәҗәдә кыска. Әмма никадәр тирән, мәгънәле фикер салынган аңа. Җир язмышы, җирнең бүгенгесе, киләчәге өчен борчылу — менә шул инде Нәби Дәүлигә илһам бирә торган төп чыганак.

Ташка җан өргән кешеләргә мәдхия, кеше акылына баш ию, азатлык өчен көрәштә корбан булганнарга дан җырлау кебек мөһим темалар Нәби Дәүли поэзиясендә предметсыз риторика, рифма сугыштыру өчен генә күтәрелмиләр. Шагыйрь үзенең әсәрләрен югары накал белән, кичереп, шагыйрь булып яза. Әйтәсе сүзен ул йөрәгендә инде тәмам өлгереп җиткәч, хисләре ташый башлагач кына кәгазьгә төшерә:

Поездлар килә дә китә,
Дусларым кайтмый һаман.
Окоплар төшә исемә,
Авырта әле ярам.

Нәби Дәүли поэзиясенең тагын бер үзенчәлекле матур сыйфаты бар. Аның күп кенә шигырьләре гади хезмәт кешесе белән киңәш, җылы аңгәмә формасында ага. «Шигырь язу икмәк чәчүдән читенрәк» булса да, шагыйрь үзенең авыр, җаваплы хезмәте белән масаймый. Киресенчә, кышкы зәмһәрир салкыннарда буран арасында йөргән колхозчы хатын турында уйлый, буровойда эшләгән дустын искә төшерә:

Ул әйтер кебек: — Синең өеңдә
Җылы да булсын, якты да булсын.
— Җылы да миңа, якты да миңа,
Сиңа вышкада салкындыр, дустым.

Яңа йорттан фатир алган иптәшенә үгетнәсихәт бирә, улын сагынган карчык-ананы юата:

Җыр юлы авыр, җыр юлы ерак,
Давыл булса да, һаман барасы.
Улың кайтмаса — саргайма елап,
Шагыйрь анасы — солдат анасы.

Мондыйлар рәтенә «Матурлык турында», «Оныкларым белән сөйләшү», «Архимедка хат» һәм башка бик күп шигырьләрне кертергә була.

«1945 ел шигыре» исә лирик бизәкләрнең төрлелеге, элегик кичерешләрнең байлы-

[1] Н. Дәүли. Сайланма әсәрләр. I том. Казан. 1969 ел.

гы белән әлеге шигырьләрдән аерылып тора. Шигырь сугыш бетү вакыйгасы белән башланып китә:

Солдат яткан окопларда
Ямь-яшел чирәм үсте.

Бу — гади сүзләр генә түгел. Бу — җиңү, тынычлык аккорды. Сугыш бетте, ләкин аның канлы эзләре, җуелмас тирән җәрәхәтләре калды. Менә шуңа күрә дә, шигырьдә әле һаман бөек тантана тасвирланса да, шатлык вагъдә иткән строфаның өченче юлында ук кискен борылыш ясала:

Ә син нигә шатланмыйсың,
Ник моңайдың, Нәфисә?

Бу — кайгы белән шатлык арасындагы чик. Нәфисәнең сөйгәне яу кырында мәңгелеккә ятып калган. «Нәфисәнең кайгылары китәрлек түгел».

Күз яшьләре тамчы гына,
Ташка тамса — таш сизәр!
Таш сизәрлек кайгыларга
Нәфисә ничек түзәр?

Шигырь шул урында тәмамланса, күңелдә пессимизм хисе калыр иде. Әмма, бәхеткә каршы, автор Нәфисәнең биртек күңеленә сак кына, йомшак кына кагылып уза. Тол хатын... Тол кәләшкә ата булып та, иптәш булып та, шагыйрь булып та эндәшә:

Синең генә килгән кайгы түгел,
Я, елама инде, Нәфисә.

Әнә шулай әкренләп Нәфисәнең шәхси кайгысы ил кайгысына барып тоташа. «Син генә түгел, ил белән бит» дигән фикер елаучыга юатучы тарафыннан ышандырырлык итеп төшендерелә. Шигырь моның белән генә дә чикләнми әле. Нәфисәнең күз алдына сугыш картиналары бөтен дәһшәте белән килеп баса. Юатучы исә һаман сөйли:

Җир дә язын чәчәк атмас иде
Ул солдатның каны таммаса...

һәм, ниһаять, югары башлаган хәсрәт болытларын аралап, оптимизм кояшы нур сибә:

Күтәрергә безгә шәһәрләрне
Ташлар гына калган өемнән.
Елаудамы безнең яшәү яме,
Нигә безгә йөрәк бирелгән?

Нәби Дәүли — яшәү белән үлем арасын узган шагыйрь. Шуңа күрә дә аның тормыш, туган ил, икмәк турындагы шигырьләре аеруча тәэсирле, көчле, пафослы яңгырыйлар. Шагыйрь җирдәге һәртөрле җәберләүләрне, гаделсезлекләрне күрә алмаган кебек, кеше гомерен талап яшәүче тираннарны, мәкерле сугыш чукмарларын, комсыз Гансларны, гайбәтче Гарриларны да рәхимсез фаш итә.

Нәби Дәүли — киң диапазонлы шагыйрь. Аның политик, сатирик шигырьләре дә, балладалары да бер үк дәрәҗәдә уңышлы. Сатирада усал, юморда күңелле, лирикада моңлы, ләкин, шуның белән бергә, бөтен йөрәге белән оптимист шагыйрь Нәби Дәүли. Шагыйрьнең:

Кем булсам да, яшәү матурлыгын
Табар идем хәтта сахрада.
Пессимизм дигән микробларны
Йөрәгемә салып асрамам, —

дип әйтүе буш сүзләр генә түгел.

«Авыл дәфтәре» Нәби Дәүлинең иң уңышлы әсәрләреннән берсе дисәм, хата булмастыр. Поэмамы ул, әллә егермеләп новелланы берләштергән шигъри романмы? Жанры буенча ни генә булмасын, бу әсәрнең һәр битендә тыгыз динамика, гармоник камиллек бар. Әсәр Нәби Дәүли поэзиясенә генә хас шигъри аһәң, авыл кешеләренә тирән мәхәббәт белән сугарылган. Әсәрдә табигать күренешләре белән философик тәсмерләр, лирик детальләр белән юмор элементлары бер бөтен булып үрелгән. Иҗтимагый проблемалардан алып нәни нюансларга кадәр бер олы максатка — коммунизм идеалларын тормышка ашыру максатына буйсындырылган. Монда, күрәсең, шагыйрьгә милли колоритны яхшы белү, халыкның сөйләм теленә таяну да зур ярдәм иткәндер.

Дәфтәрнең беренче битендә үк сине назлы, юмарт авыл табигате үз кочагына алып тибрәтә башлый. Бернинди киртә, бернинди бусага юк. Әсәр үзеннән-үзе укыла, аны укыган саен укыйсы килә, укыган саен күңелдә ниндидер ямь, куаныч арта. Ә дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше өчен бу җырлардан узу икеләтә рәхәт. Андый кешенең:

Әгәр инде арса аякларым,
Шунда туктап мин ял итәрмен.
Мин окопта ятып белгән кеше
Җир түшәктән йомшак икәнен, —

дигән сүзләренә ышанмый мөмкин түгел.

Дәфтәрнең икенче бите борын-борын заманнан килгән изге дуслыкка — руслар һәм татарлар дуслыгына багышланган.

Кешенең тормыштагы роле, җәмгыятьтә тоткан урыны хакында фәлсәфи уйлanулардан, гыйбрәтле диалоглардан торган өченче бит өчен гражданлык мотивлары хас.

Докторымы син, әллә эшчеме син,
Дөнья кудың әллә бушкамы? —

дип сорый колхозчы хатын шагыйрьдән. Бу сорау шагыйрьне үз вөҗданы белән ачыктан-ачык сөйләшүгә этәрә, аның күңелендә бүгенге поэзиянең бурычлары турында тагын да тирәнрәк, тагын да җитдирәк сораулар туура сәбәпче була. Шагыйрь авылдашы белән гади әңгәмә алып бара һәм совет кешесенең бигрәк тә сәнгать осталарының идея-мораль сыйфатлары турында уйлана. Ниһаять, дәфтәрнең уналтынчы битендә, еләшчә булса да, әлеге сорауларның кайберләренә җавап табыла:

Начарларны яхшы кеше итү —
Поэзиянең бөек бурычы...

Берсеннән-берсе гүзәл эпизодлар алышынып, битләр берсе артыннан икенчесе ачылып тора, кабатланмас образлар, характерлар синең күңелеңә гомер буе онытылмаслык булып урнаша бара. Түбәсендә күгәрченнәр гөрләгән йортта яшәүче тату семья да, бал яратучы малай да, эшчән кызлар да, тынгысыз Хәсән бабай да, Мифтах та, Әпсәләм дә озакламый синең иң якын танышларыңа әвереләләр.

Китапта актуаль темага язылган әсәрләрнең тагын берсе — «Кеше турында монолог». Шагыйрь бу әсәрендә дә кеше турында, аның язмышы турында борчылып уйлана.

Әсәр тышкы эффектның бөтенләй сизелмәве, мәгънәви тирәнлеге, тәэсир көченең зурлыгы, публицистик детальләргә киң урын бирелүе, фәлсәфилеге, масштаблылыгы белән үзенчәлекле. Нәби Дәүли поэзиясендә бу әле — яңа күренеш. Димәк, шагыйрьнең киләчәктә тирән мәгънәле фәлсәфи поэзия өстендә эшләү, җегәрле әсәрләр тудыру мөмкинлеге бар.

Китаптагы сатира-юмор әсәрләре хакында азрак сүз булган иде инде. Кабатлап шуны әйтәсе килә: алар вак-төяк шалтыравык анекдотлар, мәзәкләр генә түгел. Аларның һәркайсында көлке пәрдәсе артына яшерелгән социаль мотивлар, әхлакый проблемалар ята, дөресрәге, алар тәрбияви көче, файдалы эш коэффициентының зурлыгы белән кыйммәтлеләр.

— Что же мин, начар кешемени?
Мин бит,— ди ул,— бывший бер эшче.
Коммунизм әгәр була икән,
Даешь миңа минем өлешне!..

Яки:

Сугышта түгел, өендә
Бер хәбәрсез югалдың,—

кебек юллар моның ачык мисалы булып торалар. Дөрес, арада «Әтәч турында тагын бер мәсәл» кебек примитиврак фикерләүгә корылган, сүлпәнрәк шигырьләр дә бар. Бәлки, аларны бик яхшылап кырку яки мондый солидный, күркәм китапка бөтенләй кертмәү мәслихәт булгандыр.

«Кесә дәфтәре» дигән бүлеккә тупланган шигырьләр үзләренең эмоциональ киеренкелеге, төрле ассоциацияләргә бай булуы белән күңелне җәлеп итә. Күп кенә шигырьләр турыдан-туры халык авыз иҗатына барып ялгана, канатлы сүз, афоризмнар булып хәтергә сеңеп кала. Мәсәлән:

Атом табу җиңелрәк
Чынлап сөйли белүдән...

Күзләре күрмәс булды,
Аягы йөрмәс булды,
Дөньяны белмәс булды,
Йөрәге үлмәс булды.

Муса Җәлилнең үлемсез образын гәүдәләндергән әсәрләр байтак инде бездә. Арада романтик биеклектән торып, символик сурәтләү чараларына таянып иҗат ителгәннәре дә, патетик рух белән сугарылып реализм күренешләреннән үрелеп язылганнары да бар. Нәби Дәүлинең «Берлинда окоп» дигән поэмасы соңгылар рәтендә. Башка әсәрләрдән нәрсәсе белән аерылып тора соң бу поэма? Беренчедән, әсәрнең буеннан-буена сузылган тирән моңы белән. Алда әйтеп киткәнемчә, Нәби Дәүлинең үзенә генә хас шигъри аһәң, гаҗәеп моң бу. «Ә мин моң төшенчәсен билгеле бер халыкның узган юлы, тарихы, җиреннән эзлим», — ди Сибгат Хәким. Патетика һәм моң. Бер караганда, болар икесе ике нәрсә кебек. Әмма шагыйрь аларны якынайта, хисләр диңгезенә салып синтезлаштыра. Нәтиҗәдә, патетикада декларативлыкның әсәре дә калмый, ә әлеге моң, киресенчә, сентиментальлектән, пессимизмнан тулысы белән арына. Икенчедән, (шагыйрь әсирлекнең коточкыч газапларын үзе кичергәнгәдер, мөгаен), поэмадагы барлык ситуацияләр дә урынлы, табигый. Әсәрне Мусаның күзгә күренмәс җан дусты, аның вөҗдан тавышы булып, һәрвакыт аңа эндәшү, аның белән сөйләшү формасында язу бу табигыйлекне тагын да көчәйтә төшкән. Өченчедән, лирик чигенешләрнең, чит ил сүзләренең юмор элементларының мул булуы поэмадагы мөһим эпизодларның вакланууына, вакыйгаларның торгынлыгына китермәгән. Поэма — гомумхалык биеклегендә, поэма — хәрәкәттә. Поэманың йөрәге герой йөрәге белән бер ритмга тибә.

Нәби Дәүли поэзиясе — аерым хезмәткә, махсус тикшерүгә лаеклы үзенчәлекле, күпкырлы поэзия. Аны бер мәкаләдә генә анализлап чыгу һич тә мөмкин түгел.

...Күңелдәге вак борчуларны, мещанлык тойгыларын куып чыгарган, олы тормышка мәхәббәтеңне бермә-бер арттырган бу китаптан аерылуы ничектер авыр. Әйтерсең лә, иң якын дустыңнан аерыласың.

**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.**

Фоат Вәлиев

# БОРЫНГЫ АРХИТЕКТУРАБЫЗ

Борынгы заманнан сакланган аерым истәлекләр, археологик казылмалар, әдәби әсәрләр, рус елъязмаларындагы мәгълүматлар, халык телендә йөри торган легенда-риваятьләр, шул чорны өйрәнүгә багышланган берничә фәнни хезмәт, ниһаять, сәнгать-архитектура үрнәкләренең соңгы вакытларгача сакланган элементлары буенча, гомуми генә булса да, борынгы архитектурабызның үзенчәлекләрен күз алдына китерергә мөмкин. Боларга тагын бу юллар авторының соңгы еллардагы тикшеренүләре дә өстәлә [Ф. Х. Вәлиев. XV—XVI йөзләрдәге Казан татарларының архитектурасы турында. «Тарих, филология һәм педагогика мәсьәләләре» җыентыгы. Казан, 1967, русча. Аныкы ук: «Казан татарларында орнамент». Казан, 1968 ел, русча].

XV йөзнең икенче яртысыннан башлап XVI йөзнең урталарына кадәрге чор эчендә Казан татарларының экономикасы, һөнәрчел җитештерүе һәм сәүдәсе генә чәчәк атып калмый, бәлки халыкның милли сәнгате, архитектурасы һәм гомумән культурасы да яхшыра, үсә. Дәүләтнең башкаласы Казан бик алга китеп, тиз арада Волга һәм Урал буйларының политик, культура үзәгенә әйләнә. Шәһәрдә ак таштан һәм кирпечтән монументаль пулатлар, караптылар салына. Дин, җәмәгать һәм гражданлык эшләрен башкару яки оборона максаты белән күп кенә агач биналар төзелә.

XVI йөзнең беренче яртысындагы Казан, Болгар дәүләтендәге шәһәрләр кебек үк, калын стеналар, хәрби манаралар белән чолгап алына. Кремльнең беренче класслы крепость булганлыгы, мәсәлән, рус елъязмаларында да искә алына.

«Казан каласы бик нык... ул җиде стена белән әйләндереп алынган, стеналар зур-зур һәм юан-юан имән агачлардан салынган... ул тирәләргә яу үтәрлек түгел» [Казанский летописец. Полн. собр. рус. летописей. XIX том, 119 бит].

Казан кремленең архитектурасы бик үзенчәлекле булып, шул заман кешеләрен сокландыра торган булган. Ул кремльнең стеналарын һәм хәрби манараларын карап-күзәтеп йөргән Иван Грозный, елъязмачының әйтүенчә, крепость стеналарының биеклегенә һәм чамадан тыш матурлыгына гаҗәпләнгән» [Н. Ф. Калинин. «Казань». Таткнигоиздат, 1955 ел, 38 бит].

Бу сүзләрдән Казан кремленең стеналары белән манараларының архитектур кыйммәте генә түгел, бәлки зур фортификацион әһәмияте дә бик ачык сизелә. Эчтәге хан сараена керү өчен кирпечтән бер биек манара салынып, аның дугалы аркасы

астыннан юл узган. А. Олеарий рәсеменнән күренгәнчә, бу арка XVII йөзнең беренче яртысына кадәр торган (шул ук китап, 56 бит).

Казан кремленең төньяк өлешендә хан сарае була, ә шәһәрнең калган өлешен феодал, бай сәүдәгәр, руханиларның утарлары, таш һәм агач каралтылары, пулатлары били. Шәһәрдә мәчетләр, сәүдә пулатлары, кәрван-сарайлар, базарлар, мавзолейлар, мунчалар күп була. Кремльнең тышында, бистәләрдә яшәүчеләр дә күп булган.

А. Курбскийның әйтүенчә, Казан кремленең эчендә «бик тә биек итеп таштан салынган патша пулатлары, мәчетләр булып, анда, үлгәч, патшаларны күмгәннәр...»

Мәгълүм тарихчы Ш. Мәрҗани язып алган бер риваятьтә әйтелгәнчә, Казан кремлендә бик зур һәм сигез манаралы җами мәчете булган (соңыннан бу мәчет җимерелеп, аның урынына Спас монастыре салына).

Русларның 1556 елгы җан исәбе алу кенәгәсендә (писцовая книга) күрсәтелгәнчә, кремльдә хан сарае, Ширин князьләренең сарае, кайчандыр дәһшәтле-мәһабәт Нургали мәчете, хан мәчете, берничә эре мавзолейның калдыклары һ. б. булган (хан сараеның калдыклары XIX йөз башларынача саклана. Хан ишек алдындагы җимерелгән 4 мәчет урынында Благовещение храмы салынган. Сөембикә манарасы янындагы Мөрәле мәчете дип йөртелә торган мәчет саклана, ләкин соңгарак сарай чиркәве итеп үзгәртелә).


Казан чоры архитектурасы борынгы Болгар традицияләрен үстереп дәвам иттерә, ләкин татар скульптура сәнгатенең алга үсешендә яңа эстетик концепцияләр дә күренә башлый, чөнки дәүләтнең чәчәк атуы, заман культурасы шуны таләп итә. Казан кремлендә сирәк-сирәк кенә ясалган археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Казан шәһәренең таш пулатларын төзүдә Болгар чорының төзелеш традицияләре нык саклаган. (Н. Ф. Калинин. «Известия КФАН СССР», Казан, 1955). Аерым биналарның калдыклары дәүләт башкаласындагы дини-культ биналарының шактый күләмле булуы хакында сөйли. Мәсәлән, сарай чиркәвенең күләменә карап, Мөрәле мәчетенең никадәр мәйданны биләвен чамаларга була: сарай чиркәве шул мәчет урынына салынган.

1860—70 елларда Казан кремлендә катлаулы гарәби (арабесковый) орнаментларга бай гипс архитектура детальләре, матурлап эшләнгән ишек-тәрәзә яңаклары калдыклары табыла. Шул ук вакытта табылган сырлы орнамент белән яхшылап бизәлгән XVI йөз кабер ташларын да искә алсак («Казан утлары», 1969, № 3), Казан ханлыгы чорының сәнгатендә һәм архитектурасында декоратив билгеләр «Көнчыгыш бароккасы» дип йөртелгән стильгә хас үзенчәлекләр барлыкка килүен күрәбез. Бу стильдә масса бик ваклана, декоратив яктан бүлгәләнә, формалар, сызыклар киеренкеләнә; орнаментларның да, архитектур формаларның да композицион чишелеше динамикалы төс ала, декоративлык, тантаналылык арта. Бу моментлар югарыда телгә алынган архитектур детальләрнең һәм кабер ташларының орнаментында да яхшы күренәләр; алар шул чордагы Казанның монументаль корылмаларында, биналарында чагылмый калмагандыр, әлбәттә.


Француз художнигы А. Бар тарафыннан үткән йөз урталарында Казан губернасының бер татар авылында рәсемгә төшереп алынган мәһабәт таш мәчетнең калдыклары да без тикшерә торган чор архитектурасының стилен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә («Нива» журналы, 1879, № 45, 881 бит. А. Бар рәсеменең фотосы «Казан утлары»нда бирелде: 1968, № 9).

Мәчетнең, А. Бар рәсеменә караганда, XVI йөзнең беренче яртысында салынган булуын күрсәтеп үтәргә кирәк (1 рәсем).

Архитектурасы һәм архитектур бизәлеше белән бу мәчет Идел-Кама буе болгарларының шундый ук биналарыннан да, соңгарак XVIII йөзнең ахырында һәм XIX йөзнең беренче яртысында җиткерелгән корылмалардан да аерылып, үзенә бер урын алып тора. Аның Болгар биналарын, аерым алганда, мәчетләр (мәсәлән, җами мәчете) белән якынлыгы шунда, ул озынча формалы нигезгә корылып, колонна-баганалар белән өлешләргә бүлгәләнгән; түшәме гөмбәзле, түбәсе ике кыеклы (реконструкциясен кара); манараның болгар архитектурасы өчен бик хас булган дүрт кырлы нигезе, кәүсәгә күчкәндә, өчпочмаклы яссылык рәвешендә «мәмлүкчә кыелган». Ә Казан татарларының XVIII—XIX йөзләрдәге таш мәчетләре белән (А. Бар рәсеменә таянып



XVI йөзнең беренче яртысындагы татар мәчете.
Художник А. Барның XIX йөз урталарындагы рәсеменнән реконструкция.



Авыл остасы тарафыннан ясалып, Әтнәдә табылган шамаил.




Казан арты мәчетләренең типик үрнәге. Үгез елга авылы.
Автор фотосы.

караганда) якынлыгы шунда, ул бер генә катлы түгел, ике катлы. Мондый катлылык Казан губернасының агач мәчетләренә хас (Казан ханлыгын рус патшасы яулап алганнан соң ике йөз ел буена диярлек мәчетләр әкренләп юк ителә. Тик XVIII йөзнең икенче яртысында гына яңадан мәчетләр салына башлый, чөнки крестьяннарның берничә тапкыр баш күтәрүләреннән соң патша хөкүмәте, татар руханиларына һәм яшь буржуазиягә, аларның турылыклыгына ышана башлап, эре авылларда гына мәчет салырга рөхсәт бирә).

Бу мәчет архитектурасының үзенчәлеге — манараның бина почмагына туры килүе. Бу композиция XVIII—XIX йөзләрдәге мәчетләрнең архитектурасында очрамый, ләкин ул булган булырга тиеш. Шул хакта, мәсәлән, XIX йөзнең икенче яртысында Һиндидер оста тарафынан шамаилгә төшерелгән бер авыл мәчетенең рәсеме сөйли (бу шамаил Татарстан дәүләт музеенда саклана. Ул 1923 елны проф. Н. И. Воробьев тарафыннан Әтнәдә табыла). Рәсемнең тагын бер әһәмияте бар: ул Казан татарларында күп манаралы мәчетләр булганлыгын раслый.

Манарасы почмакка туры килә торган мәчетләр XIV—XVI йөзләрдә Төркиядә, Кырымда һәм Мисырда, ягъни Казан ханлыгы белән культура, экономик мөнәсәбәтләр урнаштырган илләрдә киң таралган.

Манараның урнаштырылуында, А. Бар рәсеменнән күренгәнчә, Көньяк тәэсире сизелсә дә, аның формасы, югарыда аталган илләрдәге (бигрәк тә Мисырдагы) мана-




Фасадны борынгыча ике төстәге аралаш буй-буй сызыклар белән бизәкләү үрнәге. Арча.

Автор фотосы.

раларга билгеле бер дәрәҗәдә якын торса да, тулаем җирле сыйфатларга ия. Манараның нигезе дүрт кырлы, аннары түгәрәк, урта өлеше сигез кырлы, ә очы тагын түгәрәк. (1 рәсем.)

Манараның динамик композициясе декоратив бизәкләнгән булуы — Якын көнчыгыштагы мөселман илләре сәнгатенә хас булган «Көнчыгыш барокко» стиленең билгесе. Бу стиль үзенчәлекләре бүтән күренешләрдә дә чагыла. Аерым алганда, бу мәчетнең стенасы кирпеч белән ак ташны аралаштырып, декоратив буй-буй сызыклап салган һәм тәрәзә өсте гөмбәзләп (архивольт) эшләнгән. (Рәсемне кара.)

А. Бар рәсемендәге мәчет архитектурасының югарыда карап үтелгән үзенчәлекләре, әлбәттә, XVI йөздәге Казанның бүтән кирпеч-таш биналары архитектурасына да,



Казан арты авыл архитектурасындагы фронтон (кыек асты) уемның типик үрнәге. Бәхтияр авылы.

Автор фотосы.


һичшиксез, хас булган. Бу монументаль архитектура үзенчәлекләре, азмы-күпме үзгәрә төшеп, Казан татарларының авыл архитектурасында да чагыла һәм XIX йөзнең икенче яртыларына хәтле сакланып килә.

Бу хәл манараларның сигез кырлы һәм катлы-катлы итеп эшләнгән булуында (рәс. 3), мәчетләрнең аралаш ике төскә: (күк белән сары, сары белән яшел яки сары белән ак) буялган булуында күренә. Соңга табарак төрле төсләр кулланыла башлый. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: монументаль бина стеналарының бизәлешендә ал, сары һәм күк төсләр аралашмасын XIV—XVI йөзләрдәге Мисыр һәм Төркия архитектурасында да күреп була (бу архитектур система Византия архитектурасыннан күчә). Мондый төсләр XVI йөздәге Казанның монументаль корылмаларын бизәгәндә дә кулланылган булырга мөмкин.

Казан артындагы татар авылларына барып чыккан тикшеренүче авыл йортларының алды һәм фронтоны (кыек асты) декоратив бизәкләргә бик бай икәнлекне күреп таң кала. Мәсәлән, кыек астына кертеп эшләнгән монументаль характердагы уемнар шундый. Ул Идел буе халыкларының бүтән берсендә дә очрамый, тик Казан артында гына бар. Фасадны (алны) буй-буй сызыклап, аралаш төсләргә буяу да, эчкәре кертеп эшләнгән, очлы гөмбәзле яки кыеклы уемнар да (5 рәс.) Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорының кирпеч белән ташны аралаштырып төзү архитектурасына барып

тоташа. Бу уемнарның төп сызыклары Болгар архитектурасының, мәсәлән, Кара пулатның, шулай ук XVI йөз башы кабер ташларының шундый ук бизәкләренә якын тора («Казан утлары» журналы, 1968, № 7; 1969, № 3).

Кыеклы һәм очлы гөмбәзле формадагы уемнар һәм куышлар XVI йөзнең беренче яртысындагы Казан архитектурасында, Болгар архитектурасындагы кебек үк, монументаль биналар декорациясенең төп сыйфатларыннан булып, соңга табарак авыл төзелеше архитектурасына да үтеп керә һәм, ныклы архитектура традициясе рәвешендә, XIX йөз ахырларына кадәр саклана. Борынгы Казан культурасының бүтән күп кенә традицияләре кебек үк, бу архитектура традицияләр дә тора-бара татар руханилары, шулай ук татар җәмгыятенең югары әһелләре тарафыннан борынгы татар тормышы-



Нечкә агач колонналарга утыртылган аркалы авыл каралтыларының бизәлеш үрнәге. Олы Мәңгәр.


Автор фотосы.

ның «изге» күренешләре итеп карала башлый. Бу традицияләрне үзгәрешсез саклауда патриархаль авыл халкының, крестьяннарның билгеле бер консерваторлыгы да роль уйнаган булырга тиеш.

Казан артындагы борынгы ике катлы йортларның архитектур декорациясендәге үзенчәлек — бер яки ике куш нечкә колонна-баганаларга утыртылып, аслары төрлечә бизәлгән аркалар бик кызыклы (6 рәс.). Кайбер сәнгать белгечләре, мәсәлән, П. М. Дульский бу системаны Европа классицизмының рус үзенчәлеген дә эченә алган тәэсире дип карыйлар. Дөрес, бу тәэсир Казан артының бик күп авыл каралтыларында сизелә (бу яклардагы авылларда элек-электән үк йортларның зур проценты ике катлы була), ләкин игътибар белэнрәк өйрәнгәндә, шуны күрәсең: колонналарга утыртылган аркалар системасы борынгырак заманнан килә; ул — XV—XVI йөзләрдәге төрек тәэсирен дә эченә алган Кече Азия ордер системасының үзгәртелгән формасы булырга кирәк. Соңгарак, XVIII йөз ахыры һәм XIX йөз башларына таба, бу система рус классицизмындагы архитектур күренешләр белән кушылып, үрелеп китә. Шунысы бәхәссез, колонналарга утыртылган аркалы система Казан ханлыгы чорының монументаль корылмалар архитектурасында да гамәлдә булган.

Казанның ул чордагы декоратив формаларга һәм сәнгатьле бизәкләргә бай монументаль архитектурасы Казан арты авылларының архитектурасына да зур йогынты ясап, XVI йөзнең беренче яртысында ук инде аларда югарыда әйтелгән архитектур

формаларның, бизәлешләрнең барлыкка килүенә сәбәпче булә; бу архитектур сәнгать XIX йөзнең урталарынача сакланып, Казан татарларының үзенчәлекле авыл архитектурасы формалашуга китерә. Казан җирләрен яулап алырга килгән князь Курбскийның Арча тирәләреннән үткәндә әйткән түбәндәге сүзләре бер дә очраклы түгел: «Ул җирләрдәге... хан нәселләренең һәм югары түрәләрнең йортлары бик тә гүзәл һәм чын-чынлап таң калырлык [Сказания князя Курбского. Устрялов нәш. 1868, 23 бит]. XVI—XVII йөзләрдәге татар феодалларының һәм хезмәтчел крестьяннарның «йортлары» һәм башка каралтылары безнең замангача сакланмаган, ләкин, Курбский сүзләренә караганда, ул чордагы авыл архитектурасының булуы гына түгел, бәлки югары баскычта торганлыгы да күренә, исбатлана. Андый «чын-чынлап таң калырлык» йортларны, Казан артына барып чыксаң, сирәк булса да, бүген дә очрата аласың әле. Берәм-берәм генә булса да, мондый югары сәнгатьле борынгы йортлар Татарстанның бүтән якларында да очрый.



М. Г. Худяковның схематик реконструкциясе: XVI йөзнең беренче яртысындагы Казанның монументаль каралтылары.

Автор фотосы.

XVI йөзнең беренче яртысында яңа тип мәчетләр дә барлыкка килә: аларның манарасы катлы-катлы һәм очлаеп күккә сузыла [3 рәс.]. Бу мәчетләрнең архитектурасында композициянең ачыклыгы һәм гадилеге сокландыра, аларның пропорцияләре бик яхшы. Авыл осталарының агач мәчетнең үзенә бер төрле сәнгатьчә әйбәт рәвешен табуына хәйран каласың. Соңгарак — XVIII—XIX йөзләрдә — бу стиль Казандагы таш мәчетләрнең дә [Мәрҗани, Апанаев мәчетләренең һ. б.] өлгесенә әйләнә.

XVI йөз башларындагы Казан архитектурасы турында кайбер мәгълүматларны тагын М. Г. Худяков хезмәтләреннән табып була [«XVI йөз рәсемнәрендә татар Казаны»]. XVI йөзләрдәге рус иконографиясе материалларыннан да һәм XVIII—XIX йөзләрдәге Казан арты авыл архитектурасының үзенчәлекле үрнәкләреннән дә файдаланып, автор, якынча гына булса да, Казан кремлендәге шактый корылмаларның элек ничек булу рәвешен сурәтли [7 рәс.]. Худяков рәсемнәрендә кимчелекләр юк түгел, әлбәттә. Аерым алганда, күп кенә схемалар иконаларның шартлы рәсемнәреннән чыгып ясалганнар. Шулай булуга да карамастан, бу рәсемнәр шуны раслыйлар: XVI йөз башларындагы Казан архитектурасында борынгы Болгар архитектурасының шул чорларда яңарган формалары белән «Көнчыгыш бароккосы»ның стиль билгеләре үзенчәлекле рәвештә кушылып, үрелеп китә. Бу үсеш шул чордагы дәүләт сәнгатендәге гомуми алга китешнең чагылышы булып тора. Казан архитектурасының тагын да үсүе дәүләтнең Кырым һәм Якын көнчыгыш илләре белән тыгыз культура-экономик элемтәләренә дә бәйле.

Бу яңа, тормышчан үзенчәлекләр татар сәнгатенең архитектура өлкәсенә дә дөньяви рух үтеп керүен һәм, шул рәвешчә, үзенә бертөрле татар архитектура

сәнгате барлыкка килүен күрсәтәләр. Бу сыйфатлар, заманнар узу белән, күрше халыкларның архитектура сәнгатенә дә билгеле йогынты ясый. Мәсәлән, төрле декоратив бизәкләргә бик бай, формасы белән бик үзенчәлекле, югары сәнгатьле Казан монументаль архитектурасының стиле Мәскәүдәге Василий Блаженный чиркәвенең архитектур бизәлешендә чагыла. Бу чиркәү 1555—1560 елларда Казанны алу хөрмәтенә салына. Аның авторы — Посник — рус чорындагы Казан кремлен салучы. Князь Курбскийны сокландырган кебек үк, Посникны да, хәтта җимереккә әйләнгән хәлдә дә, Казан архитектурасы тирән дулкынландыра, үзенең гүзәллеге белән җәлеп итә. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: бу сәнгатьчә тәэсирләр — төрле төсләрнең буй-буй сызыклар рәвешендә аралашуы, эчке орнаменталь бизәкләрнең тоташтан булуы, күп төрле галереялар һәм аралыклар һ. б. Василий Блаженный чиркәвенең бизәлешендә үзенчәлекле рәвештә чагылдырылганнар. Чиркәүнең сигез (соңыннан гына тугыз) башлы булуына да хан чорындагы Казанның сигез манаралы җәми мәчетенең югары сәнгать көче тәэсир итми калмагандыр диясе килә. Бу уңайдан Казан татарларының бишәр манаралы мәчетләрен искә алырга кирәк. Шунысы да кызыклы: Шәрыкъ халыкларының шәһәр төзү практикасындагы 5 белән 9 саннары һәм дин-культ йортларының композициясе борынгы заманнардан бирле символик мәгънәгә ия булып, дини мифологиягә китереп бәйләнә торган булган.

Мәгълүм ки, Василий Блаженный чиркәве рус архитектурасының үзенә бертөрле үрнәге булып, Октябрьга кадәрге чорның кайбер тикшеренүләре аның архитектур сурәтендә татарчалык билгеләрен күрсәттеләр. Шунысы да игътибарга лаек: XVII йөз рус руханилары аерым культ храмнарының вертикаль рәвешендә очлаеп күккә сузылган булуына кискен каршы чыккан булганнар, чөнки, янәсе, алар татар манараларына охшыйлар.

Казан ханлыгының тарихи үсешендә татар халкының сәнгать культурасы, шул исәптән архитектурасы да, катлаулы юллар аша барлыкка килә, һәм бик югары дәрәҗәдә була. Әмма бу үсеш 1552 елгы вакыйгалар аркасында бүленеп кала, туктала. Тик XVIII йөз ахырларына таба гына аңа азмы-күпме юл ачыла, ләкин чикләүләр барыбер зур була. Фәкать совет чорында татар архитектура сәнгате чын мәгънәдә үсү мөмкинлеге ала.

## Хәсән Сарьян

# ФИНАЛ

хикәя

Курыкмагыз, кешедән түгел, үземнән көләм. Бу моннан бик күп еллар элек булган хәл. Ул чакны мин студент идем. Айлык стипендиям — ике йөз егерме сум. Иске акча белән, билгеле. Шуннан башка, беркайдан керер җире юк, чыгар җире генә күп иде. Аягыма көзге ботинка, башыма бүрек кирәк. Хәзер генә ул бик күп егетләр бүрексез йөри, ә без ул вакытта алай йөри алмый идек — көздән үк батырып киеп куябыз да майсыз салмыйбыз — модасы булмагач без гаеплемени? Бүрек белән ботинкадан тыш, өстемә дә берәр сырган фуфайка юнәтеп булмасмы дип уйлыйм. Ике йөз егерме сум стипендиянең ай саен йөз сумын калдырып барганда да, бүрек өчен бер ай, ботинка өчен ике ай, фуфайка өчен биш ай җыярга кирәк. Минем кебек башка егетләр, товар вокзалына төшеп, я ташкүмер, я бүрәнә ташыйлар. Ә мин... хикәя язам. Төннәр буе күз талдырып язам-язам да, иртән институтка чабам. Аннан — редакциягә. Ләкин минем бер хикәямне дә басмыйлар әле — илтә торам, кире кайтара торалар.

Ахырда, газетада эшләүче бер агай, минем хәлемә кереп, бер киңәш бирде:

— Бездә барыбер басмаслар, энем. Газет-журналлар, үзең беләсең, эллә ни күп түгел,— синекен бассыннармы анда, минекенме? Шулай булгач, син боларны Сәнгать идарәсенә алып бар. Алар филармония өчен шундый кыска-кыска гына көлке әйберләр ала торганнар иде.

Мин, булган хикәяләремне җыеп, катыргы папка эченә салдым да Сәнгать идарәсенә киттем (ул вакытта шундый идарә бар иде). Салкын көнле октябрь ае. Шулай да, янып-пешеп, театр бинасына урнашкан Сәнгать идарәсенә барып кердем. Бик зур, бик якты бер бүлмәдә кара-каршы өчәр өстәл куелган, өстәл саен берәр кеше утыра иде. Барысы да берьюлы миңа күтәрелеп карадылар. Мин каушап калдым, ишек төбенә басып каткан килеш, салкын тиргә төштем. Шунда, минем бәхеткә, уң тарафтан:

— Сезгә кем кирәк? — дигән тавыш килде.

— Миңа?.. Мин... юмористик хикәяләр алып килгән идем... Шуларны...

Мин карашымны өмет белән теге апага юнәлдереп тә өлгермәдем, икенче бер тавыш ишетелде:

— Монда килегез.

Мин урта өстәлдә утырган агай янына уздым. Ул бик ябык, ак чырайлы иде. Күңелемнән: «Кешегә мин дә шулай күренәмдер инде...» дигән уй узды.

— Я, нәрсә алып килдегез?

Мин кабаланып папкамны аның кулына суздым. Ул аны ашыкмыйча гына чиште, иң башта берәм-берәм хикәяләрне, аннары битләрен санап чыкты.

— Бер табаклы әйбер икән,— диде ул.— Ярый, иркенләп кенә укып чыгармын. Бу эштә һич ашыгырга ярамый. Фамилиягез ничек әле?.. Әһә, язылган икән. Адресыгыз да язылганмы?.. Молодец, бик ыксым егеткә охшыйсыз! Бер атнадан нәкъ шушы вакытта кереп чыгыгыз, яме. Мин булмасам, Нугайбәк агай кайда дип сорарсыз. Сөйләштекме?

Миңа бик ошады бу агай.

Бер атнадан соң, әйткән вакытын минутка минут туры китереп, Нугайбәк агай янына килдем. Ул минем хикәяләрне укып чыккан икән.

— Ничауа, ничауа! Бигрәк тә әнә теге Яңа Шомбай, Хуҗа Насретдин турындагылары ничауа! — дип мактап та алды.— Бөтенесе дә исән-сау үтеп китсә, мең ярым акча диган сүз! Студент кешегә ярап куя ул. Инде сезгә бәләкәй генә бер формальность үтәргә кирәк булыр: сез хәзер үк, бездән чыгыгыз да, Язучылар союзына барыгыз. Алар анда иҗат секциясе диган бер нәрсә җыеп, хикәяләрегезне тикшереп алсыннар да, безгә: «Тәкъдим итәбез» диган кәгазь язып бирсеннәр. Булдымы?..

Мин Язучылар союзына чаптым. Әдәби консультант шул чакны Союзга килгән берничә язучыны:

— Рәхим итеп, керегез әле! — дип чакырып алды да, мин шуларга кычкырып хикәяләремне укып чыктым.

Җиде хикәянең икесен яратып бетермәделәр, калган бишесе турында «тәкъдим итәргә» диелде. Икенче көнне мин, шул протоколны бастырып алдым да, кул куйдырып, Сәнгать идарәсенә йөгердем. Нугайбәк агай мине көтмәгән иде булса кирәк — бик аптырады:

— Бик ти-из!..

— Шу-лай! — дидем мин. Эчемә сыймаган шатлык белән, катыргы папканы өстәленә куйдым.

Ачты бу папканы, укыды бу протоколның иң соңгы өлешен.

— Әһе, икесен суйганнар икән,— диде.— Ярый, болай да меңнән артык алачаксыз. Сезнеке түгел, кайчак өлкәнрәк абзыйларныкы да шулай киселә. Аңа бер дә исегез китмәсен. Инде сезгә тагы бер формальность эшләргә туры килер: сез хәзер филармониягә чабыгыз. Дилбаева иптәшнең үзен күреп әйтегез, шулай-шулай дигез. Укып чыгып, безгә рәсми заявка бирсен. Ул анысын үзе белә инде. Курыкмагыз, курыкмагыз, без бар авторларны да аларга җибәрәбез. Чөнки бу әйберләр безгә түгел бит, филармониягә кирәк. Филармонияне беләсездер инде?.. Алайса ярый, хуш иттек — пока!

Дилбаева авырый иде. Ул бер ун көннән соң гына эшкә чыкты. Хикәяләрне алып калгач та әле, менә бүген укыйм, менә иртәгә укыйм дип, шактый йөртте. Инде тышта көзге суык, ачы җил ыжгыра иде. Минем башта җәйге кепка, аягымда брезент туфли — башы күн дә, үкчәсе күн. Ярый әле, башта чәч, аякта йон оекбаш бар. Чәчне алдырмыйм — хәзерге кызлар кебек, бик кадерләп кенә кепка эченә өеп куям. Бөтен шәһәр урамында миннән дә кызу йөргән кеше юк; кайсы көнне трамваена хәтле узып китәм. Суык шулай йөртә, суык!

Ниһаять, Дилбаева да укып чыкты әйберләрне. Ул да берсен яратмаган.

— Анысының финалы юк,— диде ул. Һәм, бик озак итеп, финал турында сөйли башлады: — Сәхнәдә укый торган һәр нәрсәнең финалы булырга тиеш. Газетага чыгарганда, бәлки, финалның ул кадәр кирәге дә юктыр. Әмма ләкин сәхнәгә — финалсыз әйберне чыгарып булмый. Чөнки газетаны аны укыганы укый, укымаганы — юк. Ә сәхнәдән сөйләгәнне барысы да тыңлый. Шуңа күрә һәр әсәрнең яхшы финалы бу-

лырга тиеш. Финалсыз әсәр — әсәр түгел ул. Кешеләр «ха-ха-ха» дип кенә көлмәсеннәр, финал аларны уйландырсын. Финал — аккорд ул!..

Шунда секретарь-машинистка миңа дигән заявканы басып кертте. Мин, кабат килергә язмасын, финалы шушы була күрсен иде дип, чыгып киттем.

Нугайбәк агай мине онытып бетерә язган иде инде, кабат сөйләп биргәч: — Ә-ә-ә!..— дип, исенә төшерде тагы. Союздан бик тиз урап килгәч аптыраса да, филармониядә бер ай йөрүемә бер дә аптырамады.

— Әһе, Дилбаева да берсен суйган икән. Ну, ничауа, ярты табаклык әйберегез калган әле монда.— Ул минем дүрт хикәяне, Союз протоколын, филармония заявкасын папкадан алды да җәһәт кенә аягына басты.— Сез утырып торыгыз, мин хәзер башлык янына кереп чыгам. Тик сорарга онытканмын, хикәяләрегез бер җирдә дә басылмаганмы?

Минем тән буйлап бер көтү таракан йөгереп төшеп киткәндәй булды. Әгәр, басылмаган дигәч, «басылмаганны алмыйбыз», дисә? Яки «нигә басылмады?» дип сорый башласа?.. Мин көчкә генә:

— Юк... басылмаган...— дидем.

— Басылмавы яхшы. Юкса без басылганны алмыйбыз,— дигәч кенә иркен сулап куйдым.

Ул чыгып китте.

Мин шевиот кепкамны өстәлгә куеп, туфли башына карап утырам. Утыз ике сантиметр киңлек чалбар балагымның үкчә ягы пычранып идәндә ята, алгы ягы туфлиемнең брезент йөзен каплап алган, миңа күн башлы очы гына күренеп тора. Икенче аягым читтәрәк — анысы бөтенләй ачык. Мин ул аякны да якынрак тарттым. Хәзер ике аягыма да күн туфли кигән кебек.

Нугайбәк агай да ишектән бик тиз килеп керде.

— Булды бу, энем! Менә күрәсезме, договор төзергә дип, мөбарәк куллар куелды.

Ул миннән дә бигрәк шатланган кебек иде. Аның шатлыгы секунды белән миңа да күчте: мин утырган җиремнән сикереп куйдым.

— Хәзер договор төзибез! — диде ул. Әллә каян гына бланкасын да тартып чыгарды.— Тә-әк, тулар-тулмас ун өч бит — димәк, ярты табак. Бер табагы мең ярымнан — җиде йөз илле сум. Студент кешегә ярап куя ул, шулай бит?..

Ул шул кадәр кычкырып сөйли, әйтерсең лә бу бүлмәдә бер ул гына инде. Теге биш кешенең әле берсе, әле икенчесе безгә карап куя, алар караган саен мин аягымны урындык астынарак җыя төшәм, ахырда балак эченнән туфлинең очлары да күренмәс булды.

Ниһаять, без ике данә итеп договор төзедек. Мин һәр икесенә кул куеп чыктым. Нугайбәк агай иң түрдә утырган юан бер апага дәште:

— Нина Ивановна, менә бу егетнең бездән акча аласы булачак, кайчанрак килсен дип әйтим?

— Через недельку...

Мин коштай очып чыгып киттем. Институтка да коштай очып кына йөрим. Инде мин трамвайларны гына түгел, машиналарын да узып китәм кебек. Уенмыни — җиде йөз илле сум! Мең ярым булганда, тагы да әйбәтрәк буласы иде дә бит... Ярый инде монысы да. Ике йөзенә уйламый да туфли белән галош алам, бер йөзенә бүрек, калганына...

Көчкә үтте бу атна!.. Йөрәгем: «Җиде йөз илле!.. Җиде йөз илле!» — дип шашып типкән хәлдә Сәнгать идарәсенә очып барам. Якыннанрак самолет очса, аны да узып китәрмен төсле. Ләкин Нугайбәк агайның гаять коры һәм кырыс йөзен күргәч, очып килгән йөрәгем каядыр түбәнгә төште дә китте. Шулай да үземне уйламыйм, Нугайбәк агайны уйлыйм: бер-бер хәл булгандыр мона, дим. Беткәнмени дөнья кайгысы... Курка-курка гына өстәле янына барып бастым.

— Бүген... акча алып булыр микән?..

— Нинди акча тагы?! Әнә бит — договорга кулын куймый кире чыгарган.

Мин каттым да калдым.

— Монда Язучылар союзы гаепле,— дип сөйли Нугайбәк агай.— Алар бит әнә: «Кайбер житешсезлекләре булуга карамастан» дип язганнар. Тикшерүдә булган һәр язучы диярлек шуны әйткән. Шулай булгач, без нишләргә тиеш? «Кайбер житешсезлекләре» бар килеш алырга тиешме?..

Бүлмә каранғыланып китте. Мин әкрен генә эреп югала башладым. Бөтенләй югалып киткәнче әйтеп калыйм дип, Нугайбәкнең каранғы бүлмәдә кара коелган йөзенә карадым.

— Алай булгач нигә мине, Союздан кәгазьләр алдырып, филармониягә чаптырып, бу кадәр гомер азаплап йөрттегез?!

Нугайбәк агай, никтер, бөтенләй бүтән агай кебек иде.

— Алай бик кыю булсагыз, энем, бу сүзләрегезне барыгыз әнә, башлыкның үзенә кереп әйтегез.

Мин катыргы папкамны өстәл өстеннән сибереп алдым да бу бүлмәдән атылып чыгып киттем. Приемныйдагы секретарь кыз: «Ул занят, керергә ярамый!» — дип әйткәндә, мин начальникның кабинетында идем инде. Ул аптырап, ләкин елмаеп, минңа урын күрсәтте:

— Утырыгыз. Ни йомыш?..

Мин аңлатып бирдем. Мин инде өметсезлекнең аръягына чыккан идем. Миңа хәзер атна буе ымсынып көткән акча да кирәкми, миңа фәкать: «Нигә мине айлар буе шулай алдап йөрттеләр?» дигән сорауга туры җавап кына кирәк иде. Башлык мине тыңлап бетермәде.

— Ул тикле агрессив булу ярамый, энем,— дип бүлдерде.— Сезнең хикәяләрне мин дә укып чыктым. Ләкин аларның берсе дә чын сәнгать әсәре югарылыгына менеп җитмәгән.

Аның үтә ягымлы тавышы мине дөрләтеп кенә җибәрде:

— Алай булгач нигә **язучылар** алай димәгән? Нигә филармония **директоры** алай димәгән?

— Әгәр акчаны алар түләсә, **алар да** шулай дияр иде.

— Алай булгач нигә сез үзегез Дилбаева биргән заявкага договор төзергә дип кул куйдыгыз?..

Кинәт аның чыраендагы ягымлылык юкка чыкты.

— Сез әле миннән допрос ала башладыгызмы? — дип, ул кызарынып миңа кадалды.— Минем белән шундый тонда сөйләшеп утырырга сез кем? Мин сезне сагынып китермәдем, шулай булгач хәзер үк кабинеттан чыгып китүегезне үтенәм...

— Җавап бирә алмагач, шулай итми чарагыз да юк.

— Җавабын да бирә алам,— диде дә сикереп торды башлык.— Безгә сезнеке кебек Шомбайлар, Хуҗа Насретдиннар кирәкми, безгә Гогольләр, Щедриннар кирәк! Аңладыгызмы?

— Бу кадәр ачык әйткәч, ничек аңламыйсың инде? Аңладым, билгеле. Тик сез — утырыгыз, утырыгыз, юкса мине басып озатып калган кебек була...— дидем мин. Шевиот кепкамны киеп, авыр ишеккә юнәлдем.

Менә мин сөйрәлеп кенә тулай торакка кайтып барам. Бүген миңа бар нәрсә: ишелеп яуган беренче кары да, аягыма уралган киң балаклы чалбары да, урамның теге башыннан бу башына искән җиле дә — һәммәсе каршы иде. Бала-чагасына кадәр мине узып китә башлады. Әнә бер баланы әтисе җитәкләгән. Бәхетле бала!..

Мин тулай торакка көчкә кайтып аудым. Тәнем уттай яна — минем авырып китүем ихтимал иде. Ләкин яшьтән үк, авырсам карар кешем булмый үскәнгәме, минем бервакытта да авырып ятканым юк. Әле дә авырып китә алмадым. Тәнем ут янып иртәнгә кадәр яттым да, иртән торып, ташкүмерме, бүрәнәме бушатырга тимер юлына төшеп киттем.

1969

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ӘДӘБИЯТ МУЗЕЕ

Әдәбият-сәнгать һәм гомумән культура җәүһәрләрен барлау һәм саклау буенча соңгы елларда республикабызда зур эшләр алып барыла башлады. Даһи Ленин истәлеге белән бәйләнешле урыннарны бик яхшы күргәзмә төскә китерү, Казандагы Горький музеенда «Горький һәм татар әдәбияты», «Шаляпин бүлмәсе» дигән бүлекчәләрнең булдырылуы, ниһаять, Татарстан сынлы сәнгать музее ачылу шул юлдагы уңышлы адымнар булды. Мондый культура чараларының кечерәк күләмдәге күренешләре район үзәкләрендә һәм зуррак авылларның мәктәпләрендә дә булдырыла башлавы бигрәк тә шатлыклы хәл. Тукай-Кырлай авылы мәктәбе янында, аерым йортта, Тукай истәлегенә ачылган музей әнә шундый куанычлы хәлләрнең берсе.

КПССның Татарстан өлкә комитеты, әдәби әсәрләребезне барлау һәм саклау эшен яхшыртуны күздә тотып, Казанда Татарстан дәүләт музее каршында татар әдәбияты тарихының борынгы дәвереннән алып бүгенге көнгә кадәр үсеш баскычларын чагылдырган махсус күргәзмә-бүлек оештыруны кирәк дип тапты. Аның өчен дәүләт музееның берничә залдан торган зур бер өлеше билгеләнде. Һәм ул хәзер әдәбият музее өчен яраклаштырып ремонтлана, җиһазландырыла, аны милли орнаментлар белән бизәү дә күздә тотыла. Шулай ук музейга тапшырылган кульъязмаларны, фоторәсемнәрне, әдәбият тарихына һәм язучыларның иҗатына, тормышына бәйләнешле документларны бозылудан саклау өчен шартлар тудырылган махсус бүлмә дә булдырылачак.

Башланган эшнең бу өлешен башкарып чыгуны Татарстан культура министрлыгы күзәтүендә музей администрациясе үтәячәк. Хәзергә музейның әдәбият бүлегендә биш хезмәткәр эшли. Алар, музейның структурасын һәм булачак экспозицияләренең тематик планын төзеп, гыйльми совет карамагына тикшерүгә куйдылар инде. Галимнәр, язучылар катнашы белән уздырылган ул гыйльми совет утырышы эш башлау өчен шул планны яраклы дип тапты. Хәзер бөтен көч материаллар җыюга бирелә. Менә шунда инде җәмәгать оешмаларының, аерым кешеләрнең, беренче чиратта, язучыларның һәм журналистларның якыннан булышлыгы, ярдәме кирәк. Бу ярдәмне башлап Мәскәүдәге В. И. Ленин исемендәге Дәүләт китапханәсе күрсәтте. Ул үзенең фондыннан Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзи, Нур Баян һәм башка татар әдәбияты классикларының үзләре исән вакытта басылган, хәзер сирәк табыла торган китапларын бүләк итте. Казандагы М. Горький музее да бик теләп ярдәм күрсәтте. Ул үзе күп еллардан бирле әдәбият тарихыбызга караган фоторәсемнәр, документ һәм башка экспонатларны җыеп килә иде. Ике мең ярымнан артыкка җиткән бу материаллар ачылачак татар әдәбияты музее фондына тапшырылды. Шундый ук кирәкле һәм мактаулы эшне кайбер әдәбият сөючеләребез дә башлады. Алар да музейның әдәбият бүлегенә язучыларның сирәк очрый торган фоторәсемнәрен һәм документларын, хатларын һәм кыйммәтле кульъязмаларын тапшырдылар. Язучыларның үз әйберләре дә бар анда. Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилова, Әхмәт Фәйзинең туганы Зәйнәп Фәизова, Заһидә ханым Тинчурина, Гөлчирә ханым Такташ, язучы Габдрахман Әпсәләмов, журналист Хан Җәмил иптәшләр кадерле язучыларыбызның күп кенә әйберләрен бүләк иттеләр. Музейга саклануга тапшырылган материаллар арасында Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» дә бар.

Әдәби мирасыбызны, культура хәзинәләрен саклауга җаваплы караган бу хөрмәтле иптәшләр башлаган әлеге изге эшкә журналыбызны укучылар да кушылыр дип ышанабыз.

Безгә мәгълүм булганча, татар драматургиясе классигы Мирхәйдәр Фәйзинең, шагыйрьләрдән Һади Такташ, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Ерикәйнең, прозаиклардан Кави Нәҗми, Мәхмүт Максуд һәм башкаларның кульъязма мираслары туганнарында саклана. Шулардан әдәбият музее экспозициясе өчен бик кирәк булган кульъязмалар һәм документлар һәм, һич булмаганда, аларның фотокүчермәләре алынып бирелсә, бик яхшы булыр иде. Чөнки бу язучыларга әдәбият музее экспозициясендә зур урын биреләчәк. Борынгы әдәбият һәм классикларыбыздан Гафур Коләхметов, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгәр Камал, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури һәм башкаларның тормышына, иҗатына бәйләнгән материаллар да әле аерым кешеләрдә саклана. Шуны истә тотып, без барлык әдәбият сөючеләрдән үзләрендә, архивларында саклаган материалларны: иске кульъязма һәм басма китапларны, хатлар һәм фотокарточкаларны музейга **(Ленин урамы, 2 нче йорт)** тапшыруларын үтенәбез.

Безнең җиде-сигез йөз еллык әдәбият тарихыбыз бар. Шул озак чорның тарихын күз алдына китереп бастыра алырлык әдәбият музеен торгызу — зур һәм җаваплы

эш. Бу эшне башкарып чыгуда Татарстан культура министрлыгы эшлекле чаралар күрер, ә музейның фондын баетуда язучылар һәм барлык әдәбият сөючеләр кулларыннан килгәнчә ярдәм итәрләр дип ышанабыз.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан язучылары союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышында «Казан утлары» журналының 1969 елгы 5, 6, 7 һәм 8 нче саннарында басылган материалларның әдәби эшләнешен, идея-эстетик кыйммәтләрен тикшерү булды. Редакция хезмәткәрләре өчен дә, язучылар өчен дә файдалы булган ул утырышта Нурихан Фәттах, Газиз Мөхәммәтшин, Кыям Миңлебаев, Зәет Мәҗитов һәм Мәдинә Маликова иптәшләрнең журналда басылган материалларны анализлауга багышланган чыгышлары тыңланды. Нурихан Фәттах журналның 5—8 саннарында басылган зур күләмле проза әсәрләре — Эдуард Касыймовның «Көмеш язулы кылыч» повесте һәм Габдрахман Әпсәләмовның «Яшел Яр» романы хакында сүз алып барды. Һәр ике әсәрдәге уңай якларны күрсәтеп үткәннән соң, ул, нигездә, бу әсәрләрдәге кимчелекләргә тукталды.

Газиз Мөхәммәтшин тикшерелә торган саннарда басылган хикәяләр турында сөйләде. Бу саннарда хикәяләр шактый күп басылуын һәм аларның барысы да әйбәт әсәр икәнлеген билгеләп үтте.

Зәет Мәҗитов журналдагы поэзия әсәрләренә киң тукталып, аларның һәркайсының һәм уңышлы, һәм житешсез якларын күрсәтеп барды. Аннары ул журналда басылган шигырьләрнең темалары ярлырак, бер төрлерәк булуын искәртеп үтте, редакцияне киләчәктә поэзия әсәрләренә таләпчәнрәк булырга өндәде.

Мәгълүм булганча, соңгы елларда «Казан утлары» журналында тәрҗемә әсәрләргә дә зур урын бирелә башлады. Кыям Миңлебаев үзенең чыгышында әнә шул тәрҗемә хикәяләрнең сыйфаты турында сөйләп, алардагы отышлы һәм житешсез моментларны күрсәтте һәм журналда басылачак әйберләрне киләчәктә тәҗрибәле тәрҗемәчеләрдән генә эшләтергә киңәш итте.

Мәдинә Маликова әлеге дүрт санда басылган тәнкыйть материалларына тукталды һәм бүгенге әдәбиятыбызның торышын чагылдыручы материалларның журналда житәрлек булмавын искәртте. Аннары ул үзенә Ибраһим Нуруллинның «Иҗат методларыбыз турында уйланулар», Фәрваз Миңнуллинның «Туган җир җылысы» исемле мәкаләләре аеруча нык ошаганын әйтте һәм башка тәнкыйтьчеләребез дә менә шулар кебек мавыктыргыч тел белән, тирән фикерле итеп язсыннар иде, диде.

Менә шул чыгышлардан соң фикер алышулар булды һәм анда язучылардан Эдуард Касыймов, Фатих Хөсни, Хәсән Сарьян, Рафаэль Мостафин, Гази Кашшаф һәм Ибраһим Гази катнашты.

Ахырдан утырышка катнашучылар журналның алдагы саннарын тикшерүне киңрәк аудитория алдында, мәсәлән, берәр югары уку йортында яисә китапханәдә уздырырга кирәк дигән карарга килделәр.

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ КИЧӘЛӘРЕ

Үткән елның ноябрь аенда күренекле татар совет шагыйре мәрхүм Шәрәф Мөдәррриснең тууына 50 ел тулды. Шул уңай белән шагыйрьнең туган авылы Каракитә клубында (Чүпрәле районы) һәм язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Шәрәф Мөдәррисне искә алу кичәләре үткәрелде.

Каракитәдә бик зурлап үткәрелгән кичәдә (26 октябрь) язучылардан шагыйрьнең якташы Шамил Рәкыйпов, Галимҗан Латыйп, Рәдиф Гатауллин һәм Ш. Мөдәрриснең хатыны язучы Ләбибә Ихсанова да катнаштылар.

30 октябрьда Г. Тукай клубында уздырылган кичәгә дә халык бик күп җыелган иде. Күп санлы язучылардан тыш, шагыйрьнең авылдашлары, замандашлары һәм гомумән әдәбият сөючеләр катнашында үткәрелгән ул кичәдә Шәрәф Мөдәррис иҗаты турындагы докладны яшь шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов ясады. Язучылардан Баян Гыйззәт, Атилла Расих, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Галимҗан Латыйп Ш. Мөдәрриснең тормышы һәм иҗатына бәйләнешле истәлекләрен сөйләделәр. Шагыйрьләрдән Рәшит Гәрәй, Галимҗан Латыйп һәм Мәхмүт Хөсәен Ш. Мөдәррискә багышлап язылган шигырьләрен укыдылар. Аннары Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров, Тукай премиясе лауреаты Айрат Арсланов, Татар дәүләт филармониясе җырчысы Нәҗия Теркулова, үзешчән композитор Сара Садыйкова һәм башкалар катнашында бик әйбәт концерт бирелде.

## СПЕКТАКЛЬ БҮЛӘК АЛДЫ

1968—1969 еллар сезонында РСФСР театрларының В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган фестиваль-смотры үткәрелгән иде. Безнең драматургыбыз Риза Ишморатның Муса Җәлилгә багышланган «Үлмәс җыр» әсәрен сәхнәләштереп, ул фестивальдә Новгород өлкә драма театры да катнашты һәм, тугандаш республикалар драматурглары иҗат иткән әсәрләрне сәхнәгә куюда ирешкән уңышлары өчен, бу театр коллективына 500 сум күләмендә акчалата бүләк бирелде.

## ЭРМИТАЖ ХӘЗИНӘЛӘРЕ КАЗАНДА

Ленинградтагы дәүләт эрмитажында саклана торган сынлы сәнгать әсәрләре турында ишетмәгән кеше, мөгаен, юктыр. Әмма ул әсәрләрне үз күзләре белән күрүчеләр хакында алай дип әйтеп булмый, чөнки Ленинградка бару һәркемгә дә тиз генә насыйп булмый.

Менә шуны истә тотып һәм үзендә саклана торган сынлы сәнгать әсәрләрен мөмкин кадәр күбрәк халыкка күрсәтү

максаты белән эрмитаж илебезнең төрле шәһәрләрендә күчмә күргәзмәләр оештыра башлады. Шундый күргәзмәләрнең берсе Казан шәһәрендә дә булды. Фламанд һәм Голландия художникларының XVII йөздә иҗат иткән әсәрләреннән торган ул күргәзмәгә йөзгә якын картина куелган иде. Ике ай буе дәвам иткән ул күргәзмәне карарга бик күп кеше килде һәм алар барысы да аннан канәгать булып киттеләр.

## «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР» — РУС ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ

Казанның В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры татар драматургиясе классигы Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» исемле әсәре буенча эшләнгән спектакльне тамашачыларга күрсәтә башлады. Татарстанның 50 еллыгына багышлап күрсәтелә башлаган бу әсәрне сәхнәгә РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Ш. Сарымсаков куйган. Спектакльнең художнигы — ТАССРның халык художнигы, Тукай премиясе лауреаты Э. Гельмс, алып баручылары — Э. Ливнев һәм С. Митюгов.

## «ТИРӘН ТАМЫРЛАР» — СӘХНӘДӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы әдәбиятыбызның классигы Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы буенча эшләнгән спектакльне тамашачыларга күрсәтә башлады. Романны Хәким Сәлимҗанов сәхнәләштергән. Татарстанның 50 еллыгына багышланган ул постановканың режиссерлары — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт һәм театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов.



*Рәсемдә: спектакльдән бер күренеш.*

## КУБА ЖУРНАЛИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Куба журналистларыннан Куба Компартиясе Үзәк Комитеты органы булган «Гранма» газетасының халыкара бүлеге редакторы Ренольд Росси Суарес һәм Геренса — Латино агентлыгы фотохәбәрчесе Пабло Гильдайн Пратс, Советлар Союзында В. И. Ленинның тормышына һәм революцион эшчәнлегенә бәйле урыннар буйлап сәяхәт итеп, Ильич юбилеена әзерлек турында Куба матбугаты өчен материаллар җыйнап йөрешли Казанга да килеп киттеләр. Алар Казанның тарихи урыннары белән таныштылар. Университеттагы В. И. Ленин бүлмәсен, Казан Кремлен карадылар, В. И. Ленин музеййортында, Куйбышев исемендәге химия заводында булдылар, Татарстан журналистлары белән очраштылар. Куба журналистлары Ленино-Кокушкино һәм Питрәч районының Вахитов исемендәге колхозына да барып кайттылар.

## БАШКОРТСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ МОСТАЙ КӘРИМГӘ 50 ЯШЬ

1969 елның ноябрь аенда, кардәш республикабыз Башкортстанның башкаласы Уфада бер атна буена шигърият бәйрәме үткәрелде. Күп милләтле совет әдәбиятының күренекле вәкиле, башкорт халык шагыйре, РСФСР Верховный Советы депутаты, РСФСРның Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе һәм Башкортстанның Салават премиясе лауреаты Мостай Кәримнең юбилее башкорт халкының милли бәйрәменә әйләнде.

Юбилярны котларга Мәскәүдән һәм Ленинградтан, Дагстаннан һәм Татарстаннан, Украинадан һәм Калмык АССРдан кунаклар килгән иде. Ленин премиясе лауреаты Рәсүл Гамзатов, Калмык АССРның халык шагыйре Давид Кугультинов, күренекле рус шагыйре Михаил Дудин, шагыйрьнең иҗатын рус укучысына җиткерүче шагыйрьләр Яков Козловский, Елена Николаевская, Ирина Снегова юбилярга багышланган кичәләрдә Мостай Кәрим поэзиясенә һәм аны үстергән Башкортстан җиренә тирән ихтирам хисләрен әйттеләр.

Башкортстан безнең ут күршебез, ягъни бер-беребезгә ут алырга йөргән туганнарыбыз.

Татарстаннан Мостай Кәримнең юбилеена катнашырга Тукай премиясе лауреаты Хәсән Туфан, Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре Гариф Ахунов, язучыларның Әлмәт бүлегеннән Равил Фәйзуллин һәм Рафаил Төхфәтуллин бардылар.

Мостай Кәримгә багышланган тантаналы кичәләр Уфа дәүләт университетында, Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында, шагыйрьнең туган җире — Башкортстанның Чишмә районында үткәрелде.

Шундый ук тантаналы кичәләр декабрь аенда Мәскәүдә һәм Казанда да үткәрелде.

## ӘДӘБИЯТ КИЧӘСЕ

Узган елның 22 ноябрендә республикабызның Зеленодольск шәһәрендәге «Родина» культура сараенда әдәбият кичәсе үткәрелде. В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм Татарстанга 50 ел тулуга багышлап уздырылган ул кичәдә язучылардан Идрис Туктар, Хәсән Сарьян, Фаил Шәфигуллин, Вакыйф Нуруллин, яшь шагыйрьләрдән Зөлфәт, Әхмәт Рәшитов, Әхмәт Гадел совет власте елларында татар әдәбияты ирешкән уңышлар турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Аннары тамашачыларның үзләренә сүз бирелде. Зеленодольск халык театры режиссеры Үмәров, культура сарае хезмәткәре Назыйм Ханзафаров һәм Әминә Галимова иптәшләр язучыларыбызның әсәрләренә карата үз фикерләрен, теләкләрен әйттеләр.

## СИРИН

**Озак һәм каты авырудан соң татар поэзиясенең өлкән вәкиле шагыйрь Сирин безнең арабыздан китте.**

**Сирин Хәниф улы Батыршин 1896 нчы елның 14 нче декабрендә Татарстанның Баулы районы Кәрәкәшле авылында крестьян семьясында туа.**

**Революциягә кадәр ул Бәйрәкә мәдрәсәсендә укый. Октябрь революциясеннән соң Бөгелмә педагогия курсларын тәмамлый. 1919 елның августында Татарстанда беренчеләрдән булып комсомол сафларына керә. Шул ук елларда беренче шигырьләрен бастыра. 1931—32 елларда Сирин, Казан педагогия институтын тәмамлап, тел-әдәбият укытучысы булып эшли. Сирин иҗатының чәчәк аткан чагы колхозлашу елларына туры килә. Аның крестьяннарны күмәкләшүгә өндәгән «Булмый! Булмый!» исемле атаклы шигыре нәкъ әнә шул елларда языла. 1931 елны «Тамчылар» исемле шигырьләр җыентыгы басыла.**

**Ватан сугышы башлангач Сирин фронтка китә, берничә тапкыр каты яралана. Армиядән соң туган авылына кайтып, колхозда эшли, шул ук вакытта шигырьләр дә яза.**

**Сириннең шигырьләре артык күп булмасалар да, яңа чорның эчтәлеген үзенчәлекле шигъри формада чагылдырулары белән поэзиядә билгеле эз калдырдылар.**

**Гомере буенча халык арасында яшәгән искиткеч тыйнак табигатьле, күркәм холыклы, олы җанлы шагыйрьнең якты истәлеге укучылар күңелендә озак сакланыр.**

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ.**
**ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕ.**

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Алдагы саннарда:

Газиз Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр» повесте, Эдуард Касыймовның «Сорбонна профессоры», Нурихан Фәттахның «Ител суы ака торур» тарихи романы, Вакыйф Нуруллинның «Күпер чыкканда» повесте, Диләрә Зөбәерованың «Дустым авазы» повесте, поэмалар, шигырьләр, драма әсәрләре һәм башка күп әсәрләр басылачак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА